Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2009



# 2009—СПОРТ ҺӘМ СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ ЕЛЫ


















# Казан утлары
# Qazan utları

2009

7
(1041)

*ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:*
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

*НАШИРЕ:*
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер)**, Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru
✆: **Факс**—(843) 562-11-28.
🖳: **E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Зиннур МАНСУРОВ. Кайтавазы кайта көй-моңнарның. *Шигырьләр.* ........ 5
Марат ӘМИРХАНОВ. Гәүһәршад. *Тарихи бәян.* ........ 11
Салават РӘХМӘТУЛЛА. Минем тавым. *Шигырьләр.* ........ 40
Гөлчәчәк ГАЛИЕВА. Газзәбану. *Роман.* ........ 44
Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА. Йөрәгемә учак яктым... *Шигырьләр.* ........ 101
Алсу ХӘСӘНОВА. Нокта. *Хикәя.* ........ 105
Фәнил ГАЛИЕВ. Нигә киттең, эти?.. *Хикәя-истәлек.* ........ 111

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Булат ИБРАҺИМОВ. Йөрәк. *Шигырьләр.* ........ 119
Рәмилә МАЙОРОВА. Ярты йөрәкле өмет. *Шигырьләр.* ........ 122

**ХӘТЕР**

Владимир ЛАВРИШКО. Хәтер төеннәре. ........ 124
Ядкарь АКБУЛАТОВ. «Киттек!»- диде Гагарин. ........ 151

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Фирдәвес ГАЛИЕВА. Вазифа. ........ 129

**СӘНГАТЬ**

«Уян, әйдә, татар киносы!» *Түгәрәк өстәл материаллары.* ........ 135
Флюра НИЗАМОВА. Сәхнәдә ул—аккош, сандугач... ........ 169

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәридә ХӘСӘНОВА. Өченче хакыйкать. ........ 143

**ФӘН**

Марсель БАКИРОВ. Чура батыр. ........ 153
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ........ 164

**«ИДЕЛ» ЖУРНАЛЫНА 20 ЯШЬ**

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. Менә без дә үсеп җиттек... ........ 173
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Ташка ордым башны. ........ 174
Аделия ӘСХАТОВА. «Татнет—татар халкын һәртөрле бәладән коткара торган дәва түгел». ........ 177
Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. «Зинһар, мине дә калдырма...». ........ 179
Искәндәр СИРАҖИ. Нәфисә Хәйруллина: «Артистка булмасам—бәхетсез булыр идем». ........ 181
«Казан утлары» архивыннан. ........ 184
Берлекнең яңа әгъзалары. ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 187

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: историческая повесть М. АМИРХАНОВА «Гаухаршад» (окончание), начало романа Г. ГАЛИЕВОЙ «Газзабану», рассказы Ф. ГАЛИЕВА, А. ХАСАНОВОЙ; стихи З. МАНСУРОВА, С. РАХМАТУЛЛЫ, Ш. ЗИГАНГИРОВОЙ.
«Творчество молодых»: стихи Б. ИБРАГИМОВА, Р. МАЙОРОВОЙ.
«Память»: В. ЛАВРИШКО. «Узелки памяти»; Я. АКБУЛАТОВ. «Он сказал: «Поехали!»
«Публицистика»: Ф. ГАЛИЕВА. «Долг».
«Искусство»: разговор за круглом столом о возрождении татарского кино; интервью Ф. НИЗАМОВОЙ с оперной певицей З. Сунгатуллиной.
«Литературная критика»: Ф. ХАСАНОВА. «Третья истина».
«Наука»: М. БАКИРОВ. «Чура батыр».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Публикации, посвященные к 20-летию журнала «Идель».
Новые члены Союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Лето»; писатель Рустам ЗАРИПОВ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and Poetry»: historical novel by M. AMIRHANOV «Gauharshad» (ending), beginning of novel by G. GALIEVA «Gazzabanu», stories by F. GALIEV, A. HASANOVA; poems by Z. MANSUROV, S. RAHMATULLA, SH. ZIGANGIROVA.
«Youth's creativity»: poems by B. IBRAGIMOV, R. MAYOROVA.
«Memory»: B. LAVRISHKO. «Memory knots»; Ya. AKBULATOV. «He said: «Let's go»
«Journalism»: F. GALIEVA. «Debt».
«Art»: conversation at round-table about revival of Tatar film; interview of F. NIZAMOVA with opera singer Z. Sungatullina.
«Literary criticism»: F. HASANOVA. «Third truth».
«Science»: M. BAKIROV. «Chura Batyr».
Pages of «Tatar encyclopedia».
Publications devoted to 20th anniversary of magazine «Idel».
New members of Writers' Union.
From photo archive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our cover: «Summer»; writer Rustam ZARIPOV.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.06.2009, график буенча 25.06.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–898 Тираж 4452.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210. Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2009 ел.



Зиннур Мансуров

# КАЙТАВАЗЫ КАЙТА КӨЙ-МОҢНАРНЫҢ...

## Волынка

*Болгария. Казанлык шәһәре. 1995 ел.*

**Казанымны уйлап атлыйм Казанлыкта,
монда мине әйдәп йөртә Яз кызы...
Бәрәкалла: ап-ак чәчле болгар карты
волынкада уйнап тора ялгызы.**

**Сурга өргән гарше заттай шундый мәэюс—
Җәлләп куйдым моңлы күрек хуҗасын...
Уң як биткә бәллүр тамчы килеп кунды,
апрель күге тота алмый күз яшен.**

**Яшел тауга әллә дәррәү болыт иңгән,
әллә анда куй көтүе йөриме?
Куенына авыр капчык кыстыргандай,
кардәшемнең төшеп тора бер иңе.**

**Бәгърендәге барлык-барлык ваемнарны
тыны белән өреп кертә турсыкка.
Гаҗәпләнмәм эче янар волынкадан
сүзсез генә үзәк өзгеч җыр чыкса...**

**Кызгандыргыч музыкантның күзләренә
озак карап тордым бугай, бигайбә.
Тәкъдиреңә язылганны татыгачтын,
үкенүдән, уфтанудан ни файда?!**

---

Зиннур МАНСУРОВ (1949) — *шагыйрь, публицист; "Кул бирәм", "Ваем", "Җәрәхәтле йөрәк җылырак", "Күңелдә фидаи яшәсә" һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Бүленгәнне инде бүре ботарлаган,
аерылганны күптән аю ашаган.
Таралганны кәтеп кенә торучылар,
бәрадәрем, бүгенгәчә ач һаман!..

Казанымны уйлап атлыйм Казанлыкта,
монда мине әйдәп йөртә Яз кызы.
Куптарылып чыгар булган Кубратханмы
волынкада[1] уйнап тора ялгызы?!

Моң-зар белән тутырырга язган безгә
язмыштагы аерылышу бушлыгын.
Кыйтталарга сөрән сурын кычкырткалап,
ул җыярга тели бугай биш улын.

Бигрәк кыйбат була икән нәфес хакы—
сыкрап-сыктап елый... сарык карыны;
бүлгәләнгән Бөек Болгар биләмәсен
эзләп китә волынканың һәр өне...

Казанымны уйлап йөрдем Казанлыкта,
ятим җаным Күккә ныграк сыгынды.
Кайтавазы кайта торды көй-моңнарның,
катгый тәкъдир хөкемедәй: «Соң инде!..»

Соң инде...

## Озын көй

Хәтерлимен Донбасс шахтасына
кунак булып төшкән чагымны.
Моң-зар белән тулып ашкан күңел
шундый сизгер, шундый сак иде.

Чакрымладым күмер катламнарын—
нәкъ шахтерлар кебек эш иттем.
Җирнең җиде катын үткән мәлдә
синең җырлавыңны ишеттем.

Бәргәләнеп татар бәгырендә,
язмыш юлын бергә узган җыр!..
Тетрәнүдән шахта терәүләре
шартлап сынмый ничек түзгәндер?!

Иңләп килгән алкын ташу булып
забойларга тулды тавышың.
Бөтен миргә сыймас татар моңы
биләп алды кысан тау эчен.

Кояш-айдан мәхрүм тирәнлектә,
балкыш ясап, сихри ут яктың.
Шушы озын көең белән, Җырчым,
ырудашлар рухын уяттың.

Шундый озын иде сузган көең,
күмер базы шундый тын иде.

[1] Волынка – күреге куй-сарыкның ашказанынннан ясалган халык тынлы уен коралы.

Кардәшләрнең моңы гарешләрдән
урап кайткан төсле тоелды.

Моң-мәкамең белән көтелмәстән
җирдә тетрәү хасил иткәндә,
үз-үземнән сорап өзгәләндем:
«Аңладыңмы инде, и бәндә?

Язмышында өскә ябырылган
моң-зар ташкынына терәү юк...
Төшеңдеңме тау-таш төпкеләндә—
безнең җырда нинди тирәнлек!»

...Хәтерлимен Донбасс шахтасына
кунак булып төшкән чагымны.
Ишеткәндә синең тавышыңны
җаным шундый сизгер, сак иде...

## Гайре юлдан китү

...Комедияң, Мольер, камиллектә
туктар төсле өлге булудан,—
яшәү инде күптән китеп барды
аңга сыймас гайре бер юлдан.

Артта калды хәтта битлек аша
ихлас карый алыр ул заман.
Хәзер гавам эчтән сыкрап елый
ачы көлгән чакта узаман...

Трагедия, Эсхил, чынбарлыкта
инде башкачарак корыла:
һәлакәтле хәлләр ахырында
«герой» исән кала, хор үлә...

Еламсырап иблис елмайгандай
канга батып туган таң аша.
Менә шундый, Мольер, эшләр бездә,
менә шундый, Эсхил, тамаша!..

## Татарлык

Имсез чирне ачкан Шагыйрь: «Татарлык...»
Сөйли китсәң, телне бизгәк тотарлык.

Сабыеның тырнаклары астыннан
ләззәтләнеп кер эзләве аз сыман.

Әйе, Иисус тәресеннән кан саркый...
Зөһрә кызны кем соң Айга кадаклый?!

Ханбикәсен биреп бөлгән сәүдәгәр...
Татарлыкта «тарлык» дигән сүз дә бар.

Өләшкәндә... дәүләт алган бар кавем.
Бакчы, аның «Җомга көн», дип бармавын!..

**«Хәсәд, кинә илән тулган татарлык,**
**төяб илтеб Мәкәрҗәдә сатарлык»[2].**

**Менеп татар «җеназасы-аты»на,**
**әләк белән китә Аллаһ катына...**

## Уникенче елгы шәраб

*Ни була...*
*Бу ачы гомрем шәрабен эчмәсәм?!*
Г. Тукай

**«Эчеп җибәр,—диде сакый,—Кырым сыен,**
**үз-үзеңне Хәйям итеп сана да...»**
**Уйга калдым: ошбу шәраб әзер булган**
**мең тугыз йөз уникенче сәнәдә!**

**Тукай инде соңгы җәйгә кереп бара,**
**сынык саздан саркып чыга мәгъруp өн...**
**Берни белән имли алмый икән бәндә**
**ачы гомер шәрабенең махмырын.**

**Башка сыймас хәлгә җитеп тетри акыл,**
**үз-үзенә урын таба алмый җан.**
**Сырхау тәнгә тансык дәртен өстәп торыр**
**әнкәң сөте инде тәмам айныган.**

**Тулы гасыр кичкән кебек була икән,**
**гәрчә гомер тоелса да өч көнлек.**
**Йөрәгеңне ахыргача яндырачак**
**сихри гайрәт биргән шушы эчемлек.**

**Тәкъдиренең тәдавел[3]ен тәгамлаудан**
**кайсы гына шагыйрь заты кача соң?**
**Дөнья йөзен кайчак читтән күзләр өчен**
**тоту кирәк сихри Җәмшид касәсен.**

**Шулай гына күрә ала үҗәт җаннар**
**кайгы, шатлык, җәбер-золым, наз төбен...**
**Кайдан килер иде аңа андый холык,**
**әгәр Тукай эчмәс булса насыйбын?!**

**...Йөзем багын җылы яңгыр юып үтте,**
**тустаганга нидер тамды өстән дә.**
**Кичер, Аллам: әллә ниләр уйлап куйдым**
**уникенче елгы шәраб эчкәндә.**

## Чәч алу

**Сөйләмәскә иде исәпләрем**
**искә төште менә тагын да.**
**Әти картның, кайтып, чәчен алдым,**
**үлем көтеп яткан чагында.**

---

[2] Г. Тукайдан.
[3] Тәдавел — бүтән халәткә кертә торган тылсымлы ширбәт.

Никрутларча тели алдырырга—
үзе, элеккечә, җор тагы.
«Менә шулай,—ди ул,—менә шулай
тузып бетә гомер йомгагы...»

Бүген язмыш хет бер генә тапкыр
сыйпап алса иде чал баштан!
Чуалышып беткән чәчләренә
еллар җиле кереп адашкан.

Белештерми торган чәчтараштай,
ике учма кистем як-яктан.
Беренчесен—бабам үтерелү,
икенчесен сугыш агарткан.

Чәчләренең тонык яктысында
күрәм кара еллар шәүләсен...
Минем иңнәр тотып тора алмас
дөнья белән тулы чал башын.

...Ачылышып китте тәрәзәләр—
зәһәрләнеп, ахры, җил бәргән.
Соңгы тапкыр чәчен сыйпар өчен
әллә аны язмыш җибәргән?!

Дөньядагы бөтен бәйләнешен
инде өзә барган чагында...
Сөйләмәскә иде исәпләрем,
искә төште менә тагын да.

## Җомга көн күк катында

...Самолетта рухлар сәламләшә,
сүтә вакыт гомер йомгагын.
Аныклыйдыр әнкәм оныгына:
«Җидегәннең тажы—җомга көн...»

Җомгаларда идән юдыртмады,
сугармады хәтта яранын.
«Гыйбадәткә,—диде,—гыйбадәткә
багышлансын көнең, йа Раббым!..»

Әһле ислам намаз укыр чакта
тыеп торды башка гамәлдән.
Вагыйзьләрчә әйткән вәгазьдәнме
әллә нинди гайре гамь калган?!

Тәкрар иткән үзе, тәгълим биреп,
үзе тапкан мине... җомга көн.
Самолетта рухлар сәламләшә,
сүтәм күктә гомер йомгагын...

Сәламләшкән чакта сулышыңның
тоям никтер авыр булуын...
Калдырткандыр ничә намазыңны
тулгагыңа тормас бу улың.

Ярлыкагыл, диеп ялварганда,
мин Күк белән калам бергә-бер.
Языклыга кемнәр язылганын,
хәер, Аллаһ үзе беләдер.

...Самолетта рухлар сәламләшә,
сутәм, әни, хәтер йомгагын.
Нәүмизләтә калган намазларың—
туган көнем бүген—җомга көн...

## Тамаша

Карап торам сандугачлы тал аша—
аргы ярда ике хатын талаша...

Әллә нинләр алга килә, йә Аллам—
агу сорый тузбаш... кара еланнан...

Миңа гына шәйләнәме: күр, лягыйнь—
кимәк була фәрештәнең күлмәген...

Карап торам сандугачлы тал аша—
яшел ярда менә шундый тамаша.

## Атым

Кемдер пычрак аткач, искә төште
кулдә акбүз атны юганым.
Минем әле ять-яшь егет чагым,
юк дәрәҗәм илдә, юк даным.

Суга җәйгор үзе төшкән иде,
аллы-гөлле нурлар уйнатып...
Балкып торган атка әфсен өрдем,
сихри дога сузен ун әйтеп.

Кинәт... ике канат үсеп чыкты—
чит атмы бу, әллә үз атым?!
Нихәл итим: менә шулай аны
ак-пакь килеш күккә озаттым.

Үзе өчен лаек очыш теләп,
куптарылды ярсу күңлемнән.
Минем атны җирдә һәрбер кеше
карап калды яхшы күз белән.

Инде хәзер рәхмәт юлын иңли,
түбәнлектә эше юк аның.
Кемдер пычрак аткач, искә төште
кулдә акбүз атны юганым...

Марат
Әмирханов

# ГӘҮҺӘРШАД

ТАРИХИ БӘЯН

***

Шаехгали үзе дә ничә айлар шушы сорауга җавап эзли иде. Василий Иванович аңа туганым гына дип мөрәҗәгать итә иде ләбаса, мәҗлесләрдә аерым ихтирам билгесе күрсәтеп, үзе белән рәттән утыртыр иде. Араларыннан җил дә үтәрлек түгел иде. Кырымлылар Казан тәхетенә үрмәләгәч тә олуг кенәзнең мөгаләмәсе үзгәрмәде, үзе янында тотты.

Әле дә хәтерендә, мең биш йөз дә егерме алтынчы елның кышында Мәскәүгә Рум императорының илчесе барон Сигизмунд Герберштейн килгән иде. Олуг кенәз аны бик зурлап кунак итте. Колгадай төп-төз гәүдәле турыга каткан адәм иде. Йөзе тавык күкәедәй шома, авызы уймак кадәре генә, табында да чемченеп кенә утыра, итнең сум җирен генә ашый, аны да иң элек пычак белән вак-вак кисәкләргә тураклый. Кече телгә дә йогарлык түгел бит инде. Сәер адәм. Көлсәң көл, еласаң ела.

Василий шушы илче хөрмәтенә куян авы оештырды. Анда башлыча чит мәмләкәт әһелләре генә чакырулы иде, сарай даирәсеннән санаулы кешеләр генә катнашты. Шуларның берсе Шаехгали иде. Чатырын олуг кенәз чатыры белән янәшә куйдылар. Табында да урыннары бергә булды.

Көне генә килеп җитмәде. Томан мавыктыргыч ау манзарасының колачын тарайтты, ашкынулы куыш-чабышларның зилзиләсен бөтен тулылыгы белән күзәтергә мөмкинлек бирмәде. Ә этләр, сөбханалла, күзләренә ак-кара күренми, сугымчылар тире сыдыра-сыдыра хәлдән тайды.

Аучылар үзләре дә тамаша кылып кына утырмады. Шаехгали атын кара күбеккә батырганчы камчылады. Герберштейн аны күзәтеп торган булып чыкты, ау өчен олуг кенәзгә рәхмәтен җиткергәндә аңа да мактау сүзләре әйтте:

—Хан бик өлгер җайдак икән,—диде уймак авызын бөрештереп,—ы-ы-ы, мин...

Ул егерме бер яшьлек Шаехгалинең салынып төшкән корсагына, арыш капчыгыдай җәелгән гәүдәсенә күз төшереп, төртелеп калды...

—Татар анадан ат өстендә туа,—дип елмайды Шаехгали.

---

*Ахыры. Башы журналыбызның 6 нчы санында.*

—Шәехгали хан минем иң булдыклы җиһангирым,—диде Василий.

—Иң ышанычлы вассалың,—дип өстәде Шәехгали.

—Әйе, иң ышанычлы вассалым...

Менә шушы ышанычлы вассал Ак күл сөргенендә изалана хәзер. Бу хәлгә калуының сәбәбен ул, әлбәттә, чамалый. Чөнки кулга алган вакытта, олуг кенәз исеме белән шапырына башлагач, бояр кисәтте:

—Очынма, хан, башка чакта, андый мөмкинлек туа-нитә калса әгәр, патшадан узып кыл да кыймылдатмаска сәбәп булыр,—диде.

Василийның баш өстеннән бернинди кырын эшләр дә алып барганы юк. Казан тәхетенә өмете зур иде, анысы хак. Ник дисәң, олуг кенәз үзе ымсындырып килде, синнән дә кулаерак кешем юк, диде. Ә үзе? Хәер, бу капылт үзгәрешнең асылын Ак күлгә кадәр үк житкергәннәр иде анысы. Василийны Гәүһәршад тәнәкә мәжбүр иткән, имеш. Без урысның кан дошманы Сафагәрәйне куып жибәрәбез, син Казан тәхетенә Җангали ханны тәгаенлисең, дигән таләп куйган, имеш. Мәскәү Казанны үз йогынтысында саклау өчен теләсә-нинди ташламага барачак. Ризалашкан олуг кенәз.

Шуларны ишеткәч, Шәехгалинең шайтаны котырып алды да инде, күңеленә вәсвәсә йөгерде. Бәлиш, Казанда Василий дәдәйне уч төбендә тотучы фирка барлыкка килгән икән ич, тәхеткә алар аша үрмәләү җиңелрәк булмасмы?

Уйлаган эш—беткән эш ди, алдын-артын исәпләп тормады, хат белән Тагай бәккә ышанычлы арадашчысын жибәрде. Ләкин кешесен олуг кенәзнең шымчылары тотып алып, хатны кулга төшергәннәр...

Бик үкенә хәзер үкенүен, тик ни файда, әнә, терсәк бик якын, тешләп алырга гына буй житми.

Ләкин һич тә сөргеннәргә сөрерлек гаеп түгел. Әлегә олуг кенәзнең бу адымын нәрсә дип тә юрап булмый. Нииндидер зур сәяси уенның тәүге гамәленә охшап тора. Ихтимал, дәвамы да тәгаенләнгәндер. Ходаем, үзең сакла ул зилзиләләрдән.

—Мөхәммәтшәех, бик бетерешмә инде, бераз күңел ачып алыр идең. Аллаһы боерса, патшабыз да акылына килер, килми калмас, Ходай аңа озын гомер бирсен,—дип, Фатыйма ханбикә, гадәттәгечә, мәрхәмәтле анадай кадерли-кадерли ирен юатырга керешә.

Шәехгали дөрестән дә иркә бала хәленә төште, Фатыймасын бер генә минутка да яныннан жибәрми, кулларыннан тотып кына утыра.

—Алай да син бар әле, Фатуш,—диде Шәехгали хатынына елыша-елыша,—сүзең алтын бәһәсе, хак, без фәкать Василий атакайга гына аркалана алабыз, ул безнең яклаучыбыз.

***

Гәүһәршад яшь кәләш белән мәжлестә генә күрешеп танышырга булды. Кемнен-кемлеге кеше арасында ачыграк шәйләнә диләр бит. Үз-үзен тотышыннан, ничек әңгәмә коруыннан, табын тота белүеннән кыз-хатынның холык-фигылен дә, зыялылыгын да тәгаенләргә мөмкин. Дөресен генә әйткәндә, бу никахны оештыручыларның берсе буларак, тәнәкәне кияү белән кәләш шәхесеннән бигрәк, аның кайтавазы, нәтиҗәсе күбрәк кызыксындыра иде. Монда турыдан-туры өч дәүләт: Мәскәү кенәзлеге, Казан ханлыгы, Нугай иле катнаша. Аерым мәнфәгатьләр Кырым вә Төркиягә кадәр сузыла. Әлеге никахтан һәрберсе үзенә мөмкин кадәр күбрәк файда алып калырга омтыла. Казан өчен исә Нугай белән туганлашу ханлыкның көч-куәтен бермә-бер арттыру дигән сүз. Кырымны тышауда тоту җәһәтеннән, бу бәһасез адым. Үз чиратында, Мәскәү дә ота, дустанә Нугай ат базарында теләбрәк катнашачак. Ә нугай атларын урыс яугирләре

бик ошата. Нугайлыларның үзләренә килгәндә, алар ике-өч ана имиен берьюлы имәргә бик маһир.

Менә шундый дәүләти вә зарури никах бу. Бай, мул, укалы-чукалы, асыл ташлы, алтын-көмешле, ялтыравыклы никах. Кодалашу, кыз әйттерү, туй гореф-гадәткә туры китереп, зур шау-шу белән Нугайда узды. Казанда исә кәләш багу мәҗлесләре үтәчәк. Бүген—тәүгесе. Монысына берничә генә бикә чакырулы. Иң дәрәҗәлеләре. Дәрәҗәлеләрнең дә дәрәҗәлесе, билгеле, Гәүһәршад түтәкә.

Гәүһәршад, гадәттәгечә, мәҗлескә иң соңгы кеше булып килде. Аны монарчы аягүрә басып каршы алалар иде. Бу юлы гадәт бозылды. Дөресрәге,башлар үзеннән-үзе горур вә көяз кыяфәттә түр башындагы кәнәфидә күл камышыдай төзгә катып утыручы бикә ягына борылды. Ханбикә рәвешен үзгәртмәде. Кунаклар да берни булмагандай әңгәмәләрен дәвам иттеләр.

Шушы чикерткә икән инде алайса безнең ханбикәбез, дип уйлап куйды Гәүһәршад. Һәм шунда ук тәүге энәләрен дә очырды:

—Әссәламегаләйкүм, ханбикә, кыргый дала вазгыятендә тәрбия алган кешегә Казанның хөр вә зыялы һавасына ияләшү авырдыр инде,—дип текәлеп карап алды.

Бик азга гына карашлары чәкеште. Борчаклары пешмәсен аңлау өчен шушы мизгел дә бик җиткән иде.

Гәүһәршад бернинди сәбәпсез яшь кәләшне читкә типте. Ханбикәнең күркәм килеш-килбәте дә, мөкәммәл буй-сыны да, чибәрлеге дә күзенә чалынмады.

Чибәр иде кәләш, бал кашыгына салып йотардай чибәр иде. Кешенең күрке йөз, йөзнең күрке күз булыр ди. Әлеге әйтем аңа тулысы белән туры килә иде. Йөзе дә, күзе дә карап кына торырлык. Ияк очына беленер-беленмәс кенә мәхәббәт уемы да уелган. Бу аңа үзгә бер самимилек өсти. Киемне дә сайлый белгән. Аккош кебек балкып утыра.

Сөенбикә бик иркә кыз булып үсте, һәрвакыт сүзен сүз итте, чөнки ирек куйдылар. Казанга озатканда атасы Йосыф би кызын шулай ук кисәтеп җибәрде: «Казан бикәләре бик вакчыл, тәкәббер, һавалы, беренче көннән үк бирешмә, нык тор»,—диде.

Әлегә Сөенбикәнең дөньядагы барча яшь кәләшләр кебек үк фәкать сөясе вә сөеләсе генә килә иде. Тик тәнәкәне дә җавапсыз калдырырга ярамый, йомшак авыз икән бу димәсеннәр.

—Юләр җиндем дияр, акыллы юл бирдем дияр, әйдә, тәнәкә, утырышыйк, мәҗлескә җыелдык лабаса,—дип елмаеп куйды.

Кунаклар күгәрченнәрдәй гөрләшеп алдылар, берсе дә Гәүһәршадның кара янып чыккан чыраена игътибар итмәде.

Догадан соң бүләк бактылар. Бүләкләр затлы иде, зиннәтле. Гәүһәршад та әзерләнеп килде. Бүләк сайлаганда башта Үрбәт ханәкәдән калган алтын-көмештән коелып, асыл ташлар белән бизәлгән китап савытын кулына алган иде. Аны җиңгәсе мәшһүр Казан көмешчесе Насыйр остадан, өстендә торып диярдәй, эшләтеп алган иде. Яшь ханбикәгә бик мәгънәле бүләк булыр дип уйлаган иде. Шулай да янадан нигәдер кире уйлады. Алып килгән бүләге дә башкаларныкыннан өстен иде анысы. Кытай осталарының бизәнү әйберләре нәфислеге белән дан тота. Кәләш тә ошатты булса кирәк, учында әйләндереп-әйләндереп торды.

Тәгам туй ризыгыннан башланды. Яшь гаиләнең тормышы ипекәй сыман бәрәкәтле, сары май кебек йомшак, балдай татлы булсын өченгә һәр кунакка иң әүвәл бал-май ягып, бер телем ипи ашау фарыз.

Әлеге йоланы бикәләр җиренә җиткереп үтәде. Аннан бәрән ите салып

пешерелгән токмач чыгарылды. Пилмән дә шома гына үтте. Янә дә кәбестә бөккәне. Итле бәлештән соң гына кашыклар авырайгандай булды.

—Гадәттә бәлештән соң җырчылар керә торган иде,—дип, Боерган сәеднең яшь хатыны Гадәния абыстай ханбикәгә карады.

Сөенбикә бикәләрнең тәлинкә арты тәлинкәне ялт иттерүләрен чын кызыксыну белән күзәтеп утыра иде: болар да мангыт тәтәләре кебек үк бирән күркәләр икән ич, күр, ничек тетәләр.

—Безнең Гадәния абыстаебыз шулай чуар йөрәк инде ул, ханбикә, алда булачак туй өчен атна-ун көн элек бии башлый,—дип кеткелдәде күршесе.

Бүлмәгә көйчеләр, җырчылар, биючеләр кереп тулды. Арада ир-егетләр дә бар. Кайсы курай, кайсы гөслә, кайсы кубыз, кайсы сорнай тоткан.

Тамаша җыр белән башланып китте. Кымыз гөбеседәй юантык гәүдәле, көпшәк битле егет салмак агышлы бер моңлы җыр җырлады. Тавышы тигез, аһәнле. Тыны да озын, сузыпмы-суза:

Аерылу агуы мине парә-парә итмәс микән?
Бирмәс мәдәт җаныма им булып дару өмид...

—Бәрәкалла, ниндәй күркәм җыру,—дип бәһасен чыгарды ханбикә.

Уртага биючеләр атылып чыкты. Үзләре такмак әйтә, үзләре бии. Туктаусыз көй янгырый. Бүлмә гөр килеп тора.

Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була...

Боерган сәеднең яшь кәләше дөрестән дә чуар йөрәкле икән. Башта утырган җирендә гәүдәсен селкеткәләп кыланды, ахыры дәрте тәмам түгәрәкләнде, күрәсең, сикереп торып, биючеләр арасына ук кереп китте.

—Һай, Гадәния абыстай, күрегезсәнә, кара халыктан ким сикерми,—дип көлеште бикәләр. Үзләренең чүмәләдәй юан гәүдәләрен түгел, кулларын кыймылдатырлык та хәлләре юк иде.

—Җитеп торыр, ханәкә, тавышлары башка капты,—диде утырган каз шикелле муенын тота алмыйча йокымсырап изаланган карт бикә.

—Әйтмә дә инде, Бану-солтан, тәмам шайтан туе ясадылар,—дип җөпләде аны ахирәте.

Яңа дәрт белән тагын кашыклар уйный башлады. Иң элек кызыл серкәдә пешкән суган белән бозау итеннән авыз иттеләр, аннан парда гына изерәгән чөгә балыгы килде. Анын белән араны өзүгә, табынга бер-бер артлы кыздырылган каз, кыздырылган күркә, кыздырылган үрдәк ише кош-кортлар кунаклады. Гөбәдиягә кадәр табан балыгы белән корбан балыгын каймакка мана-мана бөгәрләп аттылар. Һәм дә биниһая күп тәм-том, камыр ризыклары...

Гәүһәршад соңгыларының берсенә дә кагылмады, чемченеп кенә утырды. Бу яктан яшь ханбикә белән алар охшаш иде, тик араларына яткан кара күләгәне әлеге охшашлык кына җуя алмый иде инде.

—Хатыны чибәр кешенең гомере кыска булыр,—дип, Гәүһәршад янә агуын чыгарды.

Сөенбикә бу төртмә ишарәне ишетмәде, чөнки нәкъ шушы вакытта ашсу биреп торучы гасәбә туташ ялгыш таеп китте дә кулындагы тәлинкәсен төшереп ватты. Бикәләр бәбкәләренә куркыныч янаган ана каз шикелле ысылдашып алдылар. Йөзләре чалшайды, бәгъзеләре хәтта куркуыннан

дер-дер калтыранган кызны чеметкәләп тә алды. Ихтимал, тавыш зурга да киткән булыр иде, янә Боерган сәеднең яшь хатыны көлеп-елмаеп күңелсез вакыйганы күркәм гамәлгә әйләндерде дә куйды.

—Сөбханалла, мәшалла, туй мәҗлесендә савыт-саба ватылу хәерлегә генә бит ул, юкка шаулашмагыз, мона фәкать сөенү генә фарыз, әйдәгез, ханбикәгә ак бәхетләр теләп дога кылыйк,—диде.

Бикәләр догага оеды. Гәүһәршад исә үзе дә сизмәстән әллә нинди аңлаешсыз халәткә керде: мәҗлес тә, ханбикә дә, кунаклар да томан эчендә калдылар. Күз алдында әле генә авызыннан ычкынган агулы әйтемнең сурәте пәйда булмасынмы. Әнә, Казансу елгасының үги ана яфраклары басып киткән комлыгында бер мәет аунап ята. Баш очында инде козгыннар кайнаша...

Бу—Җангали ханның мәете иде.

***

1530 елның 25 августында кояш баер алдыннан Мәскәүдә гарасат чыкты, тузан өермәсе купты. Мизгел эчендә кала караңгылыкка чумды, җилле-давыллы яңгыр башланды. Шәһәр өстенә күп башлы аждаһа авызыннан сибелгәндәй ут телләре сузылды. Таш диварларны дер селкетеп күк күкри. Мәхшәрнең мәхшәре...

Шушы мәхшәр Русиягә варис алып килде. Шуңа күрә Василийның бик бәхетле көннәр кичергән чагы. Улы туды бит, улы! Хәзер Мәскәү тәхетенең кануни хуҗасы бар. Ул аңа атасының исемен бирде. Иоанн! Ходай кушып, бабасы шикелле үк акыл иясе булыр, абруйлы вә мәртәбәле патшага әйләнер, Русияне дан-дәрәҗәгә күмәр, мәмләкәтне зурайтыр, күп халыкларны буйсындырыр...

Олуг кенәз шушы истәлекле вакыйга уңаеннан хәтта дошманнарын да гафу итте, чиркәүне алтын-көмешкә коендырды. Шулай булмыйча, урманда кош ояларын күргәндә дә күзеннән яшь бәреп чыга иде ич. «Кошларның да балалары бар, мин генә ялгыз»,—дигән сүзләрен ишетеп, җанатарлары йоммый түгеп елыйлар иде.

Варис хакына егерме ел яратып-сөешеп яшәгән гүзәл җәмәгате кысыр Соломонияне, чәчен кырдырып, монастырьга озаттырды. Хәлбуки, үзе ошбу «кансыз»лыгын бик авыр кичерде. Ник дисәң, ул аны үз вакытында Русиянең мең биш йөз кәләше арасыннан сайлап алды, атасы олуг кенәз Иоанн шундый ирек биргән иде. Кәләшенең нәсел-нәсәбе бик үк затлы булмавына да карамады. Бабасы Сабуровка үзе тәхеткә утыргач кына бояр титулы бирде. Шуңа күрә әлеге никахны өнәп бетермәүчеләр дә шактый булды. Хәер, яшь хатыны Елинага карата дәгъвәләр тагын да җитдирәк иде. Кайчандыр Глинскийлар Русиядән китеп, Литва канаты астына сыенганнар. Урап кайтканнар-кайтуын, әмма аларга хыянәтче исемен инде тагып өлгергән булалар. Өстәвенә, Елина немец милли традицияләре рухында тәрбияләнә. Ә немецлар урысның кан дошманы.

Василий Елинага тиз ияләште. Яшь кәләшнең кочагы кайнаррак иде шул. Иркәли дә, иркәләнә дә белә. Олуг кенәз аның һәр капризын үтәргә тырыша иде. Чираттагы бер ләззәтле төндә Елина шаяртыпмы, сынау өченме:

—Төкләрең без кебек очлы, күр инде, бөтен тәнемне сыдырып бетердең ич,—диде.

Василий иртән иртүк иң беренче эш итеп сакал-мыегын кырдырып ташлады. Сарай өнсез калды. Ничек инде олуг кенәз малай-шалай кебек шома бит белән йөрсен ди? Йөрде. Башкалар да күнде.

Елина баланы иренә караганда да өзелебрәк көтте. Чөнки никахтан соң бер ел үтте, ике, әнә, өченчесе башланды. Ә көмәнгә узмый да узмый.

Варис хакына ярәштеләр ич аны олуг кенәзгә. Бу—иң төп вазифасы. Әгәр ышанычны акламый икән, Соломония кебек аның да чәчен кырачаклар...

Тырыша да бит инде, иренә тынгылык бирми, төннәре бик зилзиләле үтә. Василий да бөтен көчен куя. Бергәләшеп Переславль, Ярославль, Вологда, Белоозеро храмнарына барып, күп мәртәбәләр гыйбадәт тә кылдылар, елый-елый Ходайдан бала бирүен сорадылар. Елина ялгызы гына да мосафирларча җәяүләп изге урыннарга сәфәр чыккалады, шыксыз далаларда йөрде, хәерче-мохтаҗларга учлап-учлап хәер өләште...

Ниһаять, Тәңре аның ялварулы өзгәләнүләрен ишетте булса кирәк, бер чиратында күреме вакытында килмәде. Ул тиз генә табибын чакыртты.

—Әлегә тәгаен генә бернәрсә дә әйтеп булмый, бөек княгиня, тагын ике ай көтеп карыйк, шуннан соң барысы да ачыкланыр,—диде табиб.

Ике айны энә өстендә үткәргәндәй үткәрде. Ашаудан ваз кичте, күзенә йокы кермәде. Ябыкты, битендә юка борыны гына утырып калды.

Авырга узганы мәгълүм булгач, бүлмәсенә бикләнеп, шатлыгыннан өч көн, өч төн елады. Чөнки сарай гайбәтчеләре гүзәл Соломония дә чәчен кистергәндә көмәнле булган икән дигән хәбәр таратты. Ул да монастырьда ир бала тапкан, имеш.

***

Василийның йөрәге бу шатлык-куанычларны күтәрә алмады. Әле ана илле дүрт кенә яшь иде. Тәхеткә Иоанн утырды. Бәлигъ булмау сәбәпле, дәүләт эшләрен анасы, бөек княгиня Елина Глинская алып барды.

Тиз арада тол княгиняның алманнарга хас сыйфатлары өскә калкып чыкты. Үз сүзле, тәкәббер, йөгәнсез дәрәҗәдә тәвәккәл. Болар сабырлык таләп ителгән дәүләти сәясәткә күп зыян китерде. Ире Василий еллар буе корган мәшһүр дипломатия мәктәбен берничә ай эчендә пыран-заран китереп бетерде. Мәскәү үтә сак һәм хәйләле дипломатиясе белән көчле иде. Русиянең бу чордагы орыш кырында кичергән уңышсызлыклары шул бәрабәргә тәгаенләнә иде. Уйланылмаган килде-китте боерыклар, фәрманнар ил эчендәге ыгы-зыгыга, ризасызлыкка юл ачты.

Мондый шартларда Казанның сәясәт көймәсе кайсы ярга борынын төртергә тиеш? Элеккечә Мәскәү кушканча яшәргәме, Кырым ягына авышыргамы? Шушы вазгыятьтә бәйсезлекне ничек саклап калырга?

Гәүһәршадның: «Итәк-чабуларны җыештырырга вакыт җитте», дигән канатлы сүзе шул үзгәрешләргә ишарә иде. Хәзер иң җайлы вакыт. Әлеге форсаттан файдаланмау гөнаһ кына түгел, бөтен татар халкы мәнфәгатьләренә хыянәт итү дә булыр иде.

***

Гәүһәршад утарына җыенды.

—Ике-өч көннән хәбәр салырмын, килерсез, шунда карарымны җиткерермен,—диде Булат бәккә.

Ире төпченеп тормады, чөнки тәнәкә тыкшынуны сөйми, аннан соң, әле аның фикере бөреләнеп кенә килә иде булса кирәк. Шуның өчен утарга китә дә ич инде, аулакка, тул җыярга.

Гадәттә ханбикәләр, берсеннән-берсе күреп, үз катларында сайрар кошлар, дингез аръягыннан кайтарылган бизәкле-чуклы телмәр тутыйлар, купшы йонлы эреле-ваклы затлы җәнлекләр, төрледән-төрле матур әкәмтөкәмнәр тоталар. Тәнәкә мондый шөгыльгә битараф. Өендә мәче дә юк. Ә маэмае бар. Җанвар-җәнлекләр арасында бердән-бер яраткан заты ул аның.

Узган җәй утарда яшәгәндә ялгызы гына йөрергә күнегеп киткән иде. Җилме-яңгырмы, салкынмы-эссеме—барыбер, йөрүе йөрү.

Ул көнне дә һава сытылам-сытылам дип кенә тора иде. Чәчәк таҗлары йомылган, бал кортлары да күренми. Тынчу. Урман артында инде болытлар укмашып килә. Әнә, зелпе тамырларыдай чуалышып, җиргә яшен чаткылары сызылып төште. Күк шартлап икегә ярылды...

Гәүһәршад шушындый зилзиләле табигатьне ошатарак төшә. Мондый һавада башы ачыла, кайдадыр йокымсырап яткан уй-фикерләре кузгала, өр-яңалары борын төртә. Әле дә яңгыр шыбырдый, җил котырына, ул исә атлавын белә. Шунда аякларына ниндидер йомгак уралды. Караса, көчек.

—Кит моннан, мәхлүк, бимазалап йөрмә,—дип, тәнәкә көчеккә тибеп җибәрде. Тегесе чинап читкә тайпылды.

Бу хәл берничә мәртәбә кабатланды. Тәнәкә тибә, көчек чиный, әмма барыбер иярә. Утарга да аллы-артлы кайттылар.

Тәнәкәгә көчекнең үҗәтлеге ошады. Карап торырга да ким-хур түгел иде. Корымга батырып алганнар диярсең, чем кара, тәпиләре белән колаклары гына ак. Бу аңа сөйкемлелек өсти иде.

— Исемең Табылдык булыр,—диде Гәүһәршад. Менә шулай маэмай малаеның язмышы хәл ителде.

Табылдык эре сөякле, көчле эт булып үсте. Күрәсең, бүретотарлар нәселеннән иде. Хәзер дә тотам да калмый Гәүһәршадка ияреп йөри, хуҗасының кайчан утарга киләсен дә сизеп-белеп тора, ул көнне иртә таңнан үз-үзенә урын таба алмый башлый: шатлыгыннан арлы-бирле йөренә, чиный, өрә...

Бүген бәхете түгәрәкләнде. Бергәләп сәяхәткә чыктылар. Гәүһәршад, гадәттәгечә, эчен бушата. Читтән караганда бу ике фикердәшнең эчкерсез әңгәмә коруы кебек тоела. Чөнки Гәүһәршад эткә мөрәҗәгать итеп сөйли.

—Табылдык, синең менә көчең ташып тора, нәсел үгезеннән ким түгелсең. Ләкин куян тота алмыйсың. Җә-җә, миңа алай усал итеп карама, өрүеннән дә курыкмыйм. Әллә дөрес түгелме? Куып карадың бит инде, унбиш-егерме адымнан гыҗылдап төштең. Бүрегә, төлкегә тының җитә, беләм, ә куянга—юк!

Табылдыкның калтыравыклы калын тавышы мичкәдән яңгырап чыккандай булып ишетелде: һау-һау-һау. Килешүе идеме, килешмәвеме, әнә, койрыгы йомарланган хәлдә гел селкенеп тора. Бу—ярату билгесе.

—Төлкенең аяклары кыска-кыскасын,—дип дәвам итте Гәүһәршад сүзен,—тик озын аяклы куян да аннан качып котыла алмый. Беләсеңме, хикмәтнең нәрсәдә икәнен? Белмәсәң бел, Ходай төлкегә хәйләкәрлекне бик мулдан биргән. Хәйлә ифрат үтемле корал ул. Сәясәттә бигрәк тә. Күп очракта хәйлә гакылдан өстен йөри. Фаразан, Мәскәү белән Казанның тату яшәвен гакыл һәрьяктан хуплый. Хак. Чөнки бу теләк-ниятләргә дә тәңгәл килә. Урыс хәзер ныгыды, җиргә нык басып тора. Көче дә, гаскәре дә житеш. Василий аларның берсен дә үзе белән гүргә алып китмәде...

Табылдык юлда чүпләнеп йөргән көртлекләрне өркетеп-куркытып чабулап йөрде дә янә тәнәкәгә килеп сарылды.

—Син мактау көтәсең булыр инде, мәхлүк, ә мактарга тел әйләнми. Берәрсен эләктереп тамагыңны ялгап алган булсаң әгәр, һичшикшез, хуплар идем,—дип, Гәүһәршад маэмаеның башыннан сыйпаштырып алды.—Мәскәү дә безнең башыбыздан сыйпамак итенә, ә үзләренең эчләре тулы мәкер. Шәт, аңлагансыңдыр. Мәскәүлеләр белән тартышырга гакыл да, хәйлә дә, сабырлык та, тәвәккәллек тә зарур, барысы берьюлы. Әлегә

бөек княгиня тәхете белән кинәнү чоры кичерә, хакимлек сөременнән кая барып бәрелергә белми, башкада гаме юк. Талак өчен менә дигән вакыт. Һәм бу талак кешеләрне истән тайдырырлык булырга тиеш.

Шулай булып чыкты да.

—Тә-әнәк-ә, мин дө-өрес іше-тәм-ме,—дип Чура морза хәтта тотлыгып торды.—Сафагәрәйне янә тәхеткә тәкъдим итәсең түгелме? Ике ел элек кенә үзебез куып җибәргән идек ләбаса. Апай угланның җебеклеге аркасында гына исән калды ич ул. Син тәхет дисең. Үзеңә-үзен гөнаһ алма, тәнәкә...

—Рәхмәт, морза, ниятемне шәрехләп бирдең,—диде Гәүһәршад тыныч кына,—Кырым шаһзадәсе Сафагәрәйне Казан-йортка хан итеп чакыру хәзерге вазгыятькә яраша дип саныйм. Узганы онытылган инде, кем кемнең борынын канатканны исәпләп утыра торган чак түгел. Мәскәү олуг кенәзне югалту шаукымыннан арынгалаганчы кыласы гамәлләребезне кылып кую хәерле булыр.

—Казан тәхете буш түгел бит, тәнәкә,—дип аптыравын белдерде Булат бәк,—безнең Җангали ханыбыз бар. Аны да үзебез сорап алдык...

—Җангали хан үз бурычын үтәде инде, бәк, кирәге бетте.

—Куып җибәрергә туры килә, фаразан,—диде Колдаш морза тәнәкәне хуплагандай,—бу мәсләктән тәҗрибәбез бар анысы.

—Җангалинең кәфен кулмәге күренә әле монда...—диде тәнәкә һәм аның күз алдында яшь кәләш белән очрашу мәҗлесендәге шикелле янә Җангали ханның мәете пәйда булды.

—Казансу ярында...

Бүлмәдәгеләр сорау бирмәделәр, фәкать бер-берсенә карашып кына куйдылар.

***

Пакизәнең көмәне көннән-көн тулыша, кабарына бара иде. Эчне кысып бәйләп кенә кеше күзеннән яшереп булмас чак килеп җитә. Чикерткәдәй сикергәләп йөргән кызның куллары еш кына биленә сарыла башлады, хәрәкәтләре салмакланды.

—Әллә бер-бер хәлең бар инде, кыз, һаман утыру ягын гына карыйсың,—дип, өлкән гасәбә дә төрттерәсе итте.

Бу хакта ул Җангалигә дә җиткерде.

—Мин инде сарайда кала алмыйм, хан, авырым һаман зурая, нарасый да риза түгелдер, мөгаен, туктаусыз тибенә,—диде,—менә, ышанмасаң, капшап кара.

Җангали кызның кабарынкы корсагына зур учларын куеп, беразга тын калды.

—Эчеңне ярып чыкмасын тагын...

—Сиңа кызык...

—Ярар, ярар инде, тынычлан, сиңа еларга ярамый,—дип, Җангали мәгъшукасының яшьләрен сөртеп алды.

—Аллаһы боерса, кыз бала алып кайтырмын дип торам,—диде Пакизә яшь аралаш.

—Каян беләсең?—дип сорады Җангали.

—Күнелем сизә,—диде Пакизә,—беләсең килсә, миңа күз атасыңны да алдан ук сизеп-тоеп йөрдем мин. Никахыңны да...

—Никахны күнелең буташтырган,—диде Җангали үпкәләгәндәй,—минем күңелем сине тели иде, акбурга буялган мангыт курчагын түгел.

Пакизә элеккечә келтер-келтер көлеп алды. Сөйгәненнән шундый күркәм сүз ишетү аңа чиксез рәхәтлек китерә иде.

—Кызганыч, кәләш сайлау хан ирегенә куелмый шул,—дип дәвам итте

Жангали,—хан, гомумән, богау эчендә. Ул бернәрсә дә хәл итми, анын өчен башкалар уйлый, башкалар сөйләшә, башкалар кайгырта.

—Рәхмәт яхшы сүзенә,—диде Пакизә,—ханга ярәшсеннәр өчен хан кызы булырга кирәклекне үзем дә бик әйбәт беләм... Кәләшен матур, минем ише генә түгел...

—Житте,—дип, Жангали Пакизәнең авызын каплады,—йөрәгемә ярамый ул минем.

—Ярар сон, әйттем исә кайттым...

—Мин сине ханбикә итә алмадым, Пакизә бану, тик шуны вәгъдә итәм: кызыбыз тулы хокуклы хан кызы булыр. Күрерсен. Бу әле алда. Хәзер исә аңа кадәр башкарыласы эшләр турында баш вату хәерлерәк булыр.

—Нинди эшләр ул, Жангали?—дип сорады Пакизә. Бу анын ханга тәүге һәм соңгы тапкыр исем-аты белән мөрәҗәгать итүе иде.

—Минем өчен иң мөһиме, синен, туачак баланын иминлеген тәэмин итү.

Шушы сөйләшүдән соң Пакизә сарайда күренмәде. Аны карангы төндә, кендек әбисенә ияртеп, Арча каласы янындагы бер яшерен утарга илтеп урнаштырдылар, сак куйдылар.

Сарай иснәнүчеләре ары сугылды, бире сугылды, әмма шактый вакыт бу югалтунын эзенә төшә алмыйча гаҗиз булдылар. Әлеге хәбәр ханбикәгә дә барып ирешә. Ханнын сөяркәсе барлыгын ул белә иде инде, килен булып төшүгә житкергәннәр иде. Ә анын бәхетле чагы. Шуңа күрә гайбәтләрне колак очыннан гына очырып җибәрде. Чөнки, хәбәр хак булган очракта да, ул ятимәбикә аңа бервакытта да көндәш сыйфатында юлына аркылы төшә алмаячак иде. Үз бәясен бик яхшы белә иде Сөенбикә. Вакыт үтәр, ә анын турында: «Нугай кызлары арасында Сөенбикәгә охшаган кыз булмаган кеби, Казан һәм урыс йортларында да аңа тиндәш булырлык кыз юк иде. Ул көн ягынын иркен җәйләүләре илә анын мөлаем һавасында тәрбияләнеп үскән вә шунын илә бәрабәр тумыштан матур булганылыгы өчен, дөньянын беренче сөйкемлесе иде»,—дип язачаклар.

Сызлану, канәгатьсезлек, рәнҗү сонара килде. Сөенбикә бөтен жаны-тәне белән иренә тартылган, аңа ярарга тырышкан, иркә-назлары белән коендырган бер вакытта, ул йөзен чыта, киреләнә, тупас вә дорфа кылана.

Тик шунысы бар, Сөенбикә кияүгә ир көен көйләү өчен генә чыкмады. Ул гади кәләш түгел. Ул—ханбикә! Барча Казан жиренең кануни ханбикәсе! Ханбикә исә дәүләт эшләрендә дә катнашырга хокуклы. Мисырнын Клеопатрасы, Кырымнын Нурсолтаны, Монголнын Гаймишы, Византиянен Софьясы шикелле мәмләкәт тоткан югары сәясәтнен үзәгендә кайныйсы, ханнын иң якын киңәшчесе, турылыклы көрәштәше, ышанычлы таянычы буласы килә. Монын өчен укымышлылыгы да, хәзерлеге дә, тәрбиясе дә житәрлек. Чибәрлекнен дә үз урыны бар, ул да сарай даирәсендә бик үтемле корал. Кайвакыт акыл теше үтмәгәнне чибәрлек жинә.

Бу яктан алар Гәүһәршад белән су тамчылары кебек охшашканнар: икесе дә дан-шөһрәт ярата, хакимлеккә дәгъвә итә. Ихтимал, араларына күләгә ятунын сәбәбе дә шундадыр. Ике куйнын башы бер табакка сыймас ди бит.

Тик әлегә Сөенбикәнен омтылыш-дәгъвәләре кысыр хәлдә, бик үрчеп китәрләр иде дә, Жангали ханнын битарафлыгы, санашмавы кулдан тота.

Бу ханбикәнен горурлыгына, мин-минлегенә тия. Әмма ул иренә сиздерми. Аны кече яшьтән үк, ризасызлыгынны тышка чыгарма, теленне аркылы тешләп булса да түз, дип өйрәттеләр. Би кызынын бизәге—тәкәбберлек вә горурлык!

Сөенбикәне Җангалинең кызы туу, ханның аны үзенеке итеп тануы чыгырыннан чыгарды. Җә, хуш, тусын ди, ир кеше бер уйнап алмый утырмый диләр. Әмма дә ләкин уйнаштан туган балага хан кызы дәрәҗәсен бирү акылсызлыкның да акылсызлыгы лабаса! Хурлыгы ни тора! Житмәсә, хан башы белән адәм көлдереп: «Пакизә бикә минем тәүге һәм соңгы мәхәббәтем», дип әйтә икән.

Кызына да бала тапканда үлгән шул сөйрәлчегенең исемен куштырган. Әле ярый кызын кендек әбие белән Касыймга озаттырган. Монысына башы җиткән.

Сөенбикәнең һич тә артык кашык кимәлендә яшисе килми. Тик нишләргә? Уйлана торгач, ул иң дөрес юлны сайлады: бик ышанычлы кеше аша атасы Йосыф морзага мәктүп юллады. Мәктүп бик кыска иде, берничә генә җөмлә: «Сәгадәтле вә гыйззәтле атаем! Хәлләрем бик мөшкел. Киявен, Барча Казан җиренең хөрмәтле ханы Җангали, мине яратмый, кага, кимсетә, ханбикә вазифаларын башкарырга ирек бирми. Кызыңа нишләргә, акыллы киңәшеңне бир».

Йосыф бәкнең кашлары җимерелде. Иң зирәк, иң чибәр, иң хәйләкәр кызыннан ул мондый эчтәлекле хәбәр көтми иде, яраткан кызымны бик дәрәҗәле, бик мөхтәрәм җиргә урнаштырдым дип зур канәгатьләнү хисләре кичерә иде. Шуңа күрә җавабы да бер җөмләгә сыйды: «Төшкән җирендә таш бул!»

Мәктүпләр килүдән туктамады. Чөнки Сөенбикә атасының ярдәменә мохтаҗ иде. «Алманың пешкәнен аю ашар», дип сыкранып уйлап куйды Йосыф морза. Аннан соң күпне күргән бер ушлы илчесен чакырып хәлне аңлатты да әйтте:

—Вәкаләтең чикләнмәгән, үзең хуп күргән теләсә-нинди гамәлне кыла аласың, миннән хәер-фатиха,—диде.

Ата белән кыз арасындагы әлеге мәктүп алышулар никадәр генә сак һәм яшерен алып барылмасын, никадәр генә сер итеп сакланмасын, бу мәгълүмат Нугайдагы Мәскәү илчесе Димитрий Губин катына кичектергесез рәвештә килеп ирешә. 1535 елның 22 июнь көнендә Мәскәүгә хәбәр китте: « К Юсуфу из Казани дочь письмо прислала, Яналеева царица. Сказывают, Яналей царь ее не любит...»

***

Гәүһәршад 1535 елның 25 сентябрь көнендә иртә белән Сафагәрәйне кабат Казан тәхетенә чакырып язылган ярлыкка имзасын беркетте. Шул ук көнне кичке якта Казансу комлыгында Җангали ханның мәетен табып алдылар.

—Синең эшме?—дип сорады тәнәкә Чура морзадан.

Морза җавап бирергә ашыкмады, кулына кымыз касәсен алып, ясалма дикъкать белән аның бизәкләрен тикшергәндәй итенеп торды да, бер йотым эчеп куйды. Аннан мут кына елмаеп, әйтте:

—Урыс әйтмешли, чем черт не шутит, когда бог спит.

—Соравымны кабатларга мәҗбүр итмә, морза,—диде Гәүһәршад җитди генә.

—Минем кемгә теш кайравым сиңа мәгълүм лабаса,—диде Чура тәнәкәнең күзләренә туры карап,—нахак бәла такма.

Йосыф би дә шушы ук сорауны илчесенә юллады.

—Өлгерә алмадык, безгә кадәр житешкәннәр иде инде,—диде тегесе. Үз чиратында аның да соравы бар иде.

—Ханбикәне нишләтәбез соң, кузгатабызмы?—дип хуҗасына бакты.

—Сөенбикә Казан-йортның ханбикәсе, аның урыны шунда,—диде Йосыф би, икеле-микеле уйларга урын калдырмыйча.

Жангалинең фаҗигале үлемен төрлесе төрлечә фаразлады. Берәүләр Гәүһәршад төркемено аударды, икенчеләре Йосыф морзаны гаепләде, өченчеләре Мәскәү кулы уйнады дип тәкрарлады. Кырым ягына ым кагучылар да табылды. Тик барыбер тәгаен гына очына чыга алмадылар. Ныклап тикшермәделәр дә. Чөнки бу чокыну сасы ис кенә чыгарачак иде, ә аның берәүгә дә хаҗәте юк. Әмма хан кадәр ханның үтерелүе эзсез генә кала да алмый.

Җеназа мәшәкатьләре үтү белән, Гәүһәршад корылтай җыйдыртты.

—Сафагәрәй килеп җитсен инде, нигә кабаланасың?—диде Булат бәк.

—Әлеге мәсьәләгә аның бер катнашы да юк,—диде Гәүһәршад.

Чыннан да, тәнәкәнең тәкъдиме мәрхүм ханның дошманнарын гына түгел, корылтай әгъзаларын да кара көйдерде. Дөрес ишеттекме дигәндәй, ачылган авызларын ябарга да онытып, бер-берсенә карашып каттылар. Аннан дәррәү килеп кубарылдылар.

—Көтүенә чыбыркы җитми, морза, бөтенләй тузынгалап беткәнче җәтрәк утарга куып керт,—диде Гәүһәршад корылтай башлыгы Әхмәт бәккә киная беләнрәк.

Сыртларына кигәвен угы кадаган малларны тыю ай-һай авыр шул ул, кычкыра-кычкыра рәиснең үз тамагы да карлыгып чыкты.

Ниһаять, корылтай тынычлангандай итте.

—Җәмәгать, сүз алып, берәмтекләп кенә сөйләгез,—диде рәис маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен җиң очына сөртә-сөртә,—тәмам базар ясадыгыз...

—Син безне кысма, бәк, корылтай корыны бушка әйләндерә торган урын түгел ул, фаразан, дәүләти оешма,—дип, Яутәк морза да кызып китте.

—Әстәгъфирулла, морза, тәүбә-тәүбә, ниткән кысу, Ходайдан курык,—диде рәис.

—Җангали ханның уйнаштан туган баласы файдасына дәүләткүләм салым кертү дөрес үк булып бетәме соң?—дип, Кодаш бәк тә шиген белдерде.

—Менә шул хакта тәфсилләп фикер алышыгыз инде, бәк,—диде Гәүһәршад,—сезне кем тыя? Сөальләрегез булса, баш карачы җавап бирер.

Ул урыныннан торды да җәт-җәт атлап, залдан чыгып китте.

Корылтай әгъзалары, тәнәкә кушканча, озаклап сөйләштеләр. Нәтиҗәсе дә тәнәкә теләгәнчә булды. Шулай итеп, Казан ханлыгында гомум унөч салымга янә берәү—«Җангали салымы» өстәлде. Халыкта аны «Кыз салымы» дип йөрттеләр.

Бәкләр, морзалар да алдатмады. Салым ахыр чиктә сәүдәгәрләргә генә тәгаенләнеп калды. Һәр кибет хуҗасы, хан кызы бәлигъ булганчы, казнага ел саен дүрт алтын хакына торырлык акча түләп барырга тиеш табылды. Бәлигълык кызның күрем вакыты башлану белән билгеләнде.

—Ошбу уенның ни хаҗәте бар иде соң?—дип сорады тәнәкәдән Булат бәк,—җиһанда юк хәл ич бу.

—Җиһанда юк, ә Казан-йортта бар.

—Шулай да...

—Игелек ит тә суга сал, халык күрмәсә, судагы балык күрер,—диде Гәүһәршад,—затлы нәселнең гамәлләре дә затлы булу фарыз.

***

Шаехгали, ишектән керүгә идәнгә ауды да, дүрт аяклап тәхет тарафына мүкәләде. Алты яшьлек олуг кенәз чак кына шаркылдап көлеп җибәрмәде. Чөнки хан сарай шамакаеннан да көлкерәк күренә иде. Тун чабулары аяк астына эләгеп, тәгәрәп-тәгәрәп китә, янә тора, янә тәгәри. Үзенең күзләреннән туктаусыз яшь ага.

Шулай булмыйча, көтмәгәндә сөргеннән азат иттеләр бит Шәехгалине. Өметен җуеп бара иде ич инде. Илһам ханныкы шикелле гомерем тоткынлыкта өзелә икән дип бик борчыла иде.

Ходайның рәхмәте, көннәрдән бер көнне Мәскәүдән чапкын килеп төште, олуг кенәзнең ярлыгын тапшырды.

Шул көнне юлга да чыктылар. Ашыгуның сәбәбе дә күнелле иде: декабрьнең уникенче көнендә галиҗәнап кабул итәчәк икән. Ә аңа нибары бер атна вакыт калып бара. Димәк, аны тулысынча ярлыкаганнар, димәк, элеккечә сарай даирәсендә калачак! Менә бит, бәхет тә ризык сыман тешне сындырып керә икән ич.

Ул әле энесе Җангали ханның үтерелүе хакында белми иде. Шуңа күрә бу бәхет-куанычларның әлеге үлем белән бәйле икәнен дә башына китерә алмый иде.

Атлар шәпле, көн матур, күңел күтәренке. Кулыннан килсә, бөтен җиһанны кайнар кочагына кысар иде. Әнә, кесәсендәге тәңкәләрен дә кузла башында бертуктаусыз җырлап-көйләп баручы аттотарга биреп бетерде. Тегесе акчаларны җыр өчен бүләк дип кабул итә иде, ахры, отыры котырына.

—Үсендермәсәнә шул алапаны, колагым тонып бетте бит инде,—дип, икенче яктан җәмәгате Фатыйма-Солтан кабыргасына төрткәләп ала. Шәехгалинең авызы ерык, шытыр-шытыр көлә генә. Хәтта җырны күтәреп алмакчы булып та итенгәли.

—Сиңа әйтәм, җүләрләнмә, зинһар, хан лабаса син, зат иясе,—ди Фатыйма. Билгеле, ханбикәнең чәнчүләре дә куаныч галәмәте генә иде.

—Бәйрәм килде ич, бәйрәм, их... ханбикә!

—Бәхетебез аякларыбызга чорналсын иде, Ходаем мәрхәмәтеңнән ташлама.

Елина Глинская Шәехгали атлы татар ханының сөргендә ятуын юньле-башлы белми дә иде. Һәрхәлдә, ханның язмышы аны бөртек тә кызыксындырмый иде. Ире, олуг кенәз Василийның юлына аркылы төшкән икән, димәк, хыянәтче. Ә хыянәтченең урыны—сөрген.

Казан тәхетенә янә Кырым шаһзадәсе Сафагәрәй утыргач, вазгыять үзгәрде. Казан Мәскәүгә сырты белән борылмакчы. Моңа ирек куярга ярамый. Боярлар шурасында да бу хакта катгый сүз булды. Аннан алдарак Мәскәүгә бер төркем татар бәкләре килеп киткән иде. Араларында Югасды, Шаһбаз, Шаһбулат, Карамыш, Яулыш кебек күренекле бәкләр булып, барысы да Мәскәү көен көйләүчеләр иде. Җангали ханның үтерелүе, тәхеткә Сафагәрәйнең чакырылуы турында бик тәфсилләп сөйләделәр. Мәгълүмат шактый тулыланды. Үтенечләре бер генә: «Падишаһыбыз безне багышлап, Шәехгали ханга карата булган ачуын бетерсә, аны үз янына Мәскәүгә чакырса иде. Шәехгали Мәскәүгә килгәч тә без Сафагәрәйне Казаннан куып җибәрер идек»,—диделәр.

Әнә шулай Шәехгалинең батып барган кояшы әкияттәге могҗизадай күк үзәгенә кайтты. Һәм менә ул урысларның мәзһәб мөнбәре—Кремльдә, тәхет залында.

Шәехгали никадәр генә тырышмасын, тәхет катына барып җитә алмады, сакчы сөңгесе юлын бүлде. Бу аңа үзен кулга алырга ярдәм итте. Тезләренә таянды да:

—Синең атаң, минем исә падишаһым Василий Иванович,—дип алдан әзерләп куйган күп сүзле мөрәҗәгатен тәгаенләп китте,—мине яшь көенчә алып, ата үзенең баласын багышлаган кебек багышлаган, Казанга падишаһ иткән, үзенең олуг ярлыкашлары белән ярлыкаган иде. Минем начарлыгым шомлыгында, Казан бәкләре белән Казан кешеләре арасында талашлар

булды. Мин шуннан соң тагы да үземнең падишаһым, синең исә атаң янына Мәскәүгә кайтмыш идем. Ул исә мине ярлыкап, үзенең жирендә шәһәрләр бирмеш иде. Мин, гөнаһым сәбәпле, үземнең падишаһым каршында гаепле булдым. Үземнең начар гакылым, шулай ук яман уем өчен Аллаһ мине якламады. Шуңа күрә синең атаң, минем падишаһым, шушы начарлыкларым өчен миңа ачуланып, мине каргады. Хәзерендә син, минем падишаһым, атаңның миңа булган яхшылыкларын уйлап, миңа мәрхәмәт күрсәттең, моны синең күңеленә Аллаһ салды. Юкса минем гөнаһым сәбәпле, бу булмас иде...»

Иоаннның бала күңеле бу дилбегә буе нотыкны йота алмады, күрәсең, чыраен бозыштыра-бозыштыра аякларын селеккәләргә тотынды.

Шәехгали мыгырдана да мыгырдана. Иоанн сыналган алымны кулланырга мәҗбүр булды. Моның өчен кулыңны гына сузарга кирәк. Кеше йөгереп килеп аны үбә. Бу инде кабул итүнең төгәлләнүенә ишарә.

Шәехгалине берничә көн дәвамында җиз иләк аша үткәргәндәй үткәрделәр, эченнән сөрем чыкканчы тәүбә иттерделәр. Максат бер генә—Шәехгалине рухи манкорт хәленә төшерү. Ул Мәскәүгә тәкъвә диндарларча бирелеп хезмәт итәргә тиеш. Үзбашыннан һичнәрсә кылмаска, әйткәнне жиренә житкереп башкарырга. Хәер, аны өйрәтәсе түгел. Чөнки белә: язмышы да, яшәеше дә Мәскәүгә бәйле. Мәскәү бар икән, ул да бар, Мәскәү юк икән, ул да юк.

—Мин колыгыз,—диде ул бөек княгиняга әңгәмә вакытында,—һәм сез падишаһларыма сүз бирәм. Шул сүземдә үлгәнчегә чаклы нык торып, шул юлда үләргә, шулай ук үземнең туганым Җангали хан үлгән шикелле, сезнең хезмәтегездә башымны бирергә телимен.

Бөек княгиняга Шәехгалинең үз-үзен тотышы ошады. Йомшарып китеп, хәтта Фатыйма-Солтанга да йөзен күрсәтергә рөхсәт бирде. Алар янына патша үзе дә керде. Кәефе шәп иде. Ник дисәң, бүген ул иртәнге уен вакытында ботак очына кунган бер олы карганы тәү атуда бәреп төшерде. Башка көннәрдә өчәр-дүртәр, кайчак бишәр ук сарыф итә иде.

—Тапугъ салам,—дип, ханбикәне төркичә сәламләде, мөселманча ике куллап күреште.

Табын өстендә ханбикәне Елинаның уң ягына утырттылар. Сул ягында—чукынчык Ходайкол—Петр Ибрагимовичның кызы, иң дәрәжәле кенәзләрдән саналган Федор Мстиславскийның хәләл җефете Анастасия. Өстәл янында Елинаның каравычы кенәз Иван Челядов булып, Фатыйма-Солтанныкы кенәз Василий Репнин иде.

Трапеза вакытында бердәнбер дөньяви мәгънәгә ия хәбәрне Фатыйма-Солтан житкерде.

—Туганыбыз мәрхүм Казан ханы Җангалинең кызын Шәехгали хан үз тәрбиясенә алды,—диде.

Ханның бу адымын табындагылар да хуп күрде.

***

Сафагәрәй чын мөрәүвәт адәм. Көчле, гайрәтле, күркәм. Бу яктан агасы Сәхибгәрәй хан белән бериш. Егерме яшьтә дүрт никахлы ир иде инде. Соңгысы—Мамай морза кызы Хәдичә. Риза-бәхил иде ул хатынынннан. Шуңа күрә Казан жиренә аяк басуга, яңа никах тәкъдим иткәч, аптырап китте. Аптырамаслык та түгел, моннан ике ел элек кенә Казан-йорттан куып жибәрелгән иде ич. Хәзер шул ук кешеләр, чакыртып алып, янә тәхеткә утырттылар. Өстәвенә, кәләш тә сайлап куйганнар.

Сафагәрәйнең әсәребрәк калуын Гәүһәршад та сизеп алган иде, юатасы итте.

—Борчылма, хан, ханәкә затлы ырудан, Нугай бие Йосыф морза кызы, үзе чибәр, укымышлы,—диде.—Карап торуга ук пар килгәнсез.

—Тәнәкә галиҗәнаплары, бу никахның ханлык вазифаларына нинди мөнәсәбәте бар соң?—дип белеште Сафагәрәй.

—Гореф-гадәт кануннары таләп итә моны, хан,—диде Гәүһәршад, сүзне озакка сузмыйча гына,—Сөенбикә Казан ханбикәсе, аны урнаштыру безнең бурыч.

Сафагәрәйне җавап канәгатьләндермәде. Күренеп тора, гореф-гадәттән тыш та ниндидер астыртын мәгънәсе бар бу никахның. Шулай да шиген белдерергә ашыкмады, фәкать:

—Уйланырга күпме вакыт бирәсең?—дип кенә белеште.

Гәүһәршадның нәфис кашлары сикергәләгәндәй итенде. Аннан соң әйтте:

—Аның нәрсәсен уйлап торасың, уйланылган инде ул,—диде.

Сафагәрәйнең җитез акылы әлеге никахның үзе өчен ни-нәрсә китерәсен тәгаенләү белән мәшгуль иде. Әйе, булачак бабасы Йосыф би—Нугайның иң абруйлы, иң күренекле заты. Бу бик әйбәт фал. Чөнки моңа кадәрге бичәләренең нәсел-ыруы белән әллә ни мактана алмый иде. Һәм дә әлеге никах Казан белән Нугайның этле-мәчеле мөнәсәбәтләренә чик куяр. Аннан соң, Нугай белән дуслашу Мәскәүнең тамагына кылчык булып кадалачак. Монысы икеләтә-өчләтә яхшы.

Гәүһәршад тәнәкә, Казан әлеге никахтан ни ота? Ул аны тол ханбикәне бәхетле итү, үзе әйтмешли, гореф-гадәтләр мәнфәгатендә генә башкармый, билгеле. Бу—уен. Һәм бу уенның төбендә җитди сәбәп ята. Нинди ул сәбәп?

Сафагәрәй сиздерми генә тәнәкәгә күз төшереп алды. Гәүһәршад шөгыленә шулай да мөкиббән киткән иде ки, иреннәре бүлтәйгән, күзләре чекрәйгән, ияк астындагы тиресе салынып төшкән... Ямьсез иде ул бу кыяфәттә.

Башында да ямьсез уйлар чуалышадыр монын, дип гоманлады Сафагәрәй. Гәүһәршад исә әлеге мизгелдә фәкать чәй ясау белән генә мәшгуль иде. Ул чәйне үзе ясап эчә. Чәе гап-гади: сөтсез, тәм-томсыз, үлән-төнәтмәсез, бары коры чәй. Әмма куелыгының кәефенә тәңгәл килүе шарт. Ә моны үзе генә тоемлый ала.

Никахка килгәндә исә, ул исәпне хисапка чыгарырлык итеп инәсеннән җебенә кадәр тәгаенләнгән иде инде. Никах Казан өчен сәяси вариантлар мөмкинлеге тудыра. Мәсәлән, Казан—Кырым—Нугай берлеге Мәскәүнең көньяк, көньяк-көнчыгышка кагылышлы яулап алу ниятләренә юлны яба. Яки, киресенчә, Казан—Мәскәү берлеге кырымлылар вә нугайлыларның өстенлеккә омтылуларына киртә куя. Казан шулай ук Мәскәү—Кырым—Нугайны үзара дошманлаштырып та түл җыя ала. Болар, әлбәттә, нинди сәяси вазгыять урнашуга бәйле. Ничек кенә булмасын, Кырым белән Нугайны йөгәндә тоту Казан өчен иң отышлы вариант. Бу җәһәттән Сөенбикә ханбикә алтын бәрабәренә тиң кәләш.

Ханнар алышына, ә Казан-йорт тоткан юнәлеш элеккечә кала бирә. Һәрхәлдә, Гәүһәршад исән чакта шулай булачак.

—Тәнәкә галиҗәнаплары, мин аудинциянең мөһимрәк мәсьәләләргә, әйтик, хан эшчәнлегенә багышлануын көткән идем,—диде Сафагәрәй. Ул бу сорауны тәнәкәне ачыктан-ачык сөйләшү эзенә төшереп булмасмы дип бирде.

Гәүһәршад ялт итеп башын күтәрде. Иреннәре дә, ияк асты да җыелды, күзләре дә урынына утырды. Сафагәрәй каршында элекке ыспай буй-сынлы, кырыс вә чибәр тәнәкә иде инде.

—Өйләнүне мин моңарчы нигәдер мөһим эшләр исәбендә йөртә идем,—дип, ул чеметүлерәк төсмер белән елмаеп алды,—күрәсең, ир-ат өчен никах көнбагыш яру кебек кенә...

—Мин дәүләт башлыгы, тәнәкә, шәхси мәсьәләләргә өстенлек бирүне мәгъкуль санамыйм.

—Сизәм, хан, синеңниндидер мөһим тәкъдимең барга охшый. Шулаймы?

—Әйе, тәкъдимем бар,—диде Сафагәрәй,—киңәш-табыш итешәсе иде. Ханның гамәлләре ханлыкның гомум мәнфәгатьләренә туры килергә, җәмәгать, халык тарафыннан хупланырга тиеш дип саныйм. Мин бу юлы озакка килдем...

—Тыңлыйм, хан, рәхим ит.

Сафагәрәй тирән итеп сулыш алып куйды да әйтте:

—Мин Мәскәү белән төзелгән 1487 ел Килешүен юкка чыгарырга кирәк дигән фикердә торам,—диде,—тәүге ярлыгым шул хакта булачак. Мине Мәскәү белән килештермичә тәхеткә чакырып, син аны үзең дә боздың, тәнәкә...

Бу юлы Гәүһәршадның иреннәре җеп шикелле булып кысылды, ияге шөшле кебек алга очлаеп чыкты. Ләкин сүз әйтергә ашыкмады. Дөресрәге, югалып калды. Үз гомерендә ул бик күп сәяси зилзиләләр оештырды, берничә ханны гына алыштырды, баш карачылар турында әйткән дә юк. Күрше мәмләкәтләрдә дә буран уйнаткалаганы бар. Шулай да, һәрвакыт мөнәсәбәтләрне кануни нигездә кору ягында булды. Чөнки бары тик шундый мөнәсәбәтләр генә дәүләтнең тотрыклылыгын тәэмин итә, бары тик шундый мөнәсәбәтләр генә киләчәкне күзалларга булыша. Сафагәрәй исә дистә еллар буе бөртекләп җыелган әлеге тәҗрибәнең нигезен какшатмакчы.

Сафагәрәй бу Килешүгә кизәнүченең тәүгесе түгел иде. Беренче булып аңа Үрбәт ханбикә таш ыргытты. Ире Мөхәммәдәмин кулы белән Мәскәүнең тешен сызлатырдай шактый күп гамәлләр кылырга өлгерде. Хан авырып, урын өстенә егылмаса, ихтимал, Килешүне өзәрлек сәбәпләр дә туплый алган булыр иде.

1487 елгы Килешүгә Мәскәүнең олуг кенәзе Иван III һәм Барча Казан җиренең бөек ханы Мөхәммәдәминнең имзалары куелган. Иван үзенең тәрбиягә алган улын, тәҗрибәсез яшь Мөхәммәдәмин ханны тәхет бәрабәренә әлеге кабалалы Килешүгә кул куярга мәҗбүр итте. Беренче карашка мөстәкыйльлеген югалтмаган кебек булып тоелса да Казан ханлыгы инде кулы-аягы белән Мәскәүгә бәйләнде. Дипломатия телендә бу протекторат дип атала.

—Син бу адымыңның нәтиҗәсен күз алдына китерәсеңме соң?—дип, Гәүһәршад ханга текәлде.

—Бик ачык күз алдына китерәм, тәнәкә. Килешүне юкка чыгару Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләрен чиктән тыш катлауландырачак. Орышлар да котылгысыз.

—Шулай булгач...

—Азатлык барысыннан да өстен, тәнәкә.

***

Сафагәрәй яшь кәләше катына, сөннәти кагыйдәләрдә фарыз булганча, өч көнгә дип кенә кергән иде. Өч көн күз ачып йомганчы үтте дә китте. Янә бер көн. Һич аерылыша алмыйлар.

—Син мине сихерләдең, ахры, бичәм...

—Үзем дә шуны тукыйм ич инде, әшең кала, дим...

Сөенбикә ак нәфис бармаклары белән иренең җонлач күкрәген

кымтырыклап алды. Аннан соң ул өттергеч бармаклар җилкәгә таба шуышты да, муенны сыйпап узды, яңаклар аша җөйле кашларга барып җитте...

Һәр тукталышта ләззәтле тәм сарылып кала, күзәнәкләргә ниндидер ашкынулы рәхәт наз тула...

—Ah-h...

Йосыф морза йорт-җиренең кыз-хатыннар каты шау-шулы түгел иде. Ул фәкать хәләл җефетләре, туган-тумача, якыннары, балаларыннан гына гыйбарәт булып, гарәп хәрәмсарайларыннан бик нык аерыла иде. Җарияләр, сөяркәләр бөтенләй юк. Әмма яшь туташларны гаилә тормышына әзерләү, ир хатыны булуның үзенчәлекләренә төшендерү, интим мөнәсәбәтләрнең асылына өйрәтү белән гарәпләрдән ким шөгыльләнмиләр иде. Сөенбикә дә әлеге гаилә мәктәбен үтте. Әмма орлык шытым бирсен өчен дымлы уңдырышлы туфрак зарур. Сафагәрәйнең гыйшкый бакчасында әлеге шартларның барысы да бар иде. Чәчәккә йомарланып та һаман бөредә утыручы Сөенбикә дигән зиннәтле гөл, ниһаять, җиһанга купшы таҗларын күрсәтте, хан йөрәгендә кайнардан-кайнар мәхәббәт уты кабызды...

Дөрес, Сафагәрәй башта яңа кәләшен яшь җәмәгате Хәдичәбану белән чагыштырып караган иде каравын, әмма бик тиз бу чагыштыруның мәгънәсезлеген аңлап алды. Чөнки Сөенбикә бөтенләй үзгә зат иде. Ул бу үзгәлекнең серенә дә төшенде: Сөенбикәнең йөз сылулыгы белән җан вә тән сылулыгы тәңгәл килә, алар бербөтен, бер-берсеннән һич аера алмыйсың.

—Сафагәрәй, мин сине бик озак көтеп алдым,—дип пышылдады бәхете тулып ашкан Сөенбикә.

Чыны да шулай иде. Ул ифрат дәрәҗәдә тойгылы, чиктән тыш тәэссоратлы, хисле бала булып үсте. Бу сыйфатлары, буйга җиткәндә, гыйшык сөременә уралып, иксез-чиксез мәхәббәт дәрьясына әверелде. Юк, тәгаен гына беркемгә дә гыйшык тотмады. Үзе тирәсендә әвәрә килүче егет кәмәшләрен гомумән җене сөйми иде. Билгесез каһарманга гашыйк иде ул. Өнендә дә, төшендә дә күз алдында шул батыр да, чибәр дә, гайрәтле дә, тәвәккәл дә, кыю да егет солатны.Ул егетнең уенда да—Сөенбикә. Һаман аны эзли. Һәм табачак та, алар кавышачак!

Казанның яшь ханы Җангалидән яучылар килгәч, и сөенгәннәре! Ни кызганыч, хыяллары акланмады. Хан кыз баланың саф вә пакь омтылышларын, сөю, наз өмет иткән тәнен, яклау көткән җанын аңламады.

Бер начарның бер яхшысы ди. Җангали ханның фаҗигасе китерде аңа бу бәхетне. Сафагәрәй яшьли хыялында йөрткән каһарман иде.

—Пәрием!

Сөенбикәнең назга үрелгән куллары тукталып калды. Пәри дигәнне ошатмады, ахры, дип уйлап куйды Сафагәрәй.

Дөрестән дә, яшь кәләшкә сәер тоелды бу сүз. Пәри шул ук җен ләбаса инде ул, адәм баласын аздыра, ялгыш юлга кертә. Кара көч, Иблис токымы.

—Рәхмәт инде, моңарчы пәри икәнемне белми йөргәнмен,—диде Сөенбикә сүрән генә,—матурлык морат түгел, ямьсезлек оят түгел...

—Үзен дә «Шаһсуар» дигән кушамат тагып куйдың бит әле, әнә...

—Шаһсуармы? Шаһсуар осталардан да остарак җайдак дигән сүз ул бик беләсең килсә,—дип җанланып китте Сөенбикә.

—Пәри дә җеннәрнең иң матуры, иң гүзәле,—дип хатынын кочагына кысты Сафагәрәй,—пәрием!

—Казан тәхетенә чакыруына син тәнәкәгә бик рәхмәтледер, мөгаен, шулаймы?—дип, Сөенбикә сүзне бөтенләй икенче юнәлешкә борып җибәрде.

Сафагәрәй өстендәге җәймәне сыдырып төшерде дә торып ук утырды.
—Ә син?
—Мин аеруча рәхмәтле, югыйсә без кавышмаган булыр идек,—диде Сөенбикә,—ләкин тәнәкәне кара эчле диләр...
—Кем кара эчле, кем ак эчле, моны ачыклыйсы да ачыклыйсы...
Бу әле кармакка җим утырту гына иде. Чөнки Сөенбикә дәүләт эшләрендә дә ханның иң ышанычлы, иң якын булышчысы була алыр иде. Күренә ки, ханның бу җәһәттән бик ачыласы килми. Әмма су барыбер үз юлын таба ул, сабырлык зарур.
—Кичер, шаһсуарым, бу җүләр хатыныңны,—дип, Сөенбикә иренең ireннәренә беректе.

***

Энем кырлач... Өттергеч салкын төн. Ак кар. Аяз күк. Баш очында йолдызлар жемелдәшә, ай балкый. Энә сапларлык якты.
Гәүһәршад селкенергә дә кыймыйча күкне күзәтә. Төнге күк үзе бер могҗизалы дөнья икән ләбаса. Әле чәчелеп-чәчелеп йолдызлар атыла, әле күкне ярып кышкы аҗаган балкып ала. Шунда Җидегән йолдызның алтын бөртекләре күз кысыша. Ялтыр-йолтыр ялтырап, Иләк йолдыздан энҗе-мәрҗәннәр коела...
Хак, җирнең чиге бар, күкнең чиге юк. Гәүһәршад менә шул чиксез күк хәлләре белән мавыгып китте. Аның асылына төшенергә теләүчеләр элек тә күп булган.
Нәсраниләр[1] даирәсе, мәсәлән, җирдәге тормышны күк җисемнәренең торышы билгели дип исәпли. Шуңа күрә төрле фаҗигаләрнең, афәт вә зилзиләләрнең сәбәбен күктән эзли. Әйтик, 1533 елның 24 август көнендә өйләдән соң кояш рәвешен үзгәрткән, имеш: ике ягына ике колак үсеп чыккан, өске өлеше тешләп алынган ипи телеменә охшап калган.
Китек кояш, билгеле инде, фаҗигагә ишарә. Ә дәүләттә кояш белән фәкать патша гына тиңләшә ала.
Бер мәшһүр күрәзәче моны Василий патшаның үлеменә юрый. Үз башына, әлбәттә. Патшаныкы түгел, аның гомере өзелә, усал аюдан тәпәләтәләр.
Василий исә үзен искиткеч яхшы хис итә. Көзге якта җәмәгате, балалары, туганнары белән Троицки монастыренда изге Сергей көнен бәйрәм итү тантанасында катнаша. Ауга йөри, күңел ача. Тик бер көнне чуан аркасында ауны өзәргә туры килә, чөнки ул нәкъ кирәкмәс җиргә, бот төбендә борын төртә. «Бераз вакыт тыныч кына өйдә утырырга туры килер»,—ди табиб. Ләкин шушы вакыт эчендә чуан җәрәхәткә әверелә. Күкрәге дә кыса башлый олуг кенәзнең, сулыш алуы авырлаша. Хәленең мөшкелләнә баруын тоеп, Василий ашыгыч рәвештә Мәскәүгә васыятьнамә артыннан чапкыннар җибәрә. Шөкер, даирәсе алдында кул куярга өлгерә. Ә өченче декабрьда мәңгелеккә күзен йома.
Күрәзәче еретикның фаразы рас килә.
Иран, Харәзем тарафларында да күк җисемнәрен күзәтү белән бик борынгыдан шөгыльләнгәннәр икән. Баксаң, күктәге һәр җисем: кояш та, ай да, йолдызлар да туктаусыз хәрәкәттә ди. Хәтта җир дә. Монысы инде бернинди киртәләргә дә сыймый. Әгәр җир әйләнә торган булса, кешеләр йөри алмаслар, мәтәлешеп бетәрләр иде. Йортлар, абзар-куралар, мал-туарлар, җәнлек-җанварлар—барысы да, барысы да...
Көтепханәче Габбас хәзрәттән күп мәгълүмат алды Гәүһәршад. Ә аның белмәгәне юк.
—Ай тотылуны аңлатып буламы, кеше аның сәбәпләрен белә аламы?—дип сорашты бер очрашуда.

1 Нәсрани – христиан

—Була, ник булмасын,—диде хәзрәт тыныч кына,—мәсәлән, ай кояш белән җир арасына кергәч тотыла. Һәм Ходай кодрәте буенче котыла.

—Ә Ходай кодрәт итмәсә?

—Дөнья бетә,—диде аксакал шундый ук тынычлык белән.

—Ай еш тотыламы?—дип төпченүендә булды Гәүһәршад.

—Аны исәпләп чыгарырга мөмкин, тик ул Аллаһы гамәле...

—Чираттагы ай тотылу кайчан булырга мөмкин, хәзрәт, минем бик беләсем килә,—дип, Гәүһәршад көтепханәчегә үтенечле караш ташлады. Кыяфәте дә элекке һавалы тәнәкә кыяфәтенә охшамаган иде. Әйтерсең лә, йомыш йомышларга килгән ярдәмчесез гади бер кыз-хатын. Хәзрәтнең тәнәкәне шушындый чарасыз хәлдә беренче тапкыр күрүе иде, күнеле йомшарып китте. Ләкин үтенеч тә гадәти түгел бит. Моңа кадәр аның беркемгә дә Күкләргә кагылышлы гыйлемен ачканы булмады, үз эчендә саклады. Хәлбуки, Көнчыгышның Әбугалисина кебек мәшһүр йолдызнамәннәре аны сер итмәгән, ташка басып калдырган. Ул үзе дә шул гыйлем ияләренең хезмәтләреннән белем эстәгән кеше. Бәлкем, тәнәкәнең үтенечен канәгатьләндерергәдер? Күр, ничек нәүмизләнеп карап тора.

—Үтенеп сорыйм, хәзрәт...

Көтепханәче тирән итеп сулыш алып куйды да:

—Гөнаһысы үзенә булыр, тәнәкә,—диде.

—Гыйлем гөнаһ булмыйдыр, хәзрәт.

—Гыйлем гөнаһ булмый, тәнәкә,—диде хәзрәт,—әмма да ләкин гөнаһлы гыйлемнәрдән азат түгел адәм баласы.

Габбас хәзрәтнең исәп-хисаплары буенча ай тотылу Энем кырлач чорына турын килергә тиеш иде. Менә атна-ун көн булды инде, Гәүһәршад төннәрен күкне күзәтә. Бүген башка көннәргә караганда да салкынрак иде. Күзләре яшьләнеп бетте, аякларына суык йөгерде.

Әлеге үҗәтлекнең сәбәбе житди шул. Бу аның гыйрафәт-күрәзәлек сәләтенә бәйле. Моңарчы күңел күзе үзеннән-үзе ачыла иде. Хаҗәте бармы-юкмы, аңа карамый, ачыла да китә. Хәзер исә күңел күзенең ул үзе билгеләгән вакытта, тәгаен зат, тәгаен вакыйга уңаеннан ачылуын тели. Күрәзәче Фагыйлә абыстай исә гыйрафәтлек тылсымы җир тетрәү, күз кабагы ачылу, ай тотылуише төрле табигый зилзиләләр вакытында бермә-бер арта дип әйтеп калдырган иде. Күк белән кызыксынуының сәбәбе менә шушы.

Гәүһәршадны, мисал өчен, соңгы вакытта яшь ханбикәнең язмышы борчый. Чөнки бик тиз халык теленә керде. Абруе арткannан арта гына бара. Хәтта ханның Казан—Мәскәү арасында төзелгән кабалалы килешүне өзүен дә Сөенбикә исеме белән бәйлиләр икән. Эшләр болайга китсә, Олуг Мөхәммәд ыруы белән бәйле Нурсолтан ханбикә, Үрбәт ханбикә, Гәүһәршад тәнәкә кебек мәшһүр татар хатын-кызларының мәртәбәле исемнәрен дә изеп-басып китүе ихтимал бу Кырым килененең. Ә моңа һич тә юл куярга ярамый.

Гәүһәршадның уйлары бүленде. Ник дисәң, урман ягыннан, йөрәккә шом салып, бүреләр улаган тавыш ишетелде. Ни гаҗәп, аларга барча этләр кушылды, абзарда сыер мөгрәп куйды, саташкан әтәч кычкырып җибәрде.

Табылдык та муенын сузды:

—У-у-у-у...

Тәнәкәнең бит очын жил чеметеп алды. Ул аны тоймады, чөнки нәкъ шушы мизгелдә күзе айга төште. Ә ай әллә нишләгән,бизгәк хастәсенә юлыккандай дер-дер калтырангандай итенә иде. Ул, ялгышмыйммы дигәндәй, күзләрен, йөзен уыштырып алды. Манзара үзгәрмәде. Айны

ниндидер үтә күренмәле саргылт элпә каплап бара, бер чите корым яккандай каралып та өлгергән...

Ай тотыла лабаса! Нинди бөек галим икән Габбас хәзрәт. Фаразы дөрескә чыкты бит. Чыкты!

Гәүһәршад баскан урынында аякларын тыпырдатып алды. Куанычы шуның кадәр зур иде ки, хәтта хәзрәтнең: «Аллаһы Тәгалә кодрәт итмәсә, дөнья бетә»,—дигән кисәтүе дә онытылган иде.

—Табылдык, Табылдык,—дип, шатлыгын уртаклашасы итте. Табылдык аны ишетмәде, ул әле һаман улый иде.

—У-у-у-у...

Кинәт кенә җиһан дөм караңгы пәрдә эчендә калды.

—Йә раббым, ошбу колыңа гыйрафәт ачкычлары бир, Сөенбикә атлы ханбикәнең тәкъдир дәфтәрен ачып күрсәт,—дип күккә кулларын сузды тәнәкә,—Ходаем, догаларымны кабул күр, Ходаем...

Караңгылык эчендә тычкан күзе кадәрле генә тоныкнур пәйда булды. Ул зурайганнан-зурая барып, тәрәзә өлгесе рәвешенә керде. Ә эчендә—кала диварлары сүрәте. Каланы танырлык түгел иде. Кая карама, җимереклек, кая карама, хәрәбә. Бер төзек йорт, бер төзек морҗа юк. Әстәгъфирулла! Урам тулы мәет. Ат үләксәләре өстендә козгыннар чукыша. Шунда ук сөңгеләр, кылычлар, калканнар аунап ята. Зур, аяусыз орыш булган монда. Әнә, канаулардан кан ага... Кала бушап калган. Кала үлгән!

Күкләр Гәүһәршадның күңеленә хәбәр салды: « Ун елдан соң Казан каласын шушы язмыш көтә».

—Ходаем, рәхмәтеңнән ташлама...

Хәбәр: «Казан-йорт яшәүдән туктаячак...»

—Ходаем...

Хәбәр: «Ай тотылган төндә...»

Күкләр Сөенбикә ханбикәнең тәкъдир дәфтәрен ачмады. Әмма моның хаҗәте калмаган иде инде. Бу мәхшәрдә ханбикәгә дә, ханга да урын юк. Гәүһәршадның үзенә дә. Башкаларга да. Фаҗигале ай тотылуның шаһиты гына булырга язмасын.

Бу хәбәрне ирештереп, Күкләр аңа хак җәзасын бирде. Чөнки ул алар вазифасына тыкшынырга җөрьәт итте. Җә, Ходай, болай булгач, бакыйга да бәгыренә таш булып утырган шушы хәфевле хәбәр озатачак бит инде.

Аллаһым, түземлекләр бир. Тәнәкә өчен Казан-йортның бетәсен алдан белеп торудан да зуррак бәхетсезлекнең булуы мөмкинме соң?

***

Кырым ханы Сәхибгәрәйдән мәктүп килеп төште. «Иң уңайлы форсатны кулыңнан ычкындырасың бит, нигә тавыш-тының ишетелми»,—дип кисәткән иде ул.

Чыннан да, Мәскәүнең язгы боз шикелле йомшарган чагы, аны кашып алу, ганимәт җыю, әсир төшерү өчен бик кулай вакыт. Агасының шуңа ишарәләве. Ә ул яшь кәләшенең кайнар кочагыннан арына алмый.

—Мине тиз генә көтмә,—диде Сафагәрәй Сөенбикәгә,—син пәри генә түгел, шайтан, чын ир-егетнең урыны яуда.

Шөкер, Кырымнан үзе белән алып килгән яугирлар аның үрнәгенә иярмәгән, хатын күңелен күреп ятмаганнар, гаскәр туплау белән ныклап шөгыльләнгәннәр. Сафагәрәйнең атына кадәр иярләнгән иде, сикереп мен дә яуга чыгып кит. Ул шулай эшләде дә. Җиргә төшкәнче төкрек туңарлык кырлач суыгына карамастан, гаскәрне күтәрде.

—Ганимәтнең дүрттән бере үзегезгә, рәхәтләнеп талагыз,—дип күңелләрен

дә җилкетеп куйды. Ханның бу мәрхәмәтлелеге бик ошады, төрле яктан канәгать авазлар яңгырады:

—Авызына бал да май, хан!

—Сөбханалла, бирсен Ходай.

Бу—1536 елның гыйнвар ае иде. Иң элек Түбән Новгородны тезләндерделәр, аннан соң күршедәге Балахна кирмәненә кызыл әтәч җибәреп, кирәгенчә талап чыктылар. Җәен Костромага бәреп керделәр. Каршылык күрсәтергә дип кылычын кынысыннан алган воевода Засекинның башы шундук җиргә тәгәрәде. Инде Муромга чират җитте.

Казанлылар кайбер төбәкләрдә урыс гаскәре белән хәтта йөзгә-йөз очрашмадылар да диярлек. Чөнки тегеләре куркыныч хәбәр алуга, коралларын, мал-мөлкәтләрен ташлап, кайсы-кайда качып бетә. Һөҗүм ысулы да бик дөрес сайланган иде: башта дошман өстенә иң хәзерлекле, иң каһарман яугирләр чирүе ташлана. Бу ыргым шулай тиз, шулай искәрмәстән башкарыла ки, каршы як капкынга эләккәнен белми дә кала. Алар аңына килеп, коралга тотынганда инде соң була, төп көчләр дә килеп җитә.

Сафагәрәй шушы борынгы татар ысулына җан өрде.

Елина Глинскаяга аерым Казан бәкләренең чик буендагы шәһәр-авылларны талаулары хакында мәгълүмат бер-бер артлы килә торса да, аларга әлләни игътибар итмәде. Хәлбуки, боярлар бу хәлгә бик борчыла иде. Кенәз Бельский хәтта ризасызлыгын ачыктан-ачык белдерергә дә җөрьәт итте. Бу бөек княгиняга ошамады.

—Кенәз, мин дәүләткә куркыныч янавын искә алып, Түбән Новгород янында кирмән кордырдым. Кырым юнәлешендә дә бу эш бара. Нәрсә, син миңа кылыч тотып, чик сакларга чыгарга кушасыңмы әллә?—дип, яшькелт күзләрен чекрәйтте.

—Аллам сакласын, бөек княгиня, бу—воеводалар вазифасы.

—Шулай булгач, нигә мине юкка-барга бимазалыйсың?! Мәскәү урыныңдамы—урынында. Монысы өчен менә мин җавап бирәм.

Елина рәсми рәвештә хөкүмәт башлыгы булып саналса да, бу эшкә сәләте дә, омтылышы да чамалы иде. Ире Василий исән чагындагы шикелле һаман гаилә, кунак, көнкүреш, кием-салым, бүләк мәшәкатьләре эчендә кайный. Аеруча, күп вакытын улы Иоанн белән үткәрә. Баласы атка менсә, анасы ботын кыса, ди. Шуның кебек, Елина да улының һәр хәрәкәтен күз уңында тота. Патша булганы өчен генә түгел, юк, ул аны дуамал ярату белән ярата. Хәтта караучы-тәрбиячеләреннән дә көнләшә иде.

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй,шушы болганчык көннәрдә Кырым ханы Сәхибгәрәй рәсми рәвештә Казан-йорт белән якынлашуын игълан итте. Бу җәһәттән патшага хат юллады: «Казанның минеке булуы белән килешкән, аның халкыннан ясак түләүне таләп итмәгән сурәттә тату яшәргә хәзермен. Әгәр дә мәгәр яу чабарга җөрьәт итәсең икән, бу очракта илчеләренне дә, йомышчыларыңны да җибәрмә: без дошманнарга әвереләчәкбез. Ул чагында урыс җиренә басып керәчәкбез һәм анда барысы да көлгә әйләнәчәк».

Ошбу хәбәрдән бөек княгиняның җене кузгалды: бер селтәнүдә өстәл өстендәге кәгазьләрне, каләм-каурыйларны идәнгә сыпырып төшерде. Хатны тапшырган дьякка кулына эләккән чәркәне тондырды.

—Ул камыт аякның Мәскәүгә мондый ультиматум куярга хакы юк, аңлыйсыңмы, дундук, хакы юк! Ә син, аңгыра баш, миңа, бөек княгинягә, әллә нинди икеле-микеле ярлык төртәсең.

Дьякны әрләп, ачуын басканнан соң, Елина басынкы гына тавыш белән:

—Өйләдән соң боярлар шурасын җыегыз,—диде.

Боярлар шурасы шау-шулы үтте. Глинскаяга да бик нык эләкте. Ул хөкүмәт башлыгы вазифасын кенәз Иван Бельскийга тапшырырга мәҗбүр булды.

Кырымга патша исеменнән хат китте:

«Син Казанны үзеңнеке дип атыйсың. Әмма да син әвәлге елъязмаларга күз төшерер идең. Аларда исә, патшалыкны кем сугышып алган, аңа шул ия диелгән. Шулай түгелме? Аны кемгәдер башкага бирергә мөмкин, тик ул барыбер, иң югары хаким буларак, тәүгесенең карамагында торып кала. Үзеңнең уйдырма хокукларың хакында сафсата сатасың, Русиянең өстенлекле хокуклары турында исә ләм-мим. Казан—безнеке, чөнки аны минем бабам яулап алган. Ә сез—фәкать ялган һәм мәкер ярдәмендә генә вакытлыча анда хакимлек урнаштырдыгыз. Дәхи, барысы да элеккечә калсын. Һәм без, Сафагәрәйнең гаебен онытып, туганлыкта калырбыз».

Казанга дәгъвә итүнең урынлы икәнен исбатлап, урыс хөкүмәте башка теләктәш мәмләкәтләргә дә хәбәр салды: «Мәскәү патшалыгында яулап алган җирләрен кем беләндер бүлешү гадәте юк. Алар килешү-сөйләшүләргә әзер, ләкин казанышларыннан баш тарту исәбенә түгел».

Шуннан соң Казанга егерме биш меңлек урыс явы ябырылды. Урыслар ханлыкка шактый зур зыян салдылар. Шулай да калага керә алмадылар, Сафагәрәйне тезләндерү хәлләреннән килмәде.

***

Чура морза элеккеге гадәт буенча хан капкасыннан чаптырып килгән уңайга гына узып китмәкче иде дә, тоткавыллар сөңгеләрен чәкештереп, юлына аркылы төштеләр. Толпары, сакчылар өстенә менеп китмәс өчен, арт аякларына басарга мәҗбүр булды. Иярченнәре дә көч-хәл белән генә атларын тыеп калды.

—Кем син, әрәм тамак, әллә инде бәкләрегезне танымый да башладыгызмы?—дип, Чура сакчыбашның якасыннан эләктереп алды. Тегесе дә бирешә торганнардан түгел иде, ахры.

—Башлыгында тамга юк, миңа тамгалыларны гына үткәрергә кушылды,—диде,—кире борыл!

Морза тоткавылны күзеннән кичерде. Күзе кара, кашлары кара, сакал-мыегы, чәче кара. Йөзе-бите дә чуен астыннан чыккандай каракучкылланып тора.

Кырым бөҗәге ләбаса бу, күр, ничек хуҗа булмакчы.

—Аһ, син, килмешәк, әле сүз озынайтып торасыңмы?

Чура кылычын суырып чыгарды да атын сакчы ягына борды. Бер селтәнүдә тегенең бүрегә җиргә очты.

—Тотыгыз, кул-аякларын бәйләгез!—дип яралы дуңгыз тавышлары чыгарып акырды тоткавыл кул астындагы сакчыларга.

Алар ишле иде, Чурага чигенүдән башка юл калмады. Алай да:

—Мин сине сөңге очына күтәрәм әле,—дип янарга өлгерде.

Шул кызу белән ул Гәүһәршадның ишеген шакыды.

—Тәнәкә, Кырым олтанына әйләнгәнбез икән ич, безне хәзер сарайга да кертмиләр, тамгаң юк диләр...

Чураның хис-тойгылары кызу утта кайнаган шулпа кебек казанның капкачын алып ташлардай булып ташый иде.

Гәүһәршад морзага казан капкачын үзенә ачып ташларга ирек бирде, бүлдермичә генә сүзен тыңлады. Күренеп тора, сакчыларның үз-үзен тотышлары аны бик нык кимсеткән иде.

—Теге чакта тыймаган булсаң, тәнәкә, мин ул Сафагәрәйне тәмуг учагына озата идем...

—Бәк, киңәшкә килгәнсең икән, минем сүземә дә колак сал,—диде Гәүһәршад. Ләкин сүзен башларга өлгерә алмыйча калды, бүлмәгә гадәттәгечә шыпырт кына Булат бәк килеп керде. Киенгән-ясанган, туп итеп тора, бер-бер очрашуга җыенган иде булса кирәк.

—Әссәламегаләйкем, бичәм, хәерле көн, сөбханалла, бик күркәм күренәсен,—дип хатынының аркасыннан сыйпап алды. Шуннан соң гына кунакны сәламләде.

—Исән-сау гына йөрисенме, морза, бу араларда иркенләп сөйләшеп утырган да юк, эш-мәшәкать басып китте,—диде.

—Син бит түрәбаш, ханның иң якыннарыннан,—дип, Гәүһәршад иренә мөрәҗәгать итте,—морзага аңлатып бир әле, ни өчен каланың мәртәбәле бәкләрен сарай катына уздырмыйлар?

—Чак кына тоткын итмәделәр,—дип өстәде Чура.

—Үзегезгә дә мәгълүм ләбаса, Сафагәрәй мине күз буяу өчен генә тота, казанлылар да идарәдә катнаша, янәсе. Хәзер Кырым белән басалар, Кырым белән изәләр. Сарай алар кулында. Анда безнең сүз үтми.

—Сафагәрәй тәхетен ныгытты, барысын да үзенчә эшли, минем белән инде күптәннән киңәш-табыш иткәне юк,—дип, тәнәкә дә бәкнең сүзен куәтләде.

—Эт симерсә, иясен тешли ди,—диде Булат бәк.

—Нәрсә көтәбез соң?—дип Чура морза урыныннан сикереп торды.

—Һәр гамәлнең үз вакыты бар, алманы да пешкәч кенә өзәләр,—дип тынычландырырга ашыкты Гәүһәршад.—Хан читтәге хәлләр белән артык мавыга, эчке хәлләргә кулы җитми. Теләге дә юк шикелле. Безнең файдага гына бу.

—Шулаен шулай да...

—Сафагәрәй кулы белән без Мәскәүне тышауда тоттык, Казан-йортта төрки-татар рухын саклап кала алдык. Ул да үз вазифасын үтәде,—дип дәвамлады тәнәкә,—хәзер исә безнең өчен Кырымның да, Сафагәрәйнең дә хаҗәте калмады. Без моны кичәге дошманыбыз—Мәскәү ярдәмендә тормышка ашырачакбыз.

—Әллә кайчан кирәк иде,—дип, Чура морза учын учка бәргәләп алды,—ух, мин аны, килмешәкне...

—Артык шашынма әле, морза, Сафагәрәй Җангали генә түгел, биле каты ул егетнең.

***

1541 елның җәендә баш карачы Булат бәк Мәскәүгә иң ышанычлы иярченнәреннән саналган морза Чабыкаев җитәкчелегендә илчелек җибәрде. Ул ярлыгында, олуг кенәз Сафагәрәйгә каршы гаскәр җибәрсә, ханны кулга алып, Мәскәүгә озатачакларын ышандырган иде. Ләкин, һич көтмәгәндә, Иван Бельский хөкүмәте яшәүдән туктады, бу урынга килгән кенәз Шуйский тәвәккәллек күрсәтә алмады. Дөресрәге, ирек бирмәделәр. Хөкүмәтне тавыш-гауга, ызгыш-талаш баткагына тартып керттеләр.

Гәүһәршад, үз көчен саклау ниятеннән, Сафагәрәйгә теләктәшлек күрсәтергә мәҗбүр булды.

—Бу вакытлы чигенү генә, форсат чыгуга, без, һичшиксез, ханлыкны янә Олуг Мөхәммәд сызган эзгә төшерү өчен көрәшне дәвам иттерәчәкбез,—диде тәнәкә,—хәзергә, урыслар әйтмешли, сарык тиресе ябынган бүре хәлендә яшәргә туры килер.

—Анадан күлмәкле килеш тугандыр ул мөртәт,—дип тузынды Чура Нарык,—алашасы да колынлыйдыр, валлаһи...

—Артында Төрек белән Кырым торса, синең алашаң да колыннар иде,—дип көлемсерәде Булат бәк.—Сүзендә дә тора белә Сафагәрәй, мине, әнә, өнәмәгәнемне белә торып, һаман баш карачы итеп тота.

***

Ханның җәйге утарын танырлык та түгел иде. Анда бик тиз арада ике катлы купшы сарай калкып чыкты. Мәчетнең эче-тышы яңартылды. Башка корылмалар да йөзләрен үзгәртте.

Боларның барысында да Сөенбикәнең кулы уйнады. Шулай да ханбикәнең иң зур мактанычы бакча иде. Элеккесеннән анда бер агач та калмады диярлек. Ул аны Көнчыгышның иң бай солтанатлары үрнәгендә яңабаштан утырттырды. Нинди генә куаклар, нинди генә чәчәкләр юк монда? Тауҗыклар, субөркегечләр, күперчекләр—һәммәсе үзенә бер зәвык белән эшләнгән. Шул ук вакытта, табигать тә табигыйлыгын саклап калган, монда хәтта кереп адашырлык ешкынлыклар да бар.

Бу әкияти үсемлекләр, чәчәкләр дөньясында кыр кәҗәләре, боланнар, пошыйлар, читтән кайтартылган әллә нинди матур җәнлекләр яши. Кошлары тагын күпме: йөзүчеләре дә, чумучылары да, сайраучылары да...

Сөенбикә бакчасын бик ярата. Еш кына Сафагәрәй белән дә шушында очрашалар. Бүген дә сүз куешканнар иде. Ләкин никтер соңара, Сөенбикә инде борчыла башлады, менә күренер, менә күренер дип сузыла-сузыла карана торгач, муены талып бетте.

—Белеп кил әле, хан берәр җиргә китеп бармадымы икән?—диде сакчы яугиргә,—тиз ура, бер аягың монда, икенчесе—анда булсын...

Сакчы ерак китә алмады, хан йомышчысы белән йөзгә-йөз бәрелештеләр.

—Ханбикә галиҗәнаплары, хан белән очрашу кичектерелә, миңа шуны хәбәр итәргә куштылар,—диде йомышчы.

Ханбикәнең кәефе тәмам кырылды. Шулай булмыйча, бик сагынып көткән иде ич, иренең яраткан ризыкларын пешертте, урын-җирләрне яңартты. Үзе дә куана-куана хәзерләнде. Мунча керде, кырыкмаса кырык үлән суына кәрәзле бал кушып ясалган төнәтмәләрдә генә ярты көн ятты. Авызымнан ис килмәсен дип көне буена тәгам капмады. Югыйсә бик мәгънәле очрашу иде бу. Кавышуларына биш ел ләбаса! Сафагәрәй үзе дә хуп күргән иде...

—Сәбәбен җиткердеме?

—Хәзрәте Зәйнәп бикә вафат,—диде йомышчы морза.

—Ничек вафат?..

—Йокысыннан уянмаган...

Җир җимертеп йөреп тора иде ич әле, алма кебек чагы.

Алар бер чама. Сөенбикә аңардан бер генә ел алданрак туган.

—Хан мәрсия белән мәшгульмени?

Сөенбикә бу урынсыз соравы өчен кыенсынып китте.

Бер караганда шатлык, икенче караганда...

Сөенбикәнең көндәше иде Зәйнәп. Сафагәрәйнең башка җәмәгатьләре, хәтта якташы, ханның аңа кадәрге иң яраткан бичәсе Хәдичә бикә дә анда көнләшү тойгылары уятмый. Өлкәне Кырымны арттыра алмый, уллары Бүләк белән Мөбарәкне хубрак күрә. Җәй урталарында бер күренеп китә дә, шуның белән вәссәлам. Өлкән хатын вазифаларын Хәдичә ханбикә башкара. Чебеш анасыдай сарайдагы хатын-кызларны үз канаты астында тота. Мәҗлесләр җыю, Коръән ашлары үткәрү, бәйрәмнәр оештыру—барысы да аның күзәтчелегендә. Себердән төшкән Айтүкә бану аралашуны сөйми, үз даирәсендә үзенчә яши. Усал, кыргый. Ир чиратын да үткәртми, хан үзе дә аннан шүрләбрәк тора, ахры, сүз әйттертми.

Зәйнәп арада иң чибәре, иң дәртлесе, иң затлысы иде. Сафагәрәй, чираты җитеп, Зәйнәп катына барган көнне, Сөенбикә үз-үзенә урын таба алмый җәфаланыр иде. Чөнки Зәйнәп ир күңелен күрә белә иде. Оялу, кыенсынуны

белми. Һәм бу кылану түгел, аның табигый халәте иде.

Зәйнәп нәсара өммәтеннән. Кенәз кызы. Муромга яу чапканда әсир төшкән иде. Төнге чәчәк шикелле янып торган, кылгандай саргылт чәчле, зур зәңгәр күзле бу туташны Сафагәрәй бер күрүдә ошатты, хатыны итте. Шул рәвешле Зинаида Зәйнәпкә әверелде.

—Яңа исемне кабул итәм, синең гореф-гадәтләреңне дә үтәргә сүз бирәм, әмма динемне алыштырмыйм,—диде Зинаида,—мин нәсара булып туганмын, шул калебемдә үләргә дә тиеш.

Сафагәрәй ризалашты.

Зәйнәп ханга бер ул бүләк итте. Тик кәнизәкнең (чөнки никахы юк) улы ханлыкка кагылышлы хокуклардан мәхрүм. Сафагәрәйнең турыдан-туры варислары Кырымда яшәүче уллары. Казан тәхетенең төп дәгъвачесе олы ул Бүләк.

Варис дигәндә, Сөенбикәнең йөрәгенә кан сава. Монысы Зәйнәп белән көндәшлектән дә хәтәррәк иде. Сафагәрәй белән никахлашуына биш ел үтте инде, ә ул һаман йөккә узмый да узмый. Әллә, тьфү-тьфү, Аллам сакласын, кысыр булып туган инде. Югыйсә кардәш-ыруларында өй тулы бала.

Бик кимсенә Сөенбикә. Өстәвенә, ярасына тоз сибүчеләр дә хәтсез. Гәүһәршад тәнәкә, әнә, җае чыккан саен чеметкәләп кенә тора, беркөн: «Баласыз хатынга—имчәк әрәм», дигән төрттермә сүз җибәрде.

Ул үзе өметен өзми, Ходайның рәхмәте киң, боерган булса, бердән-бер көнне аның урамына да бәйрәм килер. Сабырлыкны гына җуймаска кирәк.

Зәйнәпнең матәм йоласын Сафагәрәй зур төгәллек белән үтәде. Сөенбикә катында да, шул сәбәпле, кырык көннән соң гына пәйда булды. Хикмәт йолада гына да булмагандыр, мөгаен. Чөнки урыс гаскәре янә Казанга яу белән килде. Дөрес, бу юлы да Мәскәү ымсынудан узмады.

Бер килсә, килә бит ул. Урысларны куып җибәрү шатлыгын да татырга өлгермәде, баш шымчы калада фетнә тәгаенләнеп килүен хәбәр итте.

—Урысларны Булат бәк төркеме яу белән килергә котырткан дигән фараз бар,—диде Сафагәрәй хатынына,—аны юлдан алып ташларга вакыт җитте, ахры. Син моңа ничек карыйсың?

Сөенбикәнең уе башкада иде. Сагынган иде ул ирен. Шулай булмыйча, кырык көн күрешмәделәр ләбаса!

—Җә?

—Минме... мин...

—Әйе, син,—диде Сафагәрәй хатынына текәлгән хәлдә.

Бу таләпчән караш Сөенбикәне айнытып җибәрде.

—Белүемчә, Гәүһәршад тәнәкә сүзе сүз алар арасында,—диде икеләнебрәк.

—Беләм, тик алтмышны узган ханымны дар агачына асып куя алмыйм ич инде мин. Аннан соң, тәнәкә рухи җитәкче, гамәлләрне Булат бәк оештыра.

—Казан тәхетенә сине алар утыртканны да онытма,—дип кисәтте Сөенбикә,—шулар ук безне дә кавыштырды.

—Әйе, куып та җибәрделәр, чакырып та китерделәр, өйләндерделәр дә... Ә хәзер Казан-йортны саклап калу турында сүз бара, ханбикә,—диде Сафагәрәй сүзләрен бастырыктай бастырып,—бу очракта элекке игелекләр исәпкә алына алмый...

—Гәүһәршад тәнәкә дә ханлыкны яшәтү ягында дип беләм.

—Әлбәттә... ләкин минсез, синсез... Ә минем тәхетемне саклап каласы килә.

—Димәк, кан?

—Кан, ханбикә!

***

Гарасат башлануга, Гәүһәршад өстерәлә-өстерәлә тышка чыкты да, таягына асылынып кына диярдәй, бакча эчендәге ялгыз тирәк тарафына юнәлде. Гасәбә хатын култыгыннан алмакчы иде дә, аны янбашы белән этеп кенә җибәрде.

—Кагылма, үзем генә барам!

Бу сүзләр Табылдыкка карамый, алар инде энә белән җеп шикелле бербөтенгә әверелделәр. Маэмай хуҗабикәсеннән тотам да калмый. Гәүһәршад та Табылдык дип кенә тора, чөнки ул аның бердәнбер сердәше, әңгәмәдәше, дусты хәзер.

Җил белән тартышу авыр иде, әмма Гәүһәршадның телләргә кергән мәшһүр үҗәтлеге соңгы вакытта шактый какшаган сәламәтлегеннән дә өстенрәк иде, күрәсең. Абынгалап-сөртенгәләп китсә дә, атлавын дәвам итте.

Һәм, ниһаять, тирәкнең бака кабырчыгы кебек кытыршы кәүсәсенә килеп сөялде.

Бу ике-өч буын кеше гомерен яшәгән тирәк. Биниһая юан. Аны колачлау өчен өч-дүрт кешенең дә колачы җитмәс иде, мөгаен. Ә үзе әле һаман ямь-яшел булып купыраеп утыра. Күр, авыз абыстайларның күлмәк итәгедәй кабарынкы ябалдашын ничек салындырган.

Хәер, ерактан купшы булып күренсә дә, тәнен яра-җәрәхәтләр сызгалап бетергән иде шул тирәккәйнең. Эче умарта оясыдай бушап калган. Аерым урыннары көеп, кара күмергә әйләнгән. Болары яшен галәмәте. Ел саен ике-өч мәртәбә яшен суга аны. Каныкты аңа яшен.

Гәүһәршад үзе дә монда яшен эзләп килде.

—Бисмикәллаһүммә әхйә үә әәмутү... Раббым, ошбу җиһанда һәммә нәрсә Синең иркеңдә, ал минем җанымны, кучер бу колыңны бакыйга, җибәр яшенеңне...

Коры гарасат озакка бармады, дулап-дулап яңгыр ява башлады. Күк тәмам кызган иде, күрәсең, дөбер-шатыр килеп җиргә берөзлексез утлы түкереген чәчә.

Гәүһәршад күзен йомган хәлдә тирәккә сөялгән. Көтә. Әҗәл көтә. Бер-ике мәртәбә яшен җиле өттереп тә алган кебек булган иде. Ләкин нигәдер камчысы читләтеп үтте.

—Ходаем, ал җанымны...

Гәүһәршад гомере буе Казан-йортның саф татар иле булып калуын теләде, шуңа гомерен багышлады. Берничә дистә елга сузылган аяусыз көрәш утында кайнады. Астыртын, хәйләле, чигенү-ташламалы, җиңүле-җиңелүле көрәш иде бу. Анда еш кына дус дошманга, дошман дуска әйләнә, янә бутала, әле син өстен чыгасың, әле дошманың. Әмма болар көрәшнең кыйпылчыклары гына, төп максат һәрвакыт үзгәрешсез кала бирә. Ул гүя ки якты йолдыз, барыр юлны яктыртып, рухландырып, ымсындырып тора.

Менә шул йолдыз сүнде. Фирка тар-мар ителде. Булат бәкне үтерделәр, ә аны урман эченә, утарына сөрделәр. Ханлык тулысы белән кырымлылар идарәсенә күчте. Инде Сафагәрәйнең бүресе улый. Яшәүнең мәгънәсе бетте. Ул җиңелде.

Казан белән элемтәсе өзелгәнгә дә шактый. Янына беркемне китермиләр дә, беркемне чыгармыйлар да. Хезмәтчеләре биш-алты кешедән артмый, тәмам хәерче хәленә төшерделәр.

Үзендә дә гаеп бар, Мәскәүдә дә. Мәскәү үз ыгы-зыгысына кереп батты, ярдәм дигәннәре сүздә генә калды. Ә фетнәчеләр исә ныгып өлгергән хан кирмәнен җимерер дәрәҗәдә түгел иде.

Бу соңарган үкенеч инде. Ул хәтта хәләле Булат бәкнең ничек кулга

алынуыннан да хәбәрдар түгел. Каберен күрсәтүләрен сорагач, мыскыллап көлделәр генә, янәсе, сатлык җаннарның кабере булмый.

Чынында да, Булат бәкнең кабере юк иде. Ул өйләдән соң юкка чыкты. Бүлмәсендә эшләп утырганда йомышчы морза кереп:

—Хан галиҗәнаплары сине күрергә тели, ашыгыч сүзе бар,—диде.

Баш карачы аяк өсте генә әйтелә торган мондый ашыгыч сүзләрне өнәми иде, борынын җыерды. Ләкин тыңламый да булдыра алмыйсың.

—Хәзер баш салымчы килер, көтсен,—дип, ярдәмчесен кисәтте дә китеп барды.

Хан катына барып ирешмәде Булат бәк, юл уңаенда дүрт-биш углан көтеп тора иде инде. Тавыш-тынсыз, сүзсез-нисез генә тотып алдылар да, авызын каплап, бер бүлмәгә өстерәп керттеләр. Берсе шунда башына чукмар белән орды...

Ул ниндидер ярымкарангы, шыксыз алачыкта уянып китте.

—Күзен ачты,—диде йөзенә салкын су коеп торган углан.

—Урындыкка утыртыгыз!—дигән әмер яңгырады.

Ерактан ишетелгән әлеге тавышны таныды бәк. Мондый карлыккан, бөер тавышы белән сарай даирәсендә бер генә адәм сөйләшә. Ул да булса, баш шымчы Хәмзә бәк, ханның иң ышанычлы алпары. Кансызның кансызы, аны кырымлылар хәтта үзләре дә җәллад дип йөртәләр иде.

Булат бәк, тән сызлавын басып, канлы авызыннан соравын төкерде:

—Барча Казан җиренең баш карачысын шушылай мәсхәрәләргә ничек батырчылык иттең, Хәмзә бәк?

Шымчының очлы ияге дер-дер калтыранып алды. Бу аның көлүе. Тавышсыз гына көлә белә ул. Булат бәк күрмичә дә моны бөтен үпкәбавыры белән тоеп-сизеп торды.

—Хыянәтче син, баш карачы,—диде шымчы ясалма сүрәнлек белән.

Рәхим-шәфкатькә өмет итәсе юк икән, дип уйлап куйды Булат Ширин. Ул уйларын уйлап та бетермәде, Хәмзә кырт кына борылды да, шул кызу белән бәкнең эченә типте.

—Хыянәтче, ал кирәгеңне, анаеңның кабер тактасы...

Булат бәкнең эчәгеләре өзелеп төшкәндәй булды, «лып» итеп идәнгә ауды. Аны янә урындыкка утырттылар.

—Бөтен өерегезне таш капчыкка эшереп керттек, берәм-берәм Газраилга биреп торачакбыз. Аңладыңмы, баш карачы? Ха-ха-ха...

Хәмзә янә йодрыкларын уйнатты. Кулы каты иде, бер сугуда Булат бәкнең алгы тешләрен коеп төшерде. Аннан ярдәмчеләренә борылды:

—Вазифагызга керешегез!

Баш карачыны әүвәл хан мәйданында, халык алдында җәзага тартырга теләгәннәр иде. Шунда бер акыллысы дөрес киңәш бирде:

—Казан халкы, ай-һай, бу тамашаны кабул итәрме икән? Ул бит үз кеше. Ә без барыбыз да кырымлылар, аларча әйтсәк, килмешәкләр. Дөрес гамәл булмас бу.

Сафагәрәйнең янак сенерләре уйнаклап алды, килмешәк сүзен яратмый иде ул. Әмма кисәтүне дөрес дип тапты.

—Тәнәкәне бүген үк урман эчендәге утарына сөрегез, калган хыянәтчеләрнең барысын да үлем җәзасына хөкем итәм,—диде боз чапкандай кистереп,—озаклап, интектереп җәзалагыз, газапланып үлсеннәр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам дә хәдисләрендә, җиһад аяусыз булырга тиеш, дип әйтеп калдырган.

Ике-өч көнгә сузылган җәзалаулардан соң чи ит бүкәненә әверелгән Булат бәкне кыргый ат койрыгына тагып, төнгә каршы далага чыгарып җибәрделәр...

...Яшен тынды, җил болытларны Идел аръягына куып алып китте, күк йөзен ачты.

—Табылдык, киттек,—диде Гәүһәршад.

Алар аллы-артлы яшел чирәм өстендәге күлләвекләрне лычтыр-лычтыр китереп, өй ягына тәпиләделәр.

Ул башка үлем эзләп йөрмәде, гадәти тормыш белән яши башлады. Ишеккә сыймастай булып тазарды, элекке зифа буй-сынлы, чибәр тәнәкәнең эзе дә калмады. Кытайлардан кадәр көзгә кайтартып, өен затлы көзгеләр белән тутырган бикәнең үз шәүләсен күрмәгәненә дә бишбылтыр. Хәер, күрсә дә ул үзен танымас иде инде.

Күрәзәчелекне ташлады, Күкләр карары белән дә килеште. Хак, анасын югалткан корт күче дә яшәүдән туктый бит. Казан-йорт та шул хәлдә, чөнки аңа нигез салган Олуг Мөхәммәд нәселенең тамыры корыды.

***

Казан янә бер мыжгып алды. Гәүһәршад чәчкән хөррият орлыклары биргән шытымны алай җиңел генә казып ташлау мөмкин түгел иде, билгеле. Көрәш аләмен бу юлы Боерган сәед, Кадыш бәкләр күтәреп алды. Нindидер могҗиза белән хан шымчылары тырнагына эләкми калган Чура морза әле һаман «Кырым килмешәге»нә ахирәт күлмәге кигезү турында хыяллана иде. Җае килгән саен:

—Тәнәкә ирекка куймады, теге вакытта ук җанын кыя идем мин аның,—дип уфтана.

Боерган сәед бик озак баш ватып, абруйлы төп-тамыр Казан адәмнәре белән киңәш-табыш итешкәннән соң, дәүләт язмышын үз кулына алу максатка ярашлы булыр, дигән нәтиҗәгә килде.

—Тәхеттән үз иркең белән баш тартасыңмы, әллә бәреп төшергәнне көтәсеңме?—дип, ханга ярлык юллады.

Бу—1546 елның 15 гыйнвары иде.

—Сарай фетнәчеләр кулындамы?—дип белеште Сафагәрәй.

—Синең җавапны көтәләр,—диде баш фарраш.

—Җыеныгыз!—дип әмер бирде Сафагәрәй,—без әле урап кайтачакбыз.

Ул бабасы Йосыф би бусагасына кайтып егылды. Мансур сәед тә шунда иде. Аңа ияреп Хаҗитарханга китте, ярдәмгә бер чирү гаскәр теләнеп алды.

—Казанда теләктәшләрем күп, мине шәһәр капкасын ачып каршы алачаклар,—дип ышандырды. Тик ике ай таптанып торса да, Боерган сәед җитәкчелегендәге вакытлы хөкүмәт аны калага якын җибәрмәде.

Мәскәү бу хәлдән файдаланып калырга ашыкты, Казанга илчеләр җибәрде.

—Буш мичкә дә коргаксый, тәхет иясе булганда гына ил имин торыр,—диде мәскәүлеләр,—Шаехгалине сорый идегез, патшабыз Иоанн хәер-фатихасын бирә.

Июльнең уннченче көнендә Шаехгалигә хан бүреге кигезделәр. Шул хөрмәткә барлык чәйханәләрдә керүчеләрне бушлай сыйладылар. Халык разый-бәхил булды.

Шаехгали морадына ирешә.

Берәү таба, берәү югалта ди, Сөенбикә әнә кара кайгыда. Баласын бик тә Казанда табасы килгән иде. Әйе, әйе, иң изге теләге тормышка ашты лабаса. Ниһаять, Сафагәрәй белән никахлашканнан соң тугыз ел үткәч, авырга узды. Шатлыгының чиге юк иде. Шулай булмыйча, инде өметен җуя башлаган иде ич. Утыз яшьтә аның ишеләр оныклары белән куана. Ә ул «кысыр күркә» кушаматы тагып йөрергә мәҗбүр иде.

Казан каласында туган ханзадә (ул, әлбәттә, ир бала алып кайтыр) ханлыкның кануни хакиме булачак, атасы сыман «килмешәк» тамгасы тагып йөрмәс.

Ханбикәнең бу татлы хыялларын фетнәчеләр томан урынына таратты. Әлеге хәлнең нинди зур фаҗига икәнен ул бөтен тулылыгы белән көймә ярдан кузгалып киткәч кенә аңлады. Сафагәрәйнең Казанга яу чабуы да көткән нәтиҗәне бирмәде. Шунда Сөенбикә беренче мәртәбә ризасызлыгын сиздерде.

—Ирнең ире ком өемен тау итә,—диде икәүләп кенә чәйләгән вакытта. Чынлыкта бу ирен булдыксызлыкта гаепләү иде.

Сафагәрәй кинаяны үз ягына борды. Чынаягын өстәл читенәрәк шуыштырып куйда да:

—Ике бөртек яугир белән яуны отып булмый шул,—дип, үзе дә төрттерәсе итте. Бу аның Йосыф бинең гаскәр бирмәвенә үпкәсен белдерүе иде.

—Атакай белән үзем сөйләшеп карыйммы, рөхсәт итәсеңме?—дип сорады Сөенбикә.

Сафагәрәйнең шома маңгаена беленер-беленмәс кенә сырлар ятты.

—Бу хәлдә фәкать нугайлар ярдәме белән генә тәхетне кире кайтарырга мөмкин, ханбикә,—диде,—чөнки Кырым турыдан-туры булыша алмый, ул күтәрелсә, Мәскәү кузгалачак. Төркия... Эш зурга китәчәк. Һәм аларның берсен дә безнең язмыш ныклап кызыксындырмый. Бердән-бер тотка—Нугай, туганлык мөнәсәбәтләре...

—Яраткан кызыңның көмәне борынына җитеп килә, синең хәбәреңдә дә юк, атакай,—дип, Сөенбикә бер уңайлы мизгелдә назлана-назлана Йосыф морзага елышты.

—Сөбханалла, кызым, бу оныгымны барысына караганда да ныграк көтеп алам, нахак сүз сөйләмә,—диде би,—Ходай җинеллекләр бирсен.

—Минем улымны Казанда табасым килә,—дип назлануын белде булачак ана,—без синең ярдәмеңә бик тә, бик тә мохтаж, атакай...

Йосыф бәк кызына озак кына сынап карап торды да:

—Ай-һай, хикмәт чыгармы икән, бер талпынып карады бит инде,—диде.

—Ике бөртек яугир белән яуны отып булмый шул,—дип Сөенбикә иренең сүзләрен кабатлады.

—Алайса, әйт, ханны чакырсыннар,—диде Йосыф би.

—Мин арыдым инде, атакай, бераз ятып торам, калганын үзегез сөйләшеп бетерегез,—дип елмайды Сөенбикә.

—Һи, бәбәлән йомыркасы...

Сафагәрәй Казандагы теләктәшеннән хәбәр алган иде, бине шунын белән таныштырырга ашыкты.

—Калага урыс гаскәрләрен кертмәгәннәр, җирле гаскәр таратылган хәлдә, аларны җыярга вакыт кирәк. Сарайда фәкать тоткавыллар гына ди, һөҗүм өчен иң уңайлы вакыт.

Йосыф морза өй эчен тутырып төчкереп җибәрде, хәтта тыштагы этләр дә буылып өрешергә тотындылар.

—Йәрхәмүкәллаһү,—диде Сафагәрәй,—Аллаһ һәрвакыт таянычын булсын.

—Аллаһ безгә дә, сезләргә дә һидаят итсен, юлың уң булыр, әлхәмдүлилләәһ.

Икәве дә дога укып, битләрен сыпыргалап куйдылар.

—Амин!

—Амин!

***

Гәүһәршаднын җилкәсенә Һома кошы килеп кунды. Һома—изге кош. Ул кеше күзенә чалынып йөрми. Аны күрүчеләр күк капкагы ачылуын багу куанычына ирешкәннәргә караганда да сирәгрәктер, мөгаен. Чын могҗиза иясе, күләгәсе төшкән бәндә гомерлек бәхеткә тиенә, имеш.

Гәүһәршад аны таҗыннан таныды. Таҗлы кошлар бер ул гына түгел, билгеле, алар күп. Һоманың таҗы исә үзгә, аның таҗы кояш сыман, тирә-якка нур чәчеп тора.

—Сөбханалла!

—Әссәламегаләйкем, тәнәкә,—дип телгә килде Һома,—таныдыңмы?

—Кошны таныдым, тавышын танымадым.

—Чура морзаны да хәтерләмисеңме?

—Кош сурәтендәге Чура морзаны хәтерләмим,—диде Гәүһәршад озак кына уйланып торганнан соң.

—Әрвахлар төрле сурәттә була, тәнәкә, бүген менә кош сурәтендә...

—Әрвахларны бакыйда дип белә идем,—дип гаҗәпләнде Гәүһәршад.

—Мин шул бакыйдагы әрвахларның берсе инде, тәнәкә.

—Ничек?

—Син хәбәрдар түгелсең, ахры, Сафагәрәй өченче мәртәбә тәхеткә утырды бит. Боерган сәед Казанга Шәехгалинең гаскәрен керттермәде, үзебезнекеләрне таратты. Дога, гыйбадәт, вәгазь, рухи туганлык булган җирдә хәрбиләрнең дә, коралның да хаҗәте юк, янәсе. Дин әһеле бит. Моны Сафагәрәйгә җиткергәннәр. Ә ул бабасы Йосыф бидән гаскәр алып, калага ташланды. Янә суеш, үтереш башланды. Мине, Кадыш бәкне Булат карачы шикелле ат койрыгына тактылар... Житешкәннәр Мәскәүгә качып китте. Үзең беләсең, күпме кыҗырап йөрдем мин ул Кырым килмешәгенең гомерен өзәргә. Теләгемә ирешә алмадым. Әнә, күрәсеңме, күпме кош очып йөри? Болар барысы да Сафагәрәй кулыннан үткән корбаннар...

—Мине дә үзегез янына алырга килдеңме?—дип сорады Гәүһәршад.

—Синең урының безнең янда, тәнәкә,—диде Чура морзаның Һома кош сурәтендәге рухы,—Казан-йорт бетте, ул инде Кырым-йорт.

—Тиздән Мәскәү-йортка әвереләчәк,—диде Гәүһәршад,—югыйсә, без барыбыз да татарлар... уртак тел генә таба белмибез... хәзер соң инде...

***

Бу хаста Гәүһәршадка кергән бихисап чуалчык төшләрнең иң ачыгы, иң мәгънәлесе, иң соңгысы иде. Күзе башка ачылмады. Шул ук көнне аны ялгыз тирәк төбенә күмеп куйдылар да оныттылар.

Табылдык кына югалтуны авыр кичерде. Ашаудан калды, гаме бетте. Ә бер атнадан үзе дә хуҗабикәсенең кабере өстендә җан тәслим кылды.

Тәнәкә вафатына каршы төндә Сөенбикә ир бала тапты. Казан кануни варислы булды.

Монысы инде бөтенләй башка кыйсса...

*2007-2008.*



Салават
Рәхмәтулла

# МИНЕМ ТАВЫМ

***

*Һәр шагыйрьнең үз тавыдыр...*
Роберт Миңнуллин

**Җырлы-гармунлы туган як,**
**шигырьле туган авыл:**
**минем дә тавым бар монда—**
**Очлытау дигән тау ул.**

**Түбәсенә менеп бассам,**
**җырлар ургылды җаннан.**
**Ләкин... Уфа да,**
**Казан да**
**күренми торды аннан.**

**Эстәрле—күренде.**
**Киттем**
**балта салып биштәргә:**
**төзүчеләр кирәк икән**
**«Бөек төзелешләр"гә!**

**Төзүче эше дә җырга**
**лаек икән, чыннан да.**
**Уфа да,**
**Казан да никтер**
**күренмәде моннан да.**

**ВУЗда белдем (бу кадәрле**
**белер идем кайларда?!):**
**Казан—Иделләрдә икән,**
**Уфа—Урал-тауларда.**

---

Салават РӘХМӘТУЛЛА (1942) — *Башкортстанда (Эстәрлетамак шәһәре) яшәүче татар шагыйре; татар һәм башкорт телләрендә дөнья күргән берничә китап авторы.*

Балта тота белгән куллар
каләм дә тотты әле
(Каләм тота белмәгәннәр
Кулга да сукты әле...).

Уфага да, Казанга да
шигырьләр китә торды:
Минем шигырьләрне алар
китаплар итә торды!..

Шагыйрь таулы була. Өмет
юк таусыз калганнардан.
Очлытавымның түбәсе
күккә тигәндер—күренгән
Уфадан, Казаннардан.

...Кайтып, Очлы тауга менсәм—
җырлар ургыла җаннан:
Петербурглар,
Мәскәүләр
күренә хәзер аннан.

***

Җәйләремдә яңгырлары яуса
һәм карлары яуса кышымда,
Шатлыкларым арта:
минем өчен
дөнья коты гүя шушында!

Җәйләремдә яңгыр яумый калса,
яумый калса карлар кышымда,
Хәсрәтләрем арта:
минем өчен
дөнья йоты гүя шушында...

Бер—дәртләнәм, бер хәсрәтләнәм мин,
бер—шатлык, бер хәсрәт килгәндә...
Җирем буйлап барам:
әйтерсең лә
дөнья тоташ—минем җилкәмдә...

## Күп тормабыз без...

Үзгәрттек тә—кордык илне!—
"Хөррият!"—ди көллебез:
Эчә авыл, эчә кала,
Эчә тоташ илебез!

Хәмерен эчеп, дәүләтне
Без бар итеп тотабыз:
Халыкның социаль хәлен
Илкүләм «нығытабыз!..

...Бил тиңентен хәмердә без,
Муеннан батачакбыз:
Баткач... гасырлар буена
Чыгалмый ятачакбыз.

Һәм... чыгалмаячакбыз да,—
Иш янына куш булды:
Эчкечеләр сафларына
Наркоманнар кушылды...

...Без китәрбез бер, тик илдә
Балалар торасы бар:
Киткәнче... илне кабаттан
Үзгәртеп корасы бар...

***

Йөрәгем—ут: утлы сөю белән
Сине сөйдем! Сөям!..
Ни бар соң?!
...Гайбәтчеләр гайбәтләрен җыйдың:
Әйдә, хәзер... хөкем чыгар син!

Хөкемеңнең иң катысын чыгар:
Утларга сал...
Бозда илерт син...
Зинданнарга ташлат—йөзеңне дә
Күрсәтмичә... мине тилерт син...

Себерләргә башны олактырт та,
Урман кистерт...
Ташлар ваттырт син...
(Бәлки әле, декабристкалардай,
"Тоткының"ны күреп кайтырсың...)

...Көннәр арты—кичләр килеп торыр,
Төннәр узар—таңнар сызылыр.
Тулысынча «акланырмын» берчак!
Тик... йөрәгем ул чак...
Боз булыр!..

***

*(Шаяру катыш)*

...Эт-эт булып кына яши:
Тешли һәм өрә белә.
Ә кеше...
Ә кеше менә
Мең төскә керә белә.

Бер карасаң—бүре була,
Бер карасаң—елан ул.
Бер карасаң...
Изгеләрдән
Изге җан ул—болан ул...

Куян була,
Аю була,
Төлке була белә ул!
Аттай, тешләрен ыржайтып,
Кешни-кешни көлә ул...

Үзе булып яши алмый,
Кеше ул...

Нинди бәндә?!—
Бу сорауга төгәл җавап
Биралмый әле фән дә!..

Җирдә Кеше булып яшәү—
Иң авыр шөгыль бит ул!
...Эт ник елан булып чакмый?
Ник?..—
Кеше түгел бит ул!..

***

Ныклы гына уйланмыйбыз,
Уйлансак ныклы гына,
Зарланыр сәбәп юк сыман
Тукайлар юклыгына.

Урыста да Лермонтовлар,
Пушкиннар тумый ел да.
Тукай да күктән төшмәгән—
Бер Апуш булган ул да.

«Йөз, ике йөз ел буена
Бөекләр тумый",—дибез:
Пушкин, Лермонтов, Тукайны
Аллаларга тиңлибез.

Аллалар жирдә яшәми,
Һәм Аллаһ... берәү—күктә!
Бөекләр Җирдә туалар,
Тумыйлар ләкин күп тә.

Ләкин—һәр чорда туалар,
һәр чорга—алар терәк.
...Бөекләрдә Тукайлыкны,
Пушкинлык, Лермонтовлыкны
Күрергә генә кирәк!

## Юк бит...

Кимсеттеләр кеше алларында,
Кимсеттеләр түрә кешеләр
(Туры әйтсә, хәтта туганнарын
Дошман итеп күрә кешеләр...).

Власть—үзләрендә: бәреп әйтсәм,
Әллә ниләр чыгар алардан...
Тешләремне кысып, чыгып киттем
Җыелышлар барган заллардан.

...Пирчәткәләр ташлап, шулар белән
Атышасы иде дуэльдә!
Эх...
Кеше намусларын яклый торган
Законнар да юк бит бу илдә...



Гөлчәчәк
Галиева

# ГАЗЗӘБАНУ

РОМАН

*Ир бирмәк—җан бирмәк*
(татар халык мәкале)

Газзәбану карчык инде ничәмә-ничә еллар һәр намазыннан соң көндәше рухына дога кыла. Моны ишетеп йөргән студент кыз—Саяра аптырап гаҗизләнә. «Белеп кылган вә белми кылган гөнаһларын ярлыка, урынын җәннәттә әйлә, бер Аллам!» ди бит әле, житмәсә. Көнгә биш вакыт, рамазан айларында тәравих намазы да өстәлгәч, алты намаз була ич әле ул. Ә Саяра үзе, көнчелегеннән, сабакташы Назирәне хәтта куралмый башлады инде. Әле күптән түгел генә иң якын дусты иде канә. Көндәшлекләре дә ташка үлчим генә юкса... Икесе дә яшертен генә бер егетне—Рәүфне яраталар. Ә Рәүф дигәннәре бердәнбере итеп кайсын сайлар бит әле, анысын хәзергә бары бер Аллам Үзе генә беләдер.

Менә бүген дә Газзәбануның ястү намазыннан соң «хәләл җефетем Нургали белән көндәшем Маһирә рухына»,—дип әйтә генә башлавы булды, көнчелек чире белән агуланып өлгергән кызның түземлеге тәмам төкәнде.

—И-и-и-ий, шартлыйм, билләһи! Кем инде синең шикелле көндәше рухына көненә биш-алты мәртәбә дога кылып утыра, йә?! Көнләшү дигән нәрсәнең кыйпылчыгы да булмаган ахры синдә, әбекәй.

—И-и, жаным, нинди булмаган ди ул... Бик беләсең килсә, мин алардан әле хәзер дә көнләшәм...

—Вәйт әкәмәт! Әллә кайчан җир куенында ятканнардан ничек итеп көнләшергә кирәк? Сәе-ер...

—Бер дә сәер түгел, кызым, аңлаган кешегә. Алар теге дөньяда да бергә... Ә мин бу дөньяда һаман берүзем, япа-ялгыз каз шикелле каңгырап йөрим.

Кеше хәлен кеше белми үз башына төшмәсә, дип әйтмәсләрие аны. Мин күргәннәрне Аллам берәүгә дә күрсәтмәсен, балакаем. Тынла әле,

Гөлчәчәк ГАЛИЕВА—*язучы; «Тулгак», «Өзелгән өмет», «Күңелемә якын затлар» китаплары авторы. Казанда яши.*

бер кыйсса сөйлим үзенә: көндәшемә Нургалием белән бергә йоклар өчен ак келәтне, юынырларына мунчаны елый-елый юып чыгардым. Нишлим, әнкәй шулай кушты. «Кече килене алай бик кадерле булгач, үзен ю»,—дип бик әйтәсе килде-килүен... Соныннан үзе дә кереп карагач, шаккатты.

—Сүбхәәналла, и унган да инде үзең. Мунчаң да, келәтең дә кояштай балкып тора. Бу юлы бигрәк агартып югансың дип әйтимме... Әллә селте суыннан шулай агардылар микән?—Болай ук булыр дип көтмәгән, күрәсең, әнкәй бик шат иде.

—И-и-и, әнкәй, мин синең урыныңда булсам, бәлки өзлексез түккән күз яшьләреннән ачысыннан шулай агаргандыр алар, балам,—дияр идем, дип үпкәмне белдердем.

—Яра-а-ар, вакыты җиткәч, шул ялт итеп көлеп торган мунчага беренче булып кемнәр керде дип уйлыйсың инде син? Һич уйламаганда, көтмәгәндә Нургалием белән үземә керергә насыйп булган икән бит, җаным. Көндәшем Маһирә апаң үзе шулай хәл итте дә куйды, рәхмәт төшкере! Өстәвенә ак келәтне дә Нургали белән безгә калдырып, үзе өйдә, чаршау артындагы караватка ятты. Менә шулары өчен генә дә мин аны догамнан калдыра алмасыем, җаныем.

—Абау, әбекәй, торып-торып аптыратасың ич... Ничек инде? Шул йортның төп хезмәтчесе, ирennән законный хатыны була торып, үзең яккан мунчага, үз ятагыңа әллә каян кайткан көндәшеңнең рөхсәтен көтеп торырга? Хурлыгыңнан шартларсың, билләһи! Синең урыңда мин булсаммы?.. Күрсәтерием мин аңа күрмәгәнен: чәченнән өстерәп, артына тибә-тибә куалап чыгарган булыриемен мин ул оятсызны,— дип Саяра ярсып ук китте.

—И, кызыкаем, яшь-яшь башыңнан каян килә сиңа шулкадәр усаллык, ә? Синең бит әле оясыннан яңа гына очып чыккан кош баласы кебек самими чагың. Күнелеңә ямьсез уйлар, тәмсез сүзләр салырга бик иртә өлгергәнсең түгелме соң, балакаем? Йомшак, изгерәк күңелле булуга ни җитә! Мондый гадәтең сине беркайчан да яхшыга илтмәс. Ничек тә йомшаграк, юмартрак булырга тырыш. Күңел юмартлыгы үзе бер бәхет бит ул, беләсең килсә.

—Менә синең күңелең гел изгелектә булган да бит, әбекәй, бәхетле иттеме соң ул сине? Юк бит, юк. Сөйгән ярың да уртак булган, ике малай үстереп, картлык көнеңдә япа-ялгыз яшисең, яныңда бер оныгың гына да юк бит ичмасам... Бөтенләй чит кешеләр кулына калгансың...

—Ах, ялгышасың бит, Саяра, ихлас әйтәм, ялгышасың... Әлхәмдүлилләһи шөкер, берсе дә чит кеше түгел. Араларында минем ярдәмгә мохтаҗлары да табылып кына тора. «Сулышың шифалы» дип күз тигәннәрне, җен зәхмәте кагылганнарны өшкерергә мине чакыралар. Кул-аяк буыннары тайганнарга да ярдәмем тия. Авыр күтәреп эчләре төшкән хатын-кызларга чүлмәк салырга да мине йөртәләр. «Кулларың шифалы, файдасын күрдем, бик килеште»,—дип күпме рәхмәт укыйлар. Аллаһының биргәненә шөкер, бәхет түгелмени бу?

Саулыгымнан да зарлана алмыйм: күзләрем күрә, колагым ишетә, аякларым йөри, кулларымнан эш килә. Коръәнне рәхәтләнеп укыйм, сораган кешегә юрганын да сырып бирәм, җамавымны җамыйм. Барын да күзлексез эшли алам бит әле. Авызымдагы утыз ике тешемнең утыз икесе дә үз урынында. 77 яшемә җитеп теш сызлауның, теш суыртуның ни икәнен дә белмәдем монарчы. Ризыкның—катысын да, йомшагын да рәхәтләнеп, тәмен белеп ашый алам. Йә, бәхет түгелмени бу?

Ил-күз алдында дәрәҗәмне дә төшермәдем, мең шөкер. Миңа игелек кылучыларның берсен дә, син әйткәнчә, чит кешеләр дип санамыйм, туганнарым ук булмасалар да. Авылда Коръән ашларында, бәби чәйләрендә, кода-кодагыйлар төшерү мәҗлесләрендә, монарчы һәр йортта урыным түрдә булды. Үзең күреп торасың, мин монда да кадер-хөрмәттә. Кәримә апаң

мине үз анасы кебек тәрбияли, Аллаһының рәхмәтләре яусын аңа. Бөтен Тукай урамындагылар миңа адарынып, сәдака китерә. Тормышның ачысын күбрәк татысам да, мин үземне бәхетсез карчык дип санамыйм, Саяра кызым. Тагын алда ни күрәсе бардыр, анысын бер Аллам Үзе беләдер...

Каенанам әйтмешли, «Ач үтермә, тук үтер, кыш үтермә, җәй үтер». Аз сырхау, тиз үлем бирсен, Аллаһы Тәгаләм рәхмәтеннән ташламасын. Ә сиңа, Саяра кызым, теләгем шул, бәхетле була күр. Укы, морадыңа ирешерлек булсын! Аллаһы Тәгаләм сине дә яраткан ярың белән кавыштырсын, көндәшлек ачысын күрсәтмәсен!— дип янәшәсендә утырган Саяраның аркасыннан сөеп куйды Газзәбану.

—Рәхмәт, әбекәй. Ә миңа күнеленә тупас кагылганым өчен үпкәләмә, яме. Шулай да ачыклыйсы килгән тагын бер соравым туды бит әле. Миңа теләк теләгәндә «көндәшлек ачысын күрсәтмәсен» дидең, Амин! Шулай гына була күрсен! Ә сезнең ике арагызга ничек көндәш килеп керде соң?

—И-и, жаныкаем, егерме беренче елгы ачлык кына харап итте безне. Шул елны Нургалием, дусты Нурислам белән бергә, бераз акча эшләп кайтырбыз дип Ташкин каласына китте. Күп булса өч-дүрт ай торырбыз дигәннәрие. Яз да үтте, көзләр дә җитте, «кайтабыз» дигән хәбәрләре юк та юк. Шөкер, анысы акчасын, әйбер-сәйберләрен, азык-төлеген дә җибәреп тордылар үзләре. Инде моннан соң озакламаслар, кайтып җитәрләр, дип кенә йөргәндә, Нургалинең үзе эшләгән кибет хуҗасының кызы белән никахлашуы турында хәбәр килеп төшмәсенме... Һа-ай, ул коточкыч хәбәрне ишетеп өнсез калганнарым, кара кайгыда керфек тә какмый йокысыз узган төннәрем исемә төшсә, йөрәккәем әле дә булса, нәкъ шул вакыттагыча, сызып-сызып сулкылдый башлый. Ни бетмәгән сулкылдаудыр инде ул? Чыдаса да чыдый икән бу йөрәк дигәнең... Ул көннәрдән соң юкса алтмыш еллап вакыт узса да, йөрәгемдә калган шул җәрәхәттән әле дә булса кан сава. Мондый гомер буе газап чиктергән, сагыш утларында яндырган, ачыдан-ачы хәсрәтне дошманыма да теләмәсием. «Ир бирмәк—җан бирмәк» дип әйтмәсләрие шул аны. Бу әйтемне, нишләптер, безнең әби шактый еш кабатлый торганые. Ул аны болайрак итеп: «Ил бирмәк—кан бирмәк, ир бирмәк—җан бирмәк» дия иде. Безгә һич аңлашылмый иде ул чакта. Беркөнне абыем белән әбидән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатуын сорадык. «Нинди кан? Кемгә, нәрсәгә бирергә?» дибез. Ул җавабында: «Илгә яу килгәндә бик күп бәндәләрнең каны коелу турында ул. Ә инде иреңне чит-ятларга бирәсең икән, бусы инде җан бирүгә тиң хәсрәтне аңлата. Тормышыгызда бу мәкальдә әйтелгәннәр берүк улым сиңа, кызым Газзәбану сиңа да, кагыла күрмәсен, Раббым Үзе сакласын!»—дип әйткәлидерие ул. Юк шу-ул, юк, әбекәебезнең теләкләре кабул булмады. Фәрештәләрнең «Амин» дигән сәгатенә туры килмәгәндер инде, күрәсең... Абый сугыштан гарип булып кайтты, энекәшләрнең берсе хәбәрсез югалды, икенчесенең үлгән хәбәре килде. Ә үземә, җиләк күк чагымда бит... «Ирең өстеннән өйләнгән, инде авылга кайту турында уйлап та карамый икән...» дигән иләмсез хәбәрне ишетергә язган булган икән. Шул вакытта: «И Раббым, ичмаса үлгән дигән хәбәре килсә, бу кадәр үк тә авыр булмасые», дип җир тырмашып елаганнарым һич онытылырлык түгел. Үлгәннең үкенече зур булса да, хурлыгы юк бит аның. Үлгән артыннан үлеп булмый дип, тол калган хатын хәлендә яшәүне артыграк күргән чакларым да исемдә әле. Ә иң гарьләнгәнем—әткәйләр Нургалинең өйләнеп йөргәнен миннән алдарак ишеткән булып чыкты. Әмма авызларына су капканнар диярсең, берни дә сиздермичә, тыныч кына йөрүләрен белделәр. Уларының өйләнүләренә үзләре үк хәер-фатиха бирмәделәр микән әле дигән шик туды миндә. Аларны да күралмый башладым. Инде нишләргә, кая барып бәрелергә, әллә үземнекеләргә кайтып китәргәме? Төннең төн буена керфек

тә какмыйча, әнә шундый уйлар белән изаланып чыга идем. Ниһаять, бер карарга килеп, таң беленер-беленмәстә шыпырт кына урынымнан тордым да, туп-туры әтиләргә юл тоттым. Унбиш чакрым араны ничек үткәнмендер... Үзебезнең өйгә килеп җиткәнче күз алдымда гел Нургалием булды. Ана әйтәсе бөтен үпкә сүзләремне җылый-җылый тезеп бардым. Юлда эт тә юк. Әткәйләрнең дә тетмәсен теттем. Күбрәге әнкәйгә эләкте, билгеле. Ничектер, тынычланып киткәндәй булдым. Әмма капка төбендә минем якка карап торган әнине күрү белән тагын элеккеге хәлемә төшеп, күз яшьләремә буыла-буыла аңа таба йөгерә үк башладым. Ул да кулларын җәеп каршыма атылды, минем киләсемне белеп көтеп торган диярсең.

—Ни булды, балам? Кичә көне буе нигәдер эчем пошканые аны... Төнем төн булмады, йокы да алмады, җанымны кая куярга белмичә бәргәләнеп чыктым. Җитмәсә атаң: «Үзең дә йокламыйсың, миңа да йокы бирмисең, нәрсә дип шулай бимазаланасыңдыр инде...»—дип мырылдап теңкәмә тиеп бетте.

—Әллә нинди изге якларың бар шул синең, әни. Көтмәгәндә башларыма төшкән кара кайгымны Аллаһы Тәгаләм сиңа да сиздергән, күрәсең. Әйтсәм әйтим инде, әни, киявегез өстемнән өйләнеп йөри икән бит. Локман абзый кызы белән никахлашып, шуларга йортка кергән ди.—Әйтә башлаган сүзен дә тәмамлый алмыйча, Гәззәбану үксеп елап җибәрде. Көтелмәгән күңелсез хәбәрдән һәм кызын жәлләүдән Сәгыйдә каушап калды. Бары тик теш арасыннан гына нәфрәтләнеп: «Һай, йөзе кара булгыры, мәлгунь җан...»—диде дә, кызына кушылып ихтыярсыз кычкырып ук елый башлады.

Бу тавышка сискәнеп, ишегалдында чуалган Ибраһим да капкадан килеп чыкты.

—Бу нинди гарасат, нигә улыйсыз? Бөтен авылны җыясыз бит, пычак кергерләре...—дип икесен дә җилтерәтеп өйгә алып керде.—Таң тишегеннән син нишләп монда, кызым? Кодалар белән бер-бер хәл юктыр бит?

—И-и-и, атасы, кызмале син, үзе генә күтәрә алмаслык ачы хәсрәте китергән аны безнең янга. Әнә, киявең Ташкинда өйләнеп ята икән бит, йөзекара. Ә без монда ник кайтмый да ник кайтмый дип аптырап йөрибез.

—Әти җаным, болай булгач, кайтмаячак инде ул. Миңа нишләргә? Ташланган хатын, артык кашык булып ул йортта яшисем килми,—диде дә әнисе күкрәгенә капланып, Газзәбану янә үкси башлады.

—Җитте сезгә... Ниткән сүз ул, ул йортта яшисем килми имеш, җитмәсә анаң да, чүбек баш, үз сөягебез үзебездән артык түгел, кайт кызым, үз өеңә, дип әйткәндер әле. Күңеленә авыр алма, кызым, мин сиңа ата булсам да, бу сүзне, кызым, әйтә алмыйм. Кискән икмәк кире ябышмый. Абый, энекәшләрең яшәгән бу йортта син инде киселгән икмәк. Синең үз йортың бар, ул—балаң туган йорт. Нигә әле үзеңне анда артык кашык дип саныйсың. Эш аты бит син ул йортта. И, кызым. Ил-күздән әзрәк гыйбрәт ал, дус кызларың Хатирә, Мөнәвәрә, Сәрбиҗамал, күршеләребез Гатиятулла, Гаптелбарыйлар өй эчләре белән ачлыктан шешенеп бетеп гүр иясе булдылар. Авылыбызның ярты халкын бала-чагасы белән алып китте бит ул каһәр суккан ачлык. Шул Нургали кияү аркасында гына яшәп ятабыз бит әле. Шөкер, сине яраткач, безне дә ташламады. Ашаган җиренә сыер да кайта, кияү дә кайтыр, Алла боерса, менә күрерсең. Дөрес, мин аны берәр мәткә тапты ахры бу егет дип шикләнгәли башлаганыем, кәнишне. Ә ул хуҗасы кызына ук өйләнеп ята икән, шилма... Бәлки, шулай кирәк булгандыр, кызым. Сезгә дигән өлешне күбрәк каеру җаен карыйдыр, кем белә? Аннан соң, кызым, Нургалиең япь-яшь, өрлек шикелле тап-таза ир кеше ләбаса. Ничек диләр әле: «Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә». Алар туклар, анда җиләк-җимеш, кавын-карбыз дачурты. Монда гына ул ирләр бичара булып, өрәккә әйләнеп беттеләр. Чыкмаган җаннары гына калды бит инде. Шуларның кайсысы гына

үзен ир кеше итеп сизәдер, бичаралар... И, бу ачлык. Син, кызым Газзәбану, сабырлыгынны жуймале. Ачуыннан Нургалиенә үзеңнән биздерерлек итеп хат яза күрмә тагы. Кода-кодагыйга да «малаегыз тегеләй, малаегыз болай», дип ычкындыра күрмә. Аларга илтифатлырак булырга тырыш, чыраенны бозма. Тешләренне кысып булса да түз. Болай да югалтканнардыр инде үзенне, тизрәк балаң янына кайт, каената-каенанаңа елыш.

—Һай, атасы, таштыр синең йөрәгең, валлаһи, таштыр. Әле генә килеп кергән баланы инде куа ук башладың. Жүнле ата булсаң, «Бер генә кич булса да кунып кит, балакаем, безнең янда аз булса да кайгыларың таралып торыр»,—дияр идең. Әти рөхсәт итсә, иртәгә иртүк китәрием, ди. Ташуның да иң көчле чагына туры киләчәк бит ул хәзер. Төне буе йокламаган, никадәр юл үткән... Йөзенә бер күтәрелеп кара, ичмасам, бөтенләй сулыгып калган бит... Башына төшкән ачыдан-ачы хәсрәте белән бездән башка кемгә барсын инде ул. Үзе дә бала гына бит әле.

—Бу кадәр чүпрәк баш булсаң да булырсың икән, Сәгыйдә. Бала, бала имеш... Кызың үзе бала анасы бит инде... Күкрәк баласы—Хафизы нишли икән анда? Ими көтеп елап яткан баланы ник уйламыйсың син? Кодалар нишләтергә белми азапланалардыр. Кызыңның бу сансызлыгы кодалар алдында безне дә оятлы итә дип борчыласы урынга...

—Ярар, мин гомер буе чүпрәк баш булдым инде. Син акыллы, рәхимле ата булып, бәлки аны үзең илтеп, кодаң белән тыныч кына сөйләшеп тә кайтырсың. Куптәннән күрешкәнегез да юк. Газзәбануга да кайтып керү жинелрәк булыр...

Әмма ата кеше кырт кисеп: «Үзем да йөрмим, сине да жибәрмим, ничек килгән, шулай кайтып та китәр. Жәлләгән булып әллә син аңа файда эшлисенме? Каенана-каенатасыннан узып йөрмәсен, чәенне эчерсәң эчер дә, абыйсы белән жингәсе кайтып житкәнче озат үзен»,—диде дә өйдән үк чыгып китте...

Их, әти, соңгы өметемне да кистең бит... Инде миңа нишләргә генә кала сон??? Сезнең янда әзрәк эчемне бушатырмын, килгән килеш бәлки кунып та китәрмен, тегеләрне да бераз хафага салырмын дип уйлаган булдым тагы. Яшь бала белән иза чиксәләр, каенатам да эзли чыкмый калмас. Бәлки әле, мондадыр дип уйлап, мине алмага килер дип тә өметләнгән булдым тагы. Сезгә аркаланып булса да... Үз атаңа шулай кадерсез булгач, кайнештән нәрсә көтәргә кала? Әтине шуның кадәр үк каты бәгырьледер дип уйламый идем...

«Хәерчегә жил каршы дигәндәй, монда кадәр килеп, әни, сине кайгыга батырып калдыру гына булды бит әле бу. Ярый, бик бетерешмә инде. Нишләмәк кирәк, өлешемә тигән көмешем... Язмыштан узмышлар юк диләр бит. Юк, юк... чәй дип тә әйтмә... Әтинең «чәе» дә бугазымда мәңге китмәс төер булып калды. Ярый, әни, мин килгәнне жингиләргә әйтеп тә торма»,—диюгә әни үзәкләре өзелердәй булып:

—Балам, бәгыръ кисәгем, зинһар, безгә рәнжемә, сабырлыгынны жуйма. Атанны да анларга тырыш. Ничекләр генә кайтып житәрсең икән, балакаем, Аллага тапшырдык. Олы күпердән чык, йәме, кечкенәсен ташу баскандыр инде...

Әниемнең никадәр генә мине озата барасы килсә дә, әти сүзен хаклаптыр инде, капка баганасыннан ары уза алмады. Әле дә булса күз алдымда аның өзгәләнеп елап калганнары...

## Исән йөрсә, бер кайтыр...

Өч-дүрт айга дип чыгып киткән Нургалинең соңгы хаты килгәнгә дә ярты ел узып бара. Әтисе киткәндә туып кына калган уллары Хафиз да өч яшен тутырып килә. Бу өч ел Газзәбану өчен ялгызлыкның ачы газаплары,

тирән сагышлары белән иксез-чиксез озын-озак елларга әйләнде.

Күрше Нурисламның бүген иртүк кайтып төшкәнен ул каенанасыннан ишетте.

—Килен, Нурислам кайткан ди. Үзенең кергәнен көтик микән, әллә үзебез генә кереп чыгабызмы? Нургалидән хат-мазар булса да алып кайтмый калмас, хәлләрен тизрәк беләсе ие.

Бу хәбәрдән Газзәбанунын йөрәге чыгып төшәрдәй булып дөпелди башлады. Кинәт кенә башы әйләнеп китте. Чак кына мич кырына ябышып өлгерде. Каенанасы аның бу халәтен сизмәде дә кебек, әллә сизеп тә сизмәмешкә салындымы?..

Авырлык белән генә булса да, тора-бара ул үзен кулга алды. Әмма Нурисламны бик күрәсе килсә дә:

—Әнкәй, бар әле, үзең генә кереп чык. Әткәй абзар-кура тирәсендә генәдер, икегез бергә керсәгез дә әйбәт булыр. Мин бала янында гына калыйм әле. Без юкта уянып китсә, йә куркып елый башлар,—дигән булды.

Каенанасы чыгып китүгә, Газзәбану, күнелендәге авыр хатирәләрдән кузгалган давыл өермәсенә ирек куеп, үксеп елап җибәрде.

Нурисламның бәйләнүләре генә җитмәгән, хәтта ахирәте-Сажидәсенә кадәр:

—Газзәбану җаным, ахирәткәем, зинһар, тынла сүземне, тик рәнҗи генә күрмә, яме. Нурислам сине күрдеме, бөтенләй әллә нишли, күзен дә алалмый ул синнән... Минем ул эшкә күптәннән инде ярамаганымны үзен дә беләсең ич. Нурислам көн дә: «Китәм, башка түзәр хәлем юк,»—дип җанымны ашый. «Синнән авыр ис килә, шунда ук күнелем болгана башлый»—дип яныма да ятмый бит. «Мин китсәм дә, Газзәбану ахирәтең сине ташламас әле, исән булсам, ярдәм кылучыларыңның берсен дә буш итмәм. Син мине тоткарлама инде»,—ди. Анда аның никахлашкан ук булмаса да, кемедер бардыр дип шикләнәм. Янадан китсә, синең Нургалиең шикелле никахлашып та куяр дип куркам. Борынгыларның «Ир бирмәк—җан бирмәк» дип әйткәннәрен син үзең татыдың бит инде, үзем үлсәм дә, кызым әтисе янында булырые. Әле чыкмаган җанда өмет бар, дигәндәй, Алла кушып, терелермен дип тә өметләнәсем килә. Ахирәткәем, әгәр син Нурислам белән, сирәк кенә булса да бергә булгаласаң, билләһи газим, ул Ташкинына кире китмәсие, дип уйлыйм.

—Их, Сажидә, син мине кем дип белдең? Әллә инде миннән көнләшеп ятасыңмы? Үз акылыңдамы соң син? Мин сездә еш булам икән, Нурисламың янына түгел, юк вакытларымны бар итеп, сиңа ярдәм итәргә дип керәм. Әгәр дә бу сүзләреңне мине сынар өчен генә булмыйча, чынлап әйтәсең икән, син моның ахырын уйлап карыйсыңмы, юкмы? Ахирәтеңнән көндәш ясамакчы буласыңмы? Син әле көндәшнең нәрсә икәнен белмисең шул. Көндәш—көндәш инде ул... Менә мин, зур гөнаһ икәнен белсәм дә, көндәшемә еш кына хәтта үлем теләгән чакларым да була. Тели белсәң теләк—белмәсәң имгәк, диләр. Аллам Үзе сакласын, газиземә бирмәсен! Әгәр авызыңнан тагын мондый сүз чыгарасы булсаң, мине бар дип тә белмә! Валлаһи дип әйтәм, бусагаңнан да атлап керәсем юк...

***

Әйе, күп тә үтмәде, Нурислам китте. Хатларын да, ярдәмен дә җибәреп торды үзе. Әнә үлә—менә үлә дип торган Сажидә дә аякка басып килә. Инде кәҗәсен дә үзе сава башлады. Ире дә кайткач, аягы җиргә дә тимәс инде, өзлегеп китүдән Аллам сакласын.

Нургали турында Газзәбану ни уйларга да белмәде. «Нәрсә булды соң безнекенә? Әллә үз күзләрем генә тиде инде? Чамасызрак соклана идем шул, бигрәк бер килмәгән җире юк бит. Киенеп куйса да, ялангач

калганчы чишенеп ташласа да, карап та туялмый идем үзенә. Күзләремне оятымнан гына читкә алган булырыем. Ходаем, нинди генә гөнаһларым өчен җәзалыйсын икән мине? Мәхәббәтебез дә Сажидәләрнекенә караганда күпкә көчлерәк тә, хислерәк тә иде бит югыйсә. Дүртебез генә кич утырган чакларда, Нургалинең мине тоташка назлап торуыннан Сажидә бераз көнләшеп тә куя иде шикелле. Ә хәзер мин алардан көнләшеп утырам түгелме соң? Тәүбә-тәүбә, әстәгъфирулла, гөнаһ җыюдан Үзең сакла!»—дип өзгәләнде хатын.

Ире турында берәр хәбәр ишетәсе килсә дә, Нурислам янына керергә хурланды, кимсенде Газзәбану. «Мин кемнән ким, кызлар күк матур чагым. Егерме яшемдә генә булсам да, тач Нургалием төсле таза, матур малай үстереп ятам бит әле»,—дип уйлап куйды.

Күрше-күлән дә аны яратып «безнең Газзәбез» дип кенә йөриләр. Ил-күз каршында да яман аты чыкмады. Авылдагы барлык яшь киленнәр арасында иң тыйнак, сабыр, ягымлы булуы белән аерылып тора. Чибәрлеге, эшкә унганлыгы ягыннан да аңа тиңнәр бу тирәдә юктыр, мөгаен. Тик Нургалинең, Газзәбану өстеннән өйләнеп, өч ел буе кайтмый йөрүен авыл халкы да аңлый алмады. «Шул җүнсезнең коткысына бирелмәгән булса, малай да атасы янында, үзем дә ир канаты астында булырыек. Әнкәй дә миннән көнләшеп, әткәйне таламасые»,—дип, Газзәбану үзе дә иренең читкә китүен Нурисламнан гына күрде.

Әллә әнисенең артык борчылып, үкси-үкси елавы тәэсир иттеме, Хафиз елап уянды. Өйгә килеп кергән Зариф абзый, килене белән оныгының ачыйгыланып елап утыруларын күргәч, ни әйтергә дә белмичә каушап калды. Ана белән баланың бергә үзәк өзгеч елавыннан тетрәнеп, көч-хәл белән генә:

—Бу ни хәл? Ни булды сезгә?—дип кенә сорый алды.

—Күрше Нурислам кайткан, безнеке тагын ю-у-к...

—И-и, балакайларым, шул гынамы? Бөтенләй котымны алдыгыз бит. Әллә ниләр уйлап бетердем. Исән генә булсын, исән йөрсә бер кайтыр, Алла боерса. Йа, Раббым, рәхмәтеңнән ташлама! Барыбызга да күркәм сабырлык бир! Бигрәк тә бу ике балага күтәлмәгән шатлыклар индерсәниe. Аларны Хозыр Ильяс канаты астында йөртә күр!

Каенатасының бу сүзләреннән бераз тынычлана төшеп, ана да, бала да елаудан туктадылар.

Ул арада, зур гына төргәк күтәреп, каенанасы—Зөлкамал кайтып керде.

—Аллаһының биргәненә мең шөкер, Нурислам безгә дә күнелле хәбәр алып кайткан. Тиздән безнең Нургали дә кайта икән. Хафиз улым, әтиең сиңа тәмле мәмиләр җибәргән. Тизрәк сүтик әле бу төргәкне, хаты да шунын эчендә,—диде Нурислам.

Иренең кире әйләнеп кайтуына өмете киселеп барган Газзәбану өчен моннан да сөенечлерәк хәбәр булырга мөмкинме соң?!.

—Әнкәй җаным, авызыңа бал да май! Кайчан кайтам дигән, төгәл генә әйттеме? Нигә Нурислам белән бергә кайтмаган? Шәт, бөтенләйгә кайтадыр инде, име? Бөтенләйгә кайтам дигәнме?

Зариф абзый төргәкне карчыгыннан үз кулларына алды да, күнеле тулудан ахры, сүзен дә әйтә алмыйча, беравык тынып калды. Ниһаять, «Бисмилла» әйтеп төргәкне өстәлгә куйды һәм тегелгән урыннарын килененә сүтәргә кушты. Үзе, яшь тулы күзләрен күрсәтмәс өчен, оныгын кочагына алды. Ә Газзәбанунын бөтен уе—төргәктәге хатны тизрәк табып уку иде. Хафиз, бабасыннан ычкынып китеп, өстәлгә үк менеп утырды.

Ниһаять, ике такта чәй арасыннан хатлар да килеп чыкты. Газзәбану үзенә дигәнен күкрәгенә кысып, икенчесен каенатасына сузды. Икесе дә, читкәрәк китеп, хат укырга керештеләр. Ә Зөлкамал карчык, улы Нургалигә

рәхмәтләр укый-укый, бүләк-санак һәм күчтәнәчләрне карый башлады.

—И-и, ки-ле-н, менә сина Нургалиен нинди затлы, матур күлмәк җибәргән, ә мина иллә дә матур шәлъяулыгы, бабайга түбәтәй, әллә алтын җепләр белән чигелгән инде, рәхмәт төшкере! Карагыз әле, Хафизына дигәнен аерым төргән, балакаем. Сүз тынлап алып кайткан Нурисламга да Аллаһының рәхмәтләре яусын инде.

Газзәбану бу сүзләрнең берсен дә ишетмәде. «Маһирә белән икәү кайтырга булдык. Анын барыгызны да бик күрәсе килә, улым Хафизны бигрәк тә»,—дигән урыннарны укыгач, тораташтай катып калды. Әле генә тулган айдай балкып торган нурлы йөзен, әйтерсең лә, кара болыт каплады. Хатны укып бетерергә дә көче җитмәде. Хат тоткан куллары хәлсезләнеп аска салындылар. Анын сүнеп калган күзләре кинәт уенчык ат белән уйнап утырган Хафизга төште. Сабый кулындагы кәнфитен чеметеп каба да, аннары уенчык атын сыйламакчы була. Баласының шатлыктан балкыган йөзенә дә Газзәбану битараф калды. Тик каенанасының күчтәнәчләрне бүлгәләп: «боларын табынга үзләре кайткач куярбыз, Аллаһы боерса»,—дип әйткән сүзләреннән айнып киткәндәй булды. Бигрәк тә «үзләре кайткач» дип аерата шатланып әйтүе Газзәбануның йөрәгенә агулы ук булып кадалып, аны бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Өч ел буена күңелендә бөялеп торган үпкә-ачулары ташкын булып, тышка ыргылдылар.

—Их, әнкәй, мине килен итеп төшергәндә синең болай куанып йөргәненне бер дә хәтерләмим. Бүген мина үч итеп шулай кыланасындыр инде. Төптәнрәк уйлый алсаң, минем дә хәлемә керериең. Син дә бит—ир хатыны. Яшең иллегә җитсә дә, әле әткәй белән бер түшәктә йоклап, миннән көнләшеп маташасың, адәм көлкесе. Әгәр кеше-кара ишетсә, миннән түгел, әнкәй, синнән өмет өзәчәкләр.

Моңарчы әллә һаман хат укып, әллә инде укыганга гына салышып тыныч кына утырган Зариф абзый түзмәде, телгә килде.

—Ки-лен ! Газзәбану! Сабыр, балам, сабыр! Сыер дуласа, аттан яман, дигәндәй, гомер кыланмаганны, нишләвен бу? Әнкәң сине каршылаганда да шулай ук куанып йөрде, оныткансындыр гына. Никадәр кырыс холыклы булса да, кешегә үч итә торган гадәте юк анын. Ул бит ана кеше... Өч ел буе күрмәгән бердәнбер улы кайта. Ник ике ягына ике хатын утырып кайтмый, анын әлегә анда эше юк. Алты баладан бердәнбер исән калган Нургалие кайта бит... Ана кешенең бу шатлыгын күпсенеп утырсаң, Аллаһы Тәгалә әллә ни бирер. Тфү-тфү, әйттем исә кайттым. Нинди генә хәлдә булсаң да, олы кешегә—иреңнең анасына каты бәрелүең бер дә ярый торган эш түгел. Инде җаным, үзең дә әни кеше ләбаса, Аллаһының биргәненә шөкер. Тик безнең күк сезгә дә бер бала белән генә калырга язмасын. Бер бала—ярты бала. Гомер буе аның өчен ут йотып яшисең.

—Үгет-нәсыйхәтең өчен рәхмәт, әткәй. Кызыбрак киттем бугай шул. Нишләмәк кирәк, алар кайтып төшкәнче мина Хафизны алып китәргә генә калыр, ахры. Менә хәзер дә янымда ирем булса, син әнкәйне яклаган күк, ул да мине якламый калмасые. «Ирле кеше—Идел кичкән», диләр шул. Ә ир какканны мир кага, мина да әкренләп шулай булыр инде ул,—диде дә Газзәбану, тагын елап җибәрде.

—Нәрсә тузга язмаганны сөйләп утырасың, килен?! Беркая да китү юк! Алма күк баланы ятим итәргәме? Бер киселгән икмәкнең кире ябышканы, ай-һай... Бездән ризалык көтмә. Булганына азрак шөкрана да кыла белергә кирәк. Шул Нургали аркасында бит, күпме кеше кырылганда, без егерме беренче ел ачлыгын күрмәдек. Бу юлы да, әнә, никадәр әйберләр җибәргән. Нургалинең безгә дигән хаты бик әйбәт язылган, ике сүзнең берендә Хафиз белән сине сагынуы турында яза. Әйдә, булмаса, карчык, самавырынны

яңартып җибәр, күчтәнәчләр белән тәмләп чәй эчеп алыйк. Хатны да кычкырып укырмын. Газзәбану килен камыр куйсын, син, карчык, аш салып җибәрерсең. Кичкә Нурисламнарны алдырырбыз, боерган булса. Өйлә намазына кадәр күршеләрне үзем чакырып чыгармын.

Газзәбану, елавыннан туктый алмыйча:

—Әйе, сезгә улыгыз кадерлерәк шул, минем хәлемне күз алдына да китереп карамыйсыз: алар парлашып мунчага кереп киткәндә, кичләрен бергәләп йокларга ятканда миңа нишләргә кала? Моңа ничек түзәргә кирәк? Ирен өзелеп сөйгән хатынга бу минутларда йә үзенә кул салырга, йә акылдан шашарга гына кала түгелме соң?..

—Аллам сакласын, Аллам Үзе сакласын!—дип бу сүзләрдән сискәнеп китте Зариф абзый.—Тәүбәгә кил, балакаем! Ходайдан сабырлык сора. Без синең хәленне аңлыйбыз, килен, аңламаган кая ул! Нишлик соң? Сиңа түземлек теләүдән башка нәрсә эшли алабыз соң? Безгә үпкәләмә инде, үз балабыздан бер дә ким күрмибез бит сине.

Аннары ике кулын күтәреп, Раббына ялварып дога кылды. «Рабби йәсир вә лә тугассир сәһһил галәйнә, йә Рабби вә тәммим бил-хәйр». (Раббым, бир җиңеллек, бирмә авырлык, безгә уңайлы ит һәм хәере белән тәмамла!)

Нәкъ шул вакытта, кече яктан парларын чыгарып, кайнап торган самавыр күтәреп Зөлкамал килеп чыкты. Ул, бернәрсә булмагандай, ягымлы гына:

—Әйдәгез, барыгыз да табын янына, яңа такта чәй, тәмле күчтәнәчләр белән сыйланып алыйк әле. Килен, син әле бүләкләрне дә карамадың бит...—дип Газзәбануга текәлеп карап алды.

—Юк, әнкәй, миндә чәй кайгысы түгел әле. Сез үзегез эчегез, сыйланыгыз... Ә мин Нурислам белән сөйләшеп чыгыйм әле, булмаса.

Үзе тиз генә яшьле күзләрен, битен юды да, чаршау артына кереп өс-башын алыштырды. Яшел төстәге биш куштанлы, билдән өзек итеп тегелгән, гәүдәсенә сыланып кына торган күлмәген киде. Ак батист яулыгын артка чөеп бәйләп куйды. Биленнән дә узып киткән калын толымнарының берсен күкрәк ягына салды. Инде чыгып китәм дигәндә генә Хафиз:

—Әни, мин дә синең белән Тәскиләләлгә келәм,—дип, уенчык атын күкрәгенә кысып, әнисенең кулына килеп ябышты.

—Алайса, сиңа да тәти күлмәгеңне кияргә кирәк,—дип Газзәбану аның да өстен алыштырды. Бу матур манзараны карап торган өлкәннәр куанып, аерата Газзәбануның тал чыбыгыдай сыгылып торган зифа буена, озын, калын чәч толымнарына, әле генә күргәндәй, сокланып туймадылар. Әмма күңелләренә күпме нур өстәгән, бу илаһи соклану аларны тирән шомга да салды. «Әгәр бу балалар, бая Газзәбану әйткәнчә, бездән китә калсалар, үзләре белән тормышыбызның бөтен ямен алып китәчәкләр бит. Яшәвебезнең бер мәгънәсе дә, бер кызыгы да калмаячак»,—дигән уй Зарифның йөрәген телгәләп алды. Шундый ук хисләр кичерүдәндер ахры, каенанасы да ягымлы гына итеп:

—Балакайларым, зинһар, анда озак юанырга карамагыз, без сездән башка чәйгә утырмыйбыз,—дип тышкы ишеккә кадәр озатып калды үзләрен.

***

Әтисе алдында яңа зур курчак тотып утырган Тәскирә Хафиз килеп керүгә:

—Әтием кайтты, әтием,—дип курчагына күрсәтә-күрсәтә такылдарга кереште.—Менә миңа нәлшә алып кайткан, матулмы? Хәзел безнең кәҗәне үлтәләп такмак әйтә алмашшың, без дә шыел алабыз, әти шулай диде.

—Шыел түгел, сыел диген, сакау!—дип Хафиз кырт кисте.

Әллә инде Тәскирәнең атасы алдында утыруыннан көнләшеп куйдымы, малай үзен үтә төксе тотты. Нурислам, кызын алдыннан төшереп:

—Сөбханалла, мәшалла! Мин кайтканчы ничек матур булып үсеп куйган безнең «кияү», әле кайчан гына төпсез ыштаннан артын ялтыратып, мүкәләп йөргән малай чичти егет булган бит, әй. Маладис, «кияү»! Кил әле үземә, бер рәхәтләнеп сөйләшик»,—дип Хафизны кочаклап алмакчы булды.

—Мин «кияү» түгел, мин Хафиз Ялуллин!—дип, күрше абыйга горур гына караш ташлап, әнисе артына ук елышты. Өлкәннәр көлешеп куйдылар.

Газзәбану белән күрешкәндә Нурислам элеккечә аңа соклануын яшерә алмады.

—Күрше, ни гаҗәп, син һаман чибәрләнә генә барасың, күзем тимәсен! Нургалиең күрсәме, валлаһи дип әйтәм, сиңа өрьяңадан үлеп гашыйк булачак.

Нургали исеме чыгуга, Газзәбануның күзләренә мөлдерәп яшь тулды. Моны күреп алган Нурислам, аны бу халәтеннән аралау өчен тиз генә сүз катты:

—Хафиз Ялуллин, мин дә сиңа бүләк алып кайттым бит. Йәле безнең кәҗә турындагы такмагыңны әйтеп җибәрче!

—Алдан бүләгеңне күлсәт, аннан әйтәм.

Хафизның бу сүзләреннән соң Тәскирә ашыга-ашыга яңадан әтисенең алдына менеп утырды. Нурислам кесәсеннән бик матур кош килбәтендәге таштан ясалган, матур итеп буялган сыбызгы алып, сызгыртып та җибәрүгә, Хафизның йөзенә кояш чыктымыни. Өлгереп җиткән шомырт төсле чем-кара күзләреннән нурлар чәчеп, сыбызгыга текәлде.

Кәҗә, кәҗә, кәҗәкәй,
Имиләле бәләкәй.
Бел чокыл да сөт билми,
Вәйт, унмаган нәмәкәй,—

дип, кызу-кызу сөйләп тә китте.

—Әти, дөлеш әйтми ул. Безнең кәҗә шөтне, беләшең килшә, ике чокыл билә. Шыбыжгыңны билмә аңа, миңа бил, яме, әти.

Хафиз дәшмәде, коелып төште. Тәскирә: «Алайша үжем әйтәм»,—дип такмакларга тотынды.

Тәшкилә елый икән,
Битен дә юмый икән,
Юалые ул битен,
Кәҗәше билми шөтен.

Хафиз кызга усал караш ташлап:

—Минем дә әти кайтыл әле, мин дә сиңа бел нәлсә билмәм»,—дип елап ук җибәрде. Нурислам тиз генә сыбызгыны аңа сузып:

—Матурым, мин бит аны сиңа дип апкайттым. Сыбызгы сызгыртып йөрү кызлар эшемени?. Әнә уйнасын курчагы белән. Тиздән синең дә әтиең кайтыр. Кара сиңа нинди матур ат җибәргән. Тагын әллә ниләр апкайтыр әле»,—дип малайны юатмакчы булды. Әмма Хафиз сыбызгы кулына эләгүгә, йөгереп өйдән үк чыгып китте. Чиксез шатлыклар хөкем сөргән бу гаиләдә, малайның күңелендәге фаҗигане аңламадылар да кебек, үзара көлештеләр генә. Тик Газзәбану бу көлүгә кушыла алмады. Киресенчә, ачы күз яшьләре белән елап җибәрүдән чак кына тыелып торды. Сәҗидә, ахирәтен юатыр өчен микән:

—Син бит мине, җаным, аякка бастырдың, кеше иттең! Миңа күпме

вакытлардан соң бүген, Аллага шөкер, янадан Нурисламыма хатын булу бәхетен татыдым. Менә сиңа нинди матур атлас күлмәклек, әле тагын озын чуклы ефәк шәл апкайткан. Яле, бөркәнеп күрсәт әле,—дип бүләкләрне анның кулларына салды.

—Кара син боларны, нинди житезләр. Шул арада инде өлгергәннәр дә! Шатлыгыннан, үзенә дигән бүләкләрне дә миңа бирәсен, ахры. Андый вакытта хатын-кызны артык юмарт була диләр иде, әллә дөрес инде...

Сүзгә Нурислам кушылды.

—Юк, Газзә, бу—хас сиңа дигәннәре. Ал син аларны, минем төсем итеп киярсен. Мәңге онытасыбыз юк изгелекләреңне. Аллаһының рәхмәте яусын үзенә, барысы өчен дә...

Нурисламның үзенә якын ук килеп, бигрәк тә: «Барысы өчен дә...» дип, күзенә карап әйткән сүзләреннән Газзәбануның ике бит уртасы пешкән алма кебек кызарды.

—Рәхмәт инде, тик мин аларны алмасыем. Әгәр миңа яхшылык эшлисегез килсә, бәлки, башкача килешербез. Безнеке авылдагы язгы эшләрне дә бөтенләйгә онытты бугай. Бар авыр эш әткәй белән миндә. Кайтуны да жыен вакытына гына көйләгәннәр, ай-яй, хитрыйлар да инде... Анда да жыен кунагы булып, парлашып кына кайталар бит, жан көекләре... Гозерем шул, күрше, язгы эш вакытларында безгә әзрәк булыша алсаң, бик разый булырыем. Эшләрне бетергәч, Хафизымны алып китәрмен дип торам. Бөтенләйгә дип әйтүем түгел, безнең өйдә, Әсма килен янында, без түгел, анда әтиләр дә артык жанга әйләнеп бара. Нургалиләр киткәч, монда кайтырбыз. Әле ярый әткәй безнең өчен үлеп тора, исән генә булсын инде...

Газзәбану яшь тулы күзләрен Нурисламнан читкә алды.

—И-и, Газзәбану, тукта әле, ташласана бу тузга язмаган сүзләреңне! Мин анысы көчемнән килгәнчә ярдәмемнән ташламам. Ә Нургалинең моңарчы кайта алмавы һич сезне онытканнан түгел. Син дип үлә ул! Сагынуына чыдый алмыйча, инде ничә мәртәбә бөтенесен ташлап китәргә жыенды. Анның өстендә шул кадәр күп тауар хәзер. Локман абзый тауарны Кытай, Төркия, тагын әллә кайлардан ала башлады. Череп баеды ул. Бөтен кибетләре өстеннән синең Нургалиеңне хужа шикелле тота. Ну башлы да малай булып чыкты ул. Тәки менә дигән итеп алып бара бит шундый зур эшне. Дөрес, Локман абзый аны ярты елдан артык тәжрибәле сәүдәгәрләр кул астында өйрәнчек итеп тә йөртте. Бәк шомарды ул хәзер. Әллә зрәгә генә кияве итте дип беләсеңме? Нургалинең акчасы да күп, сезне үз янына алып китмәкче була. Йорт та белешеп йөри бугай. Миңа сер итеп кенә: «Әгәренки әтиләр бик каршы булсалар, авылга кайтып ике катлы өй салам да, беренче катында кибет ачам»,—диде. Ә син, жүләр баш, китәргә жыенгансың. Хәзер нәрсәдер шунда, бөтен дөньясы буталып бетте. Сәүитне сүгеп, алтыннарын яшереп йөргән байлар өр-яңа кибетләр ачалар, туктап калган фабрикларны эшләтә башладылар. Линин да аларны яклый икән. Моны хөкүмәтнең Неп дигән өр-яңа политикасы диләр, һич аңламассың...

Иреңне Мәһирәсе белән кайта дип елап-сыктап йөрмә, анның синнән бер дә артык жире юк. Зур укымышлы дисәләр дә, хатын-кыз—хатын-кыз инде ул. Кәнишне, калфакны кыңгыр салып, жир себерерлек озын күлмәкләр, укалы камзуллар киеп, биек үкчәле бәтинкәләрдә керт-керт басып йөргәч, әллә кем булып күренәдер инде. Кайтсын әле, кайтсын... Синең чибәрлегеңне, кулларыңда ут уйнатып эшләгәннәреңне, атасына охшаган менә дигән малай үстергәнеңне күрсәме, коелып иңәчәк әле ул. Бала табарга яраклы түгел икән дип тә ишеттем әле мин аны. Дөрестерме, юктырмы, бу кадәресен анык кына әйтә алмыйм.

Газзәбану Нурисламның бу сүзләренә бик үк ышанып бетмәсә дә, бераз

тынычлана төште. Чәйгә утырырга никадәр кыстасалар да, каласы итмәде, өенә, үзенекеләр янына ашыкты.

***

Авыл халкы мәш килә—тиздән җыен. Хатын-кызлар өмә ясап өй юа, мунча яга. Яшьрәкләре яна күлмәк тектерү хәстәрен күрә. Ир-атлар сабанда арган атларын тәрбияләү, тарантас, ат сбруйларын тәртипкә китерү белән мәшгульләр. Хәллерәкләре атларын чабышка әзерли. Карт-коры, бабайлар абзар-кура тирәсен җыештыра, ишегалды, капка төпләрен себерә.

Көрәшчеләр, инде атна буе, сарык шулпасы белән итен ашап, чи йомырка эчеп тәннәренә көч җыя. Малайларның да шөгыльләре күп: исәйгәнрәкләре йөгерешкә әзерләнә. Һәрберсенең хыялында—беренче булып килү, билгеле. Ә кечерәкләре исә җыен иртәсендә, иң алдан торып, йомырка, чикләвек, кәнфит-прәннекләрне күбрәк җыйнау хыялы белән яна. Шуңа күрә, чүпрәк капчыкны зуррак итеп тектереп кулларына алганчы, апа-җингинең берсенә дә тынгылык юк. Әниләрен көненә ничә мәртәбә: «Әни җаным, үзең торганда мине уятырга онытма, яме»,—дип, ә кайбер шаянраклары: «Мине үзең уянганчы ук уят, белдеңме»,—дип йөдәтеп бетерәләр.

Инде җыенга бер-ике көн кала, хатын-кыз, нәкъ бәйрәменә хас, бөтен дирбиясын кертеп, татлы чәй ризыклары әзерләү һәм ипи салу мәшәкатьләренә чума. Ул көннәрне хатын-кыз кулында күәстер, җилпучтыр, иләктер, чәй камыры өчен генә тотыла торган агач чиләктер—чиратлашып бии башлыйлар. Ипи күәсләренә аерата эш күбәя. Алар күршеләр арасында чиратка басалар. Һәр йортның үз күәсе булмавында тирән мәгънә дә ятадыр әле. Гадәттә күәсне юып тормыйлар, өстәвенә ипи салу өчен баш ясарга дип бер тотам әче камырын да калдыралар.

Бу көннәрне мичләр, хәтта икешәр мәртәбә ягыла. Өй эчендәге кызулыктан миләр пешәрлек була. Чәй янына куела торган: балан, эремчек бәлешләре, баллы паштет, кортлы сумсалар, чәкчәк, бавырсак, кош теле шикелле татлы ризыклар өчен бодай онын җиз иләктән генә илиләр. Эченә сары май, сөт өсте, шикәр комы салып, йомырка сытып, сөткә генә басылган камыр, чүпрәсен дә мулрак җибәрсәң, күзгә күренеп кабара башлый. Шул камырдан ясаган татлы ризыклар бала-чаганы мич тирәсенә беркетә дә куя инде. Алардан аңкыган хуш искә өлкәннәрнең дә авыз сулары килгән чакта, балалар ничек түзә алсын. Маңгайларыннан борчак-борчак тирләр тамып торса—тора, әмма, өйдән чыгу юк инде. Әниләре: «йөзләре килә микән? Көеп китә күрмәсеннәр тагы»,—дип мич капкачын ачкалап караган саен, бала-чага да мич авызына ук кереп китәрдәй булып мәш киләләр.

—Әни, әни, әнә почмакта торган бәлеш кызара башлаган бит, анысын алырга да вакыттыр! Әни, дим, печтек кенә бирерсең инде, яме.

—Кунаклар килгәч, кем үзен тәти тота, шуңа иң тәмлеләрен бирермен,—дип әниләре кисәтеп куя....

Әйе, мич ашларыннан аңкыган хуш исләр өйләрдән ишегалларына, хәтта урамнарга кадәр таралды. Әле күптән түгел генә ачлыкның ачы газапларын кичергән һәм күп кенә газизләрен югалткан авыл халкы күңелендә, ирексездән, авыр хатирәләрен дә кузгатты. «И, җаннарым, бу бәхетле көннәрне сез генә күрә алмыйсыз бит. Инде, газиз Аллам, башка беркайчан да бәндәләреңне ризыксыз калдыра күрмә! Гүр иясе булган газизләребезнең урыннарын җәннәттә кыл!»—дип елашып та алдылар.

Җыенга нәкъ әвәлгечә, бөтен шартын үтәргә тырышып әзерләнү, ни генә булса да, Көек халкының күңел яралары төзәлә башлавын күрсәтә иде. Узган елның мул уңышларыннан, ниһаять, халыкның тамагы туйды, өсте бөтенәйде. Шатлык өстенә шатлык булып быел да, чәчүне тәмамлауга,

ике көн рәттән талгын гына, җиргә тәмам сеңдереп, җылы яңгыр явып үтте. Әйтерсең лә, табигать үткән елларда бөтен яшеллекне көйдереп бетергән корылыгы белән, ач үлем җибәргәне өчен гафу үтенә, хатасын төзәтә диярсең. Өстәвенә, кояшлы яңгыр вакытында күк йөзендә әкияти салават күпере сузылды. Урамнар бала-чага белән тулды. Аларның чыр-чуларыннан һәм:

Яңгыр яу, яу, яу,
Тәти кашык базарда,
Тәмле ботка казанда,—

дип сикерә-сикерә такмаклауларыннан авыл шау итеп торды. Бу матур манзарага карап сокланмаган кеше калмагандыр. Ә картлар, боларның барысын да, быелгы уңышның мул булачагына юрады.

Җыен көне якынайган саен, Газзәбануның күңелендәге кара шом да үскәннән-үсә барды.

Нургалиләрнең кайтып төшүләре нәкъ егетләрнең бүләк җыю көненә туры килүе дә аның эчен пошырды.

## Яшь хатын

Нургалинең яшь хатыны белән кайту хәбәре бөтен авылга таралды. Яше-карты, бары да Газзәбануны кызганды.

Шәригать нигезендә ирләрнең ике-өч хатын белән торуы гадәти хәл саналса да, Көектә хәзерге Фарук мулланың бабасыннан башка, берәүнең дә ике хатынлы булуын хәтерләмиләр. Күрше-тирә авылларда да мондый гаиләләр булмаган. Ил өстендә алтынчы елын хакимлек итүче совет хөкүмәте шәригать кануннарын каттый тыйган бер чакта, Нургалинең бу кыланмышын аңлый алмый йөдәделәр. «Урыс баеса чиркәү сала, татар баеса хатын ала, дигәндәй, безнең егет тә артык баеп киткән, ахры»,—дип сөйләнделәр. Шулай да бу хәбәрне, фәкыйрьлеге аркасында вакытында өйләнә алмый калган, инде менә ике ел авыл советы рәисе урындыгын биләгән Фатыйх үзенчә кабул итте. Нургалинең Ташкентта өйләнүен ишетүгә, элек тә күзе төшеп йөргән Газзәбануга өметләнә башлаган иде. Инде авылга парлашып кайтасыларын да ишеткәч, Газзә түзмәс, аерылыр дип уйлады. «Әгәренки шулай килеп чыга калса, балалы дип тә тормасыем»,—дип хыяллана ук башлады.

Газзәбану каенатасының Нургалиләрне каршы алу мәшәкатьләре белән ыгы-зыгы килгәненә гел битараф калды.

—Килен, үзенә мәгълүм, тегеләрне каршыларга мин Хафизны да алып бармакчыем. Нурислам: «Баланы да азаплама, үзең дә хафаланып йөрмә. Мин генә барыйм,—ди. Син нәрсә әйтерсең икән?—дигән соравына да илтифатсыз гына:

—Ярар, дөресен генә әйткәндә, Хафизны башта ук җибәрәсем килмәгәние,—диде. Ул арада, ялт итеп, Нурислам үзе дә кереп җитте.

—Йә, күрше, ничек? Килештегезме?

—Ярый, без риза, Аллага тапшырдык.

—Бик әйбәт, поезд иртәнге бишкә килеп җитә. Миңа сәгать дүртләрдән дә калмый кузгалырга туры киләчәк. Кичтән үк кирәк- яракларны хәстәрләп куясы булыр.

Ирләр өйдән чыгып китүгә, Зөлкамал сак кына:

—Газзәбану, балакаем, карале, кичә безнең күршеләр тарантаска салына торган ястыкларына яңа матур тыш киерткәннәр икән. Син дә үз ястыгына

теге зур чәчәкле яна теккән тышлыгынны киертеп куймыйсынмы сон? Җыенга барганда да шуны салырыегыз. Аннары, дуга кыңгыравын бераз ялтыратып, кызыл тасма белән бәйләп тә куйсагыз, матуррак булырые, дим. Бая Сәгыйдәләргә кергәнием, килене Мәрфуга, безнеке төсле үк җиз кыңгырауларын ялтыратып утыра. Шакларкаттым, самавырлары төсле ялык-йолык килеп тора. Иллә дә унган булып чыкты бу киленнәре,—дип сүз куертып алды.

—И-и, әнкәй, малаен үзе генә кайтасы булса, ниләр генә эшләмәсием. Кушканны гына эшли торган кешемени мин? Ничек бер дә сизмисең сон с-и-н? Менә инде ничә көн йокым йокы, ашым аш, эшем эш түгел. Эчләрем тулы ут. Болай да бит, мунчаны ю диден, юдым, аларга йокларга ак келәтне ю диден, анысын да юдым. Инде аларны каршы алырга үземнен бирнә ястык-җәймәләремне әзерләп куярга кушасынмы? Дәшмәгән саен, килен кеше—ким кеше, дип басымчак итүенме? Каенана булдым дигәч тә... Бу баланы рәнҗетмәгәем дип тә уйлый алмыйсың бит, ичмаса...

Килененен бу сүзләреннән сон Зөлкамал бераз уңайсызланып куйса да, сиздермәскә тырышты.

—Газзәбану, кызым,—диде ул сак кына,—баянак Сәҗидә сине үзләренә кереп чыксын әле, дигәние. Нәрсәгә икәнен әйтмәде әйтүен, көтәрмен диде. Бар әле, кереп чык булмаса. Калган эшләрне әткән белән бергәләп эшләп бетерербез, Аллаһы боерса. Син борчыла күрмә, яме,—дип, аннары килененен аркасыннан назлап кына сыйпап та куйды.

Килене белән бу сөйләшүнең зурга китмичә тыныч кына тәмамлануыннан, аны картының да ишетми калуыннан Зөлкамал бик разый иде.

***

Сәҗидәнең борчылган йөзен, яшь белән мөлдерәмә тулы күзләрен күргәч, Газзәбану сискәнеп китте.

—Ахирәткәем, ни булды? Әллә тагын авырып киттеңме?

—Ю-у-к, авырмыйм анысы, шөкер. Тик Нурисламга шигем бар, менә шул бөтен тынычлыгымны алды. Кичәдән бирле җанымны кая куярга белми изаланам. «Нургалиләрне үзем каршы алырга барам», —дип ашкынып йөрүләрен күрсәң... Зариф абзый үзе бармакчые бит, нигә дип безнекенә куштыгыз? Мөгаен, аның икесе генә сөйләшә торган яшерен сере бардыр.

—Китчәле, юкка үз башынны да, кеше башын да катырмачы. Шикләнмә дә... Сер сөйләшер өчен әллә монда җаен тапмасларыемы?

—И-и, җаным, ул гынамы сон... Кичә көтү куганда түбәноч Майҗамал: «Сәҗидә, карәле, Ташкинда синең Нурисламыңның да хатыны бар икән дип сөйлиләр. Бел аны, йоклап ятма! Нәрсә генә булса да, бүтән анда җибәрә күрмә үзен. Тәки, Газзәбану шикелле, иреннән колак кагырсың. Газзәне әйтәм, гүзәлләрнең гүзәле булып та утырып калды, ә синең саулыгың да ташка үлчим генә бит әле»,—ди, күзен дә йоммый.

—Ә син шул ыштырбитнең сүзенә ышандыңмы? Аны бит авылда гайбәт капчыгы дип кенә йөртәләр. Кеше котыртып йөргәнче, үзен генә белсәче! Инде без белгәне генә дә, ничә тапкыр иргә чыгып карады. Берсе белән дә тора алмады бит. Тапкан котыртыр кеше, әҗәткәнә! Төкереп кенә бир шул гайбәтче сүзенә...

—Гайбәтче Майҗамал сүзенә төкереп тә тормасыем әле, Нурислам үзе, инде ике төн рәттән «Зөмәрә» дип саташа башлады. Үз тавышына үзе уянып китә дә, соңыннан йоклый алмыйча изалана. Сораша башласаң, дәшми, йоклаганга салыша.

—И ахирәткәем, тагы ниләр уйлап табарсың икән инде? Үлем көтеп яткан чакларынны бик тиз оныттың әле син, җаным. Барына шөкрана кылып,

иреңне назлап, үзең дә назланып кына яшисе урынга... Ярый, «Зөмәрә» дигәне дә булган ди. Үпкән-кочкан, җилгә очкан. Ирең бит әле әллә кайда түгел, үз янында лабаса. Тазарып киткәнеңә куанып, нишләргә белми йөри, Тәскирә кызым дип үлеп тора. Менә минем хәлгә тарысаң, нишләриең икән син?!

—Синең хәлеңне аңламый дип беләсеңме әллә мине? Аңлыйм, бик аңлыйм, җаным, ярдәм генә итә алмыйм. Әйе, үз хәсрәтең таулар кадәр булгач, минеке сиңа тары бөртеге күк кенәдер инде...

—Хәтта тары бөртеге кадәр дә түгел. Юкка мокчынып үз-үзеңне бетермә. Миңа да чыгарга кирәк. Үз борчуларым да баштин ашкан, бүген әнкәй белән дә чүт эләгешеп китмәдек. Ярый, Хак Тәгалә саклады тагы. Сүз бозау имезә дигәндәй, ахшамга соңга калабыз түгелме соң? Укы намазыңны, ихлас күңел белән телә теләкләреңне. Аллаһы Тәгаләбезгә сыен!—дип Гәззәбану чыгып китмәкче булды.

—Теләгеңә алай гына ирешеп булсае ла... Син менә намазыңны да калдырмыйсың, теләкләрнең дә нindиең генә теләмисеңдер... Алайса нигә соң Аллаһы Тәгалә сиңа кайгы өстенә кайгы сала?

—Бар икән... Инде Аллаһы Тәгаләгә дә тел тидерә башладыңмы? Әстәгъфирулла, тәүбә, әйттем исә кайттым диген. Акылыңа кил, Сажидә,—дип шактый ачуланып, ишекне каты ябып чыгып китсә дә, күңеленнән нидер сизенгәндәй, ахирәтен кызганып та куйды.

Ничек сизенмәсен ди... Ахирәте урын өстендә ятканда Нурисламның үзе тирәсендә йотардай булып йөргәннәре әле дә булса күз алдында бит. «Нургали дә Маһирә янында шулай кылана микән? Аларныкы алай гына да булмагандыр әле, югыйсә, никахлашуга кадәр үк барып җитмәсләрие. И, Раббым! Нигә шулкадәр түземсез итеп яраттың ул ир затларыңны? Ә хатын-кызны гел хәсрәт-кайгы өчен генә яраткансың, ахры»,—дип ихтыярсыз авыр сулап куйды. Соңыннан бу уйларын, иблис вәсвәсәседер дип, бер Алласыннан үзен ярлыкавын сорап, ахшам намазына ашыкты.

Бу төнне Зарифлар йортында кайсы гына тынычлап йоклый алды икән? Хәер, кочагына сенеп йоклаган сабый әнисенең кайнар күз яшьләреннән мендәр тышының лычма булуын сизмәде дә...

***

Июньнең иң матур иртәсе... Тирә-якта иксез-чиксез басу-кырлар... Табигатьнең шушы матурлыгына, сафлыгына сокланып, талпына-талпына мәдхия җырлаган тургайлар тавышы күңелләрне сихри наз белән күмә. Һәр тарафтагы иртәнге саф һава сулышларны иркенәйтә, бөтен җанны иркәли.

Йомшак ястыкка терәлеп, сиртмәле тарантаста тирбәлә-тирбәлә, шушы илаһи матурлыкка таң калып, тыныч кына барасы да барасы гына бит инде Нурисламга. Аллага шөкер! Сажидәсе дә терелде, кызы да матур гына үсеп килә, сыердан да уңдылар... Юк, юк шул, барыбер нидер җитми шикелле, нигәдер җаны тынгысыз... Бара-бара да: «Алда нинди хәбәр көтә мине? Әллә сөенеч, әллә... Аллам сакласын!»—дип уйлап куя.

Малкай да нидер сизенәме, югыйсә, һич куаламый да бит үзен, ә ул гел юыртып бара. Бәлки, яшь хуҗасын каршы алырга барганын ул да сизенәдер.

Поезд килергә ярты сәгать кала, ул инде станцада иде.

Дустының күз карашыннан икесе генә сөйләшер сүзе булганын шунда ук аңлады Нурислам.

—Маһирә, без теге куаклар артын карап килик әле, кайтасы юлыбыз шактый ерак, бәлки бездән соң үзең дә барып килерсең,—дип Нургалине ияртеп, кызу-кызу китеп бардылар. Бераз китүгә, тәмам түземлеге беткән Нурислам болай дип сорады:

—Зөмәрәне күрә алдыңмы? Ни хәле бар? Бу арада гел төшемә керә. Нишләптер, бик начар күрәм. Тәмам борчуга салды әле ул мине...—диде.

—Тыс-с-с, әкренрәк, Маһирә ишетмәсен, ул берни дә белми... Ә сина борчылыр урын юк. Ул Казаннан килгән бер татар кызын фатирына керткән. Шул кыздан яздырып, сиңа хат җибәрде. Хәзер Зөмәрәң безнеңчә әйбәт кенә сукалый да башлаган.

—Әллә сезгә үзе килдеме?

—Юк, мин үзем бардым. «Бик авырайдым инде, соңгы көннәремне йөрим. Игез булсалар, ни хәл итәрмен, куркып торам»,—ди. Чыннан да, корсагы артык зур күренде. Без юлда көннәрне бәбәйләмәгән булса инде... Төшләренә дә шуна керми микән?—дип, Нургали кесәсеннән хатны алып бирде.

—Монда гына укып бетерә алмассың, бик калын күренә. Озакласак, Маһирә дә шикләнә башлар. Кайткач, аулакта иркенләп укырсың. Кара аны, сак бул! Сәҗидәнә эләксә, утлы табада биетер, Аллам сакласын...

Нурислам бераз тынычланып киткән кебек булса да, авылга тизрәк кайтып җитәргә ашкынып, Чаптарны гел куа башлады. Куеныдагы калын хат аның үзен дә чыбыркылап куа кебек. Юк-юкта хат салынган кесәсен капшап куя. Андагы билгесезлектән туган уйлар Нурисламны әллә кайлардагы Үзбәкстанга, Зөмәрәсе янына алып китте. Сәҗидәсенең терелүенә өмете киселгән чакларда, ул аны авылга алып кайтып никах укытырбыз да, шунда яшәп калырбыз дип уйлаган вакытлары да булмады түгел. Зөмәрәсе дә аннан калмас өчен Көеккә кенә түгел, дөнья читенә китәргә дә разый иде. Нурисламның еш кайтуларына да күбрәк Зөмәрәнең: «Алай-болай була калса, безгә рәнҗеп китә күрмәсен, ризалыгын алып калырга тырыш»,—дигән киңәшләре ярдәм итте. Авылга дигән күчтәнәч һәм бүләкләрне дә Зөмәрә үзе туплап җибәрә иде. Хәтта Нурислам исеменнән акча да җибәргәләде. Мондый вакытларда ул бер Алласыннан, кылган гөнаһларын ярлыкавын сорап, сәдәкам булсын дип, багышлап куя торган булды. Бу мәрхәмәтле җилнең каян искәнен Сәҗидә белмәде, билгеле.

—Их, Нурислам, белсәң иде син Хафизымны ничек сагынганымны! Мин киткәндә орчык күк кенә малай иде, үскәндер инде. Синдә кыз, миндә егет—кодалар булып китмәгәек әле...

—Бирсен Ходай! Улына нинди бүләк апкайтасың сон?

—Кечкенә гармун алдык, дус кеше.

—Үзен шикелле гармунчы итәм дисең инде, име,—дип Нурислам ничектер, үзе дә сизмәстән, артка борылып карады. Маһирәнең Нургали куенына тәмам сенеп бетеп утырганын күреп, кисәк кенә авылда боларны көтүдән җанын кая куярга белми, ут йотып йөргән Газзәбану күз алдына килде. Нурисламның ачуы чыгыпмы, әллә көнләшеп тә инде, ачы итеп сызгырып, каты гына дилбегәсен тартып җибәрүе булды, Чаптар кисәк ыргылып чабарга тотынды. Мондый кискен хәрәкәттән, артка сөрлегеп киткән Маһирә ризасызлык белгерде.

—Нигә шул кадәр куасың, Нурислам? Атың үз җаена гына атласын әле. Сезнең якларның шушы гүзәллеген тагын кайчан күрәм мин? Зинһар, ашыкмыйк! Тургайлар җырын озаклабрак тыңлыйсым килә,—диде.

—Ярар, алай озаклап тыңласың килгәч, тыңла инде, рәхәтлән! Ә мин, әнә теге, бездән артта калган артышлар арасына барып килим әле...—дип, Нурислам атны туктатып, дилбегәне дустына бирде дә, элдертте генә...

—Әллә бәвелен тота алмый инде?—дип Маһирә көлеп калды.

Нурислам артышлар арасында сузылып ятып, хатны йотлыга-йотлыга укыды. Аны үзендә саклый алмаячагын аңлап, юк иткәнче сүзен-сүзгә күңеленә салып калдырасы килеп, кат-кат укыды. Инде вак-вак кисәкләргә

ертып бетергәч тә, хатның соңгы юллары күз алдыннан китмәде.

«Нурислам бәгърем!

Бу хатым сина килеп кергәндә, мин инде, Аллаһы кушса, котылган булырмын. Син Нургали биргән адрес белән Казанга барып, точнысын белерсен, шуннан миңа хат та язарсың. Нургали артыннан хат җибәрергә әмәлен таба күр яме. Аларның кайтканын инде хәзердән үк түземсезлек белән көтә башладым. Малай тапсам, Ислам дип, кыз булса, Исламия дип исем кушарга уйлыйм. Син ничек теләриен, язып җибәр. Игез генә булмасалар ярарые, бик куркам... Бала бераз исәя төшкәч, Казанга барырга хыялланам. Шунда күрешериек, Аллаһы боерса. «Сагынганда айга кара, мин дә айга карармын. Күз нурларың айга төшсә, шуннан эзләп табармын». Хуш, Нурисламым. Үлеп сагынып, бер күрергә зар-интизар Зөмәрән».

***

Иртәнге намаздан соң ук мунча ягып җибәрделәр. Газзәбану җәһәт кенә су китерде. Аннары Нургалиләрнең кайтып житү вакытларын чамалап, өстен-башын алыштырырга кереште. Ире җибәргән затлы күлмәген кулына алса да, никтер, киясе итмәде. Гәүдәсенә бик килешле итеп тегелгән бәби итәкле жете ал сатин күлмәген киде. Ал ефәк жепләр белән баш-башын үзе чиккән ак батист яулыгын артка чөеп бәйләп куйды. Калын чәч толымнарына көмеш чулпыларын такты. Аякларына тән төсле юка фильдеперс оекларын һәм баскан саен шыгырдап тора торган, куе кызыл күннән тегелгән каймалы башмакларын киде.

Зариф абзый килененә, каш астыннан гына, күз салып:

«Сөбханалла, мәшалла! Ходаем биреп тә караган инде гүзәллекне! Кара син, һәр атлаганы саен ымсындырып торырлык тулы төз балтырлары гына да кайсы ирне әсир итмәс... Яман күзләрдән Үзең сакла, бер үк! Инде бу балага көндәш сабырлыгын да бирсәңие, бер Аллам!»—дип уйлап куйды. Шунда ук, «Бөтен авылына бер дигән, сөеп туймаслык хатынын онытырып улыбызны үзенә карата алган Маһирәсе нинди зат икән? Шул кадәр зур байның укымышлы берданбер кызы авылга, житмәсә, көндәш өстенә кайтсын әле... Бар икән кыюлык, тәвәккәллек. Аллага тапшырдык»,—дип уйлап, үзенең һәрчак укый торган догасын кабатлады. —«Рабби йәсир вә лә тугассир сәһһил галәйнә, йә Рабби вә тәммим бил хәер».

Авыл башыннан ук ишетелгән үз кынгырауларының чыңлавын беренче булып, капка төбендә басып торган Хафиз ишетте.

—Бабай, бабай, кайталал, тизләк чыгыгыз!—дип сикергәләргә дә тотынды. Зариф абзый «Бисмиллә»сен әйтеп, зур капканы киереп ачып җибәрде. Үзе урам якка чыгып бер кулы белән Хафизны житәкләде. Икенче кулын каш өстенә куеп, күзләрен Нургалиләр кайтасы якка төбәде. Киленен дә үз янына чакырды. Тик Газзәбану урам ягына чыкмыйча гына каршы як капка баганасы янында тукталып калды...

Менә, ниһаять, атлар капкага якынлашты. Газзәбануның күзе ин элек Нургалигә төште. «Абау жаным, танымаслык булып үзгәргән түгелме соң?». Әллә аркасын бик төз тотып утыргангамы, өстәвенә баш киеме дә әллә нинди биек булгангамы, әллә янында рәттән утырган хатын-кыз кечкенәрәк гәүдәле идеме, ире аңа гажәеп озын буйлы булып күренде.

Газзәбануның бу көннәрдә рәтләп йоклый алмавыннан болай да төссезләнебрәк калган йөзе акбурдай агарып китте. Тез буыннары хәлсезләнеп, күз аллары карангыланып әлже-мелже килде. Ярый әле, капкага терәлеп баскан икән. Нурисламның: «Тр-р-р, Чаптар!»—дигән тавышы да колагына тонык кына булып ишетелде.

Һәрвакыт ачык капкадан кереп китәргә иялэнгән ат урам якта ук

туктатылуына разый булмады, ахры. Башын югары күтәреп кешнәп җибәрде. Алгы уң аягы белән берничә мәртәбә, җирне каезлагандай, кискен хәрәкәтләр ясады. Аннары, башын чайкый-чайкый тыпырдап, бөтен гәүдәсен биетеп торды. Күзен аттан алалмый карап торган Хафиз:

—Бабай, калале, кала инде безнең Чаптал мина биеп күлсәтә иеме? Әллә теге мыеклы абый минем әтиме? Ә янындагы апай кем икән ул? Баш өстенә әллә нәлсә куйган?—дип Маһирәнең калфагына төртеп күрсәтте.

Ул арада Нургали тарантастан очып төштемени...

—Әссәләәмүгаләйкүм, әти, исән-имин торасызмы?—дип колачларын җәеп килә башлауга, Хафиз ятсындымы шунда, бабасыннан ычкынып әнисе янына йөгерде.

Өч ел буе күрешмәгән, сагынулары хәттин ашкан ата белән угыл кочаклашып күрештеләр. Күңелләр тулышты, күзләре дымланды... Газзәбану, ниһаять, үзен кулга алды. Күз карашы, ихтыярсыз, тарантаска төште. Маһирә әле һаман шунда утыра. Нурислам белән нидер сөйләшәләр. Газзәбануның нәфрәт тулы уклы күзләре көндәшенә текәлде. Аның буйга үзеннән күпкә кайтыш булырга тиешлеген һәм йөзе-төсе белән дә үзеннән артык түгеллеген чамалап алды. Шөкер, азга гына булса да тынычланып киткәндәй булды. Шулчак Нургалиенең елмаеп үзенә таба атлап килгәнен күрде:

—Улым, менә бу кеше синең әтиең була инде, күреш үзе белән,—дип Хафизны, аркасыннан йомшак кына этеп, әтисенә каршы атлатасы итте.

—Юк-ла, ул минем әтигә тамчы да охшамаган, аның киемнәле дә этиләлнеке төсле түгел..—дип, Хафиз баскан җиреннән кузгалырга да уйламады. Әтисенең тәмам түземлеге төкәнеп:

—Улым, бәгърем! Менә син нинди матур, зур булып үскәнсең... Кил әле, балакаем, мин бит сине үлеп сагындым,—дип Хафизны күтәреп алып, күкрәгенә кысты һәм шашып-шашып үбә башлады. «Күрәсеңме син» дигәндәй, Газзәбану тагын көндәшенә төбәлде. Тарантас тирәсендәге бала-чаганың күплеген күреп исе китте. Кайчан шулай җыелып өлгергәннәр диген, әллә гел көтеп торганнар инде? Күрше-күлән дә капка төпләренә чыгып баскан. Тагы ни күрсен:

«Каенатасы Маһирәгә тарантастан төшәргә булышып маташа түгелме соң? Бар икән, нәрсә дип ялагайлана инде шуңа, җитмәсә күпме күзләр карап торганда... Монда кадәр кайткач, үзе дә төшәрие әле»,—дип каенатасына да үпкәләп куйды ул.

Улы белән мәш килгән иренә дә, күңелендәге иң авыр сорауларга җавап таба алмаммы дигәндәй, сөзеп-сөзеп карап алды. Өстендәге затлы постаудан, тезләренә кадәр озын итеп тегелгән, ябык якалы чем-кара казакие, тирән эчле биек баш киеме (фәс), аягындагы ялтырап торган читек-кәвешләре һәм нәкъ байларныкы сыман җибәргән купшы мыеклары—бары да Нургалине танымаслык итеп үзгәрткән. Үзен тотышы, хәтта аяк атлаулары да ят булып күренде. Нургали улын кулында кысып тоткан килеш икенче кулы белән хатынының иңнәреннән кочып алды. Әмма, аннан килгән нәзакәтле хушбуй исе дә, үзен тартыныбрак тотуы да ят иде. Маһирәсе карап торгангамы, Нургали, чыннан да, элеккечә бөтен күңеле белән ачылып китә алмады.

Газзәбану, иренең бу аңлаешсыз халәтеннән гасабиланып:

—Нәрсә булды сиңа, хәзер мин нишләргә тиеш? Баланы да ятим...—дип, башлаган сүзен дә әйтеп бетерә алмыйча, кайнар күз яшьләренә тыгылып, әтисе кулында утырган улына капланды. Нургали тиз генә баланы җиргә бастырды. Күңелендәге бар җылылыгын салырга тырышып, сөеклесен юатмакчы булды. Әмма соң иде инде. Аның йөзе буйлап гөрләвектәй аккан күз яшьләрен туктатырга, ай-һай, кемнең генә көче җиткән булыр иде икән... Ул бу хәлендә көндәше белән йөзгә-йөз очрашырга теләмәде.

Тиз генә ире кулыннан ычкынып, йөгереп диярлек өйгә кереп китте. Газзәбану артыннан ишетелеп калган көмеш чулпыларның чыңлавы Мәһирә колагында, үзәк өзгеч моң булып, озак, бик озак сакланды. Ул Нургалигә ияреп авылга кайтуына үкенеп тә куймады микән әле.

Газзәбану үзеннән соң ишек алдынданиләр булганын: каенанасының улы белән елап көрешкәннәрен, икенче киленен мөлаем елмаеп каршылавын—берсен дә күрмәде. Чаршау артындагы мендәренә капланып: «Юк, юк, ул инде минеке түгел, башканыкы—Мәһирәнеке... Ә мин, җүләр, нәрсә дип монда калдым соң? Шушы ачы газапларны күреп яшь түгәр өченме?»—дип өзгәләнеп елады да елады.

Көндәшенең дә тиз генә өйгә керергә аягы тартмады бугай. Моны башкалар да сизде булса кирәк, ишегалдында озаграк юану җаен карадылар.

Өйгә башлап кергән Зариф абзый килененең елаудан туктап бераз тынычлана төшкәнен күргәч:

—Рәхмәт, балакаем! Зинһар, сабыр бул, тешеңне кысып булса да түзәргә кара, сынатма... Бары да узар, Аллаһы боерса!—дип килене ягында булуын сиздерәсе килде. Өйалдыннан Зөлкамалның «Әйдәгез, балалар, өйгә керегез!—дигән тавышын ишетүгә, Газзәбану тиз генә кече якка узды.

Мәһирә сап-сары итеп юылган баскыч такталарын, өйалды сайгакларын күрүгә гаҗәпкә калып, соклануын яшерә алмады. Зөлкамал олы килененең кече якта икәнен белеп, аңа ишеттерерлек итеп:

—Ий, безнең Газзәбанунын кулы тисәме... Аның бар эшләгән эше шулай көлеп тора, Аллага шөкер. Әле аның пешергән ризыкларын ашап карасагыз, телләрегезне йотарсыз,—дип, олы килененең дә күңелен күтәрергә тырышты.

Өйгә керүгә, Мәһирәнең күзе тәрәзә төпләре тулы гөлләргә төште.

—Гөлләрегез дә гөлләрегез, ниндиләре генә юк: ак, ал, кызыл чәчәкләргә төрелгән яраннар, кына, тамчы гөл, ислегөл, тагы, тагы әллә нинди мин белмәгән гөлләр дә бар икән...—дип, ян тәрәзәгә таба атлады.

—Апай, менә бу гөлне әклен генә каккалап куйсаң, злә дә тәмле ис чыга, әни гел шулай итә. Минем әни үстелә алалны, ул алал белән сөйләшә дә әле. Су сибәлгә әнигә мин дә булышам,—дип Хафиз ислегөлне йомшак кына каккалап күрсәтте. Чыннан да гөлнең хуш исе бөтен өйгә таралды.

Мәһирә ишетелер-ишетелмәс кенә:

—Матурым, әниең кайда соң синең?—дип сорап куйды.

—Кечкенә якта. Ул сине такта ялыгыннан калады да калады, әби югында...

Баланың кычкырып әйткән бу җавабыннан, көндәшләр бик уңайсыз хәлдә калып, нишләргә дә белмәделәр. Берсе—нигә бу сорауны биргәненә, икенчесе бала алдында ярыктан көндәшен күзәткәненә үкенеп бетә алмады. Болай да күзгә-күз очрашудан куркып торган көндәшләрнең хәле тагын да авырайды.

Кинәт кенә:

—Әнкәй, утырышып беттегезме инде? Бәлешне чыгарам,—дип һич көтмәгәндә Газзәбанунын тыныч кына дәшүеннән барысы да җиңел сулап куйды. Зөлкамал тиз генә һәр кеше турысына кашыклар таратып чыкты. Мәһирә үзенә тигән агач кашыкны әйләндергәләп карый башлауга, чулпылар чыңлавын ишетеп, сагаеп калды. Бәлеш күтәреп чыккан Газзәбануны һәм аның илаһи гүзәллеген күреп каушап та китте шикелле. Кулындагы кашыгын кая куярга белмәгәндәй аптырады, житмәсә, аны ялгыш идәнгә үк төшереп җибәрде. Үткер күзле Зариф абзый яшь килененең бу халәтен аңлап, тиз генә «Бисмиллә»сен әйтеп, кулына пычак алды. Бәлешне түгәрәкләп кисеп, табындагылар санынча өлешләргә бүлеп чыкты. Пары чыгып торган кайнар бәлештән, авыздан сулар китерерлек искиткеч тәмле ис бөтен өйгә аңкыды.

Һәммәсенең дә күзе Зариф абзыйда... Көтәләр. Шулчак Маһирә иренең атасына үтә дә охшаш булуын һәм икесенең дә бөтен яктан килгән, матур кешеләр икәнлеген күреп, кабат сокланды. Җәһәт кенә Хафизга да күз салды. «И-и, бабасы белән әтисенең бала чакларын күрәсең килсә, шушы малайга гына карарга кирәктер»,—дигән уй белән иелеп, Хафизның маңгаеннан үбеп алды. «Менә син нинди бәхетле икәнсең...»—дигәндәй, көндәшенә карап куйганын сизми дә калды.

Күзләр очрашты... Күз уклары чагышудан очкыннар чәчрәмәсә дә, бу мизгелдә эчләрендә нинди ялкыннар дөрләп киткәнен көндәшләр үзләре генә белгәндер...

Зариф абзый янә «Бисмилла»сен әйтеп, бәлештән авыз итте дә:

—Бик тәмле булган! Хафиз улым, телеңне тотып аша, яме, йә ялгыш йотып җибәрерсең,—дип шаяртып, башкаларны да бәлешкә җитешергә чакырды. Барысы да тәмләп ашарга кереште, тик Маһирә генә сәерсенебрәк нидер көткәндәй утырды. Нургали ана ярдәмгә килеп:

—Әни, бәлешне салырга тәлинкәләр бирсәң әйбәт булырые,—диде.

—Ии, улым, бәлешне кем инде тәлинкәгә салып ашый, булмаганны. Бәлешне ничек ашаганнарыңны әллә оныткансың да инде. Кайнар көе, тәмләп кенә ашагыз әле, үзебезчә.

Маһирә нәрсә соң әле үземне сынатып утырам дигәндәй, кашыгын тотырып алып, кабуы булды, авызын кулы белән каплап «Һыы-һ-һы»—дип, ыһылдарга тотынмасынмы?.. Йота да алмый, кире чыгарырга да уңайсыз. Житмәсә, яннарында утырган Хафиз көлә-көлә:

—Өлеп кабалал аны, өлеп. Өлеп капсаң авыз пешми ул. Менә миңа калап аша син, ашыкма,—димәсенме!

Нургали Газзәбануга кырыс кына караш ташлап:

—Чыгар инде бер тәлинкә,—диде.

—Юк, мәшәкатьләнмәгез, зинһар! Хәзер ничек ашарга икәнен белдем инде. Өлеп кабалга киләк икән бит, әле ярый Хафиз өйләтте,—дип, барын да көлдереп, Маһирә үзенең уңайсыз хәлдә калганын җиңеләйтә төште.

Тик көндәш-көндәш инде: «Шул кирәк сиңа... Нургали белән дә шулай авызың пешсә шәп булырые!»—дип уйлап куйды Газзәбану.

—Чыннан да, бәлеш бигрәк тәмле булган. Хафиз да булышкан, ахры, юкса, бабаң әйтмешли, телләреңне үк йотарлык булмас иде бу. Туатумыштан мондый тәмле бәлеш ашаганым юк иде әле минем,—дип, Маһирә сүзен дәвам итте.

—Ю-у-к, син нәлсә? Бәлеш пешелеп йөлелгә мин бит ил кеше... Бабайга булышам мин. Бабай «Ялый әле, улым, син булгансың, ату нишләлием,—ди.—Әйе бит, бабай?

Улының бу сүзеннән Нургали уңайсызланып китте шикелле. Әмма Хафизның үзен тотышына, акыллы, матур итеп сөйләшә белүенә сокланып туялмады. Алдына алып, күкрәгенә кысып-кысып сөясе килде. Тик... нигә бу омтылышына ирек бирмәде соң әле ул? Нигә тыелып калды?.. Юкса Газзәбануы да ничек куанган булыр иде бит...

—Сез үзегездә бәлеш пешермисезме әллә?—дип сорасы итте Зөлкамал.

—Әтиебез күбрәк вак бәлеш белән өчпочмак ярата. Бәлеш сирәк була. Бездә күбрәк манты пешерәләр.

—Манты дигәне ниндиерәк була? Безгә дә пешереп ашатырсың әле, Аллаһы боерса. Аннары синнән без дә өйрәнеп калырбыз,—димәсенме Зөлкамал. Гомерендә ризык пешерүнең ни икәнен дә белмәгән Маһирә:

—Манты казаныгыз бармы соң? Аның бит үзенең махсус казаны була,—дип пешереп күрсәтү мәшәкатеннән оста гына котылды.

Инде бәлешнең төбенә чират җиткәндә генә урамнан җыр, гармун

тавышлары ишетелде. Зариф абзый ян тәрәзәләрне ачып җибәрде. Якынаеп килүче егетләрне күреп:

—Җыен өчен бүләк җыючылар бу, бүген бигрәк иртәләгәннәр. Ах, шайтаннар, туры безгә киләләр бит болар... Сез кайтасын ишеткәч, бөтен авыл шау купты, кәнишне. Улым, әзрәк хәстәрләнебрәк кайта белдегезме соң?

—Бер дә борчылма, әти, сынатмабыз...—дип, Нургали Маһирәгә күз кысып алды. Маһирәсе дә, матур итеп елмаеп, иренә шулай ук күзен кысып җавап бирде. Боларның һәр хәрәкәтен күзәтеп торган Газзәбану: «Кыланмышларына тагын күпме чыдарга кирәк. Ташкиннарына тизрәк олаксалар, ичмаса, күзләрем күрмәсие»,—дип, эчтән сызды.

Ул арада йөгәннәре тәңкәләр һәм шөлдерләр белән бизәлгән, дугаларына җиз кыңгыраулар таккан һәм ике яклап кызыл башлы сөлгеләр аскан атлар ян тәрәзә каршына килеп туктадылар. Җиз кыңгыраулар вә шөлдерләр чыңлавына кушылган тальян моңы, егетләрнең җыр сузулары, аларга ияреп атларның да пошкыргалап куюлары Маһирәне тәмам әсир итте. Ул үзен, хәтта кайда икәнлеген дә онытып, гаҗәеп матур яңгырашлы музыка дөньясына килеп эләккәндәй хис итте. Бу һич көтелмәгән гүзәл манзараны күзләре белән дә күрәсе килеп, ашкынып, тәрәзә каршына килеп басты. Аны күреп алган егетләр, бер-берсе белән нәрсәдер пышылдашып алдылар да, шунда ук такмаклы җыр башладылар:

Зариф абзыйның йортына
Кунаклар кайткан диләр.
Монда чыгып безгә дә
Бәлки сәлам бирерләр.

Без алай да итәбез,
Без болай да итәбез.
Җыен батырларына дип
Сездән бүләк көтәбез.

Безгә сөлге дә ярый,
Безгә яулык та ярый,
Әгәр бирәм дисәгез,
Чиккән күлмәк тә ярый.

Яшь килен дә кайткан диләр,
Бүләге дә бар диләр.
Бүләкләрен алмыйча,
Барыбер китмибез диләр.

—Вәйт, шилмалар! Бигрәк иртәләгәннәр, бәлеш төбен тынычлап ашарга да бирмәделәр, шайтаннар. Кара син аларны, җыру да чыгарып өлгергәннәр бит. Анысына Сәгыйрь малае Хәниф мачтыр диләр. Ул инде төнәген үк мина: «Зариф абзый, быел бүләкне яшь киленегез бирер, әйтеп куегыз үзенә»,—дип лыкылдап торганые аны...

Маһирә тиз генә бүләкләр салынган чемоданнан җыенга дигәннәрен алып, Нургалигә тоттырды. Урамга чыгуга, егетләр Нургалине сырып алдылар. Бүләкләрне күреп исләре китте: кайсы тел шартлата, кайсы сызгырып җибәрә, кайсы: «Вәйт, ичмасам бу бүләк, һай, рәхмәт яугырлары, яшь киленкәебез дә юмарт икән...»,—дип сөйләнделәр. Яшь киленкәй дигәннәренең Газзәбану апаларыннан өч-дүрт яшькә өлкәнрәк икәнен каян белсен алар...

—Батыр калучыга миннән куен сәгате, ә менә бу бүләк—тальян гармун

Маһирәнең әтисе Локман абзыйдан, ә менә монысы — яшел атлас күлмәклек—Маһирә апагыздан. Ат чабышында беренче килгән егетнең сөйгәненә булыр,—дип Нургали бүләкләрне Хәнифкә тапшырды. Бүләк тальянны кулына алуга, Хәниф аны:

—Менә ичмасам бу гармун тек гармун!—дип, башта әйләндерә-әйләндерә карады, телләренә баскалап тавышын тыңлады. Аннары башын кыңгыр салып, уйнап та җибәрде. Барысы да бик канәгать калды. Тик капка төбен сырып алган бала-чага, берсен-берсе этә-төртә, һәркайсы алгарак чыгарга тырышып:

—Яшь килен апай безгә дә күчтәнәч бирер әле,—дип чыр-чу килә башладылар.

—Аз гына сабыр итегез! Улым, бар, киленгә әйт әле, алып чыксын күчтәнәч кәнфитләрен, шунсыз китмәсләр бу тишек борыннар,—дип, Зариф абзый чак тынычландырды үзләрен.

Бала күңелен күрү—Маһирәнең аерата яраткан шөгыле. Менә бүген дә, балаларның кәнфит алгандагы канәгать йөзләренә багып, үзе дә сабыйларча куанды. Әмма үз артыннан сипкелле генә бер малайның:

—Яшь килен апайның кәнфите тәмле—тәмлесен... Тик үзе әллә кем түгел бугай,—дип әйткәнен ишетеп, күңеле кителсә дә, сиздермәде, ишетмәмешкә салышты.

***

Чәйләр эчкәч, Зөлкамал:

—Улым, атаң мунчаны карап чыкты. Эссе салып исләрен дә чыгарып бетерде, миллеген дә пешереп куйды. Ә мин сөлге, җаймәләр керттем, өйалды колгасында булыр. Беренче мунчага юл кешеләре сез кирәгез. Сездән соң атагыз керер. Җомга намазына кадәр чистарынып өлгерсәгез әйбәт булыр,—диде.

Нургали авызын ачып өлгергәнче Маһирә тыныч кына:

—Беренче мунчага, Нургали, син Газзәбану белән кер инде,—дип әле Нургалигә, әле көндәшенә карап алды. Һич тә моны көтмәгән Газзәбану Маһирәгә ягымлы гына күз ташлап, «йә, син ни әйтерсең?»... дигәндәй, Нургалигә текәлде. Ә анысы сүзсез генә, мыек астыннан елмаеп, җәһәт кенә Газзәбануны әйдәкләп очар коштай булып, ишеккә юнәлде. Алар артыннан Хафиз:

—Әни, әни, дим, мин дә синең белән келәм,—дип кузгалуга бабасы:

—Юк, без синең белән икәү керербез, яме. Минем арканы синнән дә шәп ышкучы юк бит, улым. Ә хәзер Чаптарны таллыкка су буена алып төшик, аның да эчәсе киләдер,—дип, оныгын үзенә ияртте. Аларга бик теләп, әби дә кушылды. Ишегалдына чыгу белән бабай, бакча башындагы мунчага таба серле генә ым кагып, эче тулып ашкан куанычын карчыгына сиздерәсе итте. Зөлкамалы да:

—Аллаһым ярдәм итсен! Берүк ярдәм итә күрсен!—дип, бәхетле елмаеп, картының шатлыгын уртаклашырга ашыкты.

Маһирә үзен никадәр тыныч тотарга тырышса да, булдыра алмады бичара. Күңелендәге көнчелек галәмәте ташкын булып, бөтен җанын биләп алды. Нургалиенең үзенә күз дә төшермичә, Газзәбануы белән шатланышып ишектән чыгып китүләре бәгырен телгәләде. Бу минутларда ул Нургалигә рәнҗеп тә куймады микән әле. Бала чагыннан ук чикләнмәгән иркенлектә, үтә дә иркә булып, гел үзе теләгәнчә генә яшәргә күнеккән Маһирә беренче мәртәбә үзен кимсетелгән кебек тойды. Нургали белән Газзәбануның мунчада кылынырга мөмкин булган бөтен назлы гамәлләре бер-бер артлы күз алдына килде. Җәһәт кенә тәрәзәгә борылып, күзенә мөлдерәп тулган кайнар яшьләрен тыя алмыйча, тын гына елап җибәрде.

Зөлкамал өйгә керүгә, тәрәзә янагына сөялеп, боегып торган Маһирәнең сулыгып киткән йөзен күреп:

—Маһирә, кызым, өйлә намазына кадәр ак келәткә чыгып бераз ятып, ял итеп алмыйсынмы?—дип сорады.

—Әйбәт булыр иде, озак юлдан хәйран арылган,—дип, Маһирә риза булды.

«Балакайларым мунчадан чыкканда күз көеге булып утырмасын әле»,—дип уйлап, үз тапкырлыгына үзе куанып, яшь киленен ак келәткә озатты Зөлкамал.

## Сәҗидәнең төше

Ул көнне гаҗәеп бер төш күреп уянды Сәҗидә. Үтә дә ачык, нәкъ өндәгечә иде ул төш. Янәшәсендә изрәп йоклап яткан җанкисәген шәйләп алмаган булса, төшен өненнән аера алмыйча шактый иләс-миләс килеп яткан булыр иде әле. Болай да төшендәге бөтен вөҗүден яулап алган шатлык хисләреннән тиз генә аерылырга теләми иде ул. Иренә текәлеп: «Өнемдәге хыялларым матур төш булып кереп, куанычым күңелем касәсеннән мөлдерәмә ташып торган чакта ничек әле син, җаныкаем, таралып йоклап ятасын?—дип пышылдады. Әле ул гынамы—Нурисламының иреннән бик тәмләп бер үбеп тә куймасынмы. Ә тегесе сискәнеп киткәндәй:

—Нишләвең бу тагы? Торырга иртәдер бит әле?—диде дә, дорфа гына икенче ягына борылып ятты. Күр инде бу хәлне...

«И-и, бәгырь кисәгемдер шул! Каян килде әле сиңа мондый кыюлык? Рәхмәт төшкере!»—дип хатынын үбеп аласы да, кайнар кочагына гына саласы бит инде югыйсә... Нишләмәк кирәк, иренең бер генә хатын-кыз да гафу итә алмый торган битарафлыгыннан Сәҗидә гарьләнеп куйды куюын. Әмма, ни генә булса да, иртән күргән сихри төше тәэсиреннән бөтен җанын биләп алган шатлык хисләре күпкә көчлерәк иде шул. Ул, берни дә булмагандай, сабыр гына:

—Әйе, торырга иртәрәк әле, таң атып кына килә. Әле генә күргән төшемнән уянып китмәгән булсам, нәкъ синең шикелле үк мин дә изрәп йокларыем. Иллә дә матур төш, Нурислам. Әйбәткә булыр, Аллаһы боерса! Тыңласаң, хәзер үк сөйлимче үзеңә. Сөйләмичә генә йоклап китсәм, онытылыр дип куркам,—диде.

—Әйдә, сөйләсән сөйлә инде, барыбер йокымны ачып бетердең,—дип, Нурислам теләр-теләмәс кенә хатынына таба борылды.

Нигәдер тынгысыз иде ул... Кичтән дә озак кына йоклап китә алмыйча гаҗизләнде. Сәҗидәнең моңа әлләни исе китмәде шикелле. Иртәгә иртүк яшь кәләше белән Нургалине ничек каршы алачагын уйлыйдыр, дип юрады.

—Тыңла, яме; имеш, син кайтышка дип Тәскирә белән бергә коймак пешерәбез икән, дим. Коймакларның күплеге, мин сиңа әйтим: өстәлдә дә, мич алдында да, тәрәзә төпләрендә дә гел коймак. Ашап туйгысыз тәмләләр дә икән әле үзләре. Ә син кайтмыйсың да кайтмыйсың. Тәскирә балакаем, «шуынып бетәләл инде»,—дип борчыла ук башлады. Шулвакыт ишегебез үзеннән-үзе ачылып китте дә, кояштай балкып, яңа гына туган бозау күтәреп, син килеп кердең. «Менә, сезгә нинди матур бозау апкайттым»,—дисең икән. Чыннан да аның куе кызгылт тиресе ялык-йолык килеп тора, маңгаенда ярымайга охшаган ап-ак кашкасы да бар. Ә син, көлә-көлә: «Сыерыбыз минем күңелне күреп, безгә үгез бозау бүләк иткән. Өйдә ир затыннан бер үзем бит. Нурисламга иптәш булсын дигәндер инде», дисең. ...Тавык төшенә тары керә дигәндәй, сыерның бозаулар вакыты җитә дип

борчылып йөргәнгә кергәндер бу төш, мөгаен. Инде төштә күргән төсле бозаулы булуга да ирешсәк, Ходай кушып, Гайзелбәнат әбигә сәдака кертерием,—дип, Сажидә төшен сөйләп бетерде.

—Әнисе, бу төш сиңа тикмәгә генә кермәгәндер, әллә чыннан да сыерыбыз бозаулап ята микән?—диде дә, Нурислам абзарга ашыкты. Озак көттерми генә: «Шөкер, бары да әйбәт, сыерыбыз абзарны тутырып тыныч кына күшәп ята. Шәт, тиздән бозаулап та куяр, Аллаһы боерса,—дип шатланып кереп тә житте. Ташкентта акча эшләп кайтмаган булсам, сыер турында хыяллана да алмас идек бит,—дип, жәһәт кенә Сажидәсе янына, юрган эченә чумды. Бу минутларда алар икесе дә бик бәхетле иде. Ә йокы дигәннәре алардан мөмкин кадәр еракка-рак качу ягын карады.

Иртүк ирен озатып жибәрүгә, Сажидә төшен юратырга кемне генә табасы икән дип уйлана башлады. Газзәбануга кереп булмый да булмый инде, аның үз хәле хәл. Иң кулае Гыйззелбәнаттә булыр дип, бары ике өй аркылы гына япа-ялгызы яшәп яткан күршесенә йөгерде. Керә-керешкә үк аны ишегалдында очратып, күргән төшен бәйнә-бәйнә сөйләп тә бирде.

—И-и, күрше, бик матур төш күргән бит үзеңә. Юрарга керешкәнче тәһарәтемне яңартып алыйм, булмаса. Төшләрне тәһарәтсез килеш юрарга ярамый, ди торгание минем каенанам, урыны жәннәттә булсын! Син өйгә керә тор, яме,—дип, баскыч төбендәге елкылдап торган жиз комганын алып абзарга таба юнәлде.

Ул арада, бу өч кенә тәрәзәле кечкенә генә өйнең бар жиренә күз салырга өлгерде Сажидә һәм мондагы илаһи пөхтәлеккә, чисталыкка хәйран калды. Тәрәзәләрендә кашагалы ап-ак пәрдәләр, тәрәзә араларына эленгән кызыл башлы сөлгеләр, өстәлендә сөлгеләренә охшаш итеп сугылган киндер ашъяулык. Бөтен өйгә нурлар сибеп өстәлдә утырган зур жиз самавыр. Түр сәке өстендә ак сарык йонынннан басылган калын киез келәм жәелгән. Өйнең бер почмагында сыек кына зәңгәрсу төс биреп акшарланган мич. Әйтәм жирле Гыйззелбәнаттәнең миче бер дә саргаймый, акшарына синке кушадыр, мөгаен... Мич авызы ягына кыр чәчәкләре рәсеме төшкән яшел сатин чаршау корылган. Чаршавы да тәрәзә пәрдәләре шикелле бөреп тегелгән кашагалы. Ян тәрәзәдән төшкән кояш нурлары чаршаудагы чәчәкләргә жан өргән диярсең. Хәтта алар жил белән чайкалып-чайкалып та куялар шикелле. Гүя өйнең шушы почмагыннан, әйтерсең лә, чәчәкле алан башланып китә. Сажидәнең шул аланга кереп, зәңгәр күккә карап хыялланып ятасы килеп китте. Ихтыярсыз шунда таба атлый ук башлады. Әмма идәнгә күзе төшүгә тукталып калды. Гәрәбәдәй сап-сары сайгакларга басарга кыймады булса кирәк. Ишек яңагына сөялеп, жанына ләззәт биргән шушы өйнең эчен, бөтен барлыгы белән яңадан күзеннән үткәрде Сажидә. Монда хәтта кояшның да иң якты, иң шаян нурлары гына төшә торгандыр, мөгаен. Әнә, тәрәзә каршындагы балан яфраклары аша үтеп, алар өй диварларына, идән сайгакларына челтәрле бизәкләр ясап уйныйлар. Өстәлдә утырган мәгърур самавыр, ишек өстендәге пыяла астына кысалап эленгән «Аятелкөрси», кучкардагы лампаның үтә чиста пыяласы—бу шаян нурларны үзләренә жыялар да, шунда кечкенә кояшчыклар ясап балкыйлар... Ишек ачылуга Сажидә айнып киткәндәй булды.

—И-и-и, Гыйззелбәнат апай жаным, синең шикелле үз өеңдә ожмах ясап, аның бөтен жирен матурлыкка төреп яшәүче тагын кем бар икән безнең авылда? Һәр әйбереңнән әллә нинди сихри нур бөркелә. Моннан, билләһи дип әйтәм, чыгып та китәсе килми!

—Үземнең дә алай тиз генә чыгарып жибәрәсем килми әле сине. Төшеңне генә юрыйк та, жыен көнне күрше-күлән, таныш-белешләр, бала-чага керсә дип пешереп куйган бавырсак, кортлы сумсаларым белән

тәмләп чәй эчербез. Ясаган кортлы маем да бик тәмле чыкты бу юлы. Ә менә, мин ялгыз карчыкның көнелен күреп, өемне мактап әйткән жылы сүзләрең белән күнелем күкләренә ай-кояшлар индерден, Сажидә, керләр чайкый сай жирдә... дип жырлап жибәрерлек иттең бит, әй. Аллаһының рәхмәтләре яусын сиңа күршекәем! Тәненә саулык, жаныңа тынычлык бирсен Ходаем.

Төшенә килгәндә, минемчә, сыерыгыз шушы көннәрдә хәвеф-хәтәрсез генә бозаулар, боерган булса. Нәкъ син күргәнчә; аның төсе дә кызгылт, үзе үгез бозау да булыр дип тәгаенләп кенә әйтә алмыйм. Әмма Нурисламның шулкадәр шатланып йортыгызга яшь тере хайван күтәреп керүе үзегезгә зур дәүләт киләчәген сиздерә шикелле, барысы да Аллаһы Тәгалә ихтыярында. Бирәм дисәме...

—Амин, шулай гына була күрсен! Авызыңа бал да май, күршекәем! Ә менә мин, Гыйззелбанаттәй, башкачарак юраганыем. Бәлки ул тормышка ашмас хыялым гынадыр... Бозавы инде аның, билгеле, бозау күтәп йөргәнгә кергәндер. Әйтәләр бит, тавык төшенә тары кергән, чүпли-чүпли арып беткән, дип. Бигрәк тә, Нурисламның «үземә иптәшкә бер ир заты булсын»—диюен... Мин әйтәм, тәмам тазарып, яңадан балага уза башлармын микән әллә? Алла кушып, шулай була калса, арада берәрсенең малай булып куюы да бик ихтимал бит... Монарчы мине гаепләп жаныма тимәсә дә, ир баласы булмаганга кимсенеп йөри икән бит, жаныкаем...

Соңгы вакытта үземдә бер сәер үзгәреш тә сизә башладым бит әле. Әйтергә дә оят, хәтта, ярый... ярый, әйтәм инде алайса, зинһар өчен, гаеп итә күрмә. Ни хикмәттер, Нурисламым белән бергә буласым гына килеп тора башладым бит, ләгыйн. Ничек аңлатырга да белмим инде... Ә ул бер ни сизми, гырлый-гырлый йоклавын белә. Тикмәгә генә түгелдер бу, Гыйззелбәнаттәй, жаным. Тәскирәмә узар алдыннан да нәкъ шулай булганыем...

Син менә, «Киләчәктә зур дәүләтле булырсыз»,—дип юрадың. Бәлки ул дәүләт—алда туачак балаларымдыр, кем белгән? Алардан да зур байлык тагы нәрсә булырга мөмкин? Их, иллә-мәгәр, Аллаһының рәхмәте белән, шулай килеп чыкса, сарыгымның бер бәрәнен эһ тә итмичә сәдакага багышларыем. Гыйзелбәнаттәй жаным, әйдәле, авырсынмыйча гына эчемне үзеңчә баскалап карале. Ә бәлки... йә, йә инде, зинһар өчен бүлдерми генә тыңла инде гозеремне...

—Карап-карап торам да, тагын бер карап куям дигәндәй, син чыннан да бик каты үзгәргәнсең бит, күрше, хәерлегә булсын,—диде Гыйззелбәнат. Әмма сәкедә балкып яткан Сажидәнең өмет тулы мөлдерәмә күзләрен күргәч, хәтта каушап китте. Ничек итеп, «Өметләнмә, син кичергән авырудан соң, мин белгән бер генә хатын-кызның да балага узганы һәм аны житлектереп таба алганы юк әле»,—дип әйтә алсын? Шулай да, жайлап кына: «Ниемә дип бу кадәр алгысынасың соң әле син, ә? Инде шушы язмышыңа да риза булмасаң... Аллам сакласын... Әле кайчан гына үлем көтеп яткан вакытларыңны онытттыңмыни? Аннары, тәннәрең үз жанында шундый күркәм халәт туа башлаган икән, нигә дип аңа шулкадәр сәерсенәсең әле син? Бу бит бик табигый хәл һәм ул синең тәмам тазарып, тулы канлы булып яши башлавыңның бәхете ачылу дигән сүз. Иреңнән бер дә оялып торасың юк. Алар аны ничек кенә яраталар әле, жанкисәгем. Күпме хатын-кыз шушы бәхеттән мәхрүм, беләсеңме син шуны? Менә ни өчен кайбер ирләр: «Минем хатын әллә нинди шунда... тәне дә салкын, жаны да салкын—ята шунда... бүрәнә дә бүрәнә, ул да бүрәнә...—дип читтән кайнар кочак эзли башлыйлар. Ә синең Нурисламың бөтенләй башка, үзенә ярый алмаган чакларында да ташламады бит ул сине. Тазара гына күрсен

дип нинди генә җимешләр ташымады, акчасыннан да өзмәде. Әнә, ахирәтең Газзәбануга карап, азрак гыйбрәт алыр иден, ичмасам. Бар булганына шөкер ит тә: «И, бер Аллаһым, тигезлегемнән, саулыгымнан аерма. Үзең сөеп биргән бердән-бер балама бәхет бир, дип телә. Юк белән үзеңне дә, иреңне дә борчыма»,—дип үгетләп тә карады Гыйззелбәнат. Вәләкин файдасыз... Саҗидә, киресенчә, күңелсезләнә генә барды. «Үзеңне дә, иреңне дә, мине дә юк белән борчыма»,—дигән сүзләрдән соң бөтенләй коелып төште. Күз яшьләрен түгеп елый ук башлады.

—Үзең бигрәк тиз үпкәлисең инде, акыллым. Ярар, ярар, әйдә, карап карыйм булмаса, тик бик тыныч ят, эчеңне катырма, яме»,—дип эшкә керешкән булды. Ә башында бер генә, фәкать бер генә уй бөтерелде. Юк, бөтен вөҗүден көйдереп алырлык хакыйкатьне ачып, кабат сүндерергә ярамый бу баланы. Шушы көтеп алынган Җыен бәйрәме көннәрендә генә булса да, балкып йөрсен әле. Авыруыннан соң аякка басып китсә дә, ике ел буена пыскып яткан күмер төсле генә яшәде бит ул, көйрәп тә китә алмый, сүнеп тә бетми. Шөкер, уянып килә икән ләбаса... Җитмәсә, бүген яшь кәләшен ияртеп, дуслары—Нургали дә кайта. Ташкенттан кайткан әрсез кәләш алдында күңелсезләнеп йөреп, ничу сынатырга...

—И, и, күрше, тикмәгә генә ымсынып йөрмисең ахры син. Менә бу төшендә нидер тоям бит... тоям!—дигән булды.—«Аллаһының кодрәте киндер, житенне әйләндерсә киндер»,—дип әйтергә ярата иде картым. Урыны җәннәтнең түрендә булгыры. Тик, караны, беркемгә дә әйтәсе булма, хәтта Нурисламыңа да. Алдан кычкырган күкенең башы ярыла,—дигәнне беләсеңме? Яман күзләрдән, яман телләрдән Аллам сакласын! Мондый вакытында хатын-кызга үтә дә күз тиючән була, ишетсен колагың! Вакыты җиткәч, үзем әйтермен. Сабыр гына көт, балакаем... Җыеннар үтеп, Нургалиләрне озаткач, бер иркен арада, тагын бер карармын, Аллаһы боерса.

Бу сүзләрдән соң Саҗидә сикереп торды да, Гыйззелбәнатның кулларын үбә-үбә болай диде:

—Чын, коеп куйган духтыр бит син! Мине үлемнән йолып алучы да син булдың бит, рәхмәт төшкере! Әллә нинди гыйлемлекләрең бар бит, каян килә алар сиңа, Гыйззелбәнаттәй җаным? Менә хәзер дә нәкъ мин көткәнне әйттең дә бирдең бит! Бая әйткән сәдакам сиңа булыр, боерган булса! И-и, бу тормыш дигәннәре, иркенләп, рәхәтләнеп бер утырган да юк. Үзең турында да никтер берни сөйләмисең. Газзә белән безнең шикелле, төп бу авылныкы түгел икәнеңне ишеткәнем бар-барын. Шуннан кала, берни дә белмим.

—Әйе, мин дә сезнең шикелле үк, бу авылга килен булып төшкән кыз,—диде дә, тормышындагы хәтта сөйләргә дә ярамый торган фаҗигале вакыйгалары исенә төшеп, авыр сулап куйды Гыйззелбәнат.—Ярар, икенче бер вакыт сөйләрмен әле, ә хәзер чәй әзерлик,—диде.

Кая инде ул чәйләп утыру Саҗидәгә... Очар коштай булып өенә атылды. Капкадан кәрә-керешкә Тәскирәсе разбой салып:

—Әни, әни, дим, нишләп, кайда йөлишең син? Кайттылал, күлми калашың бит инде. Әйдә тиженәк бул инде...

—Сабыемдыр шул, ул кунакларны миңа бик күрсәтәсең киләмени соң? Ә минем, беләсең килсә, алардан бигрәк әтиеңне күрәсем килә. Әтиеңне күралдыңмы соң? Кайда калды әле үзе?

—Кайда калшын, шунда... Теге матул апай, кунак апай янында утылып тола. И-и, әни, шин ул апайның үҗен күлшәнме... Ә кигән киемнәлен күлшәң... Хафиҗның әтише дә безнең авылдагы әтиләл төшле түгел икән ул. Үҗе матул, үҗе әллә кем төшле шунда... Әйтеп тә, шөйләп тә булмый...

—Кунак апайны ошаттың инде алайса, име?

—Әйе, әни, Хафишның әтише кунакка әнә нинди матул апай апкайткан. И-и, анда шундый күнелле, малайлал, кызлал... бөтенеше кунаклалны калый... Бежнең әти нишләп үже генә кайтты икән ул?

Сабыйның бу соравына Сажидә эченнән генә: «Аллага шөкер!»—дип уйласа да, түзмәде, көлемсерәп куйды:

—Нигә көләшең шин, әни, ә? Миңа ышанмашаң үжең кел дә кала,—дип ирееннәрен турсайтып, үпкәсен белдерде Тәскирә.

—Йә, үпкәләмә инде, сиңа ышанмыйча кемгә ышаныйм соң мин? Шулай да, анда кереп йөрмәскә булдым әле. Син тизрәк әтиеңне алып чыга алсаң, бик шәп булырие. «Коймаклар суына, әни безне көтә, борчыла»,—диген яме. Бар, кызым, бар... Ә мин тиз генә коймакларны пешерә башлыйм.

Күп тә үтмәде, алар, аталы кызлы көлешә-көлешә, җитәкләшеп кайтып та керделәр. Әтиләре бик серле генә елмаеп:

—Әнисе, коймакларың шуынамыни шон?—дип Сажидәгә күз кысып алды.

—Анысын суынса да җылытып булырые әле, ә менә сине көтә-көтә коймак пешерүче үзе суынып китсә, анысын ничек җылытырсың икән?

—Шәт, без дә аптырап калмабыз, Сажидә. Аулак кына бер җирдә кер чайкарбыз сай җирдә...

—Кел чайкалга мин дә балам, мин дә балам,—дип ашыга-ашыга Тәскирә дә сүзгә кушылды. Өчесе дә дөньяларын онытып, бик рәхәтләнеп көлештеләр аннары.

## Җомга намазы

Ул көнне Җомга намазына килүчеләр шул кадәр күп булды ки, мәчетнең эче генә түгел, хәтта алгы ягында да халык шыгрым тулы. Мәхәлләдәгеләрдән тыш, читтән җыенга килгән кунаклар да бик теләп катнашты бу намазга. Житмештән үтеп баручы, гаять зур мәгълүматле, Көектә генә түгел, тирә-күрше авыл халкының да хөрмәтен казанган Фарук мулла вәкарь белән генә михрабка үтте. Җомга намазына килүче бихисап халыкның балкып торган йөзләрен күреп: «Сүбхааналла, бәәракалла! Әлхәмдүлиллаһ! Бу шатлыклы көннәрне дә безләргә, Синең каршыңа баш иеп килүчеләргә, насыйп әйләдең бер Аллам, шөкер! Моннан соң да рәхмәтеңнән берүк ташлама! Кабат ачлык михнәтләрен күрсәтмә!»—диде.

Намаз халкы аны дәррәү «А-ми-ин» дип җөпләп куйды. Бу намазга яшьләрнең һәм ата-бабага ияреп, бәйрәмчә киенгән сабыйларның күпләп килүләре Фарук мулланы аерата куандырды. Алгы рәттә Зариф абзый белән үтә дә затлы киемнәрдән Нургали, алар уртасында ифрат та горур кыяфәттә басып торучы Хафиз—өч буын... булдымы... Янә дә алар янында туксан яшьләрдәге Сәгыйрь абзый, аның улы—җитмешләр тирәсендәге Кадыйр, аның да—иллеләргә җитеп килүче улы Сабир, һәм Сабирнын улы—яшь егет Заһир—болары дүрт буын. Дүрт буын!.. «Шөкер, Аллаһы Тәгаләм юлындагы кырык елларга сузылган хезмәтләрем бушка китмәгән икән»,—дигән уй белән рухланып, мулла абзый быелгы җомга вәгазен аеруча тәэсирле итеп башкарды.. Ошбу илаһи вәгазьдән соң укылган намаз да гадәти генә булмады шикелле. Аның үтәдән-үтә ихлас укылуы өлкәнрәкләрнең яшь тулы мөлдерәмә күзләрендә бик ачык чагыла иде.

Намаз артыннан ачлыктан үлгән барлык әрвахларның рухларына багышлап озаклап дога кылдылар. Мулла абзыйның ачлыктан тилмереп үлгән авылдашлары рухына дигән бу изге догасын, бүген беренче мәртәбә, һәрберсенең тулы исемен атап багышлавы да халыкка нык тәэсир итте. Чөнки мәрхүмнәрнең саны бихисап иде шул... шаккатырсың, хәзрәт ник

берсен онытып калдырсын! Аның хәтер байлыгына, зиһененең зирәклегенә сокланмаган кеше калмагандыр, мөгаен. Ә аның гомере буе авылдагы һәр үлемне көне-сәгате белән калын дәфтәренә генә түгел, күңел дәфтәренә дә яза барганын монарчы күпләр абайламагандыр да.

Халык тарала башлагач, Фарук мулла Зариф абзыйларга, сөйләшәсе сүз барлыгын белдереп, калырга кушты. Сөйләшү вакытында Хафизның булмавын теләде. Хәл-әхвәл сорашканнан соң ул Нургалинең Ташкентта укыткан никахы белән кызыксынуын белдерде.

—Моннан өч ел элек без синең читтә кабат никахлашуың турында ишеттек. Инде менә яшь хатыныңны авылга да алып кайткансың икән. Анда өйләнүең ничегрәк килеп чыкты соң, Нургали улым?—дип мәхәлләнең аерата үзе никахлаган һәр кешесе өчен Аллаһы Тәгалә каршында үзенең гаять җаваплы булуын искәртеп сорау арты сорау яудырды хәзрәт.

—Кабат өйләнеп куюым, мулла абзый, үзем өчен дә көтелмәгәнрәк хәл булды ул. Бу турыда әтинең дә бик беләсе килә. Әгәр рөхсәт итсәгез, өйләнү тарихымны, сезгә яхшырак аңлашылсын өчен, тулырак итеп сөйләми булмастыр, мөгаен.

Хуҗабыз—Локман абзый эшли башлаган көннәремнән үк нигәдер бик якын итте мине. Өйләренә дә чакыргалый башлады. Маһирәне беренче мәртәбә күрүем дә шунда булды. Ул Петербурда гимназиядә укыган, зур гыйлемле, акыллы кыз. Ташкентта акушерлар әзерли торган техникумда урыс телен укыта икән. Әтисе кушкач, мине дә укыта башлады бу. Аннан соң Локман абзый үзе дә, сәүдә буенча зур белгечләр чакырып, миңа дәресләр бирдертте. Барысы да «сәләтле егет тә сәләтле егет, монда өмет бар...»—дип мактый тордылар. Миңа аларда, кайвакытларда кунып та калырга туры килгәләде. Менә шулай бер-беребезгә гел ияләшә башлаганбыздыр инде. Локман абзыйның хатыны Җиһан апа да миңа «улым» дип кенә дәшә торган булды. Алардагы ашау-эчүне әйтеп тә торасы юк—бер дә галәмәт. Баштарак оялыбрак торсам да, соңарак кыюланып та киттем бугай. Без, укымаган авыл малайлары, нәрсә беләбез инде, Маһирә мине тора-бара әкренләп кайда, ни вакытларда үзеңне ничек тотарга, ничек киенергә, хәтта ничек сөйләшергә кирәклеген дә өйрәтүне үз өстенә алды. Үзенә «Маһирә туташ» дип дәшергә кушты.

Шулай беркөнне, мин боларга килеп керсәм, Маһирә пианино дигән уен коралында уйнап, җырлап утыра. Озын, бик тә озын вә моңлы кой, әллә нишләп киттем. Җырлавыннан туктамаса гына ярарые дип, сиздермичә генә, якынрак килеп тыңлый башладым. Йөрәкләрне телгәләп, күздән яшьләр агыза торган, үзәк өзгеч җыр...

> Төн уртасы җиткәч тә, бер кыз елый, Зөлхиҗҗә,
> Яшь гомерем заяга, ай, үтә, дип Зөлхиҗҗә.

Бөтенләй көтмәгәндә җыр өзелде. Йа Ходаем, ни күрәм... Маһирә кулларына капланып, нигәдер елый ук башлады. Миңа, ничек сиздермичә кергән булсам, шулай ук чыгып та китәргә кирәккәндер бәлки. Ә мин, дурали:—Маһирә туташ, сиңа ни булды?—дип аның иңнәренә кагылганымны сизми дә калдым. Ул сискәнеп башын күтәрде дә, ишетелер-ишетелмәс кенә:

—Нигә син монда? Җырымны да ишеттеңме?—дип миңа таба борылды. Әмма елавыннан туктый алмыйча, күз яшьләренә чыланып беткән йөзе белән, күкрәгемә капланды. Ә мин нишләргә дә белмим, каттым да калдым. Маһирә минем бу халәтемне башкачарак аңлады дип әйтимме...

—Зинһар, гафу ит,—диде дә, куллары белән йөзен каплап, тиз генә икенче бүлмәгә кереп югалды.

Берәр атна тирәсе аларга барырга кыймый йөрдем, гәрчә күңелем көн дә шунда тартылса да. Бер көнне Локман абзый үзе:

—Нургали, бүген эштән соң кичке ашка безгә рәхим ит. Ә хәзер бер җиргә сугылыйк әле,—диде. Эш буенча чакыра торгандыр дип уйладым. Ә ул мина модный киемнәр сайлау өчен булган икән. Болай да өс-башым ярамаслык түгелие түгелен.

Барган җиребездә мине шундый итеп киендереп куйдылар ки, көзге каршына килгәч, хәтта үземне танымадым. Локман абзый: «Кичкә көтәбез...»—дип елмаеп озатып калды үземне. Менә шул кичтән безнең Маһирә белән очрашулар ешайганнан ешая барды.

Шулай бер кичне без өйдә икәү генә калганбыз. Маһирә тыныч кына:

—Әтиләр бүген дусларына куна киттеләр,—диде.

Чәйләр эчтек. Ул озак кына пианинода уйнады. Мине дә үзе белән рәттән утыртып, бу уен коралының кайбер серләрен аңлата башлады. Тальянда уйный белгәнгә микән, ул серләргә мин тиз төшендем.

—Син музыкада сәләтле булырга охшыйсың,—дип колларыма кагылды. Миңа әллә ничек бик рәхәт булып китте. Бу илаһи рәхәтлек бөтен тәнемә таралды. Маһирәне кочагыма тартып алганымны сизми дә калдым. Ул да карышмады, киресенчә, минем бу халәтемне күптән көтеп торгандай, бөтен гәүдәсе белән куеныма сеңде. Күпмедер вакыттан соң, ниһаять, мин акылыма килдем.

—Маһирә туташ, гафу ит. Онытылыбрак киттем ахры. Сиңа булган олы хөрмәтемә тап төшерәсем килми. Хатыным, балам була торып сине рәнҗетергә теләмимм,—дидем.

—Нинди гафу, нинди рәнҗетү турында сөйлисең?.. Мин барын да беләм бит. Хәтта Газзәбануыңны үлеп яратуыңны да беләм. Ә мин җүләр кыз, барысын да белә торып сине яраттым. Күпме көттем мин синең белән бүгенгедәй очрашуыбызны. Бер Аллаһым Үзе шаһит. Менә кемнән гафу үтенергә тиеш мин, Нургали. Сине безгә гел мине сынамак өчен җибәргәндер, бәлки... Ә мин?.. Бу очракта син түгел—мин гафу итүеңне сорарга тиешмендер,—диде дә, күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, теге көндәгечә, йөзе белән күкрәгемә капланды.

Шуннан соң берәр атна узды микән, әйтә алмыйм. Беркөнне Локман абзый өйләренә мулла чакыртып, безгә никах укытты. Менә шул көннән без ир белән хатын булып яши башладык.

Фарук мулла Нургали сөйләгәннәрне бүлдермичә, түземлек белән тыңлап:

—Ярый, ни хәл итәсең. Үз җиребездә ачлык булмаса, син дә анда китмәсиең. Шулай язгандыр, күрәсең. Үзем укыган никахларымның шөкер, монарчы бозылганы булмады, дип беләм. Андагы мулла олы хатыныңның ризалыгы барлыгын сорадымы соң синнән?

—Ул турыда бөтенләй сүз булмады.

—Хуҗаң, кызын тизрәк кияүгә бирү өчен, синең гаиләле кеше икәнлегеңне әйтеп тә тормагандыр, бәлки.

—Алай кирәклеген Локман абзый әллә үзе дә белмәде микән?

—Болай булгач, оланнар, сезнең ул никахыгыз дөрес булмаган бит. Кабат никах олы хатын ризалыгын биргәндә генә укыла. Әгәр инде икесе белән дә никахлы булып шәригатьчә яшәргә теләсәң, шәригать кушканча эшләргә кирәк,—дип аңлатты Фарук мулла.

—Газзәбануны өзелеп яратам, балам да үсеп килә. Алардан башка тормышымны күз алдына да китерә алмыйм. Хәзер миңа Маһирә дә бик якын, аңа хөрмәтем зур. Локман абзыйның да яхшылыкларын ничек онытасың?

Ике якны да тынлап бетергәч, Зариф абзый:

—Болай булгач, Газзәбану киленнән ризалыгын алып, никахны өр яңадан үзебезнең өйдә укытырга кирәк,—дип нәтиҗә ясады.

—Рәхмәт, әти! Мин ике куллап риза. Ә Газзәбану ризалык бирмәсә нишлибез?

—Анысына үзең тырыш инде, улым. Безне катнаштырма...

—Никахыгызны шәригатьчә яңартканчы ата-баба нигезенә вә үзеннән дә кендек каның тамган туган нигезенә гөнаһ кертүдән саклан инде син, улым. Нигезебезнең пакьлеген саклау—һәр барчабызның изге бурычыдыр,—дип кинәшен дә бирде хәзрәт.

Аннан соң ул, шыпырт кына, Зариф белән Нургалигә күңелен борчыган шик-шөбһәләрен дә белдерәсе итте.

—Сез инде сер сыймаслык кешеләр түгел, соңыннан мин әйткәннәрне кемгәдер сөйләрсез дип тә уйламыйм. Соңгы вакытларда динне кысарга маташалар. Сәүит тирәсендә йөрүчеләр мәчетне бөтенләй ташладылар. Фатыйх рәис булып алгач, атасын җомга намазына да җибәрми хәтта. Бер көнне миңа: «Балаларга исем кушу, яшьләргә никах уку эшләрен туктатырга туры килер. Сиңа мәетне зиярат кылу хезмәтләре генә рөхсәт ителә»,—дип кисәтеп чыгып китте. Өстән шулай кушалар, ди. Бүгенге ихластан-ихлас укылган җомга намазыбыз да соңгысы булмагае дип шикләнәм... Аллага тапшырдык...

Шулай да сезнең никахыгызны яңартуны, Газзәбану килен ризалык бирсә, үз өстемә алам, Нургали. Тик аны китәр көнегез алдыннан гына, күрше-күләнгә бик сиздермичә башкару мәслихәтрәк булыр. Шаһитләр турында да уйлашыгыз, көнен хәбәр итәрсез. Ястү намазыннан соң укып китәрмен, Аллаһы боерса...

***

Өлкәннәрнең сүзен тыңлап, мәчеттән чыгып китсә дә, гает намазыннан соң, Хафизның өйгә ялгызы гына кайтып керәсе килмәде. Берничә малай белән кибет янында туктап калды, әмма күзе гел мәчет юлында булды. Ә әтиләре күренми дә күренми... Әнә чыгарлар, менә чыгарлар дип көтә-көтә аптырагач, әллә күрми калдым микән, дип шикләнеп, ялгызы гына кайтып кергәч, әнисе гаҗәпләнеп:

—Улым, әтиләрең кайда? Нигә бергә кайтмадыгыз? Күршеләр әллә кайчан кайттылар бит инде. Без монда әбиең белән «безнекеләр дә кайтып җитәрләр», дип самавыр яңарта-яңарта да арып беттек инде. Бар, балакаем, кунак апайны да чакыр, ул да баядан бирле аптырап ятадыр,—дип Хафизны келәткә җибәрмәкче булды.

—Юк, әни, мин киттем әле. Әти белән бабайны хәзер үзем апкайтам,—диде дә, ишеген дә ябып тормыйча йөгереп чыгып та китте. Аның артыннан: «Ай күрде, кояш алды малаеңны»,—дип әбисе куанып калды.

Мәчет тыкрыгын борылуга, капкадан чыгып килүче әтиләрен күреп, сабый, очар коштай булып, аларга таба атылды. Әтисе дә адымнарын тизләтеп, кулларын җәеп улы каршына ашыкты. Һай, бу минутларда Нургали йөзендәге бәхет тулы елмаюны һәм аның газиздән газизен күкләргә чөярдәй итеп күтәреп алуын Газзәбануы күргән булса, гомере буе ирен гел шул кыяфәттә генә күз алдына китереп яшәгән булыр иде. Яшь ананың тулы бәхете—нарасыен кулына алып, аның үзенә генә хас хуш исен исни-исни, сөт тулы күкрәкләреннән имезә алуы белән генә чикләнә алмый. Тулы бәхет өчен иренең дә баласын кулына алырга ашкынып торуын, инде кулына алгач, йөзендәге бәхетенең ташып торуын күрү дә үтә зарурдыр.

—Үскәнемдер шул, бердәнберем, акыллым...—дип тагын да әллә нинди

матур сүзләр әйтергә теләсә дә, улының бөтен игътибары бабасында булуын күреп туктап калды.

—Бабай, син нигә алтта каласын? Кызулак атла инде, әни дә, әби дә сезне көтә-көтә көтек булдылал. Нулислам абыйның кайтканына да бишбылтыл,—дип Хафиз өйгә тизрәк кайтып житәсе килүен белдерде. Ә бабасы өчен бераз арттарак калып, үзенә иң кадерле шушы ике жанның бәхет дингезендә йөзгәннәрен карап кайтудан да ләззәтлерәк тагын ни булырга мөмкин? Күпме көтте, күпме догалар укып, Раббысыннан сорады ул шушы минутларны!

Кибет янына житәрәк, андагы малайларны күреп алуга, Хафиз әтисенең колагына пышылдады:

—Син мине хәзел төшел инде. Әнә ул малайлал миннән гел көләләл. «Синең әтиең юк, ул сине ташлап киткән»,—диләл. Хәзел күлсәләл: «Бәбәй, бәбәй булгансын»,—дип көлмәсеннәл әле...

Әтисе аны шунда ук жиргә бастырып, кулыннан житәкләп алды да, шыпырт кына:

—Улым, өйгә кайткач, кунак апайны күрдеңме соң син? Ул да безне шулай көтә микән?

—Белмим, мин аны күлмәдем. Әни аны келәттә диде. Йоклыймы шунда...

Нургали Маһирә белән кабат никахлашырга тиешлекләрен, әтисе белән килешеп, Газзәбануга җыен узгач кына, ә Маһирәгә бүген үк әйтергә кирәк дип санады һәм капкадан керә-керешкә келәткә күз салды. Ишеге ачык. Ишеккә эленгән чаршауның бер чите чак кына ачылып киткәндәй булды. «Э-һе-е, Маһирә монда булырга тиеш»,—дип уйлап, җәһәт кенә чаршауны ачып җибәрде. Ирен көтә-көтә зарыгып беткән Маһирә, хәтта үз-үзен белештермичә, Нургалинең күкрәгенә капланды. Тыны кысылудан күпмедер вакыт башын да күтәрә, әйтергә теләгән сүзен дә әйтә алмады. Бу минутларда аның бар теләге—ничек тә түзәргә, күз яшьләрен күрсәтмәскә, күңләгәнен сиздермәскә... Әмма никадәр генә тырышса да, иңбашларының дерелдәвен басарга көче житмәде. Көтмәгәндә бу хәлдән сагаеп калган Нургали:

—Абау, жаным, нишләвен бу, әллә елыйсың инде? Ни булды, Газзәбану белән сүзгә килмәгәнсездер бит?—дип сүз башлады.

—Юк, берни дә булмады. Сүзгә килергә безнең рәтле-юньле сөйләшкәнебез дә юк бит әле. Нишләп шулкадәр озак тордыгыз? Нурисламның кайтканына да байтак булды бит инде. Моннан соң берүк алай үземне генә озакка калдыра күрмә, яме. Бу келәттә бер ялгызым әллә ниләр уйлап бетердем. Ә син ансат кына: «Без кайтканчы юынып чык, мунча бик шәп,—диден дә китеп тә бардың. Сездән соңгы мунчада, ялгызым гына мөмкинме бу... Кайтканыма да үкенеп куйдым. Әле бер башланмаган тагын тугыз көн торасы бар бит. Ничекләр генә түзәрмен,—диде дә, яшь тулы мөлдерәмә күзләрен иренә күрсәтмәс өчен кабат аның күкрәгенә капланды.

—Маһирә, тукта, бәгырь, алай түземсезләнмә. Сабыр бул. Әле монарчы уйлап та карамаган яна сынаулар көтә икән бит безне. Монысына, бигрәк тә, син әзер булырга тиеш.

—И, Раббым, биниһая, эчем пошканые аны, хәерлегә булмаган икән... Нинди сынаулар?.. Аңлатыбрак сөйлә инде, зинһар.

—Чү, Маһирә, ишек янында кемдер йөри шикелле. Йә, тыңла, тиз генә сөйлим дә, аннары өйгә керербез, көтәләрдер... Намаздан соң Фарук хәзрәт безнең калуыбызны сорады. Ни өчен икәнен хәзер сиңа да аңлатырмын,—диде дә, келәт ишеген ябып, Маһирәне кочагына алды һәм назлап кына алдына утыртты. Алай-болай чит колаклар ишетә күрмәсен тагын дигәндәй, ярым пышылдап, сөйли башлады.

—Син менә, ник кайтканыма да үкенеп куйдым, диден. Моны безгә Аллаһыбыз Үзе кушкан булып чыкты бит әле. Бүлдермәле, бүлдермә, ничек дип инде... сабыр гына тыңласанчы. Ишек алдында кемдер йөри бугай...

Кемдер дип шикләнгәне «Ялгыз чакларында аз булса да сөйләшеп алсыннар инде балакайлар»,—дип келәт белән абзар арасында вакыт сузып йөргән Зариф иде.

—Фарук хәзрәт безнең ничек никахлашуыбызны җентекләп сорашты. Билгеле инде, мина барын да сөйләргә туры килде. Шуннан соң ул безнең никахыбызның шәригать кушканча булмаган, моңарчы ирле-хатынлы булып яшәвебезне гөнаһ кылу булган диде. Хәзер сез, кайткан көе, Газзәбануның ризалыгын алып, никахыгызны яңартырга тиешсез, диде. Шунсыз сез монда, аерата ата-баба нигезендә гөнаһка керә күрмәгез, моңарчы кылган гөнаһларыгызны Аллаһы Тәгаләнең ярлыкавын сорагыз, диде. Газзәбану килен ризалыгын бирүгә миңа хәбәр салырсыз, никахыгызны шәригать кушканча үзем яңартырмын, Аллаһы боерса, диде.

—Нургали җаным, ә Газзәбануың риза булмаса...

Нәкъ шул вакытта тышкы яктан: «Нургали, Маһирә килен, әйдәгез, сезне генә көтәбез... Ашка Нурисламнар да чакырулы, алар да килеп җитәр»—дигән тавыш ишетелде.

Һич көтелмәгән шомлы хәбәрдән болай да каушап калган Маһирә бу тавышка дертләп китте. Юк, сөйләшеп бетерик инде, дигәндәй, иренең беләген чытырдатып кысты. Зариф та алай ашыгып дәшәсе түгел иде дә бит, нишләсен. Инде көтә,көтә түземлеге тәмам төкәнгән Газзәбану үзе өйдән чыгып килә иде шул.

Нургали Маһирәне йомшак кына кочып алды да шыпыртлап кына: «Ярый, тынычлан. Калганын соңыннан сөйләшербез, керик инде, көтәләр бит,—дип, келәт ишеген әкрен генә ачып җибәрде.

Каршыларына бакча ягындагы арт капкадан Сажидәсе белән кызын ияртеп, авызын ерып, сөйләнә-сөйләнә Нурислам да килеп керде.

—Ну, ма-ла-ай, бездән калгач, җомга намазын әллә өр-яңадан укыдыгыз инде... Көттереп тә карадыгыз... Мә, дус кеше, син яраткан бу күчтәнәчебезне табынга үзең турап куярсың. Син аны бик оста башкарасың,—дип, ашап түгел, карап та туймаслык каклаган казны Нургалигә сузды.—Ә менә бу очып китәрлек юка кош телләрен Ташкент кунакларына дип Сажидә белән Тәскирә кызым бергә пешерделәр. Авыз итеп карале, Маһирә, Нургалиеңә дә каптыр, бәлки әле ошап та куяр...

Маһирәгә бу минутларда үзен кулга алу авыр, һай, бик авыр иде. Нурисламнарга елмаерга тырышуын да күңеле белән түгел, фәкать ачылыр-ачылмас иреннәре аркылы гына көчкә сытып чыгара алды. Күзләре исә кызын җитәкләп беразгына читтәрәк басып торган мөлаем йөзле Сажидәгә төбәлде. Нурисламның җылы сүзләре һәм үзен туганнарча якын тотуы эзсез калмады, әлбәттә. Маһирәгә дә җан кергәндәй булды.

—Менә нинди матур кешеләр сез, рәхмәт төшкерләре...—диде дә, бер кош телен кабып та җибәрде.—Бигрәк тәмле булган, авызда эреп кенә китә,—дип, җамыякны үз кулына алды. Ни гаҗәп, йотып җибәргән шушы кечкенә генә бер кош теленнән җанына сихәт тапкандай, хәтта тынычланып киткәндәй булды. Сажидә белән очрашуны шөбһәләнебрәк көтә иде ул. Ни генә әйтсән дә, көндәшенең ахирәте бит. «Шөкер, рәхмәтле Аллам, моннан соң да рәхмәтеңнән ташлама!»—дип уйлап куйды да, ниндидер бер җиңеллек белән: «Нургали, ач авызыңны, сиңа да каптырыйм әле, әткәй әйтмешли, тик телеңне тотып тор, йотып җибәрә күрмә, бел аны»,—дип, иренең шаярып, зур итеп ачкан авызына бер кош телен шудырып та җибәрде.

—Абау, бу кош теленең тәмлелеге... Үләм, кош теле белән үз телемне

дә йотып җибәргәнмен бит. И-и, Тәскирә матурым, ичмаса син дә тотып калмадың, инде нишләрбез икән?

Рәхәтләнеп көлештеләр. Өлкәннәрнең бу матур шаяртулары Тәскирәгә бик тә ошады. Бөгелә-сыгыла бөтен ишегалдын яңгыратып көлде балакай. Гөнаһсыз сабыйның шулай онытылып көлүен Маһирә челтерәп аккан чишмә тавышына тиңләде. «Сайрар сандугачтыр син!»—дип сокланып, Тәскирәнең алсуланып торган бит уртасыннан үбеп алды һәм баланың гел йодрыклап торган бер кулына игътибар итеп:

—Акыллым, син дә миңа күчтәнәч алып кердең мәллә? Баядан бирле карап торам, уң кулыңда нидер бар түгелме соң?—дип сорап куйды Маһирә.

—Әйе!—Тәскирә учын ачып җибәрде. Карасалар, анда кызыл билле бер прәннек. Учында озак тотудандыр, дымлана да башлаган.

—Шиңа түгел, Хафижга ул күштәнәш. Шиңа булды бит инде...

—Кешеләрнең Хафижы бар икән бит, кунак апасы... син әле белмисеңдер?—дип Нурислам да сүзгә кушылды. Тагын тәмләп көлештеләр.

Бала белән шулай мәш килгәндә, чулпыларын чыңлатып Газзәбану да күренде.

—Карале боларны, бездән башка гына бәйрәмне әллә монда ясап яталар инде? Кайчаннан бирле без аларны көтеп утырабыз...

—Киттек, киттек, әнисе, әле менә күршеләр кергәч кенә бераз тоткарландык,—дип Нургали Газзәсен култыклап алды.

Зарифның баскыч төбенә чыгып, кулындагы озын саплы агач чүмечне әйләндергәләп торуын күргәч, егетләр бер-берсенә күз кысып, серле генә елмаештылар. Хатын-кызларны салпы якларына салам кыстыра-кыстыра алдан үткәреп җибәрделәр дә, үзләре озын чүмеч артыннан тиз генә мич арасына шудылар. Мич башының горур падишасы, чиләк ярым керешле, зур кувшинга охшаган мәһабәт чүлмәк яныннан кайсы гына ир тукталмыйча, сәлам бирмичә үтә алыр икән? Мич кырыена җайлы гына кечкенә баскыч та куелган булып чыкты.

—Башта чүлмәкнең тышкы ягына колагыгызны куеп, аның эчке җанын тыңлап карагыз! Сезне көтә башлаганына бүген нәкъ бер ай,—диде Зариф.

Егетләр дә шаян... Нурислам чүлмәккә колагын куюга:—Сөбхааналла! Әйбәт, бик әйбәт пышылдый, җанкисәгем! Беләсезме, мин моны нәрсәгә охшатам: хатын-кызлар төн уртасы җитәрәк, нидер пышылдап, әкрен генә безнең җылы куенга кереп сеңәләр бит әле... Чүлмәкнең эчке җаны да нәкъ шулай пышылдый. И-и, малай, әллә ниләрне искә төшерә бу... —дип хыялга бирелде.

—Азып барасыз, тәмам азып барасыз бит, шайтаннар,—дип елмаеп куйды Зариф.—Ярар, ни генә булса да, газиз башкайларыгыз сау булсын!—дип, бисмилләсен әйтте дә, чүлмәк авызын ачып җибәрде.

—Һа-а-ай, моннан бөркелеп чыккан искитмәле гаҗәеп хуш ис, тынга килеп капланды да, күңелләрне иләсләндереп җибәрде. Димәк, тәме дә көче дә шәптер...—дип дустына күз кысты Нургали.

—Булса да булыр икән... Бөтен җанынны рәхәтләндереп, хәтта башларны әйләндереп җибәрерлек илаһи хуш ис бу. Шул исеннән генә дә исерерсең, валлаһи! Күпме кешеләрдә сынаганым бар, Зариф абый, бары сезнең чүлмәктән генә аңкый ул. Әллә аның үзенә генә хас берәр сере бармы?

—Тәмле теленә бал да май, күрше, рәхмәт!—дип Зариф чүмечен тутырып әчебалны сосып алды да, мич кырыена куелган ике чокырга тутырып салды.—Менә хәзер, бисмиллә әйтеп, тәмен дә татып карагыз. Сезгә дип

куана-куана әзерләгән шушы сыемда нәрсә, исләре, янә нәрсә тәмнәре барын да дөрес әйтеп бирә алсагыз, йоклар алдыннан Аллаһы боерса, үзегезгә тагын берәр чокыр тамар...—дип, Зариф егетләргә карап серле генә елмайды. Ә тегеләре, озаклап, йотым саен туктала-туктала мактап, рәхмәтләрен дә әйтергә онытмыйча, иллә дә тәмләп эчә торгач, чокырларын бушатып та куйдылар.

—И-и, рәхмәт төшкерләре, сыемның кадерен вә бәһасен белүегезгә мин бик шат. Менә монысы әчебал артыннан кабымлыгы буладыр дип, Зариф икесенә дә тәлинкәгә кечкенә генә шакмаклап киселгән сап-сары кәрәзле балның берәр кисәген алып кабарга кушты.

—Әти, син, «Бу малай шул гомер авылга кайтмый торгач, бал кортлары турында да уйлап карамады, әчебалымның да тәмен күптән онытып бетергәндер инде»,—дип уйлаганыеңмы әллә?

—Дөресен әйтим, жан дустың сөйләвенә караганда, сез бит анда француз шампаннары белән генә сыйланып ятасыз. Минем балга артык исе китмәс дигән шигем барые шул, балакаем.

—Әйттең сүз, Зариф абый... Синең әче балыңмы-ы?! Шампаннарыңны бәреп ега бу! Француз үзе дә бу балны татып карасамы?! Валлаһи дип әйтәм, шампанын бер читкә этеп кенә куярые. Тик бу хәзинә аларга тәтеми шул... Зариф абый, бездән яшермичә дөресен генә әйт әле, ничекләр ирешәсең син бу осталыкка? Әллә берәр серле догасын беләсең инде?—диде дә Нурислам чокырындагы соңгы тамчысын да йотып куйды.

Дүрт ел буена бердәнбер улын көтеп, сагыш утларында янган Зарифның күңеле тәмам тулышты. Шатлыктан мөлдерәмә күзләрен Нурислам белән янәшә басып торган газизеннән аерып ала алмады. Керфек араларыннан ихтыярсыз шатлык яше сыгылып чыкты. Бәхетле, бик бәхетле иде ул бу минутларда. Үзен җирдә түгел, күкнең җиденче катында итеп хис итте: хәрәкәтләре җинел, күңеле каядыр очына. Карап торышка да яшәреп үк китте хәтта. Кайтканнан бирле улының үзенә булган олы ихтирамын тоеп ләззәтләнде Зариф. Ата күңелен бәхетле итәр өчен әлләни күп тә кирәкми шул...

Көтмәгәндә мич арасында икенче бәхетле жан, бөтен йөзенә кояштай елмаю кунаклаган Зөлкамал пәйда булды.

—Карале боларны, безнең якка чыгарга уйламыйлар да. Чүлмәк булгач— шул житкән ахры. Калган сүзегезне табын янында сөйләшерсез. Әтисе, син олы кеше, ризыкны озак көттерү бер дә яраган эш түгел. Үзең белергә тиеш, кызларны да көттермәгез.

—Ярый, карчык, хәзер чыгабыз,—дип, Зариф, карчыгын җайлап кына аркасыннан сөя-сөя аш бүлмәсенә озатты да, тиз генә тагын тулыр-тулмас бер чүмеч әчебалны өчесенә бүлеп чокырларга салып куйды. Шул арада Зариф Нурисламның кайбер сорауларына кыскача гына булса да җавап бирергә ашыкты.

—Беренчедән,—диде ул,—мин әчебалга, башкалардан аермалы буларак, чүпрә салмыйм. Аның урынына балның ипиен, ягъни дә чыршын салам. Урыслар аны перга диләр. Шуңа күрә әчебалның хуш исе дә, тәм сыйфаты да яхшы саклана. Дөрес, минем балның исерткеч көче азрак, акыллы кешегә аның кирәге дә шуның кадәр генә... Ә инде артыннан кәрәзле бал кабып җибәрсә-ә-әң, әчебалның тәнгә көч, дәрт бирү сәләтен бермә-бер арттыра. Ә син, улым, бая биргән соравыма җавап табып карале!

—Бүгенге әчебалыңа, әти, юкә балы исе белән безнең Яссы Аланда гына була торган искитмәле хуш исләр бергә кушылган да, шушы чүлмәккә тулган. Ә безнең Яссы Алан гел юкә агачлары белән уралган. Нинди генә чәчәкләр үсми анда, әти, ә? Их, әти, белсәң иде минем сагынуларымны...

—Рәхмәт, улым! Ташкин кияве булып бетте, ахры, бу малай дип шактый

борчылганыем. Туган ягыңның ямен дә, балымның тәмен дә онытмаган икәнсең әле, шөкер! Әмма дә, улым, монысы гына бик аз... Нәни чагыңнан ук бик яраткан Яссы Аланың, су буйларың, ниһаять, бабаларыңнан калган иң изге җир—туган нигезең сине көтә, балакаем! Рәнҗетмә аларны... тизрәк кайту ягын кара инде син, улым.

Ниһаять, мич башындагы сихри чүлмәктән аерылып, йөзләре алсуланып, дәртләре ташып торган ир-егетләр табынга кушылгач, китте уен-көлке, берсеннән-берсе шаянрак төртмә сүзләр... Тик Маһирә генә ачылып, бу шаяруларга кушылып киталмады. Араларында Сәҗидәдән дә бәхетлерәк кеше булмагандыр, мөгаен. Аның таң алдыннан күргән төшеннән һәм аны юраудан туган шатлыгы күзләрендә, йөзендә балкый иде. Юк кына сүздән дә шундый матур итеп көлә. Һәр хәрәкәте, юк-юкта Нурисламын йотардай булып карап, каш сирпеп алулары, сөйләменә шаян сүзләр кыстырып җибәрүләре, хәтта ирен дә хәйран калдырды. Ахры түземлеге төкәнгән ир:

—Дускай, күрәсеңме, сизәсеңме.. Сәҗидәнең куанычын?.. Синең кайтуыңны барыбыздан бигрәк ул өзелеп көткән ахры. Көнләшмим дисәң дә, көнләшерсең, валлаһи...—дип, Нургалинең җилкәсеннән какты.

Сәҗидәсенең дә сер бирергә исәбе юк:

—Күрше хакы—Алла хакы диләр, ничек куанмыйсың, ә?.. Ул югында җырсыз-моңсыз калып, сөрсеп бетә язганыек бит. Аның кайтып күзгә күренүеннән үк шушы йортка гына түгел, хәтта бөтен урамыбызга ямь керде. Үзең дә: «Җомга намазында Фарук хәзрәт тә Нургалидән күзен алалмады, әле намаздан соң Зариф абзый белән икесен алып та калды»,—дип әйттең бит.

Ул арада Зөлкамал, нигәдер борчылып:

—Ай, Алла-а... атасы дим... карап торган күршебез, нарасыйларыбызның кендек әбиләрен ашка дәшәргә ник беребезнең башына килсен. Без монда шау-гөр, ул бер ялгызы бит... Улым, Хафиз, барыгыз, Тәскирә белән бергәләп йөгереп кенә чакырып чыгыгыз әле әбиегезне,—диде.

—Юк, әнкәй, бала-чаганы гына җибәрү яхшы булмас, хәзер үзем керәм!—дип, Газзәбану кузгалуга, Нургали: «Әйдә, бергә керәбез!»—диде дә, хатынына серле генә елмаеп, сабыйларча җитәкләшеп, очардай булып чыгып та киттеләр.

Түрдә утырган Маһирә ихтыярсыздан тәрәзәгә борылды. Маһирәнең һәр хәрәкәтен күз уныннан ычкындырмаган Сәҗидә, «аларда эшең булмасын әле», дигәндәй, аны тиз генә үзенә каратып, күрше Гыйззелбәнатның кем булуы, ниләр эшләве турында бәйнә-бәйнә сөйләргә тотынды.

Күп тә үтмәде, бөтен фасонын китереп, баш түбәсендә түгәрәк поднос белән күчтәнәчен куеп, керт-керт басып, көләч йөзе белән бөтен өй эчен балкытып «кендек әбисе» дигәннәре килеп тә керде.

—Бәйрәмнәр котлы булсын! Шушы матур табыныгызга мине дә чакырып куандырганыгыз өчен Алланың рәхмәтләре яусын! Мәле, күрше, минем күчтәнәчемне дә алып куйчы. Нургалиебез кайтышка дип пешердем, ул ярата торган катлы паштет бу,—дип, аны Зөлкамалга сузды һәм җәһәт кенә паштетны каплаган чигүле ак тастымалын читкә алып куйды. Паштетның гаҗәеп матур өске бизәлешен күреп, барысы да аһ итте. Соклануын яшерә алмаган Маһирә дә, Сәҗидәгә карап, әкрен генә: «Сүбхааналла! Бу паштетны ничек кул барып, өлешләргә кисkәләргә кирәк... Татарның чәй ашы дип үзбәкләргә күрсәтерием мин аны. Шаккатсыннар иде»,—диде.

Ул арада, Гыйззелбәнат: «Әйдәгез, йортка бер дога!»—диюгә, бары да кулларын күтәреп, гадәттәгечә, дога кылдылар. Дога артыннан Зөлкамал бисмилләсен әйтеп, пилмән бүләргә кереште.

—Газзәбану кызым, син табынга биреп торырсың, яме,—дип әйтүе булды, Сажидә чәчрәп чыкмасынмы:

—Юк, ул бу арада болай да би-ик күп чапты. Бүген ничәмә еллар буе тилмереп көтеп алган ире янында кунак кына булып утырсын әле. Кияү пилмәнен дә үзем таратам, башка эшләренә дә үзем булышам, яме, Зөлкамал апай,—дип, мөлдерәмә тулы беренче тәлинкәне:—Менә, күрше, монысын әниең синең алдыңа куярга кушты,—дип, Нургали алдына китереп куйды.

—Рәхмәт, әни! Шулай да, бу йортта беренче тәлинкә һәрчак әти алдына куела торганые. Бүген дә шулай калсын әле,—диде дә, пилмәнне атасы алдына куярга теләде Нургали.

—Илтифатына рәхмәт, улым! Әйдәле, бүген анаң әйткәнчә булсын. Коръән дә ана хакын олырак күрә бит. Оҗмахны да аналарның аяк астында дип тикмәгә генә язмаганнардыр, улым.

Сажидә үзенә тапшырган эшне тәмле теле, ачык чырае, күз иярмәс житезлеге белән башкарып та куйды. Аның ярдәменнән бик тә канәгать калган Зөлкамал:

—И-и-и, рәхмәт төшкере, баскан җирендә биеп торган яшь кызлардан бер дә ким түгел икәнсең әле син, күрше. Пилмәнне салып өлгертер хәл юк үзенә... Шул арада һәр кемгә хас шаян сүзен каян табып өлгерә диген...,—дип соклануын белдерде. Аңа бик теләп Гыйззелбәнат та кушылды.

—Бүген сиңа күзебез тимәсә генә ярарые, Сажидә. Эчтән генә «Сүбхааналла» дип утырам. Мондый ук дип белми идем әле мин сине. Нәрсә эшләсәң, ни сөйләсәң бары да килешеп тора тагы үзеңә. Аллага шөкер, янында яраткан ирең, нинди матур булып кызың үсеп килә. Гомерең буе шулай шат, бәхетле яшәсәңие!

Бу мактау сүзләренә тагы да үсенеп киткән Сажидә:

—Җәмәгать, кайсыгызныңдыр тәлинкәсендә эченә он салып ясаган бәхет пилмәне эләккән булырга тиеш. Ашыкмыйча әйбәтләп чәйнәп ашагыз. Бер шартыбыз бар: әгәр ул парлы кешегә чыкса, башта безгә күрсәтеп, аннан үзенең пары белән бүлешеп ашасын.

—Әйтик, ул Нургалигә чыкты ди, йә, чәнти бармак башы кадәр генә пилмәнне ничек итеп өчкә бүлмәк кирәк?—дип, Нурислам, уенын-чынын бергә кушып шаяртып куйды.

—Язмышын ничек өчкә бүлгән, бәхетен дә шулай өчкә бүлер,—диде Сажидә көлә-көлә.

—И-и, бигрәк вак итеп бөккәнсез, чикләвек диярсең, унысын берьюлы кабып йотарлык кына булган бу. Бәхетемне табам дип ничек итеп берәмләп кенә ашарга кирәк моны? Ну-у, кызлар...— диде Нургали.

—Аның бөтен кызыгы да шунда инде... Вак-та вак дисез, кияү пилмәне булганга вак алар! Өмә ясап бөктек без аларны. Ул вакытта башкалар ни уйлагандыр, белмим, әмма мин: «Нургали өчен кияү пилмәненең монысы соңгысы гына булсае. Сине тауар алырга чит илләргә дә күп йөри диләр. Тагы шунда берәрсенә гыйшкы төшеп, кабат бездән кияү пилмәне ясата күрмәсәе,—дия-дия бөктем мин аларны, Нургали дускай.

Әлеге сүзләрдән соң да көлешеп алдылар алуын, ләкин ул ничектер ясалмарак килеп чыкты шикелле. Газзәбану үзе дә сизмәстән көндәшенә карап куйды. Көтмәгәндә кинәт күзләр янә очрашты... Бары бер мизгел, әмма бу мизгел икесе өчен дә: «Йә Раббым, бир сабырлык...»—дип кенә уйларлык булгандыр, мөгаен. Нәкъ шул вакытта:

—Ул-ла, бәхет пилмәне миңа келгән, миңа,—дип Хафиз кычкырып җибәрмәсенме... Һәммәсе дә көтелмәгән бу хәлгә шау-гөр килеп, Хафизга текәлделәр. Табында туган киеренкелек тә узып китте.

—Кая, кая, безгә дә күрсәт, күрсәтмичә йотып җибәрә күрмә,—диештеләр. Хафиз уч төбендәге ярым сытылган пилмәнен табындагыларга «менә ул, менә» дип күрсәткәндә, кинәт Тәскирәнең үзенә карап, үпкәләгән сымак, турсаебрак утырганын күреп алды да:

—Сина да билимме соң?—дип сорарга мәҗбүр булды. Моны көтмәгән кыз куанычыннан елмаеп җибәрде.

—Биләшен килшә, бил!—диде.

Балаларның мәш килеп бәхет пилмәнен бүлеп маташулары һәм аны бер-берсенә карап ашап куюлары бу күркәм мәҗлескә янә ямь өстенә ямь булды.

Зөлкамал, урыныннан кузгалып, Нургали янына килеп утырды.

—Улым, менә хәзер гармуныңны алып уйнап җибәрсәң дә була. Син киткәннән бирле безнең йортта җырлаучы булмады. Ни җырларга яраткан атаң да бөтенләй тынып калды.

—И, әни, болай булгач, әйдә, кызлар, әни яраткан җырны җырлыйк әле,—дип гармунын алды да башын кыңгыр салып уйнап һәм җырлап та җибәрде:

Су буена төшкәнем юк,
Үсә диләр тал-тирәк.
Яна дисәң, ялкыны юк,
Ялкынсыз яна йөрәк.

Нигә пешми икән лә җир җиләк?
Нигә яна икән лә бу йөрәк.

Нургалинең үзе уйнап җырлаганын шулкадәр сагынганнар, күрәсең, аңа кушылырга берсе дә җөрьәт итмәде. Бердәнбер улының шушы үтә дә моңлы тавышын бер ишетергә зар-интизар булган ана, «өнемме бу, әллә төшем генәме» дигәндәй, әле улына, әле Газзәбануга, әле Маһирәгә карый-карый улын йотлыгып тыңлады. Ниләр генә уйламады ул бу минутларда. Маһирәнең, үзенең кайда икәнен дә онытып, Нургалине тыны белән суырып алырдай булып утыруын ошатмады, әллә көнләшеп тә куйды инде... «Син шулай суырып алмаган булсаң, улыбыз әллә кайчан безнең янда яшәгән булырые»—дип өзгәләнде. Житмәсә, нәрсә дип монда тагылып кайткан диген? Нургалиен дә әйтерием... Ир кеше булып, үз сүзенне дә әйтә алма инде... Алма күк хатынының тилмерепләр көтеп торганын белә бит юкса. Ярар, яшьләрнең башы-күзе тонган, уйлап та житкермәгәннәр ди, ата-анасы ни караган?! Локманын да әйтерием, шуның кадәр байлыгы белән кызына өйләнмәгән кеше тапмаган... Безнең малай шикелле бөтен яктан коеп куйган, ышанычлы кияү булырлык кешене ычкындырамы сон?! Өйләнгән булмагае, чурт булсын, кызына әйбәт кияү, үзенә тугры ярдәмче булсын, дигәндер. Байлар төптән уйламыйча, берни дә эшләмиләр. Акыллары алтын аларның.

Шул чак Нурисламның:

—Зариф абый, син дә үзеннең теге борынгы җырынны сузып җибәр әле,—диюенә, Зөлкамал да, авыр уйларыннан арынып:—Әйе шул, улым, син уйна, элеккечә итеп атаң да бер җырласын әле, ичмасам.—Ә улы шуны гына көткәндәй, шатланып:

—Маһирә, кил әле безнең янга. Скрипкәң белән син дә кушылсаң, әти ничек кенә җырлар әле. Теге җыр дип синең белән бергә җырлый торган «Уел»ны әйтәләр бит алар,—диде дә, читтәрәк торган зур чумаданнан нечкә билле тартма алды. Менә скрипкә дигәннәре кайда яткан икән.

Йә, Раббым, скрипкәдән агылган үзәк өзгеч, илаһи моңнан табындагылар бары да өнсез калды. Ни түзем Зариф та яшь тулы мөлдерәмә күзләрен Маһирәнең нәфис кулларыннан аерып алалмыйча, үзе дә сизмәстән, ишетелер-ишетелмәс кенә:—«И бала, бала...»—дип куйды. Ниләр генә уйлап әйтте икән ул бу сүзләрне...

Маһирә әллә ишетте инде, уйнавыннан туктап, тагын нидер ишетергә теләгәндәй, Зарифка текәлде.

Зариф исә:

—Уйна, кызым, уйна, туктама,—диде дә, әле моңарчы берсе дә ишетмәгән сүзләргә салынган җырын сузды.

Ай-һай диеп бер җырласам,
Селкенәдер кыя ташлары.
Упкыннарга керми, ни күрәсең белми,
Җилкенәдер егет башлары.

Скрипкәнең сихри тылсымы белән үрелеп барган бу моңлы җырны һәркем үзенчә кабул итте. Нургали атасын кочаклап ук алды:

—Рәхмәт, әти! Белсәгез иде, күпме көттем мин бу көнне! Әти, бу җырыбызның бергәләп җырлый торган үз сүзләре дә бар бит әле. Әйдә, нәкъ электәгечә анысын да җырлыйк әле.

Арыслан ла киек ай алдырмас,
Каршысында биек тау булса!
Егеттәй генә егет һич кайгырмас,
Газиз башы аның сау булса...
Газиз башы аның сау булсын!

—дип, җырны үзенчә тәмамлады Зариф.

***

Ташлыярдан зурлап чакырылган кунаклар сәгать сигезләргә килеп җиттеләр. Үзләре белән оныклары Фәргат белән Мансураны да алганнар. Алар артыннан Хафиз да күрше-тирә йортлардан җыйган бәйрәм күчтәнәчләрен күтәреп, кайтып керде. Ишегалдында песи малае белән уйнап утырган Фәргатне күргәч, куанычы икеләтә артты. Көлеп үк җибәрде малаең. Үзенең саран түгеллеген күрсәтергә тырышыптыр инде, горур гына кыяфәт белән, бер кәнфитен алып Фәргаткә сузды.

—Мансура да килде. Әби белән бабай да монда...—дип, тезеп китмәсенме кунак малаең. Хафиз әле капчыгына, әле Фәргаткә карап:—мә, аңа да бил алайса,—дип капчыгыннан саргылт төскә буялган бер күкәй алып бирде. Алуын алды Фәргат, әмма рәхмәтен әйтмәде. Ул гынамы әле, кырт борылды да өйгә үк кереп китте. Ошамады бу Хафизга. «Янында әбисе булса—улым, ләхмәтең кайда, дип әйтелие. Юк, әбисе дә, бабасы да күлмәде шул»,—дип уйлап кына өлгерде малай...

—И-и, минем улым кайткан икән! Ә без әниең бик тәмләп пешергән баз коймагы белән чәй эчәргә җыенып йөри идек. Ерак әби-бабаең сиңа иптәш булсын дип кечкенәләрен дә алып килгәннәр,—дип әтисе сүз катты.

—Белә-әм, дип,—боек кына җавап бирде Хафиз.

—Нәрсә, улым, юлларың уңмадымы әллә? Кәефсез күренәсең. Әле без сине болай тиз кайтырсың дип уйламаганыек. Тәскирә белән бергә йөрдегезме? Чыгуын бергә чыгып киткәч, кайтуын да бергә кайтырсыз дип көткәниек.

—И-и, әни капчыкны бигләк кечкенә итеп теккән. Тиз тулды ул. Тәскиләнең капчыгы зул, Фәми абыйлалга келеп калды. Ул абый, анын апае да бәйләм булмаган көнне дә кучтәнәч биләләл.

—Улым, синең дә бик күп булган бит. Кая, капчыгынны карыйк әле,—дип капчыкны күтәреп карады әтисе:—у-у-у бик күп булган бит бу! Кемнәрне генә сыйлап бетерерсең икән инде?

—Балыгызны да...

—Матур апайныдамы?

—Әни аны матул апай дип әйтмә ди. Исеме белән әйт ди. Ә анын исеме мина ошамый. Кунак апай дип әйтә башладым.

—Ә ул үпкәләмәдеме соң?

— Белмим, нигә матул апай димисең, алай әйтүенне ялатканыем,—ди.

—Син нәрсә дидең?

—Нәлсә, нәлсә дим—әни кушмый әйттем.

—И, бәгырь кисәгемдер шул! Шатлыгым да, бәхетем дә син бит, балакаем!—дип, улын кочагына кысып, маңгаеннан, күзләреннән үбә-үбә, күнеле булганчы сөйде Нургали,—Раббым, исән-имин булып, үзем үстерә алсамые. Синең дә бәхетле булуынны күрсәмие!

Үзе башлаган бу матур әңгәмәне һич кенә дә өзәсе килмәде Нургалинең. Бу кичерешләрен гомеренең соңгы минутларына кадәр оныта алмаячак ул... Хафизга сорау артыннан сорау бирүен дәвам итте:

—Күршеләргә килеп кергәч, үзеңне ничегрәк тоттын, ничек сүз башладын?

—Кызык син, әти. Үзегез ничек өйләтсәгез, шулай инде. Кетгәч тә «Әссәләмәгаләйкүм!—Жыен бәйләмегез котлы булсын!—дидем дә капчыгымны суздым.—Нургали янә сак кына елмаеп:

—Шуннан, шуннан, улым?—дип сорашуын белде.

—Шуннан утылган да шуган.—Икәүләшеп рәхәтләнеп көлештеләр.—Кайсылалы кочаклап алды, капчыгыма кучтәнәчләл салды, исән-сау бул, авылма, дәү үс, диделәл.

—Йә, йә, улым, чыгып киткәндә үзең ни дидең?

—И-и, әти, анысын да үзегез өйләттегез бит инде...—«Ләхмәт яусын! Сау булыгыз, бай булыгыз!»—дидем.

—Рәхмәт, улым, өйрәткәннәребезнең берсен дә онытмагансын. Исән генә була күр.

—Әти, син менә Тәскиләне тынлап кала әле, яме. И сакау да инде...

Яннарына Маһирә килеп житкәнен сизми дә калдылар.

—Кайларда гына йөрде икән безнең кунак апабыз иртә таңнан?

—Инеш буенда менә шушы матур малайны эзләп йөрдем,—дип, икесен дә кочаклап алды Маһирә.

—Әти, дөлес әйтми ул, Тәскилә белән без уламга киттек, ә ул—Сажидә апай янына,—димәсенме малаең.

—Улым, кунак апаңа кучтәнәченне бирмисенмени?

—Ана гына түгел бит ул. Өйгә келгәч бөтенегезгә дә биләсе...

—Ай рәхмәт, улым. Әйдәгез, ерак бабайлар да өйдә, баз коймагы ашарга безне генә көтәләр,—дип, Нургали икесен дә житәкләп, ашыктыра ук башлады.

—Ул баз коймагы дигәнегезне дә «өлеп кабалга» киләкме? Өйрәтерсен әле, Хафиз, йәме.

—И, син бигләк инде...—диеп, чыркылдап көлеп жибәрде Хафиз.

Күнеле тыныч түгел Маһирәнең. Ничек тыныч булсын инде? Көндәшенең әти-әнисе белән беренче очрашачак минутларын төрлечә күз алдына китереп, төне буе ниләр генә уйламады ул. Ул гынамы—дүрт елга якын сөю-сөелү ташып торган парлы төннәреннән соң, беренче мәртәбә ялгыз

калган төн... Житмәсә, Нургали белән Газзәбануның бер-берен житәкләп, куанышып мунчага йөгергәннәре күз алдына килә дә баса, килә дә баса... һәм шуна гажәпләнә—авылга жыенганда бала-чага күк берни уиламый чык та кит инде... Бары тик Нургалием белән сәяхәт кылам. Ниһаять, бабаем сагынып сөйли торган жыенны күрәм, жыенга бүләкләр алып кайтабыз. Ул авылның урманнарын, данлыклы Яссаланын, Кирәмәтен, тирән елгасында тезелеп аккан чишмәләрен, ул чишмәләрнен челтерәп аккан саф суларын татып карыйм, язларын ташу вакытында күперләрен агызып китә торган мул сулы елгасын күрәм, кайда гына булсам да, гел Нургалием белән бергә булам, имеш. Шунын кадәр чикләнгән уй, хыяллар—гәжәп түгелмени? Тагы да гәжәбрәге—дөнья күргән, гомер иткән әти-әнисе дә ник бер сүз әйтсен, ник бер искәртсеннәр.

Маһирә баскыч төбендә туктап, бисмилласын укыды. Анын көндәшенең әти-әнисеннән уңайсызланганы, күнеленә авыр җәрәхәтләр ясарлык сүзләр әйтмәсләрме дип шикләнүләре нык сизелә иде.

—Әйдә, жаным, каушама әле. Ибраһим абый да, Сәгыйдә әби дә бик әйбәт, аңлы кешеләр. Мина хөрмәтләре зурдан. Шөкер, сиңа да шулай булыр, бер дә шикләнмә яме, тыныч бул!.

—Рәхмәт, бергенәм! Шикләнүләремне, әйтерсең лә, жилгә очырдын...

...Ишектән керә-керешкә Ибраһим ачык чырай белән Маһирәгә кулларын сузды.

—Исәнме, кызым,—дип, ике куллап, чал башын иеп, зурлап күреште.—Хәерле сәгатьтә, балалар. Зариф кодалар үзеңне яшь киленнәре итеп, «төкле аягын» белән дип кабул иткәннәрдер. Зөлкамал кодагыебыз бигрәк тә, Нургали кияү анын бердәнбер улы бит. Сәгыйдә белән безгә кем буласындыр, анысын бер Аллам үзе беләдер. Ни генә булмасын, язмыштан узмыш юк дигәндәй, бергә-бергә тату, хөрмәт күрсәтеп яшәргә язсын! Кызыбызны да, оныгыбызны да ятим итмәссез, дип ышанабыз Сәгыйдә апагыз белән, Аллам үзе сакласын!—шулай диде дә, күнеле тулды, ахыры, мөлдерәмә күзләрен, күз төпләрен кул аркасы белән сөрткәләп куйды.

Маһирә дә:

—Аллаһының рәхмәтләре яусын, Ибраһим абый. Мине эчкерсез, туганнарча кабул итүегезне гомерем буена да онытмам—диде.

Бу минутларда өстәл янында утырган Сәгыйдәнең үз хәле хәл иде. Сәгыйдәнеке генәме соң?... Бите буйлап аккан яшьләрен сөртеп бетерергә өлгерә алмыйча изаланды ул. Маһирә бераз гына сабыр итеп, анын каршына үзе килде, һәр сүзенә тирән мәгънә салып, түземлек вә итагать белән күреште. Әти-әнисенең сәламнәрен житкерде, һәм алдан әзерләп куйган бүләкләрен тапшырды. Сәгыйдәгә—бик гүзәл зур кәшимир шәл белән ак батис яулык, Ибраһимга—затлы камзул вә ука белән чигүле шәп түбәтәй һәм балаларга мул гына тәм-том кучтәнәчләр.

Кунакларга Ташкент бүләкләре ошады булса кирәк. Күрешкәндә, салкынлыгын сиздерү өчен ахыры, бармак очларын гына сузган Сәгыйдә дә кинәт ачылып китте. Тыныч кына рәхмәтен дә әйтте. Киләсе атнада үз авылларында буласы жыенга кунакка да чакырды, хәтта.

Хафиз да үзенең кучтәнәчләрен—кемгә кәнфит, кемгә төрле төсләргә буялган күкәйләрен таратып чыкты. Барысы да аны хуплап, рәхмәтләрен әйттеләр.

## Җыен

Авылның элек-электән сабан туйлары, жыеннары уза торган урынга килеп житүгә, мондагы гажәеп гүзәллекне күреп өнсез калды Маһирә. Авыл ягыннан зифа буйлы яшь каеннар белән каймаланган, тирә-юне

яшеллеккә күмелгән гаҗәеп зур болын. Болынның өске ягында—тау битендә борынгыдан ук килгән зур зират. Анда нинди генә агачлар юк. Ул биек-биек чыршылар, наратлар, искитмәле каеннар! Читтән, еракганрак караганда калын урманны хәтерләтә бу зират. Аз гына җил булганда да андагы карт агачларның шаулавы кешеләргә нидер сөйли, йә нәрсәдәндер кисәтә дә шикелле. Болынның аскы ягында шактый мул сулы инеш. Инеш тирәли урыны-урыны белән ябалдашлары тоташып диярлек үскән тал-тирәк. Инешнең тегермән бөясенә кушылган җирдән бераз өстәрәк авылның ике катлы су тегермәне. Аннан бераз читтәрәк тегермәнченең каралты-курасы белән рәттән җиренә житкереп салынган үз йорты. Бу зур хуҗалыкны авыл белән болыннан аерып торган күпъеллык юан-юан карт өянкеләр, зирек агачлары, яшь таллар нинди генә вакыйгаларның шаһитләре булмагандыр. Кинәт шунда, башка агачлардан читтә япа-ялгызы үскән карт өянкегә күзе төште Маһирәнең. Нигәдер серле булып күренде ул аңа. Монда башка вакытта килергә кирәк әле, дип уйлап куйды.

Яшь киленнең авылны яратуы, үзе өчен гел гадәти күренгән һәр нәрсәдән матурлык табып, сокланып, мөкиббән китеп барулары Зарифны аерата куандырды. Карчыгының да канәгать кенә елмаеп утыруын күреп, атын да кумаска булды. Дилбегәне бушатып җибәрүгә, хуҗаның ни теләгәнен аңлады малкай. Аякларын биеткәләп, кыска-кыска адымнар белән атлый башламасынмы... Баш югары, кыңгырау вә шөлдерләрнең чыңлаган тавышларына үзе дә куангандай, горур башын еш кына чайкаштыргалап та ала. Атларда адәм акыллары бардыр, диеп тикмәгә генә әйтмиләрдер шул. Күрә бит ул, тоя бит ул мәйданга агылган халыкның үзенә карый-карый сокланып узганын.

—Маһирә килен, карале бу малкайны, ниләр кылана!... Син кунагыбыз өчен, син күрсен дип артисланадыр әле, мөгаен,—дип, аты белән мактанмакчы булды Зариф. Әмма, килененең бөтен гаме үзләреннән алда барган аттагы Нургалидә икәнен күреп, күңеле сүрелеп китсә дә, сиздермәде. Алдагылар исә һаман ераклаша барып, тәмам күздән дә югалдылар.

—Әткәй, Чаптарны кызулатыйк әле. Нурисламнар да күренми, әллә алар да узып киттеләр инде?

Ниһаять, атларны тиешле урында калдырып, Зарифныкылар бер тирәгә җыйналдылар. Кода-кодагыйлар бергәрәк, өлкәннәрчә. Алар янында яшьләр үзләре бер төркем булып, мәйданны күзәтәләр. Мәйданның нәкъ уртасында матур-матур бүләк сөлгеләр эленгән озын колга куелган. Башка төр бүләкләр зур гына арбада, халыкка күренерлек итеп, тәртип белән урнаштырылган. Бераз гына читтәрәк озын гына колга очына бик тә, горур кыяфәтле әтәч салынган кәрҗин асып куйганнар. Аның ара-тирә дәү канатларын җилпеп, үзенчә кычкыргалап куюы—үзе бер кызык. Мәйданнан читтәрәк тезелеп киткән олауларда балалар өчен кәнфит-прәннектер дисеңме, яшь кыз-кыркыннар өчен бизәнү әйберләре дисеңме—ни генә юк. Мәйдан тирәли төркем-төркем яшьләр гармун уйнап, җырлап узалар. Мәйдан гөж килә. Халыкның олысы-кечесе Зариф кунакларын, аеруча Ташкенттан яшь килен булып кайткан Маһирәне, энә күзеннән үткәргәндәй күзәтәләр. Авылдашларының Нургалине нык сагынганнары, шулай ук аны аңлап ук бетерә алмаганнары да хәтта күз карашларыннан ук сизелеп тора. Яннарына киләләр, күрешәләр, сорашалар... Нургалинең тиздән инде бөтенләйгә кайту тиешлеген дә яшермиләр, аерым басым ясап әйтәләр. «Газзәбануыңны да, Хафизыңны да башка болай саргайтма инде»—дигәннәрен дә Маһирәгә күп ишетергә туры килде ул көнне. Унайсызрак хәлдә калган вакытлары да аз булмады аның... Әнә бит, якында гына бер төркем яшьләрнең Зарифныкыларга төбәп җырлап килүләре...

Аклы ситса кулмәгенне
Киден ни, кимәден ни.
Ятлар белән уртак ярны
Сөйден ни, сөймәден ни.

И жил исә, жил исә,
Тал яфрагын жил кисә.
Сикереп суларга төшәрсеӊ
Ярыӊ ятларны сөйсә.

Сандугач та моӊлы сайрый
Безнеӊ инеш буенда.
Мин кайгырмый, кем кайгырсын,
Ярым ятлар куйнында.

Өлкәннәр жырчыларга артык игътибар бирмәде кебек... Дөресрәге, ишетмәмешкә салыштылар булса кирәк. Чыгырыннан чыгарга житешкән Нургали:

—Кемнәр болар, берсен дә танымыйм. Бәлки син таныйсындыр? Гармуннарын алып изәм бит хәзер мин боларныӊ...,—дип ачуын тыя алмыйча, Нурисламга дәште.

—Мин дә танымыйм, безнеӊ авылныкылар түгел. Шул Фатыйх көчекләредер.. Вакланма да, пычранма да, бел аны...

Түзмәде Газзәбану, әле иренә, әле көндәшенә күз төшереп алды да: «Жырласыннар,—диде эченнән генә. Монысын гына йотарсыз... миӊа тагы да ачыракларын йотарга туры килә бит әле. Жәй життеме, улым белән йоклаган келәт яныннан һәр төнне диярлек жырлап үтәләр. Миӊа нәрсә эшләргә кала соӊ? Бары тик күз яшьләремә тыгылып, төннәрне ялгыз вә йокысыз уздырудан башка».

Газзәбануга, ничек тә дулкынланмыйча, тыныч кына (читләр ишетмәсен өчен) сөйләвен дәвам итү жиӊел булмады. Шул ук вакытта көндәшенә дә бик ишеттерәсе килә иде аныӊ. Әмма соӊгы жөмләсендә үзен шулкадәр «мескен» хәлдә калганын тоеп, күӊеле тулышты. Жылап жибәрүенеӊ котылгысыз булуын аӊлап, кисәк Нургалидән кулын тартып алды да, инеш буена йөгерде. Нургалинеӊ аны куып житеп, юатасы килде. Әмма Маһирәсе кулын ычкындырмыйча, аннан калмады.

«Маһирә, жанкисәгем, син, зинһар, калып тор әле. Без хәзер килербез»,—дип караса да, «Юк, нәрсә булды? Нигә миӊа монда калырга кирәк?»,—дип, күзләрен мөлдерәтеп, иренә елышты Маһирә. Нургали ирексездән: «Аӊлады... барын да ишеткән, димәк. Халык алдында үзен генә ялгыз калдыруларын теләмәгәне әллә каян күренеп тора бит, югыйсә. Нишләмәк кирәк, юк, хәзер иӊ дөресе—хатыны янына Маһирәне алып төшмәү»—дип нәтижә ясады һәм уйга калды... Урыслар: «Хатын-кызны аӊлау өчен бер пот тоз ашарга кирәк»—диләр. Нинди бер пот, капчыгы белән ашасаӊ да, аӊлап бетерә алмассыӊдыр.

Ирләр бөтенләй башка: тиз ышанучан, үтә гади, жайлы кешеләр...

Маһирәне монда алып кайтып, ялгыштым бугай. Анын7 « Мин дә кайтам, бәгърем, синнән каламмы соӊ, бергә, только бергә кайтабыз»—дип, куйныма сарылулары... Мөнә хәзер исә әүвәл—Газзәбануны көйләргә кирәк, монысыныӊ да хәтерен калдырырга ярамый. «Ике хатын арасы—ике ут арасы» дип, минем ишеләргә әйтәләрдер, мөгаен...

Газзәбану тиз генә бер талтирәкнеӊ куе ябалдашлары астында чүгәләде дә, әчке халәтенә буйсынып, ачы күз яшьләренә ирек куйды. Күӊеле бушаганчы жылады да жылады. Артымнан төшми калмас, шунда әйтәсемне

әйтеп бетерермен дип, ирен көтте. Юк-юкта ябалдашлар арасыннан төшкән юлына күз салгалады. Шулай бер мәлне үзеннән ерак кына түгел икесенең бергә басып торганнарын күреп, йә, Ходам, агылый белән тагылый күк әллә мине көтәләрме болар? Минем шушы хәлемдә нигә ул үзе генә түгел, ә мин ялгыз! Эчтән генә «юк инде» дип, тиз генә инештә битен-күзен юды, сөртенде. Бераз тын алды да, ябалдашның бер кырыен күтәреп, йөзенә берни булмагандай төс салып, чыгарга җыенды. Ләкин ул урында алар юк иде инде. Шул чак каршысына томырылып, чабып төшкән Хафизны күрде: «Нишләп мин ялгыз булыйм ди, әнисен эзләп төшкән улым бар бит минем, рәхмәт балакаем»,—дип, Хафизын кочаклап алды.

—Әни, син кайда йөлдең? Әбиләл җибәлде мине. Алал сине көтә-көтә алып беттеләл.

—Әтиең кай тирәдә?

—Әнә ич тегендәләк! Кунак апай белән.

—Әйдә,балам, шунда алып бар мине. Тормасыннар әле кукыраеп, әлләкем булып...

—Нәлсә, нәлсә дисең? Анда җыенны башлыйлал бит, тизләк!

Фатыйхның: «Җәмәгать, җыенны башлап җибәрергә бик вакыт»—дип, сүз башлавына, төрле яктан, бер тавыштан диярлек: «Мулла абзый килеп житсен, аны көтәргә кирәк... Хәзрәтнең фатихасыннан башка ярамый... Юк, юк, көтәбез»...—дигән сүзләр яңгырады.

—Җәмәгать, шауламагыз, Фарук абзый авырып тора икән. «Бара алмыйм» дигән, көтеп тормаска кушкан,—дип, халыкны тынычландырмакчы булган Фатыйхны бер төркем картлар чорнап ук алдылар. Янә шау-шу китте. Картларны Зариф тынычландыра башлады:

—Дөрес түгел. Кичә генә җомга намазында барыбызны таң калдырган мулла абзый ничек инде җыен көнендә генә авырып китсен ди. Кем ышансын бу сүзгә. Хәзер үзем барам да, алып та киләм. Хәзрәтнең фатихасыннан башка җыен кадәр җыенны ничек уздырмак кирәк...

Иң абруйлы кешеләрнең берсе буларак, Зарифка авыл халкының хөрмәте элек-электән зур иде. Бүген дә аны хуплаучыларның бик күп булуы берәүне дә гаҗәпләндермәде. Үзен авылның төп хуҗасы итеп санаган Фатыйх та чигенергә мәҗбүр булды.

Зарифларны Хаҗәрбикә абыстай үзе генә каршылады. Сәламләшкәннән соң Зариф:

—Хәзрәт урын өстендә үк мәллә?—дип, борчылганын сиздерде.

—Юк, Аллага шөкер таза-сау. Түр бүлмәдә, иртәдән бирле Коръән укый хәзрәт. Йомышыгыз булса, рәхим итегез. Ашыгасыз шикелле, үзен генә чакырыйм, булмаса,—дип, абыстай кереп китте.

Хәзрәт ишектән күренүгә, борчып йөрүләренә гафу үтенеп, җыен халкының гозерен тапшырды Зариф. Үз чиратында Фарук мулла да, авыл халкының үзенә карата игътибарлы вә ихтирамлы булуына, һәр очракта динебезгә тугрылык саклавына рәхмәтле калуын әйтте:

Әле дә сез бар, диндәшләрем. Димәк, мин үзем уйлаганча ук, ялгыз түгелмен икән, мең шөкер! Көтеп алган олуг җыеныбызга чакыруыгыз өчен Аллаһының рәхмәтләре яусын! Ә сез көткән хәер-фатихамны мәчетебездә, нәкъ башка еллардагыча укып, җыеныбызга багышладым, Раббем үзе кабул итсен!

Бу очрашу барысында да авыр тәэсир калдырды. Үзара сөйләшкәндә Зарифның: «Фарук мулланы җыенда катнашудан мәхрүм итү, ай-һай, бер җүнсез Фатыйх эше генә микән? Әнә бит бер көнне, җыелышта нәрсә дип сөйләгән: «Дин ул халык өчен агу. Линин мәрхүм үзе исән чакта ук чиркәүләрне җимерергә кирәк»—дип сөйләгән ди. Шунда үзе «закон» чыгарырга ярата торган Кәлимулла абзыебыз: «Чиркәүләре чукынып китсен,

аларның эше шул. Әмма, безнен дин турында Линин алай әйтмәс»—дигән бичара. Бүгенге хәлебез шуның гел киресе бит. Аллага тапшырдык, тагын ниләр күрсәтер...

Зарифтан үзе теләгән хәбәрне алгач, Фатыйх тыныч күнел белән жыенны ачып жибәрде. Фарук мулланың сырхаулыгына бик ышанып ук бетмәсәләр дә, халык та тынычланды. Мәйданның үзегеннән аз гына читтәрәк көрәшчеләр үз урыннарын алдылар. Көрәшкә мөкиббән ирләр шул тирәгә якынаеп ни генә сөйләмиләр:

Сабиржан быел да батыр калачак. Ташкент бүләге—гармунны алмый каламы сон ул? Кичә үк инде бүләк жыючы Хәнифтән сорап, уйнап та караган икән... Тульке минеке булыр бу гармун дип тә әйткән ди. Булыр, булыр, бер ай буе бер сарык ашый бит ул, дип әйтә ди әнисе.

—Туктагыз әле, алдан кычкырган күкенең башын ярмагыз тагы. Әнә күрәсезме, Сабиржан белән рәттән басып торган күрше авыл егетен, Әхтәм исемле ул. Быел Сабиржанны сыртына салмасам, исемем Әхтәм булмасын дип әйтә ди.

—Лутче үзебезнең Сабиржан жинсен! Ну, өздереп тә уйный инде, ичмасам. Ә сезнең Әхтәмегез гармун уйнау түгел, жырлый да белми бит ул. Бу сүзләрне ишетү һәм көрәшчеләрне энә күзенән үткәргәндәй, күзәтеп тору Маһирә өчен рәхәт тә, кызык та иде.

Әмма нәтижә авыл халкы көткәнчә булмады шул. Сабиржанны тәки сыртына салды бит Әхтәм. Бүләкләрне тапшырганда үзенә бер кызык булды тагы. Һәрхәлдә, гармунны Сабиржанга, куен сәгатенә тагын бүләкләр өстәп, Әхтәмне ризалаштырырга маташтылар. «Син гармунның моңын табу түгел, бакасы белән телен дә бутыйсындыр әле»,—дип, шаяртып та карадылар. Ну, хурланып та карады Әхтәм бу сүзләргә. «Уйнамый торсын әле»—диде. Шулай да бераздан житди генә:

—Әгәр бер атнадан авылыгызга килеп, уйнап күрсәтмәсәм, сез дигәнчә булыр,—диде. Күршеләр белән әчелешле яшәү яхшыга илтмәс, дип уйлады ахры.

Көрәштән кала иң зур тамаша—ат чабышы. Чабышка килгән атларны Сорна урманының басу белән тоташкан урыныннан киң юл буйлап, кардон өенә якын ачыклыкка алып киләләр. Шунда атларны бер рәткә тезәләр. Барлык жайдаклар читтәрәк, атка атланган өлкән кешенең ак яулык тоткан кулына карап торалар. Ак яулык селкенүгә, атлар томырылып чаба башлый. Соңгы тукталыш—тегермәнгә житәрәк сөлге бәйләнгән багана яны. Анда янә бер өлкән ир чабышкыларны кабул итә. Жиде-сигез чакырымны үткәннән соң тау өстеннән үтеп, тегермән борылышында аска төшәргә тиешләр. Ул юл мәйданга бик ачык күренеп тора. Кемдер тау өстендә күтәрелгән тузанны күреп: «Атлар килә»—дип сөрән сала. Халык шаулаша, кайсы атның беренче киләсен чамаларга тырыша.

—Газимжан абыйның Ак бәкәле беренчелекне бирмәс.

—Икенчелекне Садрый абзый юртагы алыр, ә өченче урында, узган елдагыча, Исмәгыйльнең айгыры килер—дия-дия юрарга керештеләр. Яшьрәкләр атларны каршыларга тегермән янына йөгерде. Газимжанның улы Мәхмүт, йөргән кызы Мәфрүзә белән күптән инде шунда. Мәйдан халкы гөж килә. «Маһирәнең бүләген—яшел атлас күлмәклекне Акбәкәл ала да ала инде. Безнең авылда андый чабышкының булганын белмиләр дә. Нишләптер Газимжан абый үзе күренми»...—ди берсе. Икенчесе:—Казанга киткән ди. Мәхмүтен ачлыктан эти-әнисен югалтып, дөм ятим калган Мәфрүзәгә өйләндерәсе килә икән. Хатын-кызсыз йорт—ятим йорт инде ул. Шәмсенурымны ачлык кына харап итте шул. Үз кабымлыгын да миңа биргәндер жанашым. Мәхмүт белән Мансурамны мулла абзыйларда балалар

өчен ачылган Әмрикә ашханәсе саклап калды,—дип сөйләгәние диде. «Чыннан да, менә шул ярдәм һәм мулла абзый белән абыстайның бәяләп бетергесез хезмәтләре аркасында бездә балалар үлеме азрак булды. Күбрәк өлкәннәр кырылды шул»,—дип раслады күбесе.

Нәкъ шул вакытта тынычланырга өлгергән атларны мәйданга алып керә башладылар. Халык дуу китереп кул чаба, яшьрәкләр кайсы «ур-ра» кычкыра, кайсы сызгырып җибәрә. Нәтиҗә—чыннан да, халык юраганча. Беренче булып горур кыяфәттә Акбәкәл бара. Аның башын як-якка чайкап алулары да «күрәсезме мине, быел да ышанычыгызны акладым» дигәндәй тоела, йөгәненнән тотып барган Мәхмүт тә, ат өстендәге энесе Мансур да горур вә бик бәхетле иделәр. Алар өчесе дә бер җан булып, бер сулышта дигәндәй бөтен мәйданны әйләнеп чыктылар. Акбәкәлнең муйнына кызыл башлы зур киндер сөлге салдылар. Мансурга Зариф абыең бүләге дип каеш йөгән бирделәр. Сөенеченнән авызы колагына җиткән малай: «Зариф абый, сиңа рәхмәтләр яусын» дип кычкырып бөтен мәйданны янгыратты.

Хәниф ялык-йолык килгән яшел атлас күлмәклекне кулына алуга, ярдәмчеләренә күз кысты. Алары шунда ук: «Бүләкне алырга Мәфрүзә үзе чыксын, үзе алсын!»—дип мәйданны янгыраттылар. Оялуыннан бит алмалары кызарып чыккан. Мәфрүзә нишләргә дә белмәде, аптырап калды. Инде халык арасыннан да: «Бар җаный, бар, оялма, бүләгеңне ал»!—дигән тавышлар ишәя башлагач, башын аска иеп, оялып кына Мәхмүт янына килеп басты.

Бүләкне кулына алуга әллә нишләп китте Мәфрүзә. Кинәт, күзләрен яшь элпәсе каплап, гел томан эчендә калгандай булды. Өстәвенә тамагына төер утырды. Ник бер сүз әйтә алсын... Бер кулы белән күзләрен каплап, башын аска иде. Мәйдан халкы аның күнеле тулудан туган эчке халәтен аңлап, дәррәү кул чаба башлады. Шул чак Газзәбану тиз генә үзенекеләрдән аерылып, Мәфрүзә янына ашыкты. Каршысына бөтен мәйданны балкытып, чулпыларын чыңлатып килүченең Газзәбану апасы икәнен танығач, җан керде кызга, хәтта яшь аралаш көлеп тә җибәрде. Шулай булмыйни—соңгы елларда якын туганыдай күреп, көн саен диярлек хәлен белеп, ярдәм итеп торучы да шул Газзәбану апасы булды бит. Әти-әниләрен җирләгәндә дә Зариф абыйлары бөтен өй эчләре белән булыштылар. Инде үзе өчен иң җаваплы бу минутларда да, Газзәбану апасының янәшәдә генә булуы—әйтерсең лә, кызга канатлар куйды. Газзәбану бу юлы да башындагы өр-яңа ак ефәк шәлен алып, Мәфрүзәнең иненә салды һәм болай диде: «Менә бу шәлем сиңа Нургали абыең белән безнең бүләгебез булсын. Бәхетле бул, балакаем!» Һәм тавышын бераз акрынайта төшеп (башкаларга ишетелмәсен өчен) «Сөйгәнеңне бер кайчан да, беркемгә дә бирмә һәм һәрвакыт, һәр кайда гел бергә булыгыз!»—диде. Әмма якындарак кына Газзәбанудан күзләрен ала алмыйча, үзенең кайда икәнен дә онытып басып торган Фатыйх барын да ишетте. Ишеткәннәрен халыкка, аеруча, Зарифныкыларга ничек тә сиздерәсе килеп: «Иптәш Яруллина, сиңа авыл советы идарәсе исеменнән ятим кызыбыз Мәфрүзәгә биргән зур бүләгең өчен дә һәм аңа, аеруча киләчәк мәхәббәтенә кагылышлы изге теләкләрең өчен дә рәхмәтемне белдерәм. Синең бу теләкләреңә җыенызда катнашкан һәр кеше һәм ерактан кайткан кунакларыбыз да кушылыр дип ышанам. Ә авыл советы синең еллар буенча шушы балага кылган ярдәмнәреңне беркайчан да онытмас, рәхмәт Газзәбану!»—шулай дип, аның кулын да кысмакчы булды Фатыйх. Әмма Газзәбану аның сузылган кулларына күз дә салмыйча, толымнарын чайкалдырып кырт борылды. Яланбаш калган Газзәбану, тагы да гүзәлрәк күренде. Халык арасыннан: «Һай, сөбханалла», «Һай күз генә тимәсен», «бер килмәгән җире юк бит», «Раббым, үзең сакла», «Гүзәллекне

бирсә дә бирә икән Ходай», дигән соклану сүзләре күп ишетелде. Шулчак Мәфрүзә дә түзмәде: «И, жаныкаем, менә шушылай гына йөре, ничекләр килешеп тора үзенә»,—дип әйтми калалмады. «Бик дөрес әйтәсең, сеңлем. Шәлләр, яулыкларга уралып үз матурлыгын үзе яшереп йөрмәсен, иеме. Яна заман килә, янача яши башларга кирәк»,—дип, Мәфрүзәне хуплаган булып, Фатыйх та үз фикерен житкерде.

Газзәбану: «Әйдә, балакаем, үз урыннарыбызга барыйк инде. Син Маһирә апаннарга рәхмәтенне әйтерсең»,—дип Мәфрүзәне житәкләп китеп барды. И, бу гөнаһсыз жаннарның мәйдан буйлап, тирә-юньгә нур бөркеп атлап барулары... Юк, атлап түгел, йөзеп барулары... Әйтерсең лә, алар үзләренең Бәхет дигән диңгезләрен йөзеп үтәләр. Бәхет тә бер килсә килә бит ул... Әнә каршыларына улы белән Нургалинең житәкләшеп йөгерә-йөгерә килүләрен күреп: «Бәхеткәйләрем минем!»,—дип Газзәбану үзе дә кочагын жәеп каршы йөгерде. Шул вакытта аларны мәйдан халкының бердәм көчле кул чабулар белән алкышлаулары бәхет өстенә бәхет түгелмени?! Кешегә бәхетле мизгелләр кичерү өчен әллә ни күп тә кирәк түгелдер... Ә кода-кодагыйларның шатланулары... ...Балаларының бәхетле булуларын күрү— ата-ана өчен икеләтә бәхет дими ни дисең. Үз яннарына китертәсе килеп, ике кода бер юлы диярлек кулларын изи-изи: «Хафиз улым, әтиләренне безнең янга алып кил, безнең янга»,—дип кычкырып ук жибәрделәр. Ә Маһирә... Маһирәсе нишләсен инде... Нургалиен дә жибәрми калалмады, үзе дә иярә алмады. Калган урынында басып тора.

Хафизмы соң ул бабасы кушканны үтәмәүче... «Ярар, ярар, улым, әнә безне көтеп торган кунак апайны да үзебез белән алыйк инде»,—дип карады әтисе. «Юк, аны соңыннан үзем алып килермен»,—диде.

Кинәт мәйдан уртасында кемнеңдер кычкырып елаган тавышына сискәнеп киттеләр. Ул—Ак бәкәлен муеныннан кочаклап, «Әти, бәгърем»,— дип үксегән Мансур иде. Шунда ук мәйдан халкына Казанга киткән Газимжанның вафат икәнлеге мәгълүм булды. Күпләрнең «Иннә лилләһи үә иннә иләһи ражигун» дип дога кылулары ишетелде.

***

Жыен узуга, икенче көнне иртүк, Нургалине авыл Советына чакырттылар, Тышкы ишектән керә-керешкә Фатыйхның кемгәдер: «Әнә үзе дә килеп житте, аның белән сөйләшкәндә катыраклык фарыз»—дигәнен ишетеп өлгерде ул. «Минем белән катырак сөйләшергә тиеш кеше кем булыр икән»? дигән уй белән Нургали ябылыр-ябылмас калган ишекне ачып, эчкә үтте. Фатыйхның соңгы сүзләрен ишетеп калганын сиздерәсе килеп: «Әйе, килеп життем шул, чакыргансың бит. Тик ни өчен чакырганыңны гына белмим. Ә бу иптәшне кем дип белик»?—дип читтәрәк нидер укыган сымак утырган ят кешегә карап куйды.

—Кем булса да сиңа барыбер түгелмени?

—Ярар, әйдә, мина димәгәе әллә кем булсын, әйт йомышыңны, Фатыйх. Нигә минем кирәгем чыкты соң әле сиңа, һич аңламыйм...

—Син читтә хатын өстенә хатын алып, гүләйт итеп йөрсәң дә, әлегә шушы авыл кешесе саналасың бит. Синең кайда, ниләр эшләп йөргәнеңне тикшерергә безнең полный хакыбыз бар. Әллә хатының белән баланны ташлаган кебек, туган авылыңнан да ваз кичтеңме? Боларны авыл сәүите белергә тиешме? Тиеш! Эрвәлүтсия хатын-кызларга да ирләр белән тигез хокук бирде. Сәүит власы кирәк чакта аларны яклауны да үз өстенә алды. Боларны гына аңлыйсыңдыр шәт?

—Аңлыйм да ди, йә, шуннан?..

—Сине авылда Газзәбану белән законный аерылу өчен генә кайткан дип

сөйлиләр, дөресме шул? Бу заманда ике хатын белән яшәргә ярамаганны чамалыйсындыр инде...

—Син нәрсә тузга язмаганны сөйләп утырасың, Фатыйх? Үзең чыгаргансындыр әле бу сафсатаны... Минем аерырдай хатыным юк һәм булмас та. Өмет тә итмә... Алар икесе дә миңа бертигез газизләр.

—Да-а-а, менә кешене байлык нишләтә... Хуҗанның байлыгына кызыгып, аның кызын үзенә каратып, Газзәбануны нинди утларга салганыңны сизми дә калгансың дип әйтимме?! Ай-яй, ничек җиңел сөйләшәсең, «икесе дә бертигез газизләр» ди бит әле. Әгәр шул вакытта аны Нурислам белән күрше малае коткармаса, тәки ургылып аккан язгы ташуга ташланасы булган Газзәбануың. Күпме авырып, танымаслык хәлгә килеп йөрде бичара. Аны элеккеге Газзәбануыбызга кайтару өчен күршеләрегез кулыннан килгәннең барын да эшләде. Ә си-и-и-н «икесе дә газизләр» имеш... Юк инде, берсен аермый барыбер берни дә булдыра алмыйсың хәзер. Нибуч, сәүвит законына буйсынмый хәлең юк...

Моңарчы үзенә мәгълүм булмаган бу авыр, җан өшеткеч хәбәрне ишетү, бигрәк тә Фатыйх авызыннан, җитмәсә чит кеше алдында, җиңел булмады Нургалигә. Әмма Фатыйхның: «Хуҗанның байлыгына кызыгып...» дигән сүзләреннән гарьләнү һәм аның Газзәбануга өмет багълавын сизеп утыру, ничек тә түзем булырга тырышкан Нургалине чыгырыннан ук чыгара язды. Бүлмәдә ят кеше булганын да онытып җибәрде булса кирәк:

—Җитте, Фатыйх, канца да канцов, ни өчен чакыртканыңны аңладым. Газзәбануга юкка борыныңны сузасың. Гомереңдә бер ир чырае күрмәсә дә, яна влас, кодрәте җитеп, сине әллә кем итеп күтәрсә дә, карамаячак ул сиңа. Аны җәлләп, хәленә кергән булып, миңа каршы әллә нинди ялганнар корып, кирәксә-кирәкмәсә авыл советына чакыртып котыртуларыңны туктат. Юкса мин сиңе...

—Нәрсә-ә-ә, әле син миңа янамакчы буласыңмы?!—дип Фатыйх кулларын йодрыклап, гайрәт күрсәтер өчен микән, урындыгын ачу белән этеп җибәрде һәм аягүрә басканын сизми дә калды.

—Синең белән кул пычратырга әллә мине дурак дип белдеңме?—дип Нургали үтә мыскыллы караш ташлады Фатыйхка.

Тик моңарчы нәрсәдер укыган кыяфәттә утырган өченче кеше телгә килде.

—Иптәш Салахов, утырыгыз! Ул бит сезне специально вызывать итә, неужели шуны аңламыйсыз?—Аннары Нургалигә таба борылып:

—Ә сез, Ташкент кунагы, кайда утырганыгызны, кем белән сүз көрәштереп һәм кемгә кизәнгәнегезне, чамалыйсызмы, ә?

—Чамалыйм, бик яхшы чамалыйм. Ни укырга, ни эшкә дигәндәй, авылның бер хөрсәнтәе иде ул... Бәхетенә, илгә яңа влас килеп, аны әнә нинди зур «түрә» ясады. Башта предкамбид, ягъни «ярлылар комитеты»на персидәтел итеп куйдылар. Чөнки алар гомер буе үтә дә ярлы яшәделәр. Кечкенә генә салам түбәле өйдә, бер кәҗә дә асрый алмаган, фәкать чабата ясап кына көн күргән Сәлахетдин абзыйның игелексез малае булып үсте ул. Гражданнар сугышы елларында халык өстенә салынган әллә нинди исемдәге налоглар өчен дип икмәк җыйган чакта, Фатыйхыбыз үтә активлашып китте. Кешеләрне куркытып, йорт саен тентүләр ясап, хәтта өй тулы балаларының да соңгы умачлык оннарына кадәр алып чыгып киткән кеше ул. Менә шул тырышлыклары өчен авыл сәүите персидәтеле итеп куелган да инде ул. Ул елларда халык шул кадәр таланмаса, егерме беренче елгы ачлыкка бу кадәр бирешмәгән булырыек. Бәлки, Нурислам белән безгә дә читкә чыгып китәргә туры килмәсие. Фатыйх, сиңа да минем ничә кат өйләнгәнемне тикшереп, кайсын аерырга, кайсы белән торырга дип миңа әмер биреп утырасы булмасые.

Ә мин пока үзбәкләр жирендә яшим. Шөкер, анда болай вакланмыйлар, анда башка тәртип... Ирләрнең берничә хатын белән торганында берәүнең дә эше юк. Мөмкинлегең бар икән хет өч, хет дүрт хатын белән яшә. Хатын-кызны ялгыз, балаларыңны ятим генә итмә, барын да тигез күр.

Үзенә карата әйтелгән әр-хур сүзеннән Фатыйх бер агарды, бер күгәрде, чигә тамырлары зәңгәрләнеп бүртеп чыкты.

—Карале моны, исе дә китми, чын дошман сүзен сөйләп утыра бит әй! Ә сез шуңа полный ирек бирәсез,—дип, кунагына борылды. Ә тегесе тыныч кына:

—Ничево, тиздән үзбәкләр жирендә дә тәртип урнаштырырбыз! Бик сикерә алмассың,—дип сүз башлауга Нургали аны бүлдереп:

—Анда сезгә эш калмады инде. Сездән башка да тәртипнең шундыен урнаштырдылар, исең-акылың китәр. Урыс башкисәрләренең генә килүе житмәгән, татарларны бригада-бригада итеп жибәреп күпме үзбәкләрне кырдылар. Үзбәк аналары күпме газиз улларын, үзбәк хатыннары гаиләне туендыручы газиз ирләрен югалтып, өй тулы бала-чага белән ятим калдылар. Шул үзбәкләрнең рәнҗеше безгә дә төшмәгәе дип борчыласы урынга... Их, сез...

—Нинди үзбәкләрне? Басмачыларны диген, басмачыларны кырдылар алар, бик дөрес эшләделәр. Дан аларга! Дан!—дип, ачу белән кычкырып жибәрде теге.—Тыңлап-тыңлап торам да, чыннан да син контра сүзен сөйлисең бит, егет,—дип нәтиҗә ясады ул.

—Ә син монда килеп нәрсә сөйләп утырасың? Нинди басмачылар?.. Электәге үз тәртипләре белән яшәргә теләгән шул ук үзбәкләр бит инде алар. Ачлык вакытында күпме татарларны үзләренә сыендырып, ярдәм иткән үзбәкләр шулар бит инде. Ул бәрелешләрдә татарларның үзләре күпме кырылганнарын беләсезме соң сез? Ташкентка килеп житкәнче ук чүл-далаларда ятып калган, ерткыч хайваннарга азык булган бихисап татарларның санын беләсезме соң? Кемнәрнең газизләре бетмәгәндер анда! Үзбәкләр хәзер урыстан битәр татарларны күралмый башладылар, безгә ләгънәт укыйлар. «Татарга ит яхшылык, көт явызлык» дип, безне сүгәләр. Ә сез, дан аларга, дан дисез. Мин сезгә дошман да, контра да түгел. Бары тик дөресен генә сөйләдем. Кайбер сүзләрем ошамаса, бигайбә, Фатыйх. Башка йомышларың булмаса, мин китим инде.

Нургалинең бу сүзләреннән соң рәис тә ничектер йомшаргандай булды.

—Әйе, чыннан да йомышыбыз бар сиңа. Авыл сәүите идарәсе һәм камсамул-яшьләр исеменнән авылда клуб төзелешенә бераз акчалата ярдәм сорамакчыек синнән. Үз көчебез белән төзи башларга карар кылдык.

Шактый авыр сөйләшүнең көтмәгәндә мондый борылыш алуына Нургали эченнән генә сөенеп куйды. Әмма бу халәтен сиздермәде.

—Юк-барны тикшереп, ачу китереп утырганчы сүзне менә шуннан башларга кирәгие сиңа. Ярар, миннән эш калмас, үз өлешемне кертермен. Әти дә аты белән булышыр дип уйлыйм, сөйләшермен. Аннары яңа мәктәп салу турында да уйламыйсызмы? Мәдрәсә бинасы кечерәк тә, искереп тә килә. Кичә җыенда балаларның күплеген күреп сөендем. Бу эштә ата-аналар да ярдәм итми калмас дип уйлыйм. Менә бу эшләрегез барып чыкса, халык сиңа рәхмәт кенә укыячак. Минем дә улым үсеп килә, кулдан килгәннең барын да эшләрмен.

Нургали бераз тынычлангандай булып, саубуллашып чыгып китсә дә, үзен борчыган шикле уйларыннан өенә кайтып житкәнче арына алмады. Теге кеше кантоннан НКВД тирәсеннән булмады микән? Шул жүнсез Фатыйх коткасына бирелеп, артыграк ычкынып киттем бугай... Нишләтәсе

бу кызу холыкны? Локман абзый да: «Заманалар бозылып бара, зинһар, сак булыгыз, алдыгызны-артыгызны карап йөрегез»,—дип кат-кат әйтеп, озатып калганые бит юкса. Татарның акылы төштән соң дип белми генә әйтмәгән шул безнең халык.

***

Санаулы көннәр иллә дә тиз үтә икән. Әмма кем өчен бит, Нургали белән Газзәбануга яшен тизлегендәй тоелса, Мәһирә өчен... Көннәреннән бигрәк төннәренең озынлыгы иксез-чиксез кебек. Жыен узганга да көн артыннан көн үтә тора. Газзәбануына хәзрәтнең киңәше турында тәки бер сүз әйтә алмады Нургали. Сөйләшү, килешү һичшиксез булырга тиеш һәм аның котылгысыз икәнен дә белә үзе. Тик аның ни белән тәмамланасын күз алдына китерә алмый гаҗизләнә.

Өч елга якын аерым яшәсәләр дә, мәхәббәтләренең өр-янадан дөрләп китүе икесенә дә зур бәхет китерде. Өстәвенә, алма кебек бала белән дә бизәлгән бу илаһи мәхәббәт беренче елларыдагыга караганда күпкә кайнаррак икәнен тоеп, бер-берен назлап туя алмаганда... Йә, Хода, ничек итеп сүз башламак кирәк...Ниләр генә уйлап бетермәде Нургали. Йә, жаен табып, рөхсәт итүен сорап та карады ди. Әгәр риза булмаса... Ул чакта нишләргә?.. Бу никахның кирәклеген аңлатканда үземне таләпчәнрәк тотсам... Алайса бөтенләйгә талак, дисә... Әйтә ала ул аны, малай аның кулында. Ул вакытта нишләргә? Газзәбану белән никахлашкач, әтисенең сөйләгән вәгазе исенә төште Нургалинең. «Улым, Көектә Яруллиннар нәселе ишәергә тиеш. Бабаңның миңа үпкәлисе килгән чаклары аз булмады. Синнән башка балаларыбыз, нишләптер, йә үлек, йә терек туганнары да ике-өч көнлек кенә гомер белән тудылар. Нишләтәсең, Ходайның кушканы булгандыр... Килешеп, бик тату да һәм муллык белән дә яшәдек юкса. Бервакыт бабаң, көтеп-көтеп тә өмете киселгәч, миңа болай диде: «Зариф улым, сиңа, Зөлкамал килененнең рөхсәте белән, яшь хатын алып кайтырга кирәк. Аллага шөкер, тормышыбыз бөтен. Мин ике килен, син ике хатын асрамаслык кешеләрмени без? Шәригать тә, мөселманга мөмкинлеге булса, хәтта дүрт хатын белән никахлы яшәүне хуплаган.

Әниегез дә ризалашты кебек. Ул «яшь хатын» дигәнен бергәләп тә эзләп карадык, әмма кулаен гына тапмадык. Аңа ошаганы миңа, миңа ошаганы аңа ошамады. Бәлки әле алдагылары гомерле булмасмы дигән өмет белән яшәп карарга булдык. Нишләтәсең, безнең өчен «өмет үсендерер, өметсезлек үкендерер» дигәндәйрәк килеп чыкты булса кирәк,—дип, әтисе сөйләгәннәренең барын да хәтереннән уздырды Нургали.

Әтисенең тормышка ашмаган гамәлләре бердәнбер улында кабатланыр дип кем уйлаган. Тик нәкъ киресенчә... Мәһирәсе узган ел: «Әллә тәрбиягә бирәр бала алып карыйкмы?» дигәние. Ул бала чын Яруллин була алмаячак шул. Аннары нәселебезгә ни китерәсен кем белгән? Их, ачлык, каһәр суккыры ачлык... дип ул вакыттагы өзгәләнгәннәре дә күз алдыннан үтте аның. Житмәсә,Мәһирәсе дә жае чыкса-чыкмаса, һәр көн диярлек «Газзәнә әйттеңме, ризалыгын бирәме?» дип жанын телгәли. Кичә ул аңа: «Туктат әле бу сорауларыңны, вакыты житкәч үзем әйтермен», дип, кисәтергә мәҗбүр булды. Кисәтүен кисәтте Нургали, әмма бу кыска гына әйтелгән җөмлә икесен дә тирән уйга салыр дип кем уйлаган. Мәһирәгә сөйгәненең шул вакытта үзен кырысрак тотуы һәм әйткән сүзенең дә боерык биргәндәгедәй әйтелеше ошамады, билгеле. Ризасызлыгы хәтта йөзенә дә бәреп чыкты. «Яхшы, сез теләгәнчә булыр»,—диде дә, жылап жибәрүеннән куркып, тиз генә өйдән чыгып ук китте. Нишләргә, кая гына качып бер туйганчы жыларга дип, өй артына йөгерде. Аулак урындагы биек шомырт агачы, аның төбендә ике генә

кеше утырырлык эскәмия дә бар анда. Тын гына елады да елады Маһирә. Нургалием эзләп чыгар да, юатмый калмас әле дип тә өметләнде үзе.

Өйдә ялгызы гына калган Нургалинең дә үз уе. Маһирәнең яратуы чын ярату микән? Өзелеп яратуны, моның яраткан кешең өчен үзеңне корбан итәргә әзер булу икәнен аңлыймы икән ул. Әллә аның минем белән никахлашуы әти-әнисе алдында гел чираттагы капризы гына булды микән? Әнә бит, әтисе безнең өчен дип шәп кенә йорт салдыра башлагач, ничә мәртәбә әйтеп карадым. «Без авылда торырбыз, синең үз өең, Газзәбануның үз өе булыр», дигәч, «юк» дип кырт кисте бит. Питердан соң әтиләр хакына Ташкентта яшәргә риза булганыма да рәхмәт әйтсеннәр әле! Шул чакта, ничек мин бер ни дә уйлый алмадым икән? Туктале, ә мин үзем Маһирәне чын ярату белән яраттыммы соң? Аның гаҗәеп моңлы тавышы, татарның мин белмәгән элеккеге җырларын йөрәкләрне сыкратырлык моң белән җырлаулары, скрипкәсеннән агылган үзәк-өзгеч моңнары белән миннән тәкатьсез гашыйк ясады түгелме соң? Бу инде яратудан бигрәк талантка баш ию, соклану, чиксез хөрмәт итү генә түгелме соң? Аннан, Локман абзыйның безнең мәхәббәтебезгә катнашы бармы? Никахыбызны оештыручы, әлбәттә, ул булды, әмма кызының теләгән генә үтәмәде микән. Ничек кенә булмасын, хатынымның әтисе дә бит әле ул. Тиеш булса да, ничек мин аңа бабай дип дәшә алыйм ди, юк... Ә Маһирә әтине күрүгә «әткәй» дип, әниемне «әнкәй» дип, шунда ук әйтә башлады. Минекеләр эределәр дә киттеләр. Бик тиз яулады ул аларны. Әгәр нык яратмаса, шулай булыр идемени? Аннан, миңа карата да, һаман бер төсле игътибарлы, нишләргә белми тора... Мин салкынайсам аңа ни булыр? Ярату гына түгел, вөҗдан да бар бит әле... Саф кыз булып тормышын миңа багышлаган, чын ярату булмаса, язмышы белән шулай уйный алырые микән? Минем аны рәнҗетергә хакым бармы соң? Юк бит... Газзәбану да аңларга тиеш моны.

Маһирә шомырт төбендә алай озак та утырмады шикелле. Ишегелдында каенанасының:

—Газзәбану, Нургали, сез кайда? Мунча өлгерде, керергә бик вакыт,—дип, дәшкәне ишетелде.

—Әби, әни су буенда кел чайкый, әти дә шунда китте.

—Бар, җаным, йөгереп кенә төш тә, мунча сезне көтә диген. Су буена төшсәләр дөньяларын оныта инде алар.

—Әби, әби, нәлсәләлен онталал, диден? Анысын онытмасыннал диимме?

—Ярар, ярар, улым, бар, йөгер инде. Әби чакыра диген.

Хафизның әбисенә биргән җавапларын бик рәхәтләнеп тынлады Маһирә. Ләкин менә «мунча» сүзе аның җенен үк кузгатты. «Бар икән, ни бетмәгән мунчадыр инде бу, көн дә мунча...—дип эчтән генә сукранып та куйды. Нургалиләрнең күтәренке кәеф белән шунда житәкләшеп кереп китүләрен, аннан шундый матураеп, алсуланып, янә житәкләшеп чыгып килүләрен күреп тору, Маһирә өчен иң авыры, газаплысыдыр, мөгаен. Аерым-аерым чыксалар да була бит инде, югыйсә. Моны Газзәбану үч итеп эшлидер әле. Хәзер иң яхшысы—урамга чыгып китү. Тегермән якларын, аеруча теге ялгыз, карт өянке тирәләрен урап кайту булыр.

Ишегалдында Зөлкамал очрап:

—И-и, киленкәем, син дә су буендаең мәллә? Шактыйдан күзгә чалынмадың.

—Юк, әнкәй, бакчада булдым мин. Ә хәзер болын тирәләрен әйләнеп кайтмакчы булам. Сорасалар, әйтерсең... Сорап та тормаслар әле... Мин кемгә кирәк?..

—Алай димә, балакаем. Менә Аллаһы боерса, никахыгызны яңартуга гел бергә булырсыз әле.

—Абау, әнкәй җаным, син каян беләсең? Кем әйтте? Әллә Газзәбану әйттеме?

—Юк, кызым, безнең якта сүз иясе белән йөрми диләр. Хәере белән үтсен диген.

***

Урам тыныч, бала-чагадан башка, олы-карты күренми, очраганнары да исәнләшеп, хәл-әхвәл сорашалар да, тыныч кына китеп баралар.

Карт өянке янына тиз килеп житте Маһирә. Шунда киселгән агач төпләренә калын гына такта беркетеп, озын эскәмия сымак нәрсә ясап куйганнар. Өянке тирәсен йөреп, кайбер муртайган урыннарын капшыйкапшый агачны өйрәнә башлады.

—Апай, син монда үзең генә нишләп йөрисең?—дигән тавыштан сискәнеп китте Маһирә. Башын күтәреп, як-ягына караса, артында басып торган чибәр генә яшьүсмер кызны күрде.

—Менә бу япа-ялгыз үскән, инде бик картайган өянкенең хәлен белергә дип килгәнием.

—Анысы әйбәт булган. Тик монда ялгыз килергә ярамый диләр. Аннары таң атыр-атмас вакытта бигрәк тә куркыныч диләр.

—Ә нигә ярамый, нигә куркыныч диләр?

—Ул кеше башта саташа башлый, соңыннан чирләп үк китә икән диләр.

—Алай булгач, аның берәр тарихы да бардыр әле. Бәлки сөйләп тә бирерсең...

—Юк, аны Бибиҗамал исемле бер әби сөйли. Аны шул өянкенең яшьтәше икән дип тә әйтәләр.

—Син мине шул әби белән таныштыра алмассың микән, сеңлем?

—Аның өе ерак түгел, моннан тәрәзәләре дә күренеп тора. Ә-ә-нә!

—Күрәм-күрәм. Әйдә, бергәләп барыйк...

—Юк, монда ялгыз килгәнсең бит әле. Анда барасың да барасың инде... Аның исеме Бибиҗамал булыр.

—Ярый алайса, Аллаһының рәхмәтләре яусын үзеңә, сау бул акыллым,— дип, кызга янә сынаулы бер караш ташлап:

—Өянкебез белән дә хушлашыйк инде,—диде.

«Ий, үз гомереңдә ниләр генә күрмәгән серледән-серле Олуг Өянке,— безгә кабат күрешүләр теләп тор! Исән-имин яшә!—дия-дия Маһирә кыз күрсәткән тәрәзәләргә карап китәргә кузгалды.

Маһирә килеп кергәндә карчык өендә иде. Йорт бик таза күренә. Өйнең эчендә дә чисталык, тәртип. Бик күркәм карчык икән, башында ап-ак яулык. Өстендә матур гына зәңгәр сатин күлмәк. Итәге чигелгән ак алъяпкыч ябып куйган.

—Әссәләмүгаләйкүм, вә рахмәтуллаһ, вә бәракәтүһ, Бибиҗамал әби,— дип, зурлап сәламен бирде Маһирә.

—Сүбхәналлаһү. Вәссәләмүгаләйкүм, кызым. Йөргән аякларына җиңеллек, үзеңә күп-күп савaплар иңдерсен бер Аллам. Син кем, кемнең кызы буласың? Күзем күрми минем, таный алмыйм. Тавышың бик гүзәл үзе, җансыз җаннарны да эретеп җибәрерлек дип әйтимме, әмма миңа таныш түгел. Нинди җилләр, нинди йомышлар китерде сине минем яныма?—дип, ачык тавыш белән сорауларын тезеп бирде Бибиҗамал.

—Мин бу авылныкы түгел, кунакка гына кайткан кеше, әбекәй. Йомышым бер генә. Сездән якында гына япа-ялгыз үскән карт өянкенең тарихын беләсем килә. Аны сез яхшы беләсез дип әйттеләр. Сөйләмәссез микән?

—Сөйлим, кызым, нишләп сөйләмәскә... Өянкенен үзе турында: үскәндә ялгыз булмады ул. Аңа терәк булып, җил-давылдан саклаучылары да барые. Үзе чәчкәннәреннән тишелеп чыкканнары да күп булды. Ә хәзер ялгыз. Тагын күпме гомере калгандыр... Яшәсение әле, шаһит буларак. Тыңла алайса кыйссасын да...—Карчык бисмилләсен әйтеп, сөйли башлады.

Бу бик күптәнге тарих. Миңа тиздән 97 яшь тула. Мин туганчы ук булган вакыйга ул.

Безнен Көектә бөтен яктан килгән, искиткеч чибәр Гөлҗәүһәр исемле кыз белән Мөхәммәтнур атлы егет булган. Кечкенәдән үк бик дус, бергә уйнап үскәннәр. Күршеләр дә икән әле. Өйләре өянкегә бик якын булган. Аларның уйный торган урыннары да—шул агач төбендә. Әйткәнемчә, өянке үзе дә ялгыз түгел, янында башка агачлар да күп булган. Менә егет белән кыз үсеп буйга җиткәннәр. Алар икесе дә бик моңлы итеп җырлый торган булганнар. Мөхәммәтнур җырлый башласа, хәтта сайрар кошлар да сайрауларыннан туктап аны тыңлый икән. Бу һич аерылмас ике гашыйк җанга сокланмаган кеше калмаган. Аларның даны тирә-юнь авылларга да таралган ди. Авыл халкы, туган-тумача яшьләргә матур язмышлар юраган.

Менә беркөнне көтмәгәндә, уйламаганда кыз юкка чыга. Су буенда кер чайкарга төшеп киткән Гөлҗәүһәр эзсез югала. Озак кайтмагач, егет борчылып су буена йөгерә. Басма өстендә буш чиләкләрен, чайкарга дигән керләрен күреп, анасы да өнсез кала. Тиз генә тирә-юньгә күз сала, куак араларын караштыра, башы әйләнеп, китеп суга егылмады микән дип көянтәсе белән басма тирәсен тикшереп карагандай итә. Елганың бу тирәсе шактый тирән, юк, нишләп суга батсын ди ул. Кечкенәдән суда йөзеп үстеләр бит алар...

Шулай да, Мөхәммәтнур чума-чума шул тирәдән һәм елганың агышы буенча еpактанрак та эзләп караган. Юк, суда түгел ул, димәк, Гөлҗәүһәрне урлаганнар... Бу якларда кыз урлау йоласы юк-юктан очраштыргаласа да, үз авылы егетләренең берсеннән дә шикләнми Мөхәммәтнур. Караңгы төшүгә атка атланган авыл егетләрен үзе белән алып, күрше авылларда да булалар. Ләкин кыз табылмый. Бердәнбер өмет ул да булса, һәр йоланың үз тәртибе дигәндәй, икенче көнне иртәгесен кызны урлаган егетнең ир туганнары белән этисе кыз өенә килеп хәбәр итәргә тиешләр.

Йола үтәлми, килгән-киткән кеше дә күренми, кыз бер хәбәрсез югала. Бу вакыйга ике гаиләне генә түгел, бөтен авыл халкын борчуга сала. Телләрендә Гөлҗәүһәр дә Мөхәммәтнур... Төрлечә фаразлаулар: чынлап торып җен-пәриләргә ышанучылар—җеннәр генә алып киткәндер, бигрәк гүзәл иде шул диләр. Буй җиткән матур татар кызларын фахешханәләргә сату өчен урлаучылар да бар икән дигән хәбәрләр дә тарала. Чегәннәр эше түгелме икән дияр идек, бу арада аларның күренгәннәре юк, Гөлҗәүһәрнең әнисе мари авылына күрәзәчегә дә барып караган. «Кызыгыз исән, ләкин өйгә кайтмаячак инде ул» дигән имеш. Тагын бер өмет туа—өч көннән базар көне. Ул Көектән алты чакрым ераклыкта урыс авылында. Атна саен һәр якшәмбе олы базар. Кайлардан гына килмиләр дә, ниләр генә сатмыйлар. Мөхәммәтнур үзенең дуслары белән таң атуга шунда юнәләләр. Менә шунда кызының усаллыклары белән дан тоткан, урыс катнаш Кучат дигән авылда икәнен ишетәләр.

Икенче көнне дуслары белән Кучатка юл тоталар. Ни хәл итмәк кирәк, кыз урынына кыйналудан аңын җуйган Мөхәммәтнурны арбага салып алып кайталар. Берничә көннән аягына басса да, ул инде элеккеге Мөхәммәтнур булмый. Акылына зәгыйфьлек килгән дип тә әйтә алмыйлар. Ябыга, сула, төннәрен йокламый, телсез калгандай бер кеше белән дә сөйләшми. Тик һәр көнне таң атыр алдыннан Карт өянке янына килә дә ин моңлы җырларын җырлый. Сүзләрен дә, көен дә бутамый, бары да элеккечә, тик аларның тагы

да сагышлырак, моңлырак җырлануын сизмәү мөмкин булмаган

Гөлҗәүһәр сөйгәненең ошбу газапларын ишетеп өзгәләнә. Ул да бик нык үзгәрә. Элеккеге Гөлҗәүһәрнең күләгәсе генә кала. Газаплы булса да көннәр үтә тора. Аның бала табу вакыты да якынлаша. Беркөнне коточкыч хәбәр—Мөхәммәтнурның Карт Өянке янында үле гәүдәсенә тап булып, авыл халкының күз яшьләре белән аны җирләгәннәрен ишетә. Ишетә дә, эчен тотып сыгылып төшә Гөлҗәүһәр.

Һай, бу тулгак дигәннәре түгел микән? Ачыдан-ачы тулгаклары, хәтта Мөхәммәтнуры хәсрәтләрен, аны мәңгегә югалту кайгысын азга гына булса да оныттыра алмаган, киресенчә тагы да тирәнәйткән генә.

Янында кендек әбисе белән каенана булган кеше бөтерелә. Кендек әби Гөлҗәүһәрнең тәнендәге хисапсыз кара янган урыннарны күреп: «Һай балакаем, ни хәлләр түзәргә кирәк. Күпме бәби кабул итеп, мондый җәбер кичергән хатын-кызны беренче күрәм», дип аптырап калган. «Әйдә, син үз эшенне кара инде, җәме. Бөтен эче ду килә, баланың ашыгуы бит инде бу. Бик яшь, рәтен-башын да белмидер, ярдәм ит, киңәшләрен бир үзенә»—дип каенанасы әмер кыла.

—Кызым, тулгагың шуңа кызулый, малайдыр, бик тере күренә. Сиңа актык көченне туплап көчәнергә кирәк. Жылама, кызым, жылама, бу вакытта жылау көченне генә ала. Көчән, кызым, көчән, балам,—дип тилмергән кендек әби.

—Көчән инде, баланы харап итәсең бит. Көчәнми генә бала тумый, шуны да белмәскә,—дип каенанасы да ризасызлык белдерә җитмәсә.

—Юк,—дип кычкырып күзләрен чытырдатып йомган бичара.—Жир йөзендә бу мәрхәмәтсез токымның дәвамы калырга тиеш түгел. Үз хәсрәтем үземдә калсын, аңа кагылмагыз. Ә рәнҗешләрем Мөхәммәтнурымныкы белән кушылып шушы нигездә калсын,—дигән.

Чытырдатып йомылган, шомырт карасыдай кара күзләре башка ачылмаган. Икенче көнне Гөлҗәүһәр карнындагы баласы белән гүр иясе булган.

—Ялгыз өянке кыйссабыз шуның белән тәмам. Әллә жылыйсың инде?—дип Бибиҗамал, күзе күрмәсә дә кунагына таба борылды.

—Алланың рәхмәтләре яусын сезгә, жыладым шул, бу кыйссаны башкача тыңлап та булмыйдыр. Сезнең сөйләвегез үзе бер зур хәзинә бит. Мин бүген кайтуга язып куям, Аллаһы боерса. Ничек килдем әле...

—Карале, кызым, син кемнең кунагы буласың? Үзең әйтмәден, мин сорамаганмын. Өянке тарихын сөйли башласам, бөтен дөньямны онытам шул.

—Зариф абыйларга кайттым мин.

—Ә-ә, шулаймыный? Алайса Ташкиннан кайткан кунактыр инде син. Газзәбануыбызның көндәше буласыңмы?

—Шулайрак шул, әбекәй. Язмыштыр инде...—диде дә, Маһирә тагын күзләрен сөрткәләп алды. Ә Бибиҗамал барын да сизеп утыра.

—Яраткансыңдыр инде. Яратмасаң, хатыны, баласы булган кешегә чыкмасыең.—Әллә гаиләле икәнен белмәгән көе гашыйк булдыңмы?

—Юк, белдем. Хәтта хатынын өзелеп ятратканын, яңа туган малае барын да белдем. Иләс-миләс чагым да түгел бит югыйсә. Ул вакытта инде миңа егерме бер яшь иде. Чибәр-чибәр генә шактый гыйлемле егетләргә димләп тә, очраштырып та карамадылар түгел. Нишләтәсең, берсенә дә күңелем төшмәде. Әллә сонгарак калып та житлектем инде... Ә. Нургалиегезне бер күрү белән әллә нишләдем... аны аңлатып та, сүз белән дә сөйләп булмый. Күргән өстенә күрәсем килә, күрсәм, янәшәмдә генә йөртәсем килә. Күрше бүлмәдә эти белән сөйләшкәнен генә ишетсәм дә, йөрәгем дөп-дөп итеп ярсып тибә башлый.

Атылып шул бүлмәгә кереп китәрдәй булам... Ярый Ходай саклады. Шундый халәттә айга якын азапландым. Йокым качты, хәтта ризыгымның тәме китте. Көндезләрен тавышы колагымда, үзе—бөтен тәсе, кыяфәте белән күз алдымда булды. Гашыйк булу дигән хикмәт шушыдыр инде ул име, Бибижамал әби? Минем тәмам чарасыз калган хәлемне әтиләрем дә сизде булса кирәк. Сылтау—сәбәп табып, әйтик, зур сәүдәгәр фәлән әфәнде, төгән әфәнде белән очрашуга дип Нургалине өйгә чакыра башлады әти. Анда без әнием белән катнашырга тиеш тә тиеш инде... Ходайның рәхмәте—Нургали дә мина карап-карап ала башлады. Ул күз ташлаган саен мин комач кебек кызарам икән (монысын әнием әйтә). Шулай бер көнне, әтием аны гармунынны алып безгә кичке ашка кил дип чакырган, әнием белән килешеп инде. Мина әйткән кеше юк. Эштән кайтып керсәм, бөтен өйгә таралган тәмле аш исләреннән башларым әйләнеп китте. Пешекче Суфия апа зур залда табын көйли.

—Суфия ханым, бездә тагын бер «атаклы сәүдәгәр» белән очрашу буламы әллә?—дим. (Ә үзем булса гына ярарые дип уйлыйм).

—Мин тучнысын гына әйтә алмыйм, әтиең үзе әйтер әле,—ди. Үзе бик тә серле елмая. Мин кулымдагы сумкамны ыргыттым да, әйдә, йөгер аш бүлмәсенә. Ишекне ачар-ачмас кына колак салам. Әти белән әни нәрсәдер мәш киләләр, үзара пыш-пыш сөйләшәләр дә. Берни анларлык түгел... Ә күнелем нидер сизенә... Алар мина берәр көтелмәгән сөенче килсә, шулайрак кыланалар иде. Ә-ә-ә, шулаймы, кызык итим әле мин сезне дидем дә, «эhе-е, эләктегезме» дип, ишекне ачтым. Килеп тә кердем, икесен бергә кочаклап та алдым. Шаккатты болар:

—Менә, ичмасам, син бүген кеше төсле, кызым,—диде әти.—Шулай йөр, без синең уйнап, көлеп, шаярып йөрүенә иялəнгән. Инде кайчаннан бирле сөмсерең коелып, ни ашавың, ни йокың дигәндәй, безне борчуга салып йөрисең. Безнең бар куанычыбыз син генә, кызым, шуны онытма. Әгәр син нидәндер канәгать түгел икән, борчуларың бар икән, үзебезгә әйт. Ялгыз яну, ялгыз көюдән дә авыр тагын ни бар икән? Аллам сакласын!—Шулай дип әти бераз сабак та бирөп алды.

—Әти, ярар, барын да аңладым. Мин тырышырмын. Әгәр бүген кирәгем булмаса, планлаштырган бер эшем бар иде, мина бераз тәмле әйберләрегезне бирегез дә, мин үз бүлмәмә әллүк,—дидем.

—Кирәгем булмаса, кирәгем булмаса дип инде... Юк, кызым, син уйлаган зур кешеләр түгел киләсе кунакларыбыз. Берсен син беләсең,—Нургали, икенчесе аның дусты Нурислам. Каршы булмасаң, (дигән була бит әле!) кичке ашны бергә ашарбыз. Аннан үз җаеңны үзең карарсың тагы. Хәзер килеп тә җитәрләр инде. Әйдә, әнисе, табынны карыйк, Суфия ханымга эшлисе эшләренне кушарсың да, ул китәр,—диде әти. Әнием аңа каршы:

—Ай, Аллам, мина булышырга Суфия кирәк булачак бит, нигә җибәрәсең?—диде.

—Маhирә өйдә бит, Маhирә булышыр,—дип, әти кырт кисте дә куйды. Мин исә эчемнән генә «рәхмәт яусын, әти» дип, өсләремне алышырга элдердем. Иң кызыгы шул—Нургалием үзе генә килде. «Нурисламга кибеттә өстәмә эш бирделәр. Ул бүген фатирына да бик соң кайтачак»,—диде. Ул кичне мин гомерем буена оныталмам инде. Ризыкларны бик тәмләп, мактый-мактый ашады Нургали. Мин нәрсә ашаганымны, табында ни булганын бөтенләй хәтерләмимм. Бер-беребезгә карап та алгалыйбыз, күзгә-күз очрашкан мизгелләр дә булды. Мин «кызармасам гына ярарые» дип телим. Үч иткәндәй битләрем уттай яна, ничек кызармасын инде ул. Нургали исә тыныч, үзгәрми дә, минем төсле каушамый да. Әнием китергән hәр ризыкны мактап ашавын белә. Әни куана: «ашаган малда өмет бар, аша җаным аша»,—дип кыстый да кыстый. «Менә монысын гына, менә бу калҗасын гына, менә бу кисәген генә»,—дия-

дия ашата торгач, кунак: «Рәхмәт, Зәйнәп апа, башка булмый. Минем әни дә, нәкъ сезнең күк кыстап ашатырга ярата иде,—диде.—Алар хәзер моңдый ризыкларны төшләрендә дә күралмый торганнардыр. Бүген мин гүя үз әнием кулыннан ризыкланган күк ашадым да ашадым, гаеп итмәгез инде... Сагынам мин аларны, бик сагынам, хатынымны да, туып кына калган улымны да бик сагынам...». Миңа читен, бик тә читен булып китте. Кызгандым мин аны, ә үзем шушы кешегә башымны җуеп гашыйк... Шулчак үзенә күтәрелеп карасам, күзләре мөлдерәмә, түгелеп китмәсен дип, ахры, кул аркасы белән сыпырып куйды. Шулчак әти:—«Әйдә, якташ, ал әле гармуныңны, бер көн эштә уйнаган кебек уйнап җибәр,—димәсенме.—Минем дә үз авылымны, әти-әниләремне сагынуларымны әйтеп сыздыр әле... Үзебезчә, татарча бер моңланып алыйк. Бирешмә, якташ, синең туган җиреңнән аерылуың вакытлыча гына. Ә минеке миңа гомерлек булды... Җәсадем дә чит-ят җирләрдә калачак. Әти-әниемне дә үз кулым белән җирли алмадым. Алар мине, мин аларны, өзелеп сагынып, бер күрергә зар-интизар булып яшәдек.

Күпме татарларыбыз чукындырудан качып туган җирләрен мәңгегә ташлап китәргә мәҗбүр булды. Быелгы коточкыч ачлык, янә безнең Идел буйларында башланды. Аңа корылык кына сәбәп түгел икәнен дә беләбез, тик аны әйтергә генә ярамый. Тагын күпме кеше кырылачак...

Сиңа килсәк, кыйгырма, мин сине сынап өлгердем инде. Син ышанычлы, гадел, зирәк акыллы, булган егет. Синең өчен кулымнан килгәннең барын да эшләячәкмен. Сиңа сәүдәдә гыйлем алырга һәм урыс телен өйрәнергә кирәк. Укытучысы каршында утыра, үзең тырышсаң миннән дә, Маһирәдән дә эш калмас.

—Ну, әти-и, минем белән сөйләшмичә дә шулай эшләп буламыни? Мин риза булмасам әгәр?

—Ә син кем кызы соң? Әллә онытып җибәрдеңме?—дип тыныч кына җаваплады әтием.

«Менә шулай, Нургали әфәндем. Бу йортта миңа «әти-әни» дигән мөһер сугылып, берәр эш йөкләнә икән, ул үтәлергә тиеш. Понятно? Әмма мин ялкауларны яратмыйм, сүз тыңламаучы, өй эшен үтәмәүче укучыларны җенем сөйми» дип, шаяртуымнан өчесе дә көлеп җибәрде. Әниемә минем бу сүзләрем әллә ошамады инде, ул мине «әйдәле» дип аш бүлмәсенә алып китте. Сөйләшергә дә өлгермәдек, гармун тавышы... Шулкадәр моңлы, мин ишетмәгән көй. Залга атылдым. Үзләренә күренмичә генә көйнең ахырын уйнап бетергәнен көттем. Йөрәк бәгырьләреңне сызлатырлык моңлы көенә, Нургалинең шушы көйнең үзе таләп иткәнчә уйный алу осталыгына таң калдым. Түзмәдем: нинди көй бу? Композиторы кем? Шулай оста уйнарга сезне кем өйрәтте?—дип сорадым.

—Безнең авыл көе ул. Көйне чыгарган кешесен әйтә алмыйм. Минемчә, аны беркем дә белмидер...—диде ул.

—Бу көйгә, кызым, әле генә без искә алган үз татарларыбызның ачыдан-ачы язмышы, хәсрәте салынган. Шуңа күрә дә шулай моңлы, үтә моңлы ул.

Көн арты көннәр үтте. Рус теленнән Нургалигә бик теләп дәресләр бирәм. Аннан соң җыр, музыка дәресләре китә. Менә шулай без бер-беребезгә һаман якыная бардык. Күбрәк мин яраттым бугай, миңа шулай тоела. Ниһаять, без никахлашып, бергә яши дә башладык.

—Әле авылга, көндәшең янына да кайтырга батырчылык иткәнсең. Ничегрәк кабул иттеләр соң үзеңне? Зарифлар нәселләре белән Көекнең иң дәрәҗәле кешеләреннән берсе. Алар киң күңелле, мохтаҗларга ярдәмле, тырыш, булган кешеләр. Газзәбану да авылыбыз күрке. Әйтәләр бит әле: «килен каенеш туфрагыннан» дип, ул да бик уңган, булган, ачык чырайлы, үзләре төсле үк мәрхәмәтле бала булып килде. Минем үземне дә ач үлемнән

алар коткарып калды. Шешенә башлаганыем инде. Газзәбану белән Зөлкамал көн саен чиратлашып килеп ризыкландырып тордылар. Алар мине генә түгел, байтак кешеләрне саклап калган затлар. Әле күптән түгел генә вафат булган мәрхүм Газимҗаныбызны да... урыны җәннәттә булсын. Нургалинен Ташкиннан җибәреп торган ярдәме аркасында... И-и, җаным, барыгызга да Аллаһының рәхмәтләре яусын! Әйтсәм әйтим инде, Нургалиеннең кендек әбисе булам мин. Аны кулыма алган минутларда, бер Раббемнан, монысын үзең сакла инде, гомерле итә күр» дип сорап ялварганнарымны һич онытасым юк. Күзем сукырайганчы авылыбызда кендек әбисе булдым. Аннан миңа ярдәмгә Гыйззелбәнат килде. Аллага шөкер, безнең авылның туфрагы бик уңдырышлы булып чыкты. Тупырдаталар гына хатыннар, җанашларым. Төн йокылары күрмәгән чаклар күп булды инде... Күбесенчә төнлә туалар бит алар, үч иткәндәй. Кай төннәрне, чиратка баскандай, өчәр, дүртәр бала кабул иткән чаклар да булае. Авылның бер башыннан икенче башына чабаек инде, Гыйззелбәнат белән. Шөкер, бик тату эшләдек без.

—Карале, Бибиҗамал әби, ул Гыйззелбәнат апаны «килде» дидегез. Бу авылныкы түгелмени ул?

—Юк, Казан кызы. Ул безнең ише генә түгел. Зур духтыр, әллә прафисырмы шунда, шундый кешенең кызы диләр аны. Ул кендек әбисе генә түгел, белмәгән эше дә юк бугай аның. Ерактан урыс авылларыннан имгәнгән ирләр дә килә аңа. Алар аны бик зурлап «хастаправ» бит ул диләр. Әче төшкән һәм балага уза алмаган хатыннарның карап торганнары ул. Безнең авыл, тирә-күршеләр генәме, Казанның үзеннән дә киләләр аңа.

—Әче төшкәннәргә ничек ярдәм итә икән соң ул?

—Чүлмәк сала. Аның кечкенә генә бик матур чүлмәге бар. Минем үземдә дә булды ул эч төшү дигәннәре. Без хатын-кызлар җүләррәк бит. Кайчакта ирләр күтәрмәгәнне дә күтәрәбез. Авыл җирендә хатын-кызга яшәүләре бер дә җиңел түгел шул. Ярый ла ул ирең таза, сине җәлли торган булса, аларның да төрлесе бар бит. Чирлеләре дә, ялкаулары да... Минем Мифтахетдинем, җан кисәгем, урыны җәннәтнең түрендә булсын, иллә дә булган кеше ие, коеп куйган балта остасы булды. Аның үз кулы белән салган йортта яшим, мең шөкер. Ачуланган чакларым да булгалады. Акча яратты, чит авылларда да йортларны күп салды, куна-төнә йөргән чаклары да булды, шаяргалаган чаклары да булгалады бугай. Үзем күрмәдем. «Кеше сүзе кеше үтерер» дигәндәй, кеше сүзе белән борчымадым, артыннан да йөрмәдем. Бәлкем шуна да рәхмәтле булгандыр. «Бар да тигез җәннәттә» дигәндәй, төрлесе булгандыр инде. Ул югында капчык-капчык ашлыгын да, бәрәңгесен дә кем күтәрсен... Менә шул вакытта эчем төшкән дә инде. Ярый Гыйззелбәнат үзенең шул сихри чүлмәге белән үз урынына утыртып куйды, рәхмәт төшкере. Ә картым, әйтер хәлем юк, үземә йомшак булды, үз гомерендә бер каты сүз әйткәне дә булмады. Сагынып кайтырые, «рәхәтем минем» дип, мине дә рәхәтләндерә ие, җанашым. Менә аннан башка, инде җиде ел, безнең яндагы ялгыз картайган өянкебез күк (мин аны үзем Байтирәк дим), Мифтахетдинемне юксынып яшим. Сине үзенә тарткан, шул өянкенең үзен яраткан Гөлҗәүһәр белән Мөхәммәтнурын сагынмыйдыр, юксынмыйдыр дип, беребез дә әйтәлмыйбыз. Ул әлегә картаеп, муртаеп бетсә дә тере, җаны бар, яши. Кешеләр өчен, ике гашыйк җанның фаҗигале тарихын онытмасыннар, гыйбрәт алсыннар дип, шулай азапланып булса да... Ә син, Маһирә, теге кыз әйткәннәрне күңелеңә якын алма, шикләнмә. Бервакыт, ул тарихны сөйләргә дә ярамый дигән сүз таратучылар да булды. Ни хәл итәсең, ышанучылар да табылды. Ә мин сөйләвемне дәвам итәм. Барыбызның да язмышларыбыз Аллаһы Тәгалә кулында. Аңа бары да мәгълүм... Гөлҗәүһәрне урлаган үтә явыз егетнең һәм аның ата-анасының язмышы да кеше ышанмаслык... Гөлҗәүһәрне

жирләгәннән соң, шул ук җәйнен бер давыллы төнендә аларның өйләрен, бөтенесе изрәп йоклаганда, яшен суга. Яшене дә гадәти булмаган, имеш. Өй эчендә бөтен җирне айкап, тәгәрәп йөри торганы булган диделәр. Зур ике катлы йорт урынында бары кара кисәүләр генә калган, диделәр.

—Абау, дөрес микән ул, әбекәй?

—Аны мин, кызым, дөрес дип тә, дөрес түгел дип тә әйтә алмыйм. Ярар, кунагым, әйтергә яраса, минем дә сина гадәти булмаган бер үтенечем бар бит әле. Җыеннан соң, кичке уенда синен скрипкәдә уйнап җырлаганыңа шаккатмаган кеше калмаган, сөйләп бетерә алмыйлар. Бик тә ишетәсем килә. Ишетеп кала алырмынмы, юкмы, белмим.

—Нургали белән сөйләшермен әле мин.

—Әгәр башка күрешә алмасак, еллар үтеп, минем вафатым турында ишетсәң, Гатиатулла кызы Бибиҗамал әби рухына дип дога кылырсың, яме. Ташкинга кайткач әти-әниенә сәламнәремне тапшырырга да онытма, яме. Газзәбану белән тату яшәргә тырыш,—дип, әйтеп кенә бетерде Бибиҗамал, ишекне шакылдатып Нургали килеп кермәсенме... Маһирәсен күреп күзе дүрт булды егетнең: «Син монда ничек килеп эләктең әле?»

—Кендек әбисе кулында яңа гына җылый-җылый дөньяга килгән Нургалиемне күрергә дип кергәнием,—диде Маһирә.

—Күзем тимәсен, бик тапкыр да икәнсең әле,—дип, соклануын белдерде карчык.

Әбинең күрмәвеннән файдаланып, гашыйклар битләрен биткә куеп, бер-беренә сеңеп бетеп, кочаклашып алдылар.

—Әбекәй, менә монысы безнекеләрнең яңа гына мичтән алган вак бәлешләре, сиңа күчтәнәчкә. Иртәгә Коръән ашына чакырып кайт дип җибәрделәр мине. Сәгать 12 тулыр алдыннан үзем килеп алырмын. Намазын бездә генә укыр диделәр.

—Һай, рәхмәт төшкерләре, мине куандырган өчен, Раббем сезне дә куандырсын. Кайтып житкәч тә, әти-әниеңә, яраткан Газзәбануыма рәхмәтләрем белән сәламнәремне тапшыра күр, улым, дип озатып калды ул.

Бибиҗамал карчык Маһирә белән очрашудан, соңыннан гына булса да Нургали белән дә күрешүдән соң нык дулкынланып калды. Гәззәбану белән икесе бергә килеп кергән булсалар, бу кадәр үк талкынмас иде, җаным. Маһирәнен кем икәнен ачыклауга, үзе өчен иң кадерле кешегә әйләнгән Газзәбану күз алдыннан китмәде. Кызганды ул аны, бик кызганды. Маһирәнен авылга кайтырга җөрьәт итүен үзенчә аңларга тырышты. Аңа нәрсә, «үлеп ярата», «гыйшкыннан аерылып, ике атна буе ялгыз яшәүгә ничек түзсен ул»... Ә Газзәбанунын йөрәгенә төзәлмәслек тирән җәрәхәт алып кайтуын каян белсен? Бала чагыннан ук, зур байлык белән яшәгән әти-әнисенә берләнбер, бик кадерле кыз булып, ни генә кылса да үз ихтыярында, үзе теләгәнчә генә яшәгән кыздан ни көтәсең... Ә менә авылыбызның иң акыллы егете дип йөргән Нургалинен Газзәбануга карата гафу ителмәслек бу рәхимсезлеген ничек аңларга? Төрлечә уйлап, хәтта үзенең Мифтахетдинен дә Нургали урынына куеп карады. Юк, ул беркайчан да мондый юлга басмасые. Шушы уйларыннан арына алмаган Бибиҗамал ястү намазында буталгалап бетте, гомер булмаганны. Аптырагач, ишегалдына чыкты. Һай, борынны ярып кергән җәйге саф һава, бөтен кара җирне каплап үскән бәбкә үләннәреннән таралган алма исләре, тын гына искән җилгә агач яфракларынын лепердәгән, чыпчыкларның чыркылдаган тавышлары җаныма мен шифадыр. Күзләрем күрмәсә дә, барын да ишетеп, тоеп, сизеп тора алуларым Аллаһы Тәгаләмнең мина биргән зур бүләгедер. Әлхәмдүлилләһ.

*Ахыры киләсе санда*



Шәмсия
Җиһангирова

# ЙӨРӘГЕМӘ УЧАК ЯКТЫМ...

## Ачам һаман бер үк фал

Ничәмә-ничә мәртәбә
Ачам һаман бер үк фал:
Кадерләрең бар чагыңның
Кадерләрен белеп кал!
Үтә икән, китә икән
Гомер дигәнең агып...
Җитә икән яшәү чоры
Кадерсезләргә калып.
Беркем килми, беркем китми,
Һичкем белми хәлеңне.
Берьялгызың үткәрәсең
Шулай картлык мәлеңне.
Телефон да телсез калган,
Йоклый никтер кыңгырау...
Җанны гел кимереп тора
Җавапсыз мең-мең сорау.
Ул сораулар барысы да
«Нигә?» белән башлана...
Һәр нәрсәнең чарасы бар,
Картлыкка юк ник чара?!
Бик ямьсез микәнни соң ул
Читтән карап торырга?—
Нигә аңа бөтен кеше
Арты белән борыла?
Артка борылып, картлыгыңнан
Качып булмый лабаса!—
Беркөн килеп нәкъ каршыңа
Ул үзе килеп баса.
Кеше картлыгын буладыр
Күрмәмешкә сабышып.

Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА — *шагыйрә, прозаик; «Төсле моң», «Балачак кая китә?», «Жирсу» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Төшенерсең: үзеңә беркөн
Картлык куйгач ябышып.
Яшьләр, яшьләр! Тыңлагызчы
Сезгә әйтер сүзем бар:
Өлкәннәргә—игътибар!
Өлкәннәргә—игътибар!!!

* * *

Мин бер гөлдәй, бу җиһанга күзем ачтым.
Торып бастым.
Уңга бактым.
Сулга бактым...
Дөрләп торган уттан гайре һични тапмыйм.
Мин шул уттан йөрәгемә учак яктым.
Язда яндым.
Җәйдә яндым.
Дөрләп яндым!..
Беркем күмер өстәмәде. Үз күмерем.
Яна-яна уза бардым бер гомерем.
Көзгә кердем...
Әле һаман йөрәгемдә утым дөрли ничә заман.
Һаман янам.
Һаман янам.
Сүндермәккә, салкын диеп, сиптем суын.
Шул салкыннан пеште җаным, янды уем...
«Янмыйм!» дигән уемны мин читкә кудым.
Янә киттем.
Кышка җиттем...
Җавап учак кабынырын өмет иттем.
Барам, барам...
Кая табан?!.
Бу җиһанда уттан башка, йә, ни таптым?!—
Утта яндым.
Утлар яктым...—
Һични таптым!..

***

Минем җаным гел ут кына!
Уттан тора!
Су сибеп тә, ком сибеп тә
Беркем сүндерәлмәс!
Әйтер кемдер: «Һи!
Яшь чагында кем дөрләмәс?!»
Юк шул! Дөрес түгел!—
Мин ут булып туган.
Яшәвемнең асылын да,
Максатын да табам шуннан!
«Җитте!» диеп сүнәр түгел
Яшьлек үткәч.
Була анысы яшьләрнең дә
Күңеле карты.
Әзме кабынганчы сүнгән җаннар!
Янәшәмдә чук-чук тезелгәннәр алар...
Ут өләшәм сүнгәннәргә, ут өләшәм!
Хөсетләрдән өстен калып һәм көнләштән.
Килегез, алыгыз!

***

Селкенәдер агач яфраклары
Җилләр искәнлеген белдереп.
Кая барсак, шунда йөзебез якты,
Без йөрмәдек кеше көлдереп.

Бер чәчкәдән күчеп икенчегә
Бал кортлары оча бал эзләп.
Асыл ирләр үзе килеп тапты,
Без йөрмәдек сөяр яр эзләп.

Урман эчләрендә агачлар күп,
Парлап үскәннәре бик сирәк.
Кемнәргәдер терәк булса җитә,
Безгә сөеп яшәр яр кирәк.

Асыл атлар күпме дуласа да,
Беләм араннарны ватмасын.
Дөнья малларына кызыкмадык,
Сөелмәүдән Аллам сакласын!

***

Урам. Буран. Тәрәз. Тәрәздә—мин.
Үткән һәр кешене карап торам.
«Бер, ике...» дип шулай, «егерме...» дип,
Гомер мизгелләрен санап торам.

Атылып чыгам буран уртасына,
Көртләр ярып барам, барам, барам...
Ничә айлар инде, ничә еллар
Уем белән һаман сиңа табан.

Тик бураннар гына туктамасын!—
Килеп җитәм инде менә-менә...
Урам. Буран. Тәрәз. Тәрәздә—мин.
Яшәп булмый шигырь белән генә.

***

Ә мин яшим һаман үткәннәрдә!
«Бүгенеңдә яшә!»—дисәләр дә.
Сагышларым җанны кисәләр дә...
Әйләнәм дә кайтам үткәннәргә.

Үткәнемә кайтам. Синең янга.
Моңсу күзләреңә табынырга.
Мин бит синнән берни өмет итмим
Һәм рөхсәт көтмим сагынырга.

Сагынам да өзелеп... сине эзләп
Кайтып китәм кабат үткәннәргә.
Бүгенемдә сине табар өчен!
«Үткән кире кайтмый...» дисәләр дә.

Ә мин менә үткәнемдә яшим...
Синсез бүгенемнән кача-кача.
Сөяр идем сине шаша-шаша,—
Үткәнемә кире кайта алсам.

* * *

Ярамый икән, ярамый
Әйтергә берәүгә дә
Өзелгәнен үзәккәең
Чит тәнгә тералгәндә.

Ярамый икән, ярамый
Чишәргә эч серенне—
Яратмыйча бу дөньяда
Яшәү мөмкин түгелне

Әйтмә икән беркемгә дә,
Җаныңда гына сакла,
Әҗәл белән бер икәнен
Йоклауның чит кочакта.

Иртән күзеңне ачуга
Җаның ник әрнегәнне
Әйтә күрмә берәүгә дә,
Берәүнең бар берәве.

Шул берәү әйтер берәүгә,
Таралыр потлап гайбәт...
Сорашсалар хәлләреңне,
Бер җавап булсын: «Әйбәт!»

Ярамый икән, ярамый
Әйтергә берәүгә дә!..
Өйгә кайткач, рәхәтләнеп,
Була яшь түгәргә дә...
Әйтмә син берәүгә дә!

* * *

Ничә еллар инде, ничә еллар
Ачык тотам сиңа ишегемне.
Син кил генә, мин гафу итәрмен,
Кичерермен синең кичегүне.

Ничә еллар инде, ничә еллар
Моңсу караш тотам тәрәзәмдә.
Сөеп була икән, беләм хәзер,
Җитеп хәтта шашар дәрәҗәгә.

Ничә еллар инде, ничә еллар
Җаным сиңа «кил!» дип сөрән сала;
Кышларыма зинһар соңга калма,
Җәйләремә инде соңарсаң да...

Ничә еллар инде, ничә еллар
Ачык тотам сиңа ишегемне.
«Синдер!..» дисәм, бүген менә тагын
Ишегемне буран ачып керде.

***

Учак яктык икәү кар өстендә—
Бер кочак утын...
Син—бер ялкын, мин—бер ялкын гүя,
Арада—упкын!

Ыргылып алуың җитәр иде
Упкын чыгарга...
Бер-береңне сабырлыкта күпме
Була сынарга?!

...Карап тордык икәү ике якта
Дөрләгән утны.
Синдә—ялкын, миндә—ялкын юкса!—
Нигә курыктык?!

Ир солтаны бит син! Ил солтаны!
Кая егәрең?!—
Учак ялкыныннан уттай дөрләп
Яна күзләрең!

Дөрләр идек бергә—икәү булсак!—
Арада упкын!
Ике ялгыз җанны җылыталмас
Бер кочак утын...

Учак яктык икәү кар өстендә—
Бер кочак утын!



Алсу
Хәсәнова

# НОКТА

ХИКӘЯ

Ниһаять, ул инде күпме вакытлар чын мәгънәсендә аның бердәнбер һәм соңгы таянычына әверелгән култык таягын ташлап, өенә үз аяклары белән кайтып китәчәк! Әле генә табиб авызыннан чыккан шушы шатлыклы хәбәрдән соң Сәрия үзен күкнең җиденче катында кебек хис итте. Хәтта менә шушында тирә-якны яңгыратып, башын күккә чөеп кычкырып җырлап җибәрәсе килде. Көнен күр тагын, көнен! Кояш та, сөенечен уртаклашырга теләгәндәй, аның алсу йөзен ничектер сөеп иркәли, алай гына да түгел, үзенә бертөрле җылылык һәм саклык белән чем-кара кыйгач кашларын, бөдрәләнеп ике чигәсенә төшкән берничә бөртек куе коңгырт чәчен сыйпап-сыйпап куя сыман. Сәрия бөтен күңеле белән елмайды, бит уртасында «мәхәббәт чокыры» пәйда булды. Коңгырт күзләрен нык кыса төшеп, кояшка карап өлгерде. Их, рәхәт бит ул дөньяда яшәүләре!

Ничәмә-ничә еллык газапларын да оныттырган әлеге бәхетле халәттә хастаханә баскычы төбендә басып торган хатын бер әүнен: «Сәрия?!»—дип эндәшүеннән кинәт имәнеп китте. Никадәр карап торса да әлеге ир-атның йөзен һич исенә төшерә алмый азапланды ул. Әмма бу кешедәге гаҗәпләнү катыш әллә кайдан эчтән, күңел төпкеленнән килгән ниндидер яшерен өмет, сүзсез дә аңлашылырлык ялвару белән төбәлгән кара күзләр генә бераздан аның хәтерен яңартып, сөенечле хисләреннән айнытып җибәргәндәй булды.

...Туктале, тукта, Илдус түгелме соң бу?! Алай дисәң, ул монда ничек килеп чыгар икән?!

Сәрия дәшүчегә тагын да текәлебрәк карады. Юк, йөзенә түгел, кара күзләренә. Шунда ир кеше, ничектер уңайсызланган сыман, читкә борылды. Үзе бит бу—татлы телле Илдус!.. Күзләренә туп-туры текәлгән чакларда ул гына менә шушылай карашын гел читкә бора.

...Татлы тел дигәннән, чыннан да, егет матур сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел иде. Бөтен җире килгән Илдусның озын буй, шомырттай кара күз, ике якка сызылып киткән каш, дегет сыман кара чәч, чибәрлеге өстенә сүзгә-телгә оста булуы да үзенә тарта иде бит.

---

Алсу ХӘСӘНОВА — *яшь язучы; «Ватаным Татарстан» газетасында әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөхәррире. Казанда яши.*

—Дөньяда кызларның иң-иң чибәрләре менә кайда икән бит, ә!—диде Илдус. Студентлар тулай торагына авылдаш кызының туган көненә Марсель белән икәүләп килгән иде алар. Әлбәттә, Илдус тикмәгә генә ияреп килмәгән иде бугай.

—Танышыйк, кызлар: мин үзем эти-әни малае Илдус булам, ә сезләрне ничек дип йөртик?

Таныштылар. Иптәш кызының туган көнен студентларча әзерләнгән табын янында үткәрделәр. Илдус егетлеген күрсәтергә шунда да җаен тапты: янында утырган Сәриягә йә ипиен, йә салатын алып бирде, йә фужерына сок салды, аны кулына тоттырды, кыскасы, кызны гел игътибар үзәгендә тотты. Хәтта биеп алганнан соң килеп утыргач, рестораннардагы шикелле, урындыгына тикле этәреп куйды.

Сәриягә егетнең биегәндә үзенә сыенып-ябышып бетәргә тырышмавы да ошады, Илдус чыннан да үзен бик әдәпле тотты. Дөрес, авызы гел кызның колак төбендә булды. Башкалар ишетмәсен дигәндәй, нигәдер пышылдауга күчә барды:

—Моңарчы ничек очратмадым икән мин сине, Сәрия?!—диде ул, гаҗәпләнгән булып.

Егет танышуга ук, кайберәүләр шикелле әле «сез», әле «син» дип буталмады, беренче сүзеннән үк өздереп: «син» дип сөйләшеп китте. «Мин синнән башка никадәр вакытымны әрәм итеп йөргәнмен, бит, әй!—дип тә өстәп куярга онытмады.

Башта ял көннәрендә генә килә иде, тора-бара Илдус ешрак кергәли башлады. Кич җитте исә әле киногa, әле театрга, әле концертка чакыра. Дөрес, билет алганчы башта Сәриядән фәлән-фәлән көнне вакыты булу-булмавын сорый. Еш кына чәчәк бәйләмнәре дә бүләк итә. Егетнең чәчәк бирүе дә үзгә: ул аларны яшереп кенә керә дә, аннары куенынннан чыгарып бирә. Шул ук мизгелдә Сәриянең битеннән җинелчә генә үбеп тә ала! Һәм колагына: «Сагынудан саргая яздым мин, Сәрия», яисә: «Синең яныңа төнге уникедә килерлек булдым, валлаһи!», яки: «Без кайчан бергә булырбыз икән инде, ә, җанашым?»—дип пышылдарга да өлгерә. Ул моны шундый житез, шундый оста итеп эшли ки, Сәрия нидер әйтү түгел, авызын ачарга да өлгерми кала.

Әле танышуларына өч айлап та узмаган, бер мәлне—ял көне иде бугай, ул—Илдус килеп керде дә ишектән үк:

—Мин башка түзә алмыйм, Сәрия, син диплом алуга—Загска барабыз!—дип әйтеп салды.—Күпме янарга, күпме көяргә болай?! Кара күмергә калам ич инде мин!..

Иптәш кызлары авылга кайтып киткәннәр иде. Бүлмәдә икесе генә, әллә шуңа батырайды егет.

—Сиңа ни булды бүген, Ил-ду-ус?— дип гаҗәпләнде Сәрия, инбашларын җыерып.—Саташма! Танышу кая да кавышу кая монда...

—Нәрсә, урлап алып киткәннәрен көтәргә кушасыңмы?—диде моңа каршы егет, өч роза чәчәге сузып. Юк инде, булмый болай! Син укып бетерүгә өйләнешәбез! Баста! Ышан миңа, мин сине өзелеп сөям, Сәрия, миңа синнән башка беркем кирәкми! Язмышым син минем.

Араларында мәхәббәт уты кабынды бугай. Моңарчы егетләр белән йөрмәгәнгәдерме, Сәрия йомшак сүздән тәмам эреде. Илдус кайбер авыл егетләре кебек тупас сөйләшмәс. Кигән киеменә дә, хәтта йөзенә аз гына кершән салсаң да игътибар итми калмый, шундук күнеленә ятышлы җылы сүз әйтеп куя. Кызлар күнелен яулау өчен әлләни күп кирәк тә түгел бит—хатын-кыз колагы белән ярата диләр. Сәриянең колакка бик сизгер чагы шул...

Егет сүзендә торды. Бишенче курсны тәмамлаган җәйдә үк авылга Сәрияне сорарга кайттылар. Икенче көнне кыз төш күрде. Монысы элеккесеннән дә шомлы иде...Туктале, беренчесе ничек иде соң әле аның? Әһә, әйе.

Аларны нииндидер өермә үз эченә бөтереп алып кереп киткән иде. Кулга-кул тотынышып, куркыныч өермәдән менә-менә котылабыз дип талпынганда, Илдус, кинәт кечкенә генә ноктага әверелеп, давыл эчендә юкка чыкты...

Яна күргән төшендә дә никтер тагын өермә иде. Бөтен дөньяны инләгән шул коточкыч давыл Сәрияне нииндидер утрауга илтеп ташлаган имеш. Утравы кечкенә генә, үзе нокта кебек түм-түгәрәк, үзендә бер адәм заты да күренми. Кыз шунда жан-фәрман килеп Илдусны эзли, ә ул исә беркайда да юк! Сәрия тырыша-тырмаша нииндидер ярга үрмәләгәндә кинәт бармагыннан балдагы төшеп, аска тәгәрәде. Эзли-эзли аптырап бетте, тик таба алмый гына бит! Үзе менә шушында гына кебек...Ялтыраган һәр төрткене, яр буендагы һәр ташны актарды, аларның һәрберсен тотып-тотып карады, бармаклары канап бетте, ә балдак барыбер табылмады, суга төшкәндәй юк булды...

Сәрия манма тиргә батып, авыр йөк сыман иннәрен басып торган нииндидер шомлы билгесезлектә уянып китте. Куркынып күзен ачып жибәрсә, янында әнисе басып тора.

— Әллә нишлисең син, кызым,—диде ул, гажәпләнеп,—ыңгырашасың. Йокың тыныч түгел. Берәр жирең авыртмыйдыр бит?

—Борчылам бераз...Ни әйтсәң дә, кияүгә чыгам бит, әни, уен эш түгел. Ә шомлы төше турында бер сүз дә әйтмәде.

—Кәләш дигәч тә, алай бик иркәләнмә әле, үзеңне рәткә китерергә кирәк, син туйда барысыннан да чибәр булырга тиеш. Тор әйдә, тиз бул!—диде әнисе кырыс кына.

Әнисе вакыт-вакыт ягымлы да, ә кирәксә кырыслана да белә. Әйе, тормыш йөген күбрәк аңа тартырга туры килде шул. Әтисе төшеп калганнардан түгел түгелен, сабыр, туры сүзле. Әмма әнисе күпкә үткенрәк, үз дигәненә ирешә торган нәселдән: алам дигән әйберсен алмыйча, эшлим дигәнен ахырына житкермичә калмый. Аңа карап иренә дә сүз тидермәде. «Әтиең кебек тыныч, сабыр кешегә чыксаң, бәхетле булыр идең, кызым»,—дип гел әйтә килде.

Булачак кияве әтисе кебек сабыр холыклы булмаса да, туры сүзлелеге белән аңа охшаган иде. «Безгә яраша торган кеше син»,—дип мактадылар аны.

—Чиләгенә күрә капкачын сайлап бирәләр инде аның, әбекәй!—диде кияү, кинаяле елмаеп.

Туйга ун машина белән төп-төгәл киләм дигән иде, нәкъ шулай эшләде дә. Туганнардан берсе: «Кияү кеше берәр сәгатькә соңга кала инде ул, артык ашыкмагыз»,—дип авызын ябарга да өлгермәде, авыл башында машиналар кычкырткан тавыш ишетелде.

—Нәкъ вакытында! Илдус үз сүзен тота торган егет ул!— диде Сәрия, куанып.

—Фатаңны ничек куябыз, иң авыры шул,—диде иптәш кызы Ләйсән. Биегәндә килеп төшмәсен тагын, хур булырбыз! Бик яхшы итеп каптырырга кирәк. Инде килеп тә житәләр, ә без әле һаман...

Ике-өч кыз берьюлы аның чәченә ябышты. Артык кабалануданмы шунда, берсе аны авырттырып өлгерде.

—Туйга әзерләнәм дигәч тә...башымны тишәсез бит инде!—диде Сәрия, чыраен сытып.

—Матурлыкка корбан кирәк. Шулай булгач, түзәсең инде, жаныкаем,—диде Ләйсән.

Туйдан соң Кара диңгез буенда ял итеп кайттылар.

Әмма кайтыр юлда Сәриянең башы, дөресрәге, чигәсе сызлап тинтерәтте. Дарулар да эчеп карады, тик берниндн файдасы тимәде.

—Абау, кызым, берәр хәл булдымы әллә?!—диде әнисе, диңгез буеннан ябыгып, төсе китеп кайткан Сәриягә карап.—Нишләп бетәштең бу тамаша?!

—Дингез һавасы килешеп бетмәде бугай. Шул гынадыр.

Сәрия чыннан да шулай дип уйлый иде. Ләкин кайтканына бер ай узып та һаман шул урыны гына сызлагач, монда һаваның берминди дә катнашы юклыгына төшенә башлады.

—Иртәгә үк шәһәргә, табибка барабыз,—диде тимерне кызуында сугарга күнеккән әнисе.

Иртүк Илдусның таныш табиблары янына хастаханәгә киттеләр. Сәрия юл буе инде ничә көннәр буе кереп йөдәткән шомлы төше хакында уйланып барды. Төшендә күргәннәренең азагын өнендә күтәргә тиеш микәнни?..

Хастаханәдә Сәриянең авыру сәбәбен өздереп кенә әйтүче юк. Төрле анализлар бирергә, рентген, томограф үтәргә куштылар, аларның нәтиҗәләрен көтәргә кирәк иде. Дәрәҗәле хастаханә профессорларына да җибәреп карадылар...Ул анализ дигәннәренең ниндиләрен генә ясамадылар! Ходаем! Канын гына да кырыкмаса кырык җирдән алып, кырыкмаса кырык мәртәбә тикшергәннәрдер!

Анда-монда йөртә торгач, бу чирнең сәбәбе туй чорыннан калган ноктадагы яра булмагае дигән нәтиҗәгә килә башладылар.

—Бер төрткән чәчкаптырма эзе шундый яра ясамый ла инде! Бәрелмәдем-сугылмадым, егылмадым...—дип акланырга теләде Сәрия.

Туктаусыз дәвалану юлларын таптар көнгә калган кәләш сөекле ире барын да онытты. Табибларның көн саен төрләндереп торган фаразлары белән тәмам башы әйләнде. Шәһәрдәге фатирларына хәлсезләнеп кайтты да егылды. Юньләп ашарга пешерергә дә вакыты калмады.

Мәскәүгә җибәрелгән соңгы анализ барысын да хәл итәргә тиеш иде. Сәрия, борчыла-борчыла шуны көтеп, берничә атнаны ут йотып уздырды. Әйтерсең, төшендәге теге куркыныч өермә эчендә калды ул.

Пошынулары юкка булмаган икән. Сәрияне Мәскәүдән анализ кайткан көнне үк ашыгыч төстә хастаханәгә чакырттылар.

—Күңелем тыныч түгел, син янымда булсаң, үземне көчлерәк тояр идем,—дип, ул Илдусны да үзе белән алып барды.

— Борчылма, нинди генә авыр минутларда да бергә ич без!—диде ире, иненнән кочып.—Ышан, җаным, миңа!

— Хәзер үк операциягә!—дип каршы алды аны профессор.—Һич тә кичектерергә ярамый.

Сәрия эсселе-суыклы булып китте, күз алларын ниндидер кара томан каплады...Аны операция бүлмәсенә җитәкләп алып керделәр. Илдус мондый ашыгычлыкның сәбәбен белү өчен табиблар белән тагын киңәшләште. Хәлләр чыннан да шәптән түгел икән шул: теге нокта эзеннән баш сөягенә зыян килгән, хәтта гангрена башланган...

Өч сәгатькә дип тәгаенләнгән операция сигез сәгатькә сузылды...Аннан соң да атна-ун көн эчендә аякка басарга тиешле Сәрия алай тиз генә йөреп китә алмады. Сонрак беленде, зарарланган сөяк кисәген ачканда баш миенең аяк нервларына да зыян килгән икән. Сәриянең үзенә: «Тиздән аякка басарсын»,—дисәләр дә Илдуска киресен әйттеләр: «Гомер буе инвалид арбасында калырга мөмкин...»

Медицина көчле бүген дип үз-үзен юатты Илдус. Ниндидер могҗизага өметләнә иде ул. Эзләде, киңәште, хатынын кат-кат тикшертте...Тик могҗиза һаман үги итте Сәрияне...Туйга җыелган акчалары да кереп бетте. Атналар, айлар гына түгел—еллар үтте, ә хатын һаман аягына баса алмады.

Сәрия, Илдусы бераз ял итсен дип, авылдагы әнисенә дә күчеп карады. Көннәр буе түшәмгә текәлеп ятудан да авыр нәрсә юк икән. Ни гаҗәп, ана түшәмдәге ботак үзәге дә тыелмас өермә-давылны хәтерләтә иде. Кечкенә генә ноктала да күңел төпкелендәге ялыктыргыч хатирәләрне казып чыгара. Ямьсез төшләр искә төшеп йөдәтә, гүя алда шомлы, газаплы көннәр

көткәнен сиздерергә, шуңа әзер торырга куша иде.

Сәрия яшәвенең өнен-төшен анлый алмый интекте. Дөньядан әкренләп ваз кичә барды. Илдусы янадан фатирларына алып кайткач та шул халәт үзгәрмәде. Алай да өйләренә нindider салкынлык ингәнен эчке бер тоем белән сизенде. Өй эче инде Сәрия җыештырганча түгел, җиһазлар да урыныннан күчкән. Юк, юк, авыру хатын саташуы йә холыксызлануы гына түгел инде болар. Үзгәрешне Илдусның үзеннән дә аның көн аралаш диярлек йә соңарып, ә кайчак хәтта иртән кайтып керүеннән дә күрергә, эшләрнең кая барганын чамаларга мөмкин иде. Моңарчы авызына хәмер алмаган ире шактый гына салгалый да башлады. Үзенең туган көнендә исә исереп кайтты...

Ә Сәрия бу бәйрәмне зурлап үткәрергә теләгән иде. Университетта бергә укыган иптәш кызы белән ир кайтышка мул итеп табын әзерләделәр. Һәм Илдус ишектән күренүгә дусты өйләренә кайтып китте. Шәмнәр белән бизәлгән табынны күргәч үк, Илдус иңбашларын сикертеп куйды. Элеккечә матур-матур сүзләр, җылы, ягымлы караш өмет итү сизелә иде Сәриянең елмаюында. Менә хәзер булыр, әйтелер ул сүзләр...

—Нинди бәйрәм бу?—диде ир кырыс кына, өстәлгә ымлап.

—Бүген синең туган көнең бит, Илдус! Сине чын күңелдән котлыйм,—дип, Сәрия инде күптән әзерләп куйган бүләген—ак күлмәк сузды.

—Рәхмәт инде,—диде Илдус һәм, күз төшермичә генә, урындыкка куйды.

—Тиз генә өстеңне алыштыр да, әйдә, өстәл янына утыр!

—Ашыйсым килми. Арыдым мин бүген...

— Ә мин туган көнеңне истә калырлык итеп үткәрербез дип табын әзерләгән идем...—диде Сәрия, елмаерга тырышып.—Нәкъ вәгъдә бирешкән көндәге кебек... Туган көнне үткәрмичә ярамый бит инде, Илдус! Әйдә өстеңне алыштыр да утыр!

—Нигә җанымны ашыйсың икән һаман? Нигә гел-гел ярарга тырышасың икән син?!—диде Илдус кинәт, әллә кайчангы ачуларын берьюлы чыгарып өяргә теләгәндәй кабынып.—Һаман бер үк нәрсә, һаман бер үк нәрсә: «Кайттыңмы? Утыр! Кайттыңмы? Утыр!» Туйдырды! Гарык мин синең бу кыстауларыңнан! Моннан миңа ни файда?! Мин сау-таза кызга өйләндем, ә кайда хәзер ул сау-таза кыз?! Алдады мине ул, алдады! Әйе, әйе, алдадың син мине, Сәриякәй, алдадың. Син...син бит минем алма кебек яшьлегемне урладың, хәзер минем киләчәгем дә юк, дәвамым да...Ә син: «Утыр, алыштыр, туган көн...» Кая соң шатлыгы ул туган көннең?!

Илдус шулай ярсып кычкыра-кычкыра йокы бүлмәсенә кереп китте дә ишекне шап итеп ябып куйды.

Сәрия катты да калды. Мондый ук ачыктан-ачык, җитмәсә, шулай ярсып әйтелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңласа да күңеле белән ризалашмый азапланды. Әлеге сүзләрнең Илдус авызыннан чыгуын көтеп йөрсә дә, бүген түгел иде әле ул. Каршы стенада эленеп торган көзгегә күзе төшкәч кенә ике битендә юеш эз калдырып иреннәренә таба яшь тамчылары тәгәрәгәнне күреп алды Сәрия.

Яратып-сөеп, ышанып йөргән, якын күргән, гомерлек дип йөргән кешең әйткәч, бигрәкләр авыр икән бу сүзләр. Йа, Хода, моңа ничекләр түзәргә?! Күрше апаның сүзе дә дөрес булса кирәк. Пенсия яшендәге күрше хатын көндезләрен кереп сөйләшеп утырырга ярата иде. Сүз ара сүз чыгып, Сәриянең авылларында, әниләрендә яшәп-яшәп алуын хупламаган шикелле, ул ничектер сәер генә:

—Ирләрне ялгыз калдырырга ярамый аларны,—дип куйды.—Сикеренә башлыйлар, иреккә чыгалар. Хатыным авырый дигән сылтау белән...

Шулчакны ук Сәриянең күңеленә нindider шом, билгесез шик үтеп кергән иде. Нигә әйтте икән ул моны дип, озак кына уйланып ятты. Юкка

гына түгел бит, йә ул мин юкта Илдусның берәр хатын-кызны өйгә алып кайтканын, йә икенче берәү белән урамда йөргәнен күргән...Сәрия бу турыда күршесеннән сорамакчы да булган иде әле, тик унайсызланды. Аннары шикләреңне башкаларга чәчеп йөрү дә яхшы гамәл түгел...

Сәрия ризык тулы өстәл янында уйланып утыра торгач, шәмнәрнең сүнеп беткәнен дә сизми калды.

Икенче көнне, Илдус эштә чакта, Сәрия телефоннан әтисен чакыртып, авылга кайтып китте. Әнисе киявенең арт сабагын укытырга дип шәһәргә җыенган иде дә, Сәрия җибәрмәде. «Китәсең икән, мине исән килеш күрмисең, әни!»,—диде ул, аны куркуга салып.

Әнисенең ачуы бик яман иде шул. Кияве минем шәп табибларым бар дигәч, кызын дәвалауны тулаем аның кулына тапшырган иде, әнә эшләр кайсы якка борылды. Югыйсә аның да бар иде таныш табиблары.

—Бөтен акчамны туздырсам туздырам, әмма сине аякка бастырам!—дип кырт кисте ул.

Әнисенең бертуган апасы шәһәрдә ике бүлмәле фатирда яши иде. Вафаты алдыннан аны Сәрия исеменә яздырды. Әлеге фатирны да, авылда аларга мирас булып калган каенаталары йортын да тиз генә сатып җибәрделәр.

***

...Соңгы алтынчы операцияне ясыйсы дигән көнне тагын теге төш кабатланды. Имеш, ямь-яшел болынлыкта биек тау бар икән. Аңа шул тауга менәргә кушалар. Ул аңа бик авырлык, бик азап белән генә менде. Бармаклары канап бетте, әмма тырыша-тырмаша торгач, түбәсенә тикле менеп җитте! Менеп җиткәндә генә ташлар арасында нокта хәтле генә ялтыравыклы бер нәрсә күрде. Ташларны аралап-актарып, аны тиз генә кулына алырга ашыкты. Ә анда...анда кайчандыр үзе югалткан алтын балдак ялтырап ята иде...

...Менә хәзер кайчандыр өзелеп сөйгән, гомерлеккә дип уйлаган шул Илдус аның алдында басып тора. Юк, заманында баһадир гәүдәле, чибәр, татлы телле булган ир түгел, бөтенләй башка кеше иде бу. Йөзе йончыган, күзләре эчкә баткан, тире белән сөяккә генә калган. Ике ел элек юл фаҗигасенә очрап, умыртка баганасын имгәткән икән үзе.

Инде ничә еллар, кем әйтмешли, хаты-хәбәре дә булмаган, суга баткандай юкка чыккан иде. Әнә шул туган көн вакыйгасыннан соң бер тапкыр да килеп күренмәгән Илдус аның өчен хәзер чыннан да чит кеше иде.

—Бәлки, утырып торырбыз, Сәрия?—диде Илдус ялварулы һәм гаепле тавыш белән.—Бу елларда сөйләшәсе сүзләр күп җыелды...

—Гафу ит, сөйләшерлек бер сүзем дә юк. Без барысын да сөйләшеп бетердек инде...

—Алай кырт кисмә әле син, Сәрия. Ни дисәң дә, без яратышкан идек бит...Тормышта ялгышлар була инде ул...Гафу итә белергә дә кирәк...

—Син ялгыш белән хыянәтне бутыйсың, егеткәй. Ялгышны кичереп тә буладыр ул, ә хыянәтне...хыянәтне—юк!—диде Сәрия һәм кояшка тагын бер мәртәбә елмаеп алды да, ашыкмыйча гына аллея буйлап китеп барды.

...Аңа каршы ашыга-ашыга кулына кыр чәчәкләре тоткан ир-ат килә иде.

—Мин сине күптәннән көтәм,—диде ул.

—Менә шуңа күрә ашыгам бит инде,—дип көлде Сәрия.

Илдус алар артыннан берникадәр ияреп тә барды әле. Тирә-яктагы кешеләрнең аңа карап торуларын күргәч кенә туктап калды. Кеше язмышы артыннан күпме ияреп барырга була, дип уйлады ул. Әмма үзе барыбер Сәрияләрне ноктага әверелгәнче озатып калды.

Фәнил
Галиев



# НИГӘ КИТТЕҢ, ӘТИ?..

ХИКӘЯ-ИСТӘЛЕК

Әйтерсең лә кинәт кенә кояш тоныкланды. Гүя, тормыш тукталды да, без үзебезнең кая барасын да белмичә, аңлаешсыз юлда басып калдык шикелле.

Бу хәлләрнең сәбәбе 1953 елның 5 марты көнне СССР Министрлар советы председателе, Советлар Союзы Генералиссимусы Иосиф Виссарионович Сталинның кинәт вафаты иде...

Ул вакытта «Правда» газетасында эре-эре хәрефләр белән Сталинның үлеме турында яздылар. Маркс һәм Ленинннан соң аның дәвамчы фигура булуын зурлап күрсәттеләр.

Без, гади мәктәп балалары һәм үзебезнең укытучылар, ул хәбәрне бик авырдан кичердек. Класс җитәкчебез Ксения Васильевна Ибытаева—үзе бик яхшы күңелле, үзе таләпчән,—классыбызга ак киндердәй агарынып кереп утырды.

Дәресен аңлаткан чакта ул кулындагы акбурын берничә мәртәбә идәнгә төшереп җибәрде. Аннары, талчыбыктай сыгылып төште дә, өстәленә капланып һәм битен каплап, чарасыз хәйран гына елады. Бу чагында ул—мәктәп формасындагы алъяпкычына кара түгелеп елап утырган беренче класс баласыннан бер дә ким түгел иде бугай.

Аның безгә:

—Балалар, өегезгә кайтыгыз. Бүген дәресләр булмый...—дип әйтердән бүтән көче калмаган иде.

Безнең яшь күңелләрдә ул вакыттагы буталчык, борчулы кичерешләр тирән эз калдырды, билгеле.

Мәктәп елларында укыганда мин рәсем ясаулар белән нык мавыга идем. Берсендә шулай үземнең рәсем дәфтәренә Ленинның портретын ясап куйдым. Үземә калса, матур гына рәсем килеп чыкты шикелле һәм аны ерак Себердән күчеп килгән яшь укытучыбыз Таисия Саввишна Собакинага күрсәттем.

Юлбашчының рәсемен күргәч тә ул баштарак сокланды. Аннары, калтыранып һәм агарынып, әйтә салды миңа: «Син, әлбәттә, булдыргансың... Ләкин, хәтерлә, Владимир Ильич портретын ясарга сиңа иртәрәк. Бу сурәтне бик еракка яшер һәм беркемгә күрсәтмә».

Мин аны тиешенчә аңлап бетермәдем, хәтта укытучыма ул чакта азрак

үпкәләгән дә идем. Байтак еллар узгач кына ишетеп белдем һәм аңладым: аның әтисен,—Урал инженерын,—озак елларга төзәтү лагерына җибәргәннәр, гаиләсен туган шәһәреннән сөргәннәр, халык дошманы кызын техникумнан куганнар. Соңрак, кияүгә чыгып һәм фамилиясен алыштырганнан соң, алар безнең Теләче ягына килеп урнашканнар икән.

Апам Гамбәрбикә Сталинның үлеме хакында эшендә ишеткән икән. Ул аны алла урынына күрде бугай, шуңа күрә дә эшен ташлап, өйгә кайткач та беркем белән сөйләшмичә, бик озаклап ярты көн диярлек елады.

Фронтовик әтием Ислам, югары белем йортларында укымаган булса да, тормыш, яшәеш-сәяхәт мәсьәләләрендә үз карашын булдырган булса кирәк. Эшенә иртүк киткән җирдән әбәд вакытларына әйләнеп кайтты. Өстәл артына утыргач та кулына аш кашыгын алды һәм салкын гына, шикләнмичә: «Ишеттегезме, ниһаять, картлач бер өрәк вафат булган...»—диде.

Нигә шулай дип әйтте икән ул?

Күрәсең, үз тормышына бәйле байтак хәлләрне—каенатасының төрмәдә черегәнен, газиз кызының интеккәнен, атакага җибәрелгән солдатлар үлә калганнарның мылтыгын «эләктерергә», ахыргача сугышырга тиешлеген, мыек та чыгып өлгермәгән яшь солдатларның бар гаебе—чигенгән өчен чокырга атып төшерелгәнен күз алдыннан кичергәндер, әнә шулар өчен җаны әрнегәндер аның.

Бу минутларда әтием, Ватан сугышын кичкән кеше буларак, күңелендәгесен туры әйтеп салган булса кирәк.

«Сталинчыл» сеңелем бу сүзләрне бик авыр кабул итте һәм хәтта табынны ташлап китте. Берсендә, бик нык үпкәләшкәннән соң, әтием хәтта Орымширмәдәге үги әнисе янына китеп барды.

Әниебез, бик акыллы һәм алдан күрүчән хатын-кыз буларак, гаиләне бөтен килеш сакларга бик тырышты. Ул безнең әтине, төгәлрәге, үзенең ирен бик ярата иде. Саулыгы какшады, йорт-җирләре дә әлләни мактанырлык түгел. Әти исә бик кызу, кайнар кеше. Фронтовикларның бик күбесенә хас буларак, эчәргә дә ихласланып китте.

Әни кешегә кыз бала һәрвакыт якынрак. Әти моны аңлап бетермәде шикелле. Өлкән кыз буларак, Гамбәрбикә күбрәк әни ягына елышты.

Көннәрнең берендә, чираттагы бәхәсләрдән соң, әтиебез үзенең иң кирәкле, иң гади әйберләрен җыйнады да, әнкәй белән саубуллашып, өйдән бөтенләйгә китеп барды.

***

Әйе, әти китте. Гаиләдәге төрлечә тарткалашуларга түзеп тормыйча, китеп барды. Ул киткәннән соң мин өйдә утырып калган бердәнбер ир-егет идем.

Калуын калган, ләкин минем белән янәшәдә, ике бүлмәле кечкенә генә өйдә ике хатын-кыз—сугыштан соңгы авырлыкларны, гаилә мәшәкатьләрен күргән әнием һәм сеңелем бар бит әле. Ир затыннан буларак, мин аларга булышырга, ярдәм итәргә, кирәксә—киң күкрәгем белән якларга да тиеш идем. Ә көчем хәзергә азрак дип уйладым.

Көч, һәркемгә билгеле ки, тормыштан да, табигатьтән дә килә.

Мин нәрсә эшләдем? Эченә ком һәм вак ташлар тутырып, иң элек иске брезент чехолдан боксер капчыгы ясадым. Аннары, төрле җирдән металл ватыклары җыеп, аны ике потлы герга алмаштым. Турник та ясалды. Буш вакытым булган саен гел физик күнегүләр үткәрәм...

Нәтиҗәләр озак көттермәде. Кыска гына арада мин буйга үсеп киттем, мускулларым ныгыды, үз-үземә ышанычым да артканнан-арта барды.

Кыскасы, тормыштагы төрле ваклыкларны, унайсызлыкларны җиңәргә өйрәндем, күз һәм күңел карашларым киңәйде.

Ә әти нәрсә? Ул безнең өчен һаман да иң якын кеше булып кала бирде. Алдан килешкәнчә, кайчакны кибет янсә базарда очрашып, халык төркеменнән ераклашып, аулаграк урыннарда күңелдә җыйналган барлык кичерешләрне уртага салып сөйләшә идек. Мондый чакларда миңа, әйтерсең, әтиебез беркая да китмәгән, ул вакытлыча гына югалып торган да безнең гаиләгә кире әйләнеп кайткан сыман тоела иде.

Әмма тиздән шундый хәл булды ки, безнең ышанычлы сөйләшү-күрешүләргә бернинди урын калмады бугай.

Соңгы очрашуларыбызның берсендә әти, зарлана төшеп, миңа нәрсә турында сөйләде. Бергә яшәгән үги әнисе, авырган да, бүтән авылдагы туганнарына күчеп киткән. Хәзер әти үзе ялгызы гына яши икән, аңа шулай яшәүләр җиңелдән түгел икән. Ул ни әйтергә теләгән, моның сәбәпләрен, аның ни әйтергә теләгәнен ул чакта мин аңлап бетермәгән идем.

Менә көннәрнең берендә...

Мин өйдә дәрес әзерләгән, авыру әниемнең караватта яткан чагында безгә бүреген баш түбәсенә кырын салган, кыска толыбының төймәләрен яртылаш ычкындырган, салмыш кыяфәтле бер егет кисәге килеп керде. Орымширмә авылыннан булып чыкты ул. Исәнләшеп һәм аяк киемен салып та тормастан бүлмәбезгә узды һәм урындыкка җәелеп, махмырдан кипшергән иреннәрен ялмаштырып сөйли башлады:

—Ах, без кичә гулять итеп тә карадык соң! Безнең авылның күптәннән нә шундый туйны күргәне юк иде. Ризыклардан өстәлләр тәмам сыгылып торды, вино-мазар су урынына акты. Ислам абый молодец! Шундый туй ясап күрсәтте ул безгә! Килен дә—шәп, үзе кебек үткен һәм чая. Ә тостларны ишетсәң, бүләкләрне күрсәң иде...

—Булды, җитте!—дип бүлдерде аны әни тыныч, ләкин таләпчән тавыш белән.—Аларны мактап утыру өчен сине берәү дә чакырмаган. Ярар, шаулаганнар, шуның белән беткән. Һәр нәрсәнең үз чамасы бар...

Әмма чакырылмаган «визитер» гүя боларны ишетми иде, үрдәк сыман һаман үзенекен такылдады. Бер үк сүзләрне, мактау-мактануларны ул юри шулай кабартып сөйли иде.

Әниемнең газаплы уйларга йотылганын күреп, түзмәдем, урынымнан торып бастым да ят кунакны күз карашым белән яндырырдай итеп аңа әйтә салдым: «Ни әйтелгәнне ишеттең бит, житте сиңа! Урамга чык та сүзләреңне базар хатыннарына сөйлә әнә. Бәлки, алар сиңа баш төзәтерлек нәрсә табарлар...»

Никадәр сәер тоелмасын, бу сүзләрем аңа тәэсир итте.

—Ярар,—диде бик тиз күнеп.—Ислам абыйның өйләнүен генә әйтмәкче идем. Безнең авылның Саимә исемле кызына. Кичә туйларын үткәрдек менә...

Ишегалдына чыгып, аның артыннан ишек келәсен элдем дә өйгә кердем. Әни, яткан җиреннән стенага йөз белән борылып, тын гына елый иде...

Шушы көннән соң әти белән минем арада, әйтерсең, биек дивар калкып чыкты. Мин аның белән очрашудан качарга тырыштым, әгәр барып чыкмаса, күп сөйләшеп тормыйча, берничә җөмлә генә алмаша идек.

Бу мөнәсәбәтем белән хаклы булдым микән ул чакта? Өзеп кенә әйтү читен.

Шулай бервакыт җәйге каникул вакытында мин Казанга өлкә спартакиадасына бардым. Әйләнеп кайтуга әтинең яшь хатын белән Ташкентка китеп барганын белдем. Соныннан классташларым аның мине озаклап эзләвен, күрми китүенә бик үкенгәнен сөйләделәр.

Әтинең шулай кинәттән китеп баруы тормышыма нindidер моңсулык тамгасы салды. Урамга яисә базарга чыккан чакларымда аны күреп алырмын да бернинди үпкә сакламый гына сөйләшеп китәрмен кебек иде.

Их, юк шул, вакыт үтә бирә, ә әтинең күзгә-башка тәки күренгәне юк.

Ләкин тормыш бер урында тукталып калмый, андагы төсләр үзгәрә тора. Зурмы-кечкенәме, көтелмәгән шатлыклар йөрәгенә җылылык өсти, куаныч бирә.

Совет Армиясе офицеры Әсгать абыем, озак вакытлар Румыниядә хезмәт иткәннән соң, элекке шәһәренә әйләнеп кайтты. Ул күп акчалар һәм бүләкләр белән кайткан иде. Миңа инглиз стилендә тегелгән аксыл сызыклы кара костюм алган. Клубка, яшьләр кичәсенә күлмәк өстеннән галстук тагып, әнә шул затлы костюм белән бара идем. Студент каникулы башлангач, Казаннан сеңлем Сөембикә соңгы стипендия акчасына миңа скрипка алып кайткан! Балачактан килгән хыялым иде бу. Дөрес, миннән Паганини чыкмады, шулай да бәйрәм концертларында баян, гитара, мандолинадан тыш, инде хәзер скрипка белән дә чыгыш ясыйм.

Үземнең әдәби мавыгуларны да онытканым юк. Поэма, хәтта мажаралы роман да язып караганым булды. Әлеге өйрәнчек, камиллектән ерак торган әсәрләр дуслар һәм укытучылар арасында теләктәшлек таба иде.

Кыскасы, тормыш үз эзеннән бара бирә.

Әнә шулай бер ел узып та китте.

Көз иде. Шулай беркөн мәктәптән кайтканда кемнеңдер миңа эндәшүен ишетәм. Борылып карадым да баскан урынымда катып калдым. Юл читендә, елмая төшеп, әти карап тора иде. Күпмедер «кадакланып» торганнан соң аның янына килдем, нык итеп кочаклаштык. Әтинең агарып калганына, ябыкканлыгына игътибар иттем. Яңакларына, чәченә чал кунып өлгергән. Гел елмаеп торса да, аның уңа төшкән күзләрендә моңсулык һәм арыганлык төсмерләре ярылып ята.

Кулында аның миңа бик тә таныш, электән базарга йөри торган брезент сумка иде.

Азмы-күпме яңалыклар белән уртаклашкач, әти кинәт кенә әйтә куйды: «Беләсеңме, мин ерак түгел генә эшлим, бер карчыкка мич чыгарам. Киттек, бергәләп ашап алырбыз, сөйләшеп утырырбыз. Безнең бер-беребезгә әйтер сүзләребез бардыр дип уйлыйм...»

Дөресен әйтим, бу тәкъдим миңа ошап бетмәде. Балачактан ук чит йортларны, табында утыруларны яратмый идем. Шунлыктан баштарак каршы килеп карадым, ләкин әтинең ихлас сөйләшкәнен күреп, риза булдым.

Ул әйткән йорт бикле иде. Кесәсендәге ачкыч белән әти йозакны ачты. Йорт эче ярым караңгы, салкынча һәм дымсу иде. Яртылаш салынган мич тирәсендә бөтен яисә ярым кирпечләр аунап ята, бер читтәрәк исә сулы чиләк һәм ком-балчык өеме күзгә ташлана.

Тупас такталардан ясалган өстәл өстендә яньчелгән ике алюмин кружка тора, шулар янына әти үзенең поход биштәреннән бер шешә аракы, банкалы тозлы кыяр, колбаса, селедка һәм ярты арыш ипие тартып чыгарды.

Боларны кискәләп, җайлап урнаштырганнан соң кружкаларның икесенә дә аракы салды.

—Әйдә, улым, очрашу хөрмәтенә тотып куйыйк моны...,—диде ул өстәл артына утырганнан соң.—Синең белән ел буе күрешмәдек ләбаса. Яшермим, бик сагындым син шайтан малайны! Киткәндә күрә дә, таба да алмадым үзеңне...

Ул миңа кружкаларның берсен сузды, үзенекен кулына алганнан соң

кинәт тукталып, сынаулы бер караш белән күземә текәлде.

—Тукта, мин бит әле сорап та өлгермәгән. Аракы эчкәнең бармы?

—Бар... Бер тапкыр, дустымның туган көнендә,—дип алдаштым мин, чөнки ир-егетлек дәрәҗәсен төшерәсем килмәде.

—Ну, ярый алайса...

Ачы, салкын эчемлек шундук тамагымны яндырды, шушы кайнар йомарлам күкрәгем буйлап аска шуышты. Әти миңа тозлы кыяр сузып өлгерде, шуның сусыл тәме косасы килгәнемне туктатты бугай.

Бераздан әлеге кайнарлык күкрәгемне тутырды, кул һәм аякларым буйлап таралды, ниндидер җиңеллектән башым әйләнеп киткәндәй булды.

—Күптән кайттыңмы?—дип сорадым кыю һәм хәтта тәкәллефсез бер рәвештә.

—Бер атна элек.

—Үзең генәме, аның беләнме? Ни... Саимә беләнме...

—Син аны беләсеңмени?—дип бераз гаҗәпләнеп миңа карады әти. Күзләрен аска төшерде дә башын җиңелчә чайкады.—Әйе, без бергә әйләнеп кайттык. Тегендә баштарак бөтенесе әйбәт булды. Эш таптык, фатир, аннары...

Ул тирән сулыш алды да бермәлгә тын калды. Миңа, мөгаен, тукталып каласы булгандыр, әмма эчемлек үзенең мәкерен иткән иде: тәмам кыюланып, башка чакта аңа гомеремдә дә әйтмәслек сорау бирдем.

—Син аны яратасыңмы?

Бу юлы инде әти миңа ачыктан-ачык гаҗәпләнеп карады, әмма җавантан читләшмәде.

—Саимә начар хатын түгел, әлбәттә. Киң күңелле, илтифатлы,—диде ул бакмаклары белән ияген угалап.—Ләкин хәтерлә, улым, мин һәрвакыт чын хатынымны, синең әниеңне яраттым һәм хәзер дә яратам. Ә Саимәгә килгәндә... Теге чакта миңа нишләргә кала иде соң? Үзең беләсең, мин сугышларны кичкән, күпне күргән кеше. Чит почмакларда йөреп, чит өстәлләрдән ашап-эчеп йөрисем килмәгән иде. Ә бит мин аны, әниеңне, үз янына чакырдым. Мин бит әле ул чакта таза-сәламәт идем, гаиләне дә, килгән булсаң сине дә туендыра алган булыр идем. Ләкин әниең бергә яшәргә ризалашмады. Мин нишләргә тиеш идем соң?—Ни турындадыр уйланып, янә тынып калды.—Саимә дә бит ирен югалткан, улыннан еракта авылда озак еллар ялгызы гына яшәп ята иде. Икебез өчен дә әнә шундый чакта кушылып киттек, уртак тел таптык. Ходайның язганы шулай булган, күрәсең.

—Аңлыйм...—дидем салмак кына.—Саулыгыңа ни булды? Синең авырып киткәнеңне ишеткән идек...

—Шуның өчен кайтырга туры килде дә инде,—диде ул, күңелсезләнеп.— Миндә төзәлә алмаслык ашказаны чире таптылар, авыр операция кичерергә туры килде.

Әти, сөйләвеннән туктап, торып басты да күлмәк итәген күтәреп корсагының буеннан-буена сузылган зәңгәрсу-шәмәхә җөй эзләрен күрсәтте.

—Истәлеккә әнә шул калды... Врачлар миңа спиртлы эчемлекләр эчмәскә, майлы ризыкише нәрсәләрне ашамаска куштылар. Гомумән, диетада утырасы...

Бу сүзләрдән соң мин күз карашымны өстәл өстендәге шешәгә һәм тәлинкәдәге кыяр-колбаса кисәкләренә юнәлттем.

Әти моны күреп-сизеп алды.

—Әйе, кайчагында тозлы кыяр яисә ит кисәге кабарга да туры килә,— диде ул малайларча беркатлылык белән.—Нишлисең бит! Тормыш агышына

каршы килеп булмыйдыр. Бөтенесе бер Ходай кулында. Яңа сауган сөт эчеп, манный боткасы ашап кына эшне җиңеләйтеп булмый. Менә нәрсә әйтәм сиңа. Чир йомшак кешеләрне, кыен чакта саламга ябышырга торганнарны яратмый. Андыйларны чир үлемгә таба якынайта гына. Тегендә, фронтта да, куркаклар һәм зәгыйфь җаннар ешрак үлә иде...

Ул тагын шешәгә сузылды һәм сораулы караш белән миңа текәлде. Мин «кирәкми» дигән мәгънәдә башымны чайкадым. Үзе салып эчкәннән соң ул аталарча кайгыртучанлык, үгет-нәсихәт төсендә әйтеп куйды:

—Син уйлама, эчәргә кыставым түгел бу. Менә мин кем дип әтәчләнүеннең кирәге юк. Бу яшел шайтаннан ерак тор. Әгәр авыз итәсен икән, аның кулында уенчык булма.

Мин аның гап-гади һәм ихлас сүзләрен гаҗәпләнеп тыңладым. Тормыш кыеннарын күп ашаган, әмма вәгазендәге дөреслеккә үзе әнә шулай соңарып кына ирешкән кеше сүзләре иде бу. Әти бу мәлдә соңгы чиккәчә ихлас күренә иде, шунлыктандыр, үземне иң нык борчыган төп сорауны бирергә батырчылык иттем:

—Әнине яратам дисең. Алайса нигә соң кире әйләнеп кайтмыйсың да тормышны өр-яңадан башламыйсың?

Әти озак кына дәшми торды. Аның ябык-аксыл йөзендә күнелендә барган эчке көрәшнең тартышы, шушы тартышта үз-үзен югалтмаска тырышканы аермачык күренеп тора иде.

Бу көрәштә үзен-үзе җиңде бугай ул.

—Соң инде, улым... Хәзер әниең начар яшәми. Кызларымны да шулай дип беләм. Ни йөзем белән аларга комачау итим хәзер? Хәтта иң авыр чакларымда да мин берәү өчен дә җәфа булып яшәмәдем, кыенлыкларны һәрчак үзем ерып чыктым. Иртәгә ни буласын белмим. Хәзер, инде сәламәтлегем какшаган чакта, кемнеңдер итәгенә барып ышыкланасым килми. Ни булса шул булыр. Бөтен нәрсә Ходай кулында...

Бу минем әткәй белән беренче тапкыр ихластан, чын ирләрчә сөйләшүем иде. Ул кичтә без аның белән күп нәрсәләр турында озаклап сөйләштек әле. Икебез дә канәгать булып, кочаклашып, бер-беребезнең кулларын нык итеп кыса-кыса саубуллаштык.

***

Шушы сөйләшүләрдән соң без әти белән көн саен диярлек очраша башладык.

Ике ай чамасы үтте микән, әтинең хәле начарланып, аны ашыгыч рәвештә район больницасына салганнарын әйттеләр.

Шул ук көнне, әнкәй әзерләгән итле шулпаны алып, куркәмрәк киенеп әткәй янына юнәлдем.

Әти авыр хәлдәгеләр палатасында, хирургия бүлегендә ята иде. Төс-кыяфәте дан түгел иде аның. Йөзендәге сәер аклыкны, дөньядан ваз кичкән шундый тонык карашны минем әле беркайчан да күргәнем юк иде.

Ләкин мине барыннан да ныграк сискәндергәне күз һәм борын тирәсендәге каракучкыл таплар иде...

Минем килүем аның кәефен күтәреп җибәрде, билгеле. Ул терсәкләренә таянып күтәрелде, бераздан соң шулпадан авыз итте. Йөзеннән аклык чигенде, күзләрендә яшәү чаткысы кабынды. Әти гомуми хәлсезлегеннән, ашказанынннан зарланып алды. Кичә кан косканнан соң хәле тагын да авырая төшкән икән.

Мин укуым, спорт белән ныклап шөгыльләнүем турында сөйләдем. Җаен туры китереп, кызыксынуымны бик сиздермәскә тырышып кына сорадым:

—Эти, күз төбендәге кара көеп чыккан таплар каян килде сиңа? Әллә берәрсе белән сугыштыңмы...

Баштарак ул, нәрсә дип әйтергә белмичә, югалып калды шикелле. Берара дәшми торганнан соң авыр сулап куйды да тыныч, әмма кемгәдер рәнҗегән тавыш белән сөйләп бирде:

—Ул кадәр берни дә юк, улым. Кичә минә Саимәнең улы Рафис белән тарткалашып алдык. Ул гаиләсе белән Чиләбедә яши һәм эшли икән. Без Ташкентта чакта әнисенең йортын сатарга җыенган. Хәтта сатып алучыны да тапкан. Ә без, кар шикелле, аның баш түбәсенә килеп төштек. Кичә бераз салып утырдык, баштарак бик җайлы гына сөйләшкән идек. Исерә төшкәч, йодрыклары белән миңа ташланды. Мин, әлбәттә, каршылык күрсәттем.

—Ә Саимә нәрсә?

—Ул арабызга керә башлаган иде дә, Рафис ерткычланып әнисенә үк ташланды. Ярый әле узып баручылар булган, тавыш-кычкырыш ишетеп алар өйгә кереп җиттеләр...

Аңлашылды. Артык сораулар биреп әтине йөдәтәсем килмәде һәм, бераз торганнан соң, шулай ук фронтовик, сугышта бер аягын югалтып, инде хәзер протез белән йөрүче Акмал абый Сабиров янына кердем.

Ул мине ягымлы каршылады, өстәл яныннан урын тәкъдим итте. Ватан сугышында Берлинны штурмлауда катнашкан Ислам Галиев улы икәнлегемне белгәч, ул хәтта елмайды да, әмма шул ук минутта йөзе кырысланды.

—Да, улым... Эшләр шәп түгел, врачлык серен без катгый сакларга тиеш булсак та, күрәм, син инде мөстәкыйль егет, синең белән дөресен әйтеп сөйләшергә мөмкиндер... Яшереп тормыйм, әтиең авыр хаста хәлендә. Аңарда ашказаны һәм бавыр рагы...

Мин хастаханәне шартлау нәтиҗәсендә башы-колагы томаланган кеше хәлендәрәк ташлап чыктым. Шәфәкъ сызылган күк читләре бу юлы миңа караңгы чырайлы, күңелсез булып күренде, әйтерсең, кыш уртасында яшен болытлары кузгалырга тора. Бар дөньясына үпкәләүдән йөрәгем йомарланып кысылган иде. Ачудан, әти йөзендәге кара көйгән таплардан...

Борчыйсым килмәде, өйгә кайткач, мин боларны әнигә сөйләп тормадым. Ишегалдына чыгып, бары тик ары-бире йөренәм, уйланам, барысын да бизмәнгә салып үлчәп карыйм. Карарым әзер иде: Орымширмәгә барырга һәм булган хәлләрне ахыргача төйнәп куярга!

Декабрь иде бу. Кырларга һәм юлларга калын кар яткан. Өч чакрым араны җәяүләп узу кыенга төшәчәк. Чарлактан ау чаңгыларымны алдым да, вакытны әрәм итмәстән, күрше авылга юлга чыктым. Табыннарын майлаган идем, чаңгыларым әйбәт шуа.

Житез хәрәкәтләр белән юлдагы авылны узганнан соң боз һәм пар белән капланган Мишә елгасына килеп җиттем. Орымширмәгә биредән кул сузымы ара калган иде.

Авылга килеп кергәндә эңгер-меңгер төшә башлаган иде.

Саимә яшәгән йортның кайдалыгын белгәч, чаңгыларымны салам чүмәләсенә яшердем дә мескенрәк йортның ишеген тыныч күңел белән кыю итеп шакыдым.

Миңа хатын-кыз тавышы җавап бирде.

—Бер минутка Рафис чыгып керсен әле!—дип үтендем һәм бераздан киң җилкәле, тәбәнәк таза гәүдәле берәү өйдән чыкты. Миңа карагач, канәгатьсез һәм тупас тавыш белән:

—Нәрсә кирәк? Карангыда шулай борчып йөрисең...—диде.

—Син нигә минем әтине кыйнадың?—Тавышым тыныч иде, кирәк

була калса дип шул ук вакытта сугышчан әзерлек алыр өчен сул аягымны алгарак чыгардым.

—А-а, син икәнсең, маңка!—диде ул усалланып, сүзләрен теш арасыннан сыгып.—Нәрсә, әтиең белән бергә үзеңнең дә больница койкасына ятасың киләме?

Ул миңа таба бер адым атлап өлгерде.

Уң ягына дугалап бер селтәнүем кая, Рафис кар өстенә көлтәдәй авып төште. Ул беркадәр хәрәкәтсез ятты, башын күтәреп, өстендәге карларны какты да торып басты.

Янадан миңа таба килә башлар, ахрысы, дип уйладым да икенче ударны ясарга әзерләндем. Минем гаҗәпләнүемә каршы, ул нибары башын аска иде, кулы белән ияген ышкып төксе генә өч сүз әйтте:

—Син нигә килден?

—Минем әтигә һәм үзеңнең әниеңә моннан соң кул күтәрәсе булма! Әти авырый һәм аңа сезнең аварга торган йортыгыз кирәк түгел. Бәлки, ул соңгы көннәрен яшәп ятадыр да инде...

Рафис дәшмәде.

Җавап урынына артка чигенде һәм сүзсез генә башын чайкады.

Чаңгыларымны чүмәләдән актарып алдым да кайтыр юлга чыктым. Бу хакта берәүгә дә сөйләмәдем, ә икенче көнне шуны белдем: әйберләрен ашыгыч төйнәп, Рафис авылдан бөтенләйгә китеп барган икән.

**Редакциядән.**
***Язучы, күп кенә детектив китаплар авторы, Татарстанның атказанган юристы Фәнил Галиевкә июль аенда 70 яшь тула. Аны журналыбызның күпсанлы укучылары исеменнән котлыйбыз, саулык һәм иҗат уңышлары телибез.***

---

## Авторларыбыз игътибарына

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җиңел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.



## Булат Ибраһимов

### Йөрәк

**Күкрәк читлегемне ватып,
Чыгып китте бүген йөрәк.
Мин сүз катып калдым аңа:
—Кызма инде, ни соң кирәк?
—Ялкын җитми, кан суына,
Вулкан кирәк миңа, вулкан.
Син өшегән, син сап-салкын,
Синең туңмас җаның туңган...
Учакларга кулны сузып,
Җылы алам бүген җанга.
Кояш көтәм төнге күктә,
Тик бик ерак әле таңга.
Юлдан сулар ага ярсып,
Аңлый алмыйм: көзме, язмы?
Күңелемә нидер җитми,
Якты йөзме, тугры назмы?
Таулга менеп уйга баттым,
Йөрәк минсез, мин йөрәксез.
Пар болытлар үтә яннан,
Тик мин генә бер кирәксез.
Күкне ярып тавыш килде:
—Синең йөрәк үлеп ята,
Гарипләнгән, тәне янган,
Яннарында вулкан ата.
Эзләп тап син, терелт аны,
Җан, тән, йөрәк бергә булсын.
Синең каның, аның каны
һәр тамырга кереп тулсын.
Диңгезләрне йөзеп чыктым,
Адашмадым карурманда.
Кулга кызган күмер алдым
Җан өшеткеч бураннарда...**

Булат ИБРАҺИМОВ (1990) – *КДУның татар филологиясе һәм тарихы факультеты студенты. Шигырьләре көндәлек матбугатта басылып килә.*

Якынлашам йөрәгемә,
Ерак түгел вулкан ата.
Ә юлымда, кайнар юлда,
Дистә йөрәк аунап ята.
Кулга алам һәр йөрәкне
Алар җансыз, алар көйгән,
Күрәм ялкын кирәк булган,
Мескенкәйләр янып үлгән.
Минем йөрәк кайда икән?
Янган булса көле кайда?
Хиссез ятим итмә диеп,
Ялварам мин бер Ходайга...
Эзләп тауга менеп киттем,
Тәнгә тама кайнар ялкын.
Күкне корым, болыт баса,
Сизәм, тоям мин бик якын.
Үргә таба үрләп бара,
Тәнем күмер, очкын йотыш.
Яшьтәшләрем элмәк кигән,
Кулларына йөрәк тотып,
Кулларына мәет тотып.
Иң очында кайнар тауның,
Вулкан ата, вулкан ата.
Учак кайнап торган җирдә,
Минем газиз йөрәк ята.
Соңгы көчне, соңгы дәртне
Җыйдым да мин һәм атылдым.
Сыек утка кереп баттым,
Түзалмадым һәм ватылдым.
Тик йөрәкне алдым кулга,
Ул әйләнгән җансыз бозга.
Ул сап-салкын, үле салкын,
Вулкан ата. Дәрья ялкын.
Таулар яна. Күктә янгын,
Пар болытлар яна дөрләп.
Минем күзләр сүнә бара,
Кочагымда салкын йөрәк...
Мин уяндым, тынган янгын.
Вулкан сүнгән. Таулар көлдән
Өелгәннәр. Дөнья салкын,
Һәм мин барам акрын гына
Курка-курка басып җирдән.
Яңа җаннар индерелгән
Янып үлгән йөрәкләргә.
Алар урын алды хәзер
Исән калган күкрәкләрдә.
Ә мин барам ялгыз гына,
Минем йөрәк туңып үлде.
Янган булса, истәлеккә
Калган булыр иде көле.
Минем йөрәк туңып үлде,
Дөньялардан, күрәм, туйды.
Чү, туктале, бу ни тавыш,
Җанда нидер тибеп куйды.
Кулны куям күкрәгемә,
Күзләремә яшьләр тулды:
Наз йөгерде туңган тәннән,
Йөрәк туды, йөрәк туды!

## Кайларга таратасың, җил...

Кайларга таратасың, җил,
Янган учакның көлен?
Син куасыңмы безне, җил?
Гади кеше гомерен.
Язмыш җиле, гади җилләр,
Сез бар да туганнармы?
Әллә сез кара эш өчен
Күктән куылганнармы?
Кайларга таратасың җил,
Бергә йөргән дусларны?
Нигә бутыйсың соң син, җил,
Башта туган уйларны?
Язмыш җиле, гади җилләр,
Сез бар да туганнармы?

Сезне җирне чайкар өчен
Махсус тудырганнармы?
Кайларга таратасың, җил,
Иң–иң саф хыялларны?
Назлаган булып ватасың
Син биек кыяларны.
Язмыш җиле, гади җилләр,
Сез бар да туганнармы?
Әллә тоткын булып җирдә
Сез яшәп калганнармы?
Кайларга таратасың, җил,
Ни өчен таратасың?
Нигә үткәннәрне айкап,
Хәтерне яңартасың?

***

Нигә салкын бүген кояш нуры?
Ник сусауны басмый чишмә суы?
Наздан бүген никтер күңел ярсый,
Җәйдән тәнем тынычлыкны тапмый.
Берүзем мин, ләкин ялгыз түгел,
Гөл–чәчәктән генә тормый безнең гомер.
Тынычлыкны эзләп узып бара еллар,
Тик башларда һаман җилле уйлар.
Яуган яңгыр юешләтми тәнне,
Авыз сизми ризыктагы тәмне.
Тизләнәбез куган булып дөнья,
Тик табабыз нәни генә оя.
Никтер чайкалабыз без җилләрдә,
Ни соң җитми безгә бу җирләрдә?
Күрәзәче тик юрасын киләчәкне,
Тик аңламас ул тиле йөрәкне.
Күтәрелгән тузан кире төшми юлга,
Уңга дигән юллар каерыла сулга.
Төче дигән сулар тозлыланган,
Әллә кеше ,әллә дөнья соң бозылган?

## Кеше бүген нишли?

Кеше бүген нишли?
Машиналар эшли.
Машиналар нишли?
Безнең өчен эшли.
Заман нәрсә эшли,
Безне тешли–тешли?..
Машиналар бүген
Машиналар эшли.

Кеше бүген нишли?
Кеше бүген эшсез.
Машина янында
Кеше хәзер көчсез.
Җансыз кеше эшли,
Ә җанлысы нишли?..
Машиналар бүген
Яңа җаннар эшли.

❋



Рәмилә
Майорова

# ЯРТЫ ЙӨРӘКЛЕ ӨМЕТ

***

**Унбиш катлы йортның балконыннан**
**Карап торам күккә каерылып.**
**Шундый авыр, Аллам, яшәүләре**
**Ярты йөрәгеңнән аерылып...**

**Күктә тыныч. Салмак кына ага**
**Бер кайгысыз йомшак болытлар.**
**Ә түбәннән ыгы-зыгы шавы**
**Дәшә: "Яшә, җирдә өмет бар!"**

***

**Башын иеп, салмак кына**
**Урамнан атлый кеше.**
**Үткән-сүткән машинада,**
**Кешеләрдә юк эше...**
**Атлый кеше...**

**Ишетми ул дыңгыр-дыңгыр**
**Трамвай узып киткәнен.**
**Сизми дә ул шаян җилнең**
**Чәч толымын сүткәнен,**
**Гомеренең үткәнен...**

**Бар нәрсәдән гамьсез булып**
**Бәхет эзлиме җирдән?**
**...Башын иеп яшәр өчен**
**Дөньяга кеше килгән...**

***

**Картайган бер яфрак бар көченә**
**Ябышкан да калын ботакка,**
**Туар көнгә сары өмет чәчеп,**
**Бәргәләнә, әрнеп, як-якка.**

Рәмилә МАЙОРОВА – *яшь шагыйрә, КДУ студенты. Шигырьләре көндәлек матбугатта басылып килә.*

Кинәт чыгып шунда яшь-яшь җилләр
Уйнап кына исеп куйдылар.
Уйнап кына... бер дә уйламыйча...
Карт яфракның гомерен кыйдылар.

Ялгыз ботак калды шулай ятим
Язмыш уңаена селкенеп...
Яңа бөре туар язгача ул
Карт яфракны уйлар үкенеп.

## Кечкенә дә, төш кенә...

Уяна да хисем төнлә
Күңелемне кытыклый.
Имеш инде, оялмыйча,
Аны онытып кем йоклый?!

Көндезләрен арып бетәм—
Фикеремне җыялмыйм.
Шул кечкенә сөю хисен
Нинди зур "мин"—тыялмыйм!!!

***

Шигырь язмам бүтән, дигән идем—
Ә син менә тагын яздырасың.
Акыл дигән касәм эченә дә
Мулдан гына хисләр яудырасың.
"Мәхәббәт юк бит ул!"—дигән идем—
Киресенә син инандырасың.
Үзәгемә үтеп кереп хәзер
Күңел түрләремдә утырасың.
Сөеп утта янмам, дигән идем—
Ничек кенә әле яндырасын!
Гаҗизләнеп беттем синең беләң,
Тагын менә шигырь яздырасың...

***

Дөнья миннән нәрсә тели икән?
Нәрсә бирә алам мин аңа?
Бу сораулар бик тапталган ахры,
Бу сораулар түгелдер яңа.
Нигә туа кеше, нигә үлә?
Нигә килә фани дөньяга?
Укый-яза белгән теләсә кем
Шушы хакта, шиксез, уйлана.
Тууыбыз, яшәвебез безнең
Юкка гына түгел, билгеле.
Үлеп кенә котылып булмый, диләр..
...Җавапка да төшенәм шикелле...



Владимир Лавришко

# ХӘТЕР ТӨЕННӘРЕ

## Үтеп барышлый

Тукталышта халык шактый җыелган иде. Кечкенә генә бер кеше һәм кавказлы кыяфәтле адәм, троллейбус килеп туктагач, икесе берьюлы арткы ишеккә ыргылды. Кавказлы өлгеррәк кыланды һәм, култыксага ябышканда, терсәге белән теге кешегә эләктереп тә алды. «Кая тыкшынасың, ананны...»— дип, чын урысларча—теленә ни килсә, шул сүзләр белән—авызын тутырып сүгенде мужик. Ә кавказ кешесе, тукталып та тормастан, шул мизгелдә үк йодрыгын тегенең йөзенә ормасынмы! Һәм, әйләнеп тә карамыйча, эчкәрәк узды. Мужик, аптырап, каушап калды һәм телдән язды. Алай да үзен кыерсыткан кеше артыннан китте. Билгеле инде, теге адәмнең үзеннән шактый зур гәүдәле булуын күреп торганга, ул аңа шундый ук җавап бирә алмый иде, һәм халыкны котырта башлады: «Ни өчен? Күрдегезме?! Ә?! Ни өчен?!» Халык борылып карый башлады. «Әйе шул!—диде кавказлы.— Минем әни турында анын ни әйткәнен ишеттегезме?! Нишләткән ул минем әниемне? Ишеттегезме сез?!» Халыктан хөкем көткән бу бәндәгә дә эндәшүче табылмады. Бу сүзтезмәләрнең мәгънәсен тикшереп торасы килмәүдән түгел,—беркемнең дә теләсә нинди низагка катнашасы килми иде. Кавказда мондый сүзләрнең ят булуында, дөньяда яшәүдән туйган кеше генә шулай сүгенергә мөмкинлегендә ни эше бар соң аларның! Ә безнең әниләр кавказлыларның аналарыннан киммени соң?!

## Күкрәү кодрәте

Бертуктаусыз күк күкри. Без гаиләбез белән дачада, тәрәзәләрне биклэп, өйдә утырабыз. Йә бик еракта, йә бик якында дөберди дә дөберди. Хәер, бик якын димәс идем: чөнки яшен яшьнәгәч, күкрәү ишетелгәнче, унга кадәр санарга өлгерәм әле. Әби, хатынымның әнисе, чәч электрны үзенә тарта дип, башына яулык бәйләп куйды да, почмакка таба борылып, иреннәрен

Владимир ЛАВРИШКО (1944) — *язучы, драматург; «Узел связи», «Трава», «Перевод с глухонемого» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

кыймылдатып кына, догасын укый башлады. Яшьлегем белән аны үчеклим: Алланың болай да эше житәрлек, инде син дә яшенең белән килеп сарыласың, янәсе. «Шуна күрә Ходайның ачуыннан куркырга кирәкми»,—дим. Әйтеп бетерергә дә өлгермәдем, яшен ялтырап алуга ук, өй нигезләрен селкетеп, гөрселдәп күк күкрәде. Күк капусы нәкъ безнең өстә ачылдымыни! Соңыннан минем кәгазь төсле агарынганымны әйттеләр. Булыр да. Яшен шактый ераклашкач та, тәрәзәгә кояш нурлары сибелеп, елга аръягында салават күпере чыкканчы, гөрселдәгән мизгелдә утырган урынымда, береккәндәй, тын гына утырганмын. Шуннан соң Аллага ышана башладым дип әйтә алмасам да... Хәзер инде мин Аның исемен бик сак кына телгә алам.

### Мәңге бергә

Казанның татар зираты. Бер каберне эзләп йөрешем иде, шулчак икенче берсенә юлыктым: җыйнак, пөхтәләп җыештырылган, тәбәнәк кенә койма корганнар, якты мәрмәр такта янына тере чәчәкләр куелган. Мондый каберләр күптер инде монда. Ә нәрсә җәлеп итте соң мине? Нигә ун минут буе монысына карап торам соң әле? Барысы да гадәти кебек: фамилияләре, исемнәре, туган көннәре, еллары, сызыкча аша... Ә менә вафат булган чакларын мәрмәргә язмаганнар. Хатын-кызның—татар исеме-фамилиясе, ир-атның—яһүднеке. Ташка беркетелгән рәсемнән аларның күз карашы миңа текәлгән.

Яшь үк булмасалар да, әле бигүк карт та күренмиләр. Бик пөхтә булганга, мәңгелек йортларының урынын үзләре исән чакта ук сайлаганнардыр кебек тоела. Якыннарын артык бимазаламас өченме? Әллә, башкаларга ышанып бетмичә, артык кыйммәтләнгәнче, күркәмрәк урын алып куйганнармы? Бәлки аларның беркеме дә юктыр? Бәлки, вафат булгач, үзләрен аермасыннар дип, бергә булачакларына ышаныч өчендер?

> «Хотя бесчувственному телу равно повсюду тлевать,
> Все ближе к милому пределу мне бы хотелось почивать...—

дип язган бит Александр Сергеевич Пушкин. Бөек шагыйребез, күп мәртәбәләр шашып яраткан тиңсез мәхәббәт җырчыбыз нәкъ шулай—«сөекле илендә» җирләнгән. Тик ялгызы гына.

Миңа таныш булмаган яһүд сөекле иленнән читтә язмышын үзенчә хәл иткән. Соңгы сәгате суккач, сөйгәне янәшәсендә яту өчен. Жансыз гәүдәнең кайда черүеннән ни аерма?—димәгән ул.

### Шагыйрьләр

Шул ук зират. Аллеяләр буйлап барганда, әледән-әле «шагыйрь» дип язылган кабер ташлары очрый. Кайберләрендә алтын хәрефләр белән «менә шундый исем казанган шагыйрь» дигән кайгылы сүзләр уелган. Бары тик халык сагынып, баш иеп килә торган татар шигърияте классигы Габдулла Тукайның кабер ташында гади генә «ГАБДУЛЛА ТУКАЙ» дип язылган.

Күрәсең, Татарстанда да шагыйрь—шагыйрь генә түгел.

### Концерт туфлиләре

Матбугат һәм телевидение—Рәсәйдә шагыйрьләрнең абруе калмады, шигърият белән кызыксынуны кире кайтарып булмас инде дип көенгән бер чорда, шигырьнең дә, аны сөючеләрнең дә исән икәнлеген дәлилләү өчен, Казанның Актерлар йортында шигърият кичәсе оештырырга җыендым. Анда катнашырга дип, шагыйрьләребезне һәм ике актерны Качалов исемендәге

театрдан Геннадий Прытковны һәм Г. Камал исемендәге театрдан Илдус Әхмәтҗановны чакырдым. Геннадий Прытковтан Казанда яшәп иҗат иткән мәрхүм шагыйрьләрнең шигырьләрен укуын үтендек. Илдус Әхмәтҗанов Тукай шигырьләрен яңгыратты. Нияз Әхмәров татар халык шагыйре Габдулла Тукай шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итүче буларак, Тукай шигырьләрен ике телдә тыңлатты. Ике актер да, аларга күп түләргә чамабыз юклыгын кисәтсәк тә, бик теләп ризалашты. Билгеләнгән сәгатькә актерлар да, шагыйрьләр дә килде, тамашачылар да җыелды. Хәтта без уйлаганнан күбрәк тә килделәр әле. Уңышсызлык булмый калганга канатланып, мин кичәне ачып җибәрим дигәндә генә... Илдус Әхмәтҗанов чыгыш ясый алмаячагын әйтмәсенме! Ни булды? Әһә, ул концертларда чыгыш ясаганда кия торган туфлиләрен онытып калдырган икән! Мин аның аягындагы туфлиләренә күз салдым. Әйбәт кара ботинкалар... Һәрхәлдә чыгыш ясарга килгән шагыйрьләрнең һәм минем аяк киемнәремнән матуррак та әле. Мин аны шул ботинкалардан чыгарга үгетли башладым. Ә залда өч дистәдән артыграк тамашачы утыра. Озак үгетләдем мин аны. Юк кына! «Театр ерак түгел бит, хәзер шалтыратам, китереп бирерләр»,—ди. Нихәл итәсең, шалтыратабыз. Хәзер үк китереп бирергә вәгъдә бирделәр. Театр ничек кенә якын булса да, елгыр егетнең газетага төрелгән зур гына төргәкне култык астына кыстырып килеп җитүен ярты сәгатьләп газапланып көтәргә туры килде әле.

Алар сәхнә артында мәш килгәндә, кичәне башларга ишарә ясадылар. Мин кичәне ачык дип белдерүгә, сәхнәгә Татарстан Республикасының халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт драма театры спектакльләрендә Тукай ролендә уйнаучы, шигырьләрне оста укучы дип танылган сәхнә каһарманы Илдус Хәниф улы Әхмәтҗанов чыгып басты. Кара костюмнан, ап-ак күлмәктән, күбәләк-галстук таккан һәм лаклы кара чып-чын концерт туфлиләреннән!

## Таныклык

Ике вагонлы трамвай шалтыр-шолтыр бара. Көн уртасы. Бу вакытта күбрәк эш белән мәшгуль булмаганнар—«куян» булып, түләмичә генә йөрергә яратучы яшьләр, ташламалардан файдаланучы шәһәр транспортында түләмичә генә йөрүче пенсионерлар утырып йөри. Кондукторларга хезмәт хакы билет саткан акча күләменнән түләнә. Ә эш хакын инде берничә ай биргәннәре юк. Шуна да кондуктор ханым, трамвай буйлап әйләнеп йөреп беркем дә билет алмагач, кәефе төшкән хәлдә ачуын ничек басарга белми азаплана. Вагонның алгы мәйданында бик үк яшь булмаган һәм пенсия яшендә түгеллеге күренеп торган ике хатын-кыз басып тора иде. Муенына аскан вак акчалар гына чылтырап яткан акча янчыгын селеккәләп: «Билет аласызмы?»—дигән булды кондуктор. «Пенсиядә...»—дип таныклыгын күрсәтте теге ханым. «Ә Сезнең?»—дип эндәште кондуктор тәрәзәгә карап баручы икенчесенә. «Пенсия таныклыгы»,—диде теге ханым, урамдагы хозурлыктан күзен алмыйча гына. «Күрсәтегез соң! Йә билет алыгыз!»—дип үҗәтләнә кондуктор. Теге ханым дәшми. Аның йә акчасы юк, йә икмәк алырга җитәрлек акчаны билетка сарыф итәсе килми. «Билет алыгыз, йә төшегез!» Кондуктор тынычланырга җыенмый. Тагылган вагон як-якка селки, ул да як-якка чайкала, тик бу тарткалашуда җиңелергә җыенмый: «Билет алыгыз!»—«Мин—пенсионер»,— тәрәзә янына баскан ханым билет алырга да, таныклыгын күрсәтергә дә теләми. Кондуктор, теге ханымның яшен чамаларга теләп, тагын бер мәртәбә аның йөзенә текәлә, тик җентекләп карый алмый. «Таныклыгыгыз кайда соң?»—әлеге ханымның җиңеннән тотып, үзенә таба бормакчы була. Билетсыз ханым, кинәт кенә

әйләнеп, авызыннан ясалма теш казналыгын тартып алды да, ярсып: «Менә минем таныклыгым!»—дип кондукторга төртте. Аптырап калган кондуктор дәшми генә чигенә башлады. Аннары, шулай ук дәшми генә, иреннәрен чәйни-чәйни, әйләнеп китеп барды. Аның үзенен дә балаларныкыдай ал төстә пластмассадан ясалган теш казнасы бит.

## Кем иде ул?

Шагыйрь Михаил Давыдович Львовның исем-фамилиясе, әтисенең исеме яһүдләрчә янгыраса да, ул татар иде. Бәлки ул керәшен татары булгандыр, бәлки, Мәскәүдәге катлаулы тормышын, алай гына да түгел, әдәби тормышын гадиләштерергә теләп, псевдоним белән йөргәндер? Тик, ничек кенә булмасын, фронтовик шагыйрь, ул чакта күренекле «Новый мир» журналының баш мөхәррире урынбасары Михаил Львовка Казандагы житәкчеләр бик тә хөрмәт белән карый иде. Миңа, мәсәлән, хакимнәрнең берниндн ихтирамы юк иде, «Узел связи» дигән поэмам берничә ел инде басыла алмыйча китап нәшриятында ята иде. Анда КамАЗ төзелеше нигезендә «Без нәрсә төзибез соң? Кем өчен? Ни бәягә төшәр ул безгә?» дигән шикле сорауларга җавап эзләвем тәфсилләнгән иде. Кама автогигантының техник мәсьәләләрен күтәрмәгән идем юкса. Каләмдәшләрем мине совет иленә каршы карашларда гаепли башлады. Шулай итеп поэмамның басылып чыгуына өмет юк иде. Якташларына ярдәмчел дип ишеткән идем: моңа кадәр үзен күреп белмәсәм дә, яклау эзләп, Михаил Львов янына барырга карар кылдым.

Бервакыт, катлаулы операция кичергәннән соң бирелгән юллама белән Пятигорскига санаторийга барганда, Мәскәү аша китәсе булды да, кульъязмамны да үзем белән алдым, һич тә икеләнмичә, вокзалдан ук туп-туры Кече Путинка тыкрыгында урнашкан «Новый мир» журналы редакциясенә юл тоттым. Мин кыяр-кыймас кына ишекне ачып кергәндә, шагыйрь Михаил Львов зур илебездә яшәп иҗат итүче каләм ияләре китереп өйгән кульъязмалар белән тулган кечкенә генә эш бүлмәсендә кычкырып-кычкырып телефон аша сөйләшә иде. Аңлавымча, бер хатын-кыз аны шигъри котлау язарга үгетли, ә ул ачуыннан кәнәфиендә сикеренеп куя-куя: «Юк инде, юк! Мин булдыра алмыйм!—ди.—Андый нәрсәләр яза белмим, Аның өчен илһам кирәк. Мин—шагыйрь! Ничек инде ул—миңа берние дә юк? Мин—шагы-ыйр-рь!!!»—Әйе, нәкъ менә өч өндәүле итеп әйтте ул моны. Һәм трубкасын шапылдатып куйды. Шулчак кына ул кергән кешене күреп алды, яхшылабрак карау өчен, өстәлдәге калын папкалар арасыннан күтәрелә төште. Аның буена карап, сугышка ни өчен диңгез флотына түгел, танк гаскәренә җибәргәннәрен аңлап алдым: хәрәкәтчән гәүдәсе жем-жем килеп торган терекөмеш тамчысына тиң иде. Мин кем булуымны әйттем, үземне җәфа чиктергән иҗат җимешемне укып каравын, фикерен әйтүен үтендем. Львов кулын гына селтәп җибәрде: «Юк, юк! Булмый! Күрәсезме?!»—дип, кабинетындагы кульъязмалар өеменә күрсәтте. Имеш, синнән башка да графоманнар җитәрлек.

Безнен илдә ул чакта казылык кына түгел, теш пастасы белән сабын да житешми иде, ә халык, шәхси гигиена таләпләренә исе дә китеп тормыйча, иҗат итә. Мин бусагада таптанып торам инде шулай. Ни дип әйтә алам соң? «Алай да мин кульъязмамны калдырыйм әле, Михаил Давыдович!—дип үтендем.—Дачага йөрисезме? Бәлки юлда ике-өч битенә күз салырсыз... Ошамаса, башка укымассыз. Мин бит Үзәк комитетка да, КГБга да бармаячакмын. Ошамагач ошамый инде. Кемгә ни ошый бит...» Львов сәер генә итеп миңа карап куйды. Күрәсең, авторларның моңа кадәр аңа болай

һөҗүм иткәне булмагандыр. Бераз күтәреп кенә: «Ярар... Калдырыгыз...— диде.—Тик мин Сезгә берни дә вәгъдә итмим!»

Бер айдан кире кайтып барышлый, мин тагын вокзалдан туп-туры «Новый мир»га киттем. Бу юлы поезд бик иртә килгәнлектән, баш мөхәррир урынбасары урынында юк иде әле, сәркатип кыз Михаил Давыдовичның инде шалтыратканын, хәзер килеп җитәчәген әйтте һәм миңа көтеп торырга кушты. Мин кабинет каршындагы урындыкка утырып көтә башладым. Озак көтәргә туры килмәде. Михаил Давыдович баскычтан тәгәрәп дигәндәй коридорга менде. Өстендәге плащын җилбәгәй җибәргән, башындагы кара-зәңгәр беретын кыңгыр салган. Бу юлы ул мине күреп алуга, ике кулын сузып, каршыма ук ыргылды. «Поэмагызны укып чыктым,—диде ул кыла-килешкә. Миңа ошады.» Ул мине бүлмәсенә алып керде, шунда ук журналның рәсми кәгазенә Татарстан китап нәшриятына тәкъдим язмасын сырлап бирде һәм, үзенең эш бүлмәсендә телефоны булса да, кемгәдер шалтырату өчен, баш мөхәррир кабинетына алып керде. Ул Казанга кемгәдер шалтыратты, ә мин шул чакта Твардовский утырган бу бүлмәне кызыксынып күзәттем.

Аның кемгә шалтыратып, бик кайнарланып, минем поэмамны бастырырга тәкъдим иткәнен әле дә белгәнем юк. (Алгарак китеп әйтим: Татарстан китап нәшриятында минем китабым нәшер ителүгә иң беренче чиратка куелды.)

Ана рәхмәт әйтеп, китәргә җыендым. Тик Михаил Давыдович мине туктатты: «Дачадагы күршем Евгений Евтушенко. Казанда яшәүче кызыклы шагыйрь белән танышуымны аңа да әйттем. «Мин аны күптән беләм инде,—диде ул.—Мин аның китабына кереш сүз язсам, бик шат булыр идем». Сез моңа ничек карыйсыз?»—диде Михаил Давыдович. Ничек карыйм инде?! Сүз дә юк, зур горурлык булыр иде... Ул чакта бәхәсле шагыйрь буларак танылган Евтушенконың кереш сүзе кайбер күркәләрнең кикриген кызартачак инде! Нигә каршы булыйм ди әле? Мин рәхмәт әйттем. Мөхәррирләр шактый кискәләсә дә, ун ел җәфалана торгач, китабым тәки басылып чыкты бит. Язучылар берлегенә җиде елдан соң гына алдылар әле мине. СССР Язучылар берлегенең соңгы әһелләреннән берсе инде мин, чөнки шуннан соң озак та үтмәстән, СССР үзе дә таркалды. Зур үзгәрешләр чоры килде. Көннәрдән беркөнне әдипләр бистәсе Переделкинода Михаил Львовның архивын чүплеккә чыгарып ташлауларын телевизордан хәбәр иттеләр. Шагыйрь мәңгелеккә китте, ә варисларына аның шигырьләренең кирәге юк! Әле күптән түгел генә дошман булганнар белән дуслашучы бу илдә фронтовик шигырьләре белән тамак туйдыру мөмкин түгел шул. Күпләр Михаил Львовның яхшылыкларын ихтирам белән искә аладыр, ләкин аның иҗаты гасырның шигъри сәхифәләрендә уелып калыр микән? Сөзгеч аша үткәрә-үткәрә, шигъри антология бакчалары үстерүчеләрнең хөкеме нинди булыр? Ә минем хәтеремә шушы юллар уелып калган:

> Чтоб стать мужчиной, мало им родиться,
> Как стать железом, мало быть рудой.
> Но надо переплавиться, разбиться,
> И, как руда, пожертвовать собой.

Дүрт юл... Бары дүрт.

Йә, нәрсә өчен корбан булып яшәгән соң бу яһүдчә янгырашлы, русча язучы «федераль әһәмиятле» Мәскәү татары?

**Гөлшат САЛИХҖАНОВА** *тәрҗемәсе*

# ВАЗИФА

Мәскәү өлкәсенең Пушкино шәһәрендә татар җәмгыяте бар. Пәнҗе татарлары, Нижгар мишәрләре бу җирләргә сугышка кадәр үк килеп урнашканнар. Шунда гомер кичереп, бала-чага үстереп, аларны урнаштырып, матур гына картаеп килүче милләттәшләр байтак. Минем якын танышым, Рамаева Хәмдия Вахит кызы, туганнарына якынрак урнашып яшәү нияте белән 80нче еллар башында бирегә Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районы, Иске Зеленай авылыннан гаиләсе белән килә. Шактый тәҗрибәле укытучы буларак Май урта мәктәбе укытучылар коллективында ул шундук хөрмәт казана. Чөнки ул үзенә йөкләнгән сыйныф белән Мәскәү һәм якын-тирә шәһәр музейларын карап-йөреп чыга, балаларны төрле җәмәгать эшләренә тарта. Аның төп тәрбияви максаты булып укучыларга белем бирү генә түгел, ә бәлки кешеләргә нинди дә булса файда китерердәй эшләр белән шөгыльләнү зарурлыгын балаларның аңына җиткерү тора. Шуңа да аның хакында әлеге мәктәптә иң җылы сүзләрне генә сөйлиләр, укучылары да аны сагына.

Хәмдия ханым лаеклы ялга чыккач, белемен, көчен, тәҗрибәсен нинди дә булса файдалы эшкә юнәлтү турында еш уйлана. Ә бит чын гражданин булган затка бераз булса да кешеләр, илең турында уйлану бик тә табигый хәл.

Шулай бервакыт аның күзенә белдерү чалына: шәһәрнең мәдәният йортында татарның танылган артистлары катнашында концерт куелачак икән һәм әлеге белдерү кешеләрне булачак тамашага чакыра, билетлар фәлән җирдә сатыла дип игълан итә. Хәмдия ханым озын-озак уйлап тормый, билет сатылу урынын эзләп китә. Таба, кемлеген аңлата, һәм шактый четерекле эшкә алына, ягъни мәсәлән, билетларны татарлар арасында таратырга. Әмма татар дигәнең Пушкино урамнарында тезелеп басып торса икән! Юк шул, алар дистәләгән еллар буе бер-берсен белми, күрмичә районның төрле урыннарында яшәп ята. Бар алар, күп алар, әмма, әйткәнемчә, сибелгән. Тик, үз дигәнен эшләмәсә Хәмдия ханым Хәмдия буламени?! Ул дәртләнеп, үҗәтләнеп, район буенча үз татарыбызны барларга керешә: базарлар буйлап йөри, станцияләрдән үтә, һәртөрле эш урыннарына керә... Татарларны таба, билетларны тарата... 400 кеше сыйдырышлы зал тамашачы белән шыгрым тула! Иң гаҗәбе шул—концерт алдыннан сәхнәгә аны оештыручы күтәрелә, кешеләрне Пушкино шәһәрендә татар җәмгыяте оешу белән котлый һәм шул җәмгыятьне җитәкләүче итеп Хәмдия ханымны тәкъдим итә. «Минем хыялым без татарларны бер җәмгыятькә туплау иде. Хәмдия ханым сезне кыска гына арада бу мәһабәт залга җыя алды, димәк, татар җәмәгатьчелеген туплау, аның эшен алып баруны да шикләнмичә аңа тапшырырга мөмкин». Зал, билгеле, бу белдерүне көчле алкышларга күмә.

Хәмдия ханым район буенча җәмгысы 5000гә якын татарны барлый, милли җәмгыятьне терки. Район хакимияте әлеге оешмага Пушкино шәһәре үзәгендә урнашкан зур гына йорттан барча уңайлыклары булган шактый иркен бүлмә бирә, Пушкино районы хакимият башлыгы Лисин Владимир Васильевич ярдәме белән төүге тапкыр шәһәрдә татарларның дини йоласы булган Корбан бәйрәмен зурлап үткәрәләр. Мәдәният йортының зур залында татар ашлары куелган

өстәлләр көйләнә, бәйрәмгә күбесенчә олы яшьтәге әби-бабайлар чакырыла. Чын күңелдән булган теләкләр, аракысыз табын кунакларны һәм хакимият җитәкчеләрен соклану катыш гаҗәпләндерә. «Татарлар бик тәртипле халык икән»,—дип белдерә хакимият башлыгы да. Хәмдия ханым Пушкино районындагы музыка мәктәбе коллективларына Нарофоминск шәһәрендә үткәреләсе татар музыка фестивалендә катнашырга тәкъдим итә. Билгеле инде алар катнашкан очракта, хакимияттән транспорт белән тәэмин итү хакында вәгъдә ала. Катнашырга риза булган мәктәпләргә С. Сәйдәшев һәм башка күренекле татар композиторлары әсәрләренең ноталарын табып тарата, тегеләре башкару осталыгы өстендә эшли башлый. Ниһаять, көтелгән көн килеп җитә. Пушкино шәһәре музыкантлары үз уен кораллары белән берничә автобуска төялеп, Нарофоминск шәһәренә юл тота. Тамашачылар татар музыкасын башкаручы артистларның чыгышларын көчле алкышларга күмә, ә Софрино музыка мәктәбе укучылары беренче урынны яулый! Фестивальдә җиңү хәбәре Пушкино шәһәр җитәкчелегендә шатлыклы хисләр уята, укучыларын татар музыкасы фестиваленә әзерләгән һәммә укытучыга хакимият кыйммәтле бүләкләр тапшыра. Бу җәһәттән Хәмдия ханымга «ник безне дә катнашырга чакырмадыгыз»,—дип үпкәләп йөрүчеләр дә очрый. Ул икенче юлы шундыйрак фестивальгә барча мәктәпләрне катнаштыру хакында хыяллана. Сүз уңаеннан, балалар татар музыкасын яратып башкаралар икән. Җәмгыять карамагына Ивантеевка шәһәренең татар зираты бирелгән. Аны татарлар үзләре җыелышып карап, чистартып тора. Ярдәмчесез яшәүче ялгыз милләттәшләр турында кайгырту да җәмгыять өстендә. Андый кешеләрне, бакый дөньяга күчкән очракта, күмәк көч белән җыеп, догаларын укып, зиратта соңгы юлга озаталар.



*Республикабыз Президенты М. Ш. Шәймиев Хәмдия ханымга бүләк тапшыра.*

Хәмдия ханым хакимият һәм мөселман диния нәзарәте белән уртак тел табып, Пушкино районында яшәүче татарларга Корьән серләрен белүче, яшь кенә булса да тирән белемле, аның өстенә бик тырыш булган Басыйров Рамил атлы егетне мулла итеп бирегә китертә. Шуның белән бергә, ял көннәрендә гарәп һәм татар телен өйрәнер өчен дәресләр оештырыла, аларга милләттәшләр бик теләп йөри. Хәзер Пушкино шәһәрендәге татар җәмгыятенең балалар өчен милли җыр һәм бию түгәрәге бар, бәйрәмнәрдә татар яшьләре өчен дискотекалар оештырыла. Яшьләр өчен танышу-аралашу мөмкинлеге тудырылгач, якын араларда гына дүрт парга никах укытып, бәйрәм дә иткәннәр.

Сүз уңаеннан, шуны сөйләп үтми булмый: Хәмдия ханым хакимият каршында милләтләрнең автоном үзәген булдыру хакында тәкъдим белән чыга һәм ул хуплана. Нәтиҗәдә, элек татарларның гына җыелу урыны булган урын «Халыклар дуслыгы йорты»на әверелә. Биредә татарлар, украиннар, яһүдләр, казакълар җыелып, милли бәйрәмнәрен, дини йолаларын билгеләп үтәләр, милли җырлар, тарих, әдәбиятны, динне өйрәнәләр. Милли киемнәр тектереп, бәйрәмнәрдә үзләре дә концертлар оештыралар, үзешчән фольклор группалары булдырылган. Билгеле инде, иңгә иң торып эшләгәч, аралашкач, әлеге милли төркемнәрнең бер-берсенә тәэсире булмый калмый. Шундый бер вакыйгага минем үземдә дә гаҗәпләнү, милләттәшләребез белән горурлану хисләре уятты.

Бөек Җиңү бәйрәме барыбыз өчен дә кадерле. Шул истәлекле көннәр алдыннан татар зыяратын чистартып, тәртипкә китерүне җәмгыять көн тәртибенә куйган: һәр елны шул эшкә хакимият ярдәмендә автобуслар алып, оешкан төстә барып, изге эш эшләп кайталар. Бөек Ватан сугышында катнашкан Ветераннар аллеясын чистартып, буяп, чәчәкләр утыртып, карап-тәрбия кылып торуны да үз өстенә алганнар.

...2008 елның май башларында, зыяратта шул эшләрне башкарырга, янә дә үлгәннәр истәлегенә Коръән укырга мулланы да чакырып, җыелган кешеләрне каберстанга алып барыр өчен автобус көтеп торулары икән. Татарларның «үзләренекен» шул хәтле хөрмәт итүләре рус җәмгыятендәгеләрне дә әлеге изге эшкә канатландырган. Үзләренең гореф-гадәтләре буенча, үлгәннәр истәлегенә «поминка» оештырырга исәпләп, каберлеккә алып барыр өчен хакимияттән автобус сорарга булганнар. Әйтеп үтәргә кирәк, андый «поминка»—ул каберлек янына шәм кабызу, шунда стакан белән аракы, икмәк кую, үлгән кеше турында истәлекләр сөйләшү, аның хөрмәтенә бераз «төшереп алу», «закускалар» белән сыйлану. Безнең татарга исә каберлек янында бары тик Коръән сүрәләре уку, яхшы теләкләр теләү генә фарыз.

Хәмдия ханым бу яктан шактый хәбардар кеше буларак, аларга әйткән: «...дөрес эшләмисез. Аларга сезнең поминкагыз кирәкми, аларга дога кирәк. Сезнең изге атакаегыз бар бит, каберләрегезне чистартыгыз, аннан соң үзен алып килегез, догалар укытыгыз!» Русларга тәкъдим ошаган, шулай иткәннәр дә. Ничек шатланмыйсың, һичкем белми бит кайчан шунда барып «урнашасын»...

Пушкино шәһәрендә, шулай ук районда, бик матур бизәлгән берничә чиркәү эшләп тора. Соңгы елларда ил сәясәтендә дин мәсьәләсенә игътибар сизелерлек артты: изге атакайлар ил армиясе, төрмә-колонияләр буйлап «сәяхәткә» чыгып китteләр. Матбугатта Рәсәй буенча бик күп мәгариф бүлекләрендә балаларга дин дәресләрен, аерым алганда христиан дине нигезләрен укытуны көн тәртибенә куелганлыгын хәбәр итәләр.

Көннәрдән бер көнне, иртәнге якта бер төркем таҗиклар булса кирәк—шул чиркәүләрнең берсенә килеп керәләр. Керүчеләрнең берсе изге атакайдан әлеге чиркәүдә намаз укып алырга рөхсәт сорый. «Чөнки,—ди ул, Мәскәүдәге мәчеткә бара алмыйбыз. Эшкә дип килгән идек, хуҗа документларыбызны җыештырып алды. Документсыз Мәскәүдә безне кулга алулары мөмкин. Бүген—мөселманнарның бәйрәм көне, шуңа да без бирегә—Аллаһы йортына—килеп, намаз укырга булдык». Изге атакай, рәхмәт яугыры, чиркәүдә булган һәммә христианга тын калырга боерып, әлеге кешеләргә намаз укырга рөхсәт бирә, соңгылары исә, кыйбла якка карап, намазларын укып, рәхмәт әйтеп, тыныч күңел белән бинадан чыгып китәләр. Бу хәл нәрсә турында сөйли? Аллаһы Тәгаләгә чын күңеле белән ышанган һәм аның кануннары буенча яшәүче дин әһелләре, бәхеткә, бар, һәм Рәсәйнең якты киләчәге шундый кешеләрнең күплегенә дә бәйле.

Хәмдия ханым Пушкино районында җәмәгать эшлеклесе буларак танылган кеше: районда социаль һәм башка әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүгә багышланган утырышларда ул даими катнаша. Аның белән шул тирәдә эшләүче чиркәү башлыклары, ягъни изге атакайлар да әлемтәдә тора. Шундыйларның берсе—данлыклы Софрино бригадасына рухи хезмәт күрсәтүче Феофан атакай—көннәрдән беркөнне Хәмдия ханымга ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Баксаң, әлеге чиркәүне икенче урынга күчермәкчеләр икән, ә урынына нindидер кирәк-ярак сакларга урын төземәкчеләр, имеш. Әлеге чиркәү берьяктан борынгы тарихи истәлек булып торса, икенче яктан янәшәдә диярлек урнашкан Софрино бригадасы, анда хезмәт итүче солдатларга хезмәт күрсәтү өчен кулай булуы белән әһәмиятле икәнлеген аңлата дин әһеле. Хәмдия ханым аның белән килешә, бергәләп хакимияткә үтенеч әзерлиләр. Нәтиҗәдә чиркәү үз урынында кала. Әлеге изге ярдәме өчен атакай Хәмдия ханымга бүген дә рәхмәтле. Әйтеп үтәргә кирәк, Феофан атакай Софрино бригадасында хезмәт итүче мөселман балалары өчен Корьән сүрәләреннән үз куллары белән догалар күчереп язган. Солдатларны «кайнар нокта»ларга җибәрү алдыннан, әлеге сүрәләрне дога итеп, һәрбер солдатка таратып чыккан кеше. Минем уйлавымча, ул һәрбер баланы үзенчә Раббыбыз иркенә сыенырга күндергән, Аның яклавына өмет баглаган! Каф тау солдатлары дини белемле булулары белән аерылып торалар, ә Татарстаннан һәм Башкортстаннан булган егетләр һичнинди дога укый белмиләр икән. Шулай бервакыт, Феофан атакайга «христианлыкка күчерүне» үтенеп, татар милләтеннән булган солдат мөрәҗәгать итә. «Мин дини хәбәрдарлыгы булмаган кешене христианлыкка күчереп, үз өстемә гөнаһ ала алмыйм»,—ди Феофан атакай һәм әлеге солдатны Хәмдия ханымга җибәрә. Егетнең гаиләсен, тормышын сорашкач, шунысы

аңлашыла—ул ятимлектә, кагылып, кимсетелеп үскән. Ислам дине хакында бөтенләй дә хәбәрдар булмыйча, очраклы рәвештә, урыс динендә үксезләрне яклау, гаделлек төшенчәләре барлыгын аңлап, шул дингә күчәргә ниятләгән икән. Хәмдия ханым солдатка Ислам диненең ата-бабадан калган мирас буларак кыйммәтен, кешелек өчен әйтеп бетергесез бәһасын әйбәтләп аңлата. Егет, рәхмәтләр укып, үз динен ныграк өйрәнергә һәм тотарга карар кыла.

Хәзергесе вакытта халкыбызның дини бәйрәмнәре Пушкино шәһәре тормышында сизелерлек вакыйга итеп, оешкан төстә үткәрелә. Шәһәрдә мөселманнарның корбан чала торган үз урыннары булдырылган. Хәмдия ханым сөйләгәннәр буенча, үткән көздә шәһәрдә Корбанга кешеләр җәмгысе 230 баш сарык чалдырганнар. Корбан ашын авыз итәргә урыслар һәм башка милләт кешеләре, хакимият әһелләре теләп киләләр икән. Еш кына рус милләтеннән саналган, әмма нәселендә татар каны аккан кешеләр сәдака китереп, ата-бабалары рухына җәмгыятьтә торган әби-бабайлардан изге догалар укыталар. Бәйрәм көннәрендә якын-тирәгә урнашкан частьларда хезмәт итүче мөселман балалары татар җәмгыятьчелеге тупланган үзәккә килеп, догаларын укып, бәйрәм ашыннан авыз итеп китәләр икән.. «Үткән ел Корбан ашына үзем генә дә сарык итеннән 200 пәрәмәч пешердем. Башка әби-апаларыбызны әйткән дә юк! Кемнең кулыннан нәрсә килә—әзерләп, үзәккә китерәбез. Хакимият тә ярдәм итә. Ярдәмчел эшмәкәрләребез, шөкер, бар. Гади кешеләребез—үз хезмәтеннән өлеш чыгаручыларыбыз да байтак—шулай әзерләнә безнең бәйрәм табыныбыз! Янә дә Пушкино шәһәрендә берничә сәүдә үзәге тотучы әзәриләр, чичиннәр, башка хәлле мөселманнар казаннары белән сарык итеннән ботка пешереп китерәләр. Бәйрәм көннәрендә үзәккә килгән һәммә кешене ашатып-эчертеп җибәрәбез. Кеше күп килә: ветераннар, ялгыз карт-карчыклар, солдатлар... Нинди милләттән дип тормыйбыз, барын да сыйлыйбыз»,—ди Хәмдия ханым.

Быелгы ураза ае кергәч, Феофан атакай Хәмдия ханымга 28ләп солдатның ураза тотуын, дөреслектә ач торуларын хәбәр итә. Солдат ашханәсе сәхәр һәм ифтар өчен һәрчак бикле булганлыктан солдатларның хәле аяныч дип бәяләнә. Хәмдия ханым һәм татар җәмәгатьчелеге әлеге солдатлар өчен уразаны тиешенчә тотарлык күләмдә куертылган сөт, хәләл иттән әзерләнгән тутырма, һәртөрле тәм-том әзерләп, хезмәт итүче егетләргә китерәләр. Солдатларның шатлыгы чиксез була, күчтәнәчләрне тирән рәхмәт хисләре белән кабул итәләр.

Бер-ике ел элек булса кирәк, аңа ЮНЕСКОдан берәү шалтырата һәм Мәскәү шәһәре янында яшәүче татарлар тормышыннан фильм төшерергә ниятләвен белдерә. Хәмдия ханым шатланып, булышырга ризалыгын бирә. Өен, көн күрмешен тасвирларга риза булган милләттәшләр табыла, җәмгыять әгъзалары милли ашлар әзерлиләр, татарларның тормышында булган гореф-гадәтләр турында мавыктыргыч итеп сөйлиләр... Кыскасы безнең милләт хакында шактый эчтәлекле фильм эшләнә һәм ЮНЕСКОга китә.

Җәмгыятьнең хакимият белән уңышлы эш итү күрсәткечләре шактый. Шәһәрдә һәм районда яшәүче татарлар өчен бик тә әһәмиятле мөмкинлек булдырыла: атнага бер тапкыр җирле телевидениедән татарлар тормышы хакында тапшыру оештырыла. Хәмдия ханымның тел белгече буларак осталыгы бик тә ярап куя—тапшыруны ул үзе әзерли, үзе алып бара. Җәмгыять әгъзалары—әбиләр, бабайлар, апалар, абыйлар—үзләре дә кирәк чакта хакимияткә ярдәмгә килә. Район кысаларында картлар көнен билгеләп үтү ике-өч ел элек гадәткә кергән. Әлеге изге эш татар җәмгыяте ярдәмендә башкарыла: аягында йөри алган олылар өчен аш-су әзерләп, бәйрәм өстәлләре көйләү, йөри алмаганнарның өйләренә барып, бәйрәм белән тәбрикләү һәм бүләкләр тапшыру... Бик күпләр: «мондый игътибарны күргәнебез юк иде»,—дип, елап, рәхмәт укып калалар.

Дөрес, җәмгыять тормышында барча хәлләрне да ал да гөл итеп язу дөрес үк булмас. Җәмгыять оешкан көннәрдә кайбер милләттәшләр мәчет мәсьәләсен кузгаталар. «Районда меңнәрчә мөселман кешесе, ә үз мәчетебез юк! Хакимият алдына мәчет төзетү хакында таләп куярга кирәк!...» Хәмдия ханым, урыс арасында мәчет төзетү кебек үтә дә катлаулы мәсьәләгә житәкче буларак иситкеч акыллы чишелеш таба: «Ягез,—ди ул,—әле мәчет төзетеп, ачтырып, кем йөрер анда? Бармы безнең муллабыз? Беләбезме без догалар? Әлегә

җыелыр урыныбыз бар, укыйк бераз Корьән китабын, өйрәник догалар... Тартылырмы кешеләр? Дини бәйрәмнәребезгә нинди мөнәсәбәттә без? Әгәр инде, чыннан да, кешеләр ташкын булып килә башласа, үз эшләребез белән диннең, мәчетнең кирәклеген исбатласак, хакимият ник соң каршы килсен безнең бу изге ниятебезгә?» Хәмдия ханым хаклы булып чыга: элек татарлар һәрдаим мәчет таләп итеп шаулашкан чакларда, Мәскәү өлкәсе һәм Пушкино районы җитәкчелеге әлеге четерекле мәсьәләне уңай хәл итәргә атлыгып тормый иде. Бүген—бүтән караш, хакимият татар җәмгыятенең башкаларга үрнәк булып торырдай эшләренә игътибар бирә, һәрдаим ярдәмгә килә. Җәмгыять, шулай итеп, үз тырышлыгы, файдалы эш күрсәткечләре белән район җитәкчеләренең ихтирамын казанды. Күптән түгел хакимият җәмгыятьнең мәчет салдыру хакындагы гозерен уңай хәл итте—төзеләчәк мәчет өчен урын билгеләнде. Әйтеп үтәргә кирәк, Хәмдия ханымга әлеге мәчетне төзүдә гарәп илләреннән булган кешеләр акчалата ярдәм тәкъдим иткәннәр, төзү эшләренә алыну мөмкинлекләрен аңлатканнар. Әмма ханым мәчет төзетү кебек катлаулы эшкә үз эшмәкәрләребез алыныр дигән өметтә яши. «Ник,—дидем мин, бу хактагы хикәяне тыңлагач. Мәчет төзетү искиткеч зур чыгымнар сорый бит?...» «Эш шунда,—диде Хәмдия ханым,—кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың. Мәчетне төзерләр, муллаларын китерерләр, гарәп илләренә хас дин тәртипләрен куярлар... Ә без бераз башкабыз... Без кырыс мохитта яшәүчеләр, Ислам динен тотуда үз үзенчәлекләребез бар. Әйтик, киенү рәвеше... Хәзер бит, безнең илдә, Ислам динен тоткан хатын-кыз гарәп илләрендәгечә, баштанаяк уранып йөри йә шулай киенгәнме безнең әбиләребез элеккеге заманнарда? Әбиләребез кыз чакларында да, хатын чакларында, әби чакларында—гомерләренең һәр фасылында бик үзенчәлекле: ислам кануннарына туры килә торганча киенгәннәр, шул ук вакытта кояш нурлары аларның тәннәрен җитәрлек иркәли алган. Аларның матурлыклары җырларга салынган, ир-егетләрне фидакарь эшләргә канатландырган! Аллаһы кушса, үзебезнең кануннарны торгызучы мәчетебез булыр, иртәме, соңмы булыр...»

Кайберәүләр, әйтеп үтәргә кирәк, татар тормышыннан бик үк хәбәрдар булмаган кешеләр, болай диләр: сез, татарлар, кыргый халык. Хатыннарыгыз яулыктан, оектан... Ирләре кыерсыта... Әле ярый руслар булды, тормышыгызга бераз «демократия» галәмәтләре кертергә... Андыйларга Хәмдия ханымның җавабы әзер: «Кайсы авылда күргәнегез бар урыс әбиенең оексыз, яулыксыз урамга чыкканын? Безнең әбиләр-апалар охшаш, әдәп кагыйдәләре дә охшаш... Кешелек сыйфатларына килгәндә, урыста да төрлесе бар, татарда да...» Хәмдия ханым Пушкино халкына татарларны ниндидер мөгезле халык итеп түгел, ә бәлки эшчән, акыллы, юмарт һәм батыр йөрәкле итеп таныта килә. «Без ике бөек халык, үзара бик күп файдалы гамәлләргә өйрәнеп, бер-беребезне рухи яктан баетып яшәргә тиешбез»,—ди ул.

Пушкино районы Мәскәү өлкәсенең Ярославль юнәлешендә, башкаладан 40 чакрымнар ары булыр. Табигать бу җирләрдә искиткеч гүзәл, ул тирәләр юкка гына өлкәнең «яшел зонасы» дип аталмыйдыр. Урманнар, елга-күлләр, кая барсаң—анда мул яшеллек... Дөрес, халык бик тыгыз урнашкан. Шундый урыннарның берсендә, Звягино дип аталган, татарлар күпләп яшәгән бистәдә берничә ел инде, татар җәмәгатьчелеге тырышлыгы белән һәм Пушкино районы хакимияте ярдәменә таянып, Сабан туй үткәрелә. Бәйрәмгә килүчеләргә милли киемнәрдән булган «урындагы» төрле милләт фольклор ансамбльләре, шулай ук Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән Казаннан китерелгән артистлар күңелле тамаша күрсәтә. Сабан туен районда яшәүче милләттәшләр генә түгел, башка милләт кешеләре дә үз итеп өлгергән. Милли уеннар: баганага менү, капчык киеп сикерү, йомырка салган кашык кабып йөгерүләр, сулы көянтә-чиләк күтәреп йөгерү-ярышу, һәм бик күп, бик күп төрле уеннар, биюләр, җырлар... һәм билгеле, татарча көрәш биредә дә Сабан туеның төп бизәгенә әверелгән. «Бүләксез һичкем китмәде. Милли ашлар мулдан булды—дип шатланып сөйли Хәмдия ханым,—үзебезнең солдатлар да килеп, рәхәтләнеп бәйрәм итеп китте. Үз мөселман егетләребез ярдәм итте: казаны белән пылау пешереп, кунакларны сыйладылар, исерткеч эчемлекләр бөтенләй дә сатылмады». Пушкино шәһәрендә булырга туры килсә, һәрчак татар җәмгыяте урнашкан үзәккә сугылырга тырышам. Бу җәйдә җай чыгып, Хәмдия ханым

белән очраштым. Җәмгыять тормышында булган вакыйгаларны җиткерергә булдым. Ни өчен? Миндә шундый тойгы калды—теләсәк, без берләшә алабыз. Без татарны харап итә язган төп сәбәпләрнең: таркаулык, эчкечелек, диннән ерагаю икәнлеген искә төшерсәк, Хәмдия ханым җитәкләгән Пушкино шәһәрендәге татар милли автоном җәмгыятенең тормышы бу чирдән дәва юларын ачыклаган һәм уңышлы хәл итү юлларын тапкан. Үзәктә җыелышып, Коръән сүрәләрен укыйлар, татар тарихын, гореф-гадәтләрен, дин тарихларын өйрәнү бара. Бирeдә кешеләр бер-берсенә туганнарча мөнәсәбәттә: кайгы-шатлыклар—уртак. Хәмдия Вахит кызына үземне кызыксындырган сорауны бирми түзә алмадым: Хәмдия ханым,—дим,—яхшы, кешеләрне бер җәмгыятькә тупладыгыз. Инде максатыгыз нинди?

—Әле кайчан гына район музыка мәктәпләрендә балалар татар музыка әсәрләрен башкарырга өйрәнделәр, инде шудук мәктәпләрдә татар җыры конкурсы хакында игълан иттек. Катнашырга теләүчеләр шактый. Рус балаларының күп булуы да куандыра. Алар безнең татар җырларыбызны «бик матур көйле» дип табалар, тырышып өйрәнәләр. Балалар белән Щепкин театрыннан чакыртылган, үз милләтебездән булган белгеч эшли. Аннан соң, якын киләчәктә, үзебезнең тарихыбызны әйбәтләп өйрәнеп чыгарга ниятлибез. Бик бай китапханәбез бар. Сүз дә юк, бу эштә татар Конгрессы бик булышты.

Дөрестән дә, автоном үзәктә теләсә кемне көнләштерерлек китапханә эшли: нинди генә китаплар юк бирeдә! Диннәр тарихы буенча хезмәтләр, кайсы дин белән танышасың килә—һәммә нәрсә бар! Без татарның ерак бабалары тарихына караган, чит илләрдә дөнья күргән хезмәтләр, үзебезнең язучы һәм шагыйрьләрнең иң танылган әсәрләре... Чын мәгънәсендә бәһасыз, рухи байлык!

—Хәзер мәктәп укучылары арасында татар тарихына караган сораулар буенча даими рәвештә конкурс оештырырга уйлыйбыз. Безнең халыкның тарихы әле яңа ачыла: хәзер бит Рәсәйдә элек тыелган хезмәтләр күпләп дөнья күрә башлады. Без—татарлар—бирeдә яшәүче башка милләт халкына үзебезне танытырга тиешбез. Безнең мең елларга сузылган данлы тарихыбыз, тормышыбызны тотрыклы итүче Ислам динебез, менә дигән рухи мирасыбыз—поэзия, әдәбият, музыка һәм безне зәвыклы халык итеп танытучы башка бик күп күрсәткечләребез бар!

Әле берничә балага бу җәйдә Казандагы «Сәләт» лагерена юллама юнәттек. Шулай итеп, синең соравыңа җавап,—дип дәвам итте Хәмдия ханым,—минем максатым: милләтемә хезмәт итү. Бирсен иде Аллаһы Тәгалә гомеремне озын итеп, күзләремне соңгы кат йомганчы халкыма хезмәт итәргә насыйп булса иде...

—Амин!—дидем мин. Пушкинодагы татар җәмгыятенә тикмәгә генә «Вазифа» дигән тирән эчтәлекле исем кушылмаган. Бирeдә һәркем үз вазифасын бик яхшы аңлап, җәмгыять тормышында теләп, яратып катнаша. Хәмдия ханым кебек үз халкын сөюче, аның өчен көенүче милләттәшләребез булганда, безнең татар халкына озын гомер насыйп итәр шаять.

**Фирдәвес ГАЛИЕВА**

# УЯН, ӘЙДӘ, ТАТАР КИНОСЫ!

*Көндәлек матбугат битләрендә «Татар киносы ни хәлдә, булачакмы ул?» яисә «Киноның милләте бармы?» кебек сораулар еш яңгырап тора. Мактап сүз әйтүчеләр дә, кино сәнгатенең торышын тәнкыйтьләүчеләр дә үзләренчә хаклы кебек. Бу очракта хакыйкать—бакыр акча шикеллерәк, аның «иләк» ягы да, «күн» ягы барлыгы бәхәссез.*

*Сүз башлаганбыз икән, иң әүвәл киноның иҗтимагый тормыштагы роле, вазифасы, тоткан урыны турында кайбер фикерләрне искә төшерик. Фән-техника казанышлары нәтиҗәсендә кино сәнгате безнең чорда өр-яңа баскычка күтәрелде. Аның колачы, халыкның аңына-җанына-психикасына тәэсир көче, мөмкинлекләре ифрат зур. Монополия үрләрен яулаган «Голливуд»ны гына алыйк. Дөнья базарына ул чыгарган фильмнар аша Америка Кушма Штатлары барлык кыйтгаларга үзенең идеологиясен, сәясәтен, мактанычын таратып ята. Шушындый да зур максат өчен техника һәм акча җегәрен тамчы да кызганмыйлар. Бу, бер сүз белән әйткәндә, милли сәясәт дигәнне аңлата.*

*Хакыйкатьнең милләте юктыр, киноның исә милләте, һичшиксез, булырга тиеш! Һинд кинолары ни өчен тамашачыны һәрвакыт үзенә җәлеп итә, чөнки алар милли җирлеккә нигезләнеп иҗат ителгәннәр. Һинд җырларының төрле халыкларда кинәт кенә популярлашып китүе кино һәм телевизор экраннары аша барды лабаса. Безнең шәрык моңнарына уралган «Гөлҗамал»ны берәр әдәби-нәфис фильм аша югары сәнгати камәлдә яңгырата алсак—ул, һичшиксез, Европа халыклары күңеленә дә үтеп керер һәм үзенең лаеклы урынын табар иде. Мәгълүм бер фильмда «Болгарның җылы җилләре» исә ничегрәк искәнен күрдек ич, аңа тотылган миллионнар үзе дә җил кебек кенә исте дә билгесез тарафларга китеп таралды...*

*Кино—телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау һәм күрсәтүдә хәлиткеч роль уйный дибез. Бу бик дөрес. Киноның милләткә, шәхесне формалаштыруга йогынтысы искиткеч зур. Бу уңайдан: фильмнарда әдәп, әхлак, инсафлылык бармы? дигән сорауның тууы бик табигый. Бу сорауга «әйе» һәм «юк» дип җавап бирергә туры килә. Экраннардан корал куллану, кан, үтереш, фахишәлек кебек күренешләр сәгать саен, тәүлек саен коелып кына тора. Менә шушы ямьанлыкка каршы көрәшү өчен безгә, татарга, яңача караш, альтернатив фильмнар кирәк. Моны кем эшләр? Потенциаль мөмкинлекләребез бармы? Ә бит югары художестволы фильмнар иҗат итү өчен режиссер, сценарист, актерлар төркеме, технология, костюм-декорация цехлары һәм тагын бик күп нәрсәләр, ахыр чиктә, акча маясы кирәк.*

*Тарихыбыз бай, катлаулы. Татарның чын тарихын, милләтне башка халыклар алдында күтәрердәй милли идея кирәклеге—көн кебек ачык. Аксиома бу. Безнеңчә, татар киносын башка милләт вәкилләре дә карарлык, үз итәрлек итеп эшләү көн тәртибенә баскан. Әнә шундый киноларны «Алтын мөнбәр» сәхнәсендә күрсәтеп, безгә дә мактанасы иде бит, югыйсә.*

*Татар киносының чын хуҗасы бармы? Булса—кем? Хөкүмәт, диярләр һәм бу шактый дөрес җавап булыр. Әнә, «Аксенев укулары» дигән очрашуларга казна маллары табыла бит. Татар кино сәнгатен үстерү, көчәйтүгә дә акчалар һәм яхшы кадрлар табарга кирәктер.*

*«Казан утлары» журналы үзенең битләрендә татар киносы турында түгәрәк өстәл үткәрүне кирәк тапты. Татар киносына турыдан-туры катнашы булган әһелләрне менә шундый сөйләшүгә чакырдык. Аларга сүз бирик һәм уй-фикерен, гамьборчуларын тыңлап карыйк...*



**Әхтәм ЗАРИПОВ,**
**Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, кинорежиссер, күпсанлы сценарийлар авторы:**

–«Татар киносы» дип сүз алып барганда иң элек бу терминның нәрсәне аңлатуын ачыклау тиештер.

«Татарстанда төшерелгән кино» дигәнне аңлатамы ул, «татарлар турында» дигәннеме, «татарлар эшләгән»неме, фильмның татар телендә баруынмы, әллә инде товарның сыйфатына гына кинаяле ишарәме?

Бу сорауга җавап табылса, икенчел сораулар туа: татар киносы кемгә адреслана? Татарларга гынамы? Бөтен Рәсәйгәме? Кешелек дөньясынамы? Татар киносына ихтыяҗ җилләре кай яктан исә? Аны кем көтә, кемгә кирәк? Кайда һәм ничек күрсәтү күздә тотыла? һәм башкалар...

Фильмнарның Татарстан җирлегендә төшерелгәне дә, татарлар турындагылары да булды, архивларда алар хәзер дә саклана. Әмма аларның берсен дә «татар киносы» дип булмый. Татарлар катнашында Татар илендә төшерелсәләр дә, алар үз чорының идеологиясенә хезмәт итүче «наглядное пособие» генә, ягъни, үгет-нәсихәт коралы гына булганлыктан, сәнгать әсәрләре категориясенә керә алмаганнар, көчләп кертелгәннәре исә, шул сәбәпле, бик тиз онытылуга да дучар ителгән.

«Татар киносы» статус-кво алсын өчен, ул чынбарлыкта сәнгать әсәре буларак (как предмет исскусство) танылып, азмы-күпме яшәргә, аның сыйфаты, әһәмияте, тәэсире, файдасы яки зыяны турында җәмәгатьчелек хәтерендә ниндидер эз калган булырга тиеш. «Татар киносы» дигән тандемның «шәҗәрәсе»ндә югарыда күрсәтелгән сыйфатларның берсе дә юк, чөнки әйберсе үзе юк. «Юк»ны "бар" дип әйтеп булмагач, предметка бәйсез сүз тезмәсен «сәнгать» дип аның бүгенгесе, киләчәге хакында фикер йөртү–йомшак әйткәндә, хыялыйлык.

Кино ул–сәнгатьнең чагыштырмача иң яшь тармагы, әмма ләкин иң актив, иң нәтиҗәлесе. Сәнгатьнең тулы хокуклы бер вәкиленә миллилек мөһере сугылып, мөнбәргә милләт әләме кадау өчен аның шул милләт вәкилләре тарафыннан, шул җирлектә, шул милләт телендә иҗат ителгән булуы гына да җитми. Иң мөһиме–шул сәнгать әсәрендә башка милләтләр дә аны үз итәрлек мәгънә һәм компонент булырга тиеш. Мисалга һинд киносын гына алып карыйк. Аны башка бер милләт киносы белән дә бутамыйсың. Аны башка милләтләр дә яратып кабул итә. Чөнки һинд киноларында төп компонентлар–милли музыка, милләтнең гореф-гадәтләре, милләт традицияләренә тугрылык. Болар һәр милләт өчен уртак сыйфатлар.

Сәнгатьнең башка төрләрендә дә, әгәр үзәгендә кеше язмышлары, гомум кешелек проблемалары булып, үзенчә чагылышын тапкан икән, аның милли үзенчәлеге башка милләт халыклары тарафыннан кабул ителүенә комачауламый. Мәсәлән, гаруз ысулында язылган «Шахнамә»се белән Фирдәүси дә, газәлләр әйтү остасы Низами да. Алардан калган мираска таянып без «Шәрык әдәбияты», яки «япон шигърияте» дибез, классик әдәбиятта алар иҗатының тоткан урыны, роле турында фикер йөртәбез.

Әйе, һәр сәнгать үз урынында, үз вазыйфасын үтәп, кешелеккә хезмәт итә. Ирексездән шундый сораулар туа: сәнгать дөньясында «татар киносы»на урын

бармы соң? Әллә барлык урыннар да «занято»мы, «приватизация» тәмаммы? Кыскасы–урын табылу ихтималы бармы, юкмы?

Рәсми җавап «бар» булса да, кырык төрле өстәмә сораулар сагалап тора. Шул сорауларның иң өстә ятканы һәм иң хәтәре: «Татар киносы нигә кирәк ул, кемгә кирәк?» дигән сорау.

Федераль үзәк һәм аның сәясәтен тормышка ашырырга мәҗбүр җирле үзидарә–хакимият бу сорауга ачыктан-ачык «кирәкми» дип әйтә алмаса да, кылган гамәлләре бер дә булдыруга таба түгел.

Без күп очракта янгыннан соң чаң сугабыз. Аны ишеткән кеше аптырап кала: янгын сүндерергәме бу чаң, әллә гыйбадәткә чакыручы чиркәү чаңымы? Чаңы күп...

...Чиркәү чаңына кушылып, халык аңына һаман бер фикер сеңдерелә: «Бөек Рәсәй», «Бердәм Рәсәй», «Бүленмәс Рәсәй», «Насрани Рәсәй»...

...Арта барган машиналар гүләве, самолетлар гөрелтесе астында күгәрчен гөрләве ишетелмәгән кебек, «татар киносы» дип «безелдәү»не ишетерләрме? Ишеткәндә инде соң булмасмы?

Мирсәй Әмирнең «Сыерчык» дигән нәсере бар. Бомбалар шартлаган, снарядлар ярылган, пулеметлар тыкылдаган тавышлар арасында кайдадыр сыерчык сайравы ишетелә. Автоматын дошманына төзәгән солдатның бар игътибары тыныч көннәрне хәтерләткән шул сыерчыкка юнәлә. Бу мизгелләрдә солдат өчен сыерчык сайравыннан да матур, сыерчыктан да якын, аннан да тансык берни юк! «Татар киносы» дибез икән, ул татар өчен дә, урыс өчен дә, башка милләт тамашачылары өчен дә әнә шул сыерчык сайравыдай тансык булырга тиеш.

Каян эзләргә соң ул тансыкны? Бүген кемгә, нәрсә тансык булуын ничек белергә?

Телевизор каналлары аша гына да һәр көн 2-3 өр-яңа фильм тәкъдим ителә. Аларның саны ел эчендә 1000гә житә. Эчтәлегенә карасаң, күпчелегендә–байлык–мөлкәт өчен көрәш, зина-фәхеш, криминал, хыянәт, үтереш... Кыйбласын югалткан тамашачы нишләсен? Күрсәткеч карый инде, карагач, уртак телдәге фильмнарның саны һаман арта тора.

Мономилләт киноларыг өчен миллиардлар исраф ителә. Теге яктан кертелгән фильмарны да исәпкә алганда, Рәсәй тамашачысы татарның тансыгын кайда һәм ничек карар икән? Бу сорауга бүген җавап табу шактый авыр. Ләкин бу–«татар киносы» өчен көрәштән туктарлырга дигән сүз түгел. Ә киресенчә, таләпне парламентлар мөнбәренә күчереп, ихтыяжны канунлаштырырга кирәк. Бу җаваплы миссияне «татар киносы» дип барабан кагучы елгыр егетләр генә башкара алмый. Аларны шул заман чирләренең көчле вируслары гына «чаптыра».

Комсызлык, рухсызлык, мәрхәмәтсезлек, аяусызлык, рәхим-шәфкатьсезлек микроблары Бердәм Рәсәйнең һәр почмагына үтеп керде һәм үрчеде. Димәк, бу авырулардан дәвалану өчен «татар киносы» бер дару–витамин булуы белән дә аерылып торырга тиеш.

Даруның тәэсире бар икән–ул инде «нинди милләт?»–дип, талымланып тормый. Тик шунысы игътибарга лаек: хаста кеше, гадәттә, даруны үзенә үзе эзләп тапса, бүген, хакыйкан, дару хастаны эзли.

Илне реклама эпидемиясе томалады. «Шәп» дип, шау-шу куптарган фильмны карагач, аптырап калганда һич тә үзенне гаепләсе түгел, уңышлы сәнгать әсәре шау-шу куптармый–ул таң калдыра, сокландыра, уйга сала. Әгәр шулай түгел икән–ул сәнгать әсәре түгел, ә реклама җимеше генә.

Сәнгатьнең һәр төре аңа ихтыяж булган җирлектә туган. Дәверләр алмашыну белән сәнгатьнең роле дә үзгәрә барган. Тормыш күренешләрен тасвирлап, аны үзенчә аңлатудан тормыш-яшәешне үзгәртү коралы итеп куллана башлаганнар. Иҗат сферасына социаль заказлар вирусы иялэшкән. Бу фактны хәзер яшереп булмый һәм яшерергә тырышмыйлар да.

«Татар киносы» ул әлегә социаль заказ гына, заказны коммерция таләпләрен канәгатьләндерерлек сыйфатта гына түгел, сәнгать югарылыгында да үтәп була бит! Тәвәккәллик!

Сәнгатькә һәрчак ихтыяж бар, ул һәрчак тансык. Иммунитеты какшаган милләт организмына витамин булыр сәнгатькә мохтажлык зур.

Соңгы сүз:

Әгәр миннән: «Эшне нәрсәдән башлар идегез?» дип сорасалар, мин үзем өчен күптән хәл иткән җавапны әйтер идем: «Эшне фәнни-популяр фильмнар төшерүдән башларга кирәк».

Әйтик, беренче фильм:

«Куликово кыры тыюлыгы һәйкәле». (Тарих, чынбарлык һәм версияләр).

«Фәнни-популяр» дигән жанр аның нәфислегенә киртә түгел.

Икенче фильм: «Олуг Мөхәммәт һәм Василий Темный вәгъдәләре», өченче фильм: «Сөембикәне сатып алган коллык».

Исемлекне дәвам итү–милләтпәрвәр язучылар һәм тарихчылар эше.

Безнең эш ... сыерчык килгәнне көтү. Оясы әзер. Тик хәзер сыерчыклары да һәр ел килми. Әллә инде самолет тавышларыннан, әллә эфирдагы шау-шудан куркалар.



**Илдар МАТУРОВ,**
**Татарстан кинемотографистлар берлеге рәисе:**

–Соңгы ун еллар эчендә кино безнең күз алдыбызда диярлек байтак үзгәрешләр кичерде. Бу–аудиовизуаль технологияләр үтеп керү белән генә түгел, кинемотография эшен оештыру һәм көйләүдәге яңа формаларның, карашларның көчәюенә дә бәйле.

Татарстанда бу процессның ничек барышын мәгълүмат-матбугат чаралары азмы-күпме яктырта килде.

Бәхәссез ки, бу юнәлештә уңыш һәм казанышларыбыз юк түгел. Боларга ирешү республика җитәкчелегенең ярдәме белән мөмкин булды, билгеле. Мин моны ачыктан-ачык әйтәм.

Шуның белән бергә, бүген Татарстан кинематографистлары каршында һәм Россия, һәм чит илләр кинобазары таләпләренә җавап бирерлек зур максат–һөнәри осталыкка, саннан сыйфат дәрәҗәсенә күтәрелү бурычы куела. Шушы интеграцион омтылыштан башка без, үсештән читләшеп, тар бер кинлектә бикләнеп калыр идек.

Безгә һөнәри осталыкка ия булган кинематограф кирәкме? (Сүз әдәби-нәфис осталык турында бара.) Без һәммәбез дә бердәм җавап бирәбез: әйе, кирәк! Болай дип әйтүнең сәбәбен аңлатып торасы юк. Чөнки югары мәдәни үсеш алган бүгенге теләсә кайсы дәүләтнең заманчалык дәрәҗәсен бәяләгәндә кинематография сәнгате–югары бер күрсәткеч.

Финанслау якларын исәпләми генә дә «пәрдә» читен күтәреп карасак, кино иҗат итү бер дә гадиләрдән түгел. Сәнгать төрләреннән чагыштырмача яшь булса да (100 ел чамасы), ул–технология, тел һ.б. җәһәтеннән һаман саен үзгәрешләр кичерә килгән. Ул–күпмедер дәрәҗәдә әдәбият, сәнгать, театр, музыка дөньясының бердәм кушылмасы, синтезы. Шул ук вакытта киноның 70 проценты–технологик иҗат җимеше.

Шуна күрә, әгәр милли кинематография темасына сөйләшәбез икән, аерым фильмнарның эчтәлеге-эшчәнлегенә бәя бирү түгел, әлеге тармак һәм аның

индустриясе турында сүз алып бару сорала. Моның өчен теләк һәм интузиазм гына аз. Белгечләр фикере белән ныгытылган, төптән уйланган реаль үсеш программасы кирәк. Юкса кино эшчәнлегендә җибәрелгән хаталар бик кыйммәткә төшә.

Андый программа безнен нинди җирлектә басып торуыбызны һәм ниләр теләвебезне аермачык күрсәтер иде. Кыйммәткә төшәчәкме ул, без моны ерып чыга алачакбызмы? Бу очракта без теоретик сораулар һәм оештыру эшләренә хәйран гына җавап эзләп табар идек.

Әйтәләр: янәсе, концепция бар, павильон төзергә кирәк һәм шуның белән барысы да әйбәт булачак. Юк шул. 5-6 елдан соң без тагын тупыйкта калачакбыз. Бердән, заманча павильон салу кыйммәткә төшәчәк. Елына 3-4 картина һәм кыска метражлы фильмнар чыгарып кына юньле-башлы керемнәр алып булмаячак. Икенчедән, павильонлы булып та ныклы инфра-структура–ягъни махсус техника, урта буын белгечләр һәм башкасын әзерләми торып, төшерүче төркемне, өстәмә көчләрне туплау катлаулы булачак.

Миңа калса, федераль үзәк төбәк кинематографларын үстерүдә якыннан катнашырга тиеш. Бит Татарстан федераль казнага үзеннән бинидһая зур өлеш кертә. Димәк, ярдәмне шуннан да алырга кирәк. Ул турыдан-туры акчалата гына булмаска да мөмкин. Әйтик, безнең техника аласы да, кадрлар әзерлисе дә бар бит әле.

Вәзгыять болайрак килеп чыга. Әйтик, совет чорында елына 140 фильм прокатка чыгарыла иде. Катгый бүленеш буенча шуларның 90 дигәне РСФСРда, калган иллесе союздаш республикаларда эшләнде.

Бүген исә, төрле чыганаклар әйтүенчә, Россия картиналары елына 300 тирәсе төшерелә. Гел Мәскәүнең үзендә диярлек. Шулай итеп, Россия кинематографиясе «Садовое кольцо» чикләреннән әллә ни ерак китми. Ягъни төбәктәге мөмкинлекләрне һәм күпмиллэтле бизәкләрне күз уңыннан төшереп калдыра.

Төбәкләр исә мөстәкыйль эш итәргә мәҗбүр. Ләкин бу эшчәнлек зур һөнәри осталык белән эшләнә димәс идем. Алыйк, мәсәлән, Якутиянең «Чыңгыз хан» картинасын. Әчтәлегенә калыгып тормыйм, ахыр чиктә монысы–художникның карашларына бәйле. Фильмны төшерүгә күп көч куйган авторлар мине гафу итсен, әмма башкарылу ягы сыек чыккан. Бу–ачык сценарийның булмавына, экспромтлар белән артык мавыгуга бәйле. Актерларның уйнавы бик киренке төстә бара, мимика һәм ишара белән мавыгулар күпкә китә. Кыскасы, аны театр кешесенең куйганлыгы сизелеп тора. Ә бит, тышкы уртаклыклары күп булса да, кино белән театр арасында аерымлыклар зур. Гомумән, эпос жанры катлаулы һәм кыйммәткә төшә. Тәҗрибә җитмәс борын анардан башлау кирәк микән? Үзебездә «Болгарның җылы җилләре» белән без дә тәҗрибә ясап карадык лабаса.

Никадәр сәер тоелмасын, кинода тема һәм идеяга караганда сценарий беренчелрәк. Үзгәртебрәк әйтсәк, ул–фильмның партитурасы. Киночылар арасында шундый гыйбарә бар: «Яхшы сценарийдан начар фильм эшләп була, ә начарыннан яхшыны төшерү мөмкин түгел». Әйе, сценарий–үзенчәлекле аерым бер жанр ул. Моның өчен әдәби талант кына аз, кино төшерүнең специфик үзенчәлекләрен яхшы белү зарур. Минем драматург Туфан Миннуллинга, сценарий язуын сорап, мөрәҗәгать иткәнем булды. «Тырышып карадым. Бик үзенчәлекле эш, миннән булмый,–диде ул.–Киносценарий законнары театр драматургиясеннән нык аерыла».

Булганны сакларга кирәк безгә. Юкса бүген булган белгечләребезне дә югалтып бетерәчәкбез. Бер елда нибары 2 картина бирү бик аз әле ул.

Бүгенге кризис кино сәнгатендә чагылырмы? Әйе, чагылачак. Әмма тискәре яктан. Икенче уйласаң, кыен елларда кино һәрчак үсештә булган (Голливуд мисалын гына хәтерлик). Мөгаен, 2008 елны Россия хөкүмәте каршында ватан кинематографиясен үстерү советы төзелү юкка булмагандыр.

«Алтын мөнбәр» кинофестивале хакында аерым әйтергә кирәк. Аның колачы,

дәрәҗәсе күп нәрсә турында сөйли. Минемчә, бу биеклеккә һәм республикабыз президенты Минтимер Шәймиев һәм мәдәният министры Зилә Вәлиева ярдәме белән ирешелде.



**Наилә КАМАЛОВА,**
**«Татаркино» дәүләт оешмасының директор урынбасары, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, РФның мактаулы кинематографисты:**

–Соңгы елларда Татарстан кинематографиясе күтәрелеш кичерде дип икеләнмичә әйтергә мөмкин. Элегрәк безнекеләр документаль фильмнар белән генә билгеле иде. 2007-08 елларда, дәүләт заказы белән дистәдән артык документаль кинотасмалар төшерелгән булса, болардан тыш тагын тулы метражлы 4 уен картиналары иҗат ителде. Болар–«Дилемма» (режиссеры Р. Төхфәтуллин), «Инзинь-кура жиләк» (режиссеры С. Сивков), «Кунак» (режиссеры Р. Садриев), «Өч аяклы ат» (режиссеры Н. Җамалиева). «Бөркетләр» (Р. Төхфәтуллин) һәм «Өч аршын җир» (Ю. Фетинг). Ике фильм исә төгәлләнүгә таба бара.

Тагын әле 4 кыска метражлы кинофильмнар да иҗат ителде: «Бабай» (режиссеры А. Шакиров), «Малайлар уены» (режиссеры Р. Нәҗмиев), «Фәридә» (режиссеры С. Юзиев), «Сабакташ дуслар» (режиссеры Н. Нуриева). «Әти» (режиссеры И. Ягъфәров) дигән фильмны төшерү дәвам итә.

2008 елда эшләнгән «Камыр-батыр» (С. Литовец) һәм «Шүрәле» (Р. Төхфәтуллин) мультфильмнары тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителде.

Әйтергә кирәк, әлеге фильмнарның барысы да ике дәүләт телендә–татар һәм рус телләрендә чыгарыла башлады.

Шунысы игътибарга лаек–2007 елдан башлап дәүләт законы белән дөньяга чыккан картиналар ачык конкурс нәтиҗәләре буенча төшерелә. Бу исә кинематография өлкәсенә талантлырак әһелләрнең килүенә, булачак экран әсәрләренең әдәби-нәфис эшләнеш дәрәҗәсенә булышлык итә. Зур тәҗрибә туплаган Б. Максимов, Н. Морозов, Э. Гужиннарның эше уңыш белән бара. Урта буын вәкилләреннән Э. Габдрахманов, Б. Баишев, Р. Юзаев, С. Серова, яшьрәкләрдән А. Барыкин, П. Соколовский һәм башкаларның хезмәте дә шатландыра.

Җыйнап әйткәндә, Татарстанда киноматографияне тиешле югарылыкка күтәрерлек кино әһелләре күтәрелеп килә. Шунысы куанычлы, алар белән язучы һәм драматурглардан Ренат Харис, Туфан Миннуллин, Рафаэль Хәкимов, Айдар Хәлим, Рабит Батулла, Мансур Гыйләҗев, Наилә Ахунова актив хезмәттәшлек итәләр.

Казанда мөселман халыкара «Алтын мөнбәр» кинофестивале үткәрелү республикабызда кино эшчәнлеген үстерүдә әһәмиятле роль уйный. Әлеге кинофорумда Иран, Мисыр, Һиндстан, АКШ, Бөекбритания, Канада, Австрия, Иордания, Палестина, Төркия, Франция кебек илләрнең катнашуы үзе генә дә күпме әйтеп тора түгелмени?

Узган ел Татарстанда эшләнгән фильмнар «Алтын мөнбәр»нең барлык номинацияләрендә катнашты. «Өч аяклы ат» дигән тулы метражлы нәфис фильм фестивальнең «иң яхшы операторлык эше» призына, ә инде «Һәм дә ай ярылды» документаль тасмасы «ислам мәгърифәте эшенә керткән өлеш өчен» дигән махсус призга лаек булдылар.

Татарстан кинематографистлары иҗат иткән фильмнар «Мир» кинотеатрында тантаналы премьера белән ачылып китә. Әйтик, быелның февралендә–«Фәнис Яруллинның очышлары», «Мәмәширдән гаилә» дигән документаль тасмалар һәм «Фәридә» фильмы экранда зур уңыш белән барды. Иҗат төркемнәре,

республикабызның шәһәр һәм авылларына чыгып, тамашачылар белән якыннан очрашулар, үзләренең эшен күрсәтәләр.

Республикабыз кино җәйләнмаларында ел буена «Татарстан. Гасырлар һәм еллар» дигән тематик кинокурсәтүләр алып барыла. Әлеге сеансларны елына 50 меңнән артык кеше карый. Бу юнәлештә Балтач һәм Сарман районнары аеруча тырышлык күрсәтә.

Кинематография өлкәсендәге уңышларыбызны үстерү өчен байтак мәсьәләләрне хәл итәсе бар. Билгеле ки, фильмнар иҗат итү зур матди чыгымнар сорый. Дәүләт ярдәменә һәм химаячеләр булышлыгына мохтаҗбыз. Бу уңайдан «Өч аяклы ат» фильмын төшерүдә зур булышлык күрсәткән эшмәкәр Илһам Сафиуллинның хезмәтен аерым бер рәхмәт белән билгеләп үтәсе килә. Кулыбызда Батулла, Салават Юзиев, Роза Хөснетдинованың кызыклы сценарийлары бар. Тик шунысы кызганыч: үзләренең омтылышына мәйдан тапмаганлыктан, яхшы режиссерлар һәм операторлар Казаннан китеп барырга мәҗбүр.

Төшерү павильоны, тавыш-монтаж комплексы булдыруга да ихтыяҗыбыз зур.

Республика кинотеатрларында фильмнарны заллар экранына кадәр житкерү эше дә актуаль булып кала бирә.

Шушы барлык сораулар, аларның чишелеш юллары Татарстан Республикасында кинематография үсешенең 2015 елга кадәрге концепция программасында чагылыш таба һәм үл якын араларда мәдәният министрлыгы коллегиясендә каралачак.

Бу программаның кабул ителүе кинобыз сәнгатенә зур юллар ачар дип өметләнәбез.



**Салават ЮЗИЕВ,**
**киносценарист, режиссер:**

–Татар кинематографиясе XX һәм XXI гасырлар чигендә басып тора. Аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге хакында нәрсә әйтергә мөмкин?

Совет чорында автономияле республикаларга нәфис фильмнар эшләү хокукы бирелмәгән иде. Үен сәнгатенә бөтенләй чит булган, житдилектән ерак торган ниндидер сәер бер система яшәп ята иде. Үл да булса–юбилей киносы жанры: кайсыдыр ки истәлекле даталарга багышланган купшы, ялган, әһәмиятсез тасмалар.

Әле күптән түгел ул заманда чыккан әсәрләрнең исемлеген күздән кичергән идем. Кайберләренең аталышы ук гайрәтеңне чигерерлек. Мәсәлән, «Ит комбинаты. Күнел жылысы». Сезгә ничектер, мина калса «гениально» бу! Шунысы гаҗәп: әдәбиятыбызда тирән эз калдырган әдипләрдән Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Дәрдемәнд, Кәрим Тинчурин турында без бернинди фильмнар күрү бәхетенә ирешмәдек.

Гаделлек хакына әйтергә кирәк, сирәк булса да яхшы документаль фильмнар күренде анысы, әмма болар кагыйдәдән бер чыгарылма рәвешендәрәк иде. Сорау туа: кемгә кирәк соң мондый система? Тамашачыгамы? Әллә өстә утырган житәкчеләргәме? Бөтен хикмәк тә шунда–аларның беркемгә кирәге юк диярлек. Ләкин ул кемнәрнеңдер башында әле утыра һәм моңа каршы көрәшү кыен. Бу көрәшкә мин күп көч түгеп карадым, ләкин файдасы аз.

Үз-үземә еш кына шундый сорау куям:

Әгәр мөмкинлек бирелгән булса, XX гасыр татар кинематографиясе ничегрәк төсмерләнер иде икән? Күптән түгел мин 60-нчы елларда «Ленфильм»да эшләнгән

«Моабит дәфтәре» дигән фильмны карадым. Уртача фильм, режиссурасы да шул чама, Җәлил образы әлләни дулкынландырмый. Ләкин... Менә шушы фильмда театрыбызның атаклы артисты Рәфкать Бикчәнтәев соклангыч итеп уйный! Ул Шәфи Алмаз ролен тудыра. Аның уйнавында ирония, яшерен акыл, аристократик табигыйлек дисенме–һәммәсе бар. XX гасыр татар кинематографы менә ничегрәк булырга тиешлеге сагалап торган безне! Безнен мәдәниятыбызда кинода чагылыш табарлык энергетикабыз булган. Ләкин ул чынга ашмаган...

Бүгенге татар кинематографиясе бармы, нинди(рәк) сон ул? Тулы бер күренеш дип алсак, әлегә ул һаман да юк. Аерым хезмәтләр генә бар. Бездә бит кино традициясе, аның ныклы җирлеге юк. Киногa бездә режиссерлар башка сәнгать өлкәләреннән килә. Мәсәлән, Рамил Төхфәтуллин–театрдан, Нурания Җамалиева–телевидениедән. Мин үзем исә кино сукмагына әдәбияттан килеп кердем.

Бездә чып-чын киночы, ВГИКны тәмамлаган Илдар Ягъфәров бар. Әмма, алты ел элек «Күктау» фильмы белән дан алганнан сон, ул да әнә рекламага кереп батты. Һаман да шул система бәласедер бу. Аның кыска метражлы яңа фильм эшләвен (үз акчасына!) ишеттем дә бик сөендем. Уңышлар сиңа, Илдар, көтәбез!

Бүген Татарстанда, миңа калса, кино өлкәсендә энергетик шартлау бара һәм моны туктату мөмкин түгел. Үзләренең язмышын кино белән бәйләүчеләр арта бара. Шулай булырга тиеш тә. Алар бер-берсеннән осталыкка өйрәнәләр, яхшы мәгънәсендә көнләшеп ярышалар. Яхшы вәзгыять, иҗади казанышлар әнә шулай туа.

Соңгы елларда миңа төрле фестивальләрнең төрле конкурсларында катнашырга туры килде. Безнең «Инновация» дигән иҗат командасы Россия студияләреннән бер дә ким эшләнмәвен күрсәтә алды. Әйтик, «Алтын бубен» фестивалендә без Тукай турындагы «121» дигән фильм белән катнаштык. Татар телендә бара. Гаҗәп бит: бу фильм Мәскәү, Петербург һәм Екатеринбургның танылган режиссер-классикларын да уздырып, берничә номинациядә җиңеп чыкты. Туфан Миңнуллин турындагы татарча документаль фильм да танылу тапты.

Бу нәрсә аңлата? Димәк, безгә урынчылыктан, шәхси коткылардан арынырга, үз дәрәҗәбезне белергә вакыт. Иҗади омтылышларыбыз зурдан булсын, максатчан булсын. Без моңа ирешергә тиешбез. Без дә булдырабыз икән бит дип уйладым шул чакта.

Әгәр Татарстандагы бүгенге киноны, аның язмышын күз алдына китерсәк, без таш дивар каршында басып торабыз кебек. Без аны терсәкләребез, аяк-кулларыбыз ярдәмендә ватарга тырышабыз бугай. Без бу диварны җиңеп чыгарбыз дип уйлыйм, чөнки, көрәшә торгач, мускулларыбыз ныгый гына бара.

Ә безгә кем булышыр икән соң? Андыйлар табылыр дип уйлыйм. Безнең арсеналда ломнар, электр инструментлары, ахыр чиктә хөкүмәт дигән иң куәтле «бульдозер» да табылыр, иншалла.

XXI гасырда Татарстан киносы ничек булыр? Булырмы ул? Мин оптимист кеше, булыр дип ышанам. Хәзер санлы-цифрлы технологияләр заманы, кино эшчәнлегенә мәйданнар ачык. Кино элита өлкәсе булудан туктады. Хәзер һәркем, видиокамера белән коралланып, кинотасмалар төшерә ала. Язучы хезмәтенең хикмәте шунда, кулында каләм яисә авторучка булса да, һәркем хикәя яисә роман яза алмый. Шуның шикелле, талантлы режиссерлар кирәк булачак. Безгә алмашка яңа буын килер, алар бездән талантлырак булачак. Алар совет чорындагы кинематографистларда йөз тапкыр ирекле һәм азат. Алар өчен юбилейлар, система һәм тыюлар юк диярлек. Чын һәм сәнгати киноны менә алар төшерәчәк...

*Материалларны*
**Рашат НИЗАМИ** *әзерләде.*

# ӨЧЕНЧЕ ХАКЫЙКАТЬ

*Шигърият, син көчлеләргә ялчы түгел,*
*Кимсетелгән хакыйкатьне яклаучы син.*
*Кодрәт тоткан бозыкларга камчы түгел,*
*Рәнҗегәнне күкрәк белән яклаучы син.*
Гамил Афзал

Әдәбият белемендә лириканы тематик яктан биш төркемгә бүлеп карау күзәтелә. Бер төркемгә гражданлык лирикасы дип аталган шигырьләр туплана. Гражданлык лирикасы дип аталган бу шартлы бүленеш ил-көн гаме, милләт, халык, кеше ваемы турында язу, шуларны йөрәккә якын алып җырлау дигән сүз инде ул. Аңа эчке бер яну, фикер-кичерешләр кайнарлыгы, мөнәсәбәтләр аныклыгы хас. Шуңа күрә гражданлык лирикасында иҗтимагый яңгыраш көчлерәк була. Ә бу, үз чиратында, шагыйрьләрнең милли-мәдәни карашлары, яшәеш, язмыш хакында уйлануларын туплап, шигърияттә хакыйкать эзләүне көчәйтә.

Бу уңайдан татар шагыйрьләре шәхес һәм заман мөнәсәбәтләренә кагылышлы күп төрле проблемаларга игътибар итәләр. Әлеге проблемаларның 90 еллар башында нигездә милли кысаларда булуы, ә XXI гасыр башында исә ил күләмендә хәл итүне сорый торган дәрәҗәгә күтәрелүе күзәтелә. Татар халкынын милли мәсьәләләре һич тә кимеми, ләкин башкачарак юнәлеш ала. Шагыйрьләрнең милли зыялы кешегә таләпләрне арттыра баруы, тел проблемаларын һичшиксез хәл кылырга чакыруы, татар әдәбиятын дөньякүләм даирәдә күрсәтергә вакыт җитүен аңлатырга тырышуы чын гражданлык позициясе дип кабул ителә. Татар шигърияте шул проблемаларны куя, сәбәпләрен эзли, өлешчә чишү юлларын күрсәтә.

Ә менә чынбарлыкның реаль күренешләре, аларны шагыйрьнең шигырьдә сәнгатьле алымнар белән образлы чагылдыруы һәм, ниһаять, әсәрне укучының боларны үзенә генә хас дәрәҗәдә кабул итүе тормыш—язучы—әсәр—укучы арасында ныклы бәйләнеш булдыра. Хәзерге шигърият бер үк вакытта сөйләүченеке дә, тыңлаучыныкы да булып кабул ителә, дигән нәтиҗә әдәбият белемендә «өченче хакыйкать» буларак карала.

Күпләр билгеләп үткәнчә, шагыйрь Зиннур Мансуров кабул итү өчен катлаулы акыл эшчәнлеге сорала торган әдәби әсәрләр язуы белән үзенчәлекле. Заман шигыренә аның үз бәясе болай яңгырый: «Шигърият сәнгатьнең иң мәһабәт төре булып саналса да, шигырь кешеләргә ләззәт бирер өчен генә язылмый. Бигрәк тә татарда. Юк, шигърияттә «тормыш елмаюы» гына чагыла алмый, чөнки яшәешебез сөенечле мизгелләрдән генә тормаган. Халыкның уй-гамен аһәңле сүз белән аңлатып биргән бердәнбер сәнгать төре буларак, назым инде күптән татарның туктаусыз сызланучы җан авазын яңгырату чарасына әверелгән».

Һәр татар шагыйре иҗатында милли тема теге яки бу яктан чагылмыйча калмый. Кайсының иҗатында милли бәйсезлеккә чакыру, кайсысында милли горурлык, кайсында милли гореф-гадәт аша тәрбияләү, кайсысында гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләре, кайсында милли тарихка мөрәҗәгать итү бар. Ә менә З.Мансуров шигъриятенең төп үзенчәлеген милли яңгырашның тәнкыйди характерда булуы, сатирик юнәлеше, интеллектуаль укучыга юнәлтелүе, шәрык терминнарының еш кулланылуы тәшкил итә.

Заман шагыйрьләре иҗатында татарның танылган бөек шәхесләренә дәүләтчел карашның җитенкерәмәве хакында багышлама жанрына караган әсәрләр еш

күзәтелә. Бөек шәхесләрнең фаҗигасен күрсәткән әсәрләр дә аз түгел, З.Мансуров иҗатында да бар алар. Әмма ул әлеге мәсьәләне кинәйтеп җибәрүгә ирешә. Бөек шәхесләрнең үзләренә дә җаваплылык хисе «өсти». Шәхес трагизмын дәүләт һәм житәкчелек өстенә генә «өеп калдырмый», бәлки фаҗиганең башлангыч этабын шәхеснең үзендә күреп, трагизмга китергән сәбәпләрнең өстәлә баруын сәнгатьчә күз алдына китереп бастыра.

Шунысы үзенчәлекле, З.Мансуровның сюжетлы шигырьләре эстетик алымнар күплеге белән аерылып тора. Аларда шигъри янгыраш көчле, образлылык югары дәрәҗәдә куела, укучы, эстетик ләззәт тою белән бергә, шактый мәгълүмат алырга да өлгерә. Шуңа карамастан, аның шигырьләрендә публицистика бөтенләй сизелми. Мисал өчен шагыйрь иҗатындагы Сәйдәш образына мөрәҗәгать итик. «Соңгы сәхнәгә бару» әсәренә эпиграф итеп «1954 ел, май ае» дип куелган. Шигырьдә композиторның мәдәният һәм ял паркына соңгы тапкыр чыгыш ясарга баруы күренеше сурәтләнә. Сәйдәшне соңгы сәхнәсенә—Арча кырына үзләре үк аны «чагып» гомер иткән кешеләр алып бара. Гади кешеләр бөек композиторга теләктәшлеген белдерә: «Исемлесе, исәр, исереге / исәнләшеп китә көр генә»,—дип яза шагыйрь. Тик шагыйрь бу очракта гади халыктагы әлеге эчкерсез мәхәббәтнең Сәйдәш үлемен якынайтуга китерүен күрсәтергә алына. «Кочаклашкан саен, кәчтүменең / инбашында аз-маз тап кала», дигән юллар рефрен булып, берничә тапкыр кабатланып килә. Моның өстенә автор фаҗигагә китергән сәбәпләрне градация формасында да үстерә бара: «Фаразлыймын: ап-ак фәрештәнең / канатына кемдер... кул сөртә». Монысы инде гади халык мәхәббәтен түгел, бәлки шул заман сәясәтенә ишарә итә. Әсәрдә автор Сәйдәшне фәрештәгә генә тиңләп калмый, бәлки «пычранмаган соңгы пәйгамбәргә» үк әйләндерә. Шигырьдә композитор образы ике төрле белдерелә. Беренчесе—«бәгырь» төшенчәсенә «сыеп беткән» Сәйдәш үзе, икенчесе—татарның самимилек сыйфаты, «сөя-сөя халык сөеклесен каралтуы».

Композитор С.Сәйдәшев темасын шагыйрь «Сәйдәш ялгызы» балладасында дәвам итә. Табигатьтә пәри туе, «фәрештәләр фанфарага биегән» шартлы алым аша шомлы буран күренеше сурәтләнә. «Хәйям сые» куелган йортта олуг кунак бар. Кунак борчыла, аның күңеле тыныч түгел. Буран эченнән ул К.Тинчурин тавышын ишеткән кебек була... Шомлы табигать күренеше аша шагыйрь илдәге сәясәт китереп чыгарган ыгы-зыгыны күрсәтә. Шулай итеп, З.Мансуров кыска гына шигырендә Сәйдәшне фаҗигагә илткән шәхси һәм сәяси сәбәпләрне күрсәтүгә ирешә. Көчле ирония белән язылган әлеге шигырь, әзерлекле укучыга юлланып, бик тыгыз, төгәл, үтемле фикере белән аерылып тора: «Ап-ак кардан Сәйдәш бара төсле,/ тартып бара кара роялен...» ,—дип тәмамлана ул. Шулай итеп, сурәтләү капма-каршылыкны бер фокуска туплауга юнәлтелә.

Шагыйрьнең икенче бер төркем шигырьләре милләтнең милли горурлык сыйфатларын сурәтли. З.Мансуров, XIX гасыр татар—башкорт—казах шагыйре Акмулланың яшәү—эшләү—сәяхәт итү вазифаларын үтәгән өч бүлемле арбасына ишарә итеп, «Екатерина II каретасы» исемле шигырен яза. Шигырьдә Әби патша каретасын музей экспонаты итеп карау турында сүз бара. Автор, татар кешесенең балалар сабыны белән падишаһ арбасын юганын күргән саен, сагаеп, сискәнеп кала. Шуңа күрә ачынып сорый да: «Мәскәүнең яулыклы патшасы / ул нинди кадерле тутаң соң?» Шагыйрь татар халкының милли сыйфатларын искә төшерә. Патша арбасын юу аңа тәлинкә тоту, чит халык каршында йөз суын түгү буларак кабул ителә. Эшсөяр татарның басымчак, юаш сыйфатларын санап, автор, шигырьгә сәяси һәм милли тарих төсмерләрен өстәп, шигырен болай йомгаклый: «Болытлар өстендә кангырып / йөрәдер Акмуллам арбасы...»

Мөһаҗирлек темасы да шагыйрь өчен чит түгел. Шул исемдәге шигырендә шагыйрь читтә үлгәннәрнең җәсәден туган илләренә кайтару мәсьәләсен күтәрә. Әлеге фикер шигъри формада нәкъ менә З.Мансуров иҗатында беренче тапкыр урын ала. Шагыйрь чит җирдә калганнарның драматизмын да күрсәтә алган. «Ил чирәмен кочып елар идек, / ак күлмәкләр яшел булганчы!»- юллары, дөрестән дә, мөһаҗирнең җан ачысын күрсәтә алырлык дәрәҗәдә көчле килеп чыккан.

*Ватандагы гүр дә яктырактыр...*
*Чит туфракта ничек каласың?*
*Үги итмәс микән туган илкәй*
*кабер сорап кайткан баласын?!*

Татар халкынын бөтенлеген саклау темасы шагыйрь иҗатында шактый зур урын били. З.Мансуровнын «Ай кызына төбәлгән уй» исемле шигыре халык санын алу вакыйгасы унае белән язылган. Шагыйрь XX гасыр ахырында халык санын алу вакытында татар халкын җиде төркемгә бүлеп санауның татар милләте сафын шактый киметеп күрсәтүгә китерүенә ачына. Дөрес, шигырьдә хөкүмәт сәясәтен тәнкыйтьләү юк, әмма халыкның үзенә, аның «милли тарлык» сыйфатларына дәгъва зур. Татар милләтенә бердәмлек житми, хәтта бер гаилә эчендә дә үзара дошманлашу күзәтелә, дип нәтиҗә ясый шагыйрь. Шул рәвешле, татарның төрле кыйблаларында Сак-Соклары сагынып саргая, матур кызлары Айга сөрелә.

Шигырь бик тәэсирле язылган. Ижтимагый-милли күренештән соң шагыйрь тарихка барып чыга. Шул рәвешле, Мәскәүгә сөрелгән Сөембикә, аның чукындырылган улына, Болгар тарихыннан соң интернациональ никахларга барып җитәлә. Шагыйрь шундый шартлы алым куллана: сан алу кампаниясе вакытында татар халкы санын түгәрәкләп күрсәтер өчен бер кеше житми. Шулвакыт лирик «мин» Айдагы татар кызын искә төшерә, тик тегесенең «мәэюсләнгән күзен мөлдерәткән чал кавем»гә исе китми. Шул рәвешле З.Мансуровның «Ай кызына төбәлгән уй» шигырендә бер милләт эчендәге каршылыклар урын ала.

Шагыйрьнең бер төркем шигырьләрендә гаилә, көнкүреш мәсьәләләре күтәрелә. Бу очракта шагыйрь, «икенчел миф» дип аталган әдәби алым кулланып, чынбарлык күренешен тудыра. Су анасы турындагы миф шагыйрь иҗатында җәмгыять ихтыяҗын үти башлый. Шулай итеп, икенчел мифологиянең тематикасы кинәя, конкрет тормыш чынбарлыгына мөрәҗәгать итү барлыкка килә. Әлеге шигырь «Ятим Су анасы» дип атала.

*Күпме күлләр кибеп, корып,*
*болытларга сый булган.*
*Сусыз калган Су анасы*
*кая барып сыенган?*
*Күлнең ләмле чокырында*
*мыжгып тора корт кына.*
*Су анасы китеп барган,*
*ахры, картлар йортына.*

Биредә мифик образ булган Су анасы аталар һәм балалар проблемасын кую максатында кулланылган. Җәмгыятьтә балаларның, ярдәмчесез калган ата-аналарын карамас өчен, картлар йортларына илтеп тапшыру фактларын шагыйрь, «тәрбияләмичә генә», иронияләштерүгә ирешә.

Әлбәттә, З.Мансуров иҗатының зур күпчелеген фәлсәфи шигырьләр тәшкил итә. Әмма шагыйрьнең фәлсәфәсе гади түгел, алдан хәзерлекне көтә. Мәсәлән, «Көтүчесез авылда» ~~авылда~~ исемле шигырьне алыйк. Тарихтан Антик поэзиянең пастораль жанры авыл көтүчеләре, игенчеләре, балыкчылары турында язылган әсәрләрне тәшкил итүе мәгълүм. Әлеге шигъриятнең иң күренекле вәкиле булып борынгы грек шагыйре Феокрит саналган. З.Мансуровның шигыренә дә килеп керә ул. Шагыйрь биредә чын көтүченең дефицитка әйләнүе турында яза: «Сорап тормый чират: бармы теләк-дәртен- / авыл көтүчесе булып ала һәркем»... Әлеге проблеманы шагыйрь фәлсәфи планда чишә. Социаль статусы нинди булуга да карамастан, ягъни «хаким-башлык хатыны да, япга кайткан профессор да» бер көн көтүче булып ала. Көтү көткәндә вакыт бик озак уза, әмма «Дөрес яшисеңме?» дип уйланырга мөмкинлек туа. Шулай итеп, заман кешесенә елга бер тапкыр «Феокрит булып алу» файдага гына булып чыга.

Шагыйрь иҗатында нәзакәтле сатира да күзәтелә. Әлеге алым шагыйрьнең шагыйрьдән көлүе барышында күзәтелә. Татарда шагыйрьнең шагыйрьдән көлүе Тукайлардан ук килә. Дөрес, әлеге «Аллаһ бүләге» исемле шигырьдә «кычкырып торган» сатира юк. Шагыйрь, гомумиләштереп, аерым бер төркем гадәтләренең җәмгыятьтә киң таралган күренешкә әйләнүен генә тасвирлый.

*Ә мин... әчтән генә әйтәм шуны:*
*«Баскын дуслар»ымнан ваз кичәм;*
*дөньяныкын талап алуларда*
*түгел бугай минем вазифам...*

Биредә шагыйрь азга гына балачагына кайтып килә дә кинәт кенә бүгенгегә күчә. Заман кешесенең һәр иясез яткан әйберне үзенеке итәргә тырышуын тәнкыйтьләп, шагыйрь фикерен уйлану катыш ирония аша белдерә:

*Яшеллеккә сусар яшьтәшләрем*
*печән йолкып кала һәр йөктән.*

Заман шагыйрьләрен милли тарих мәсьәләсе гел борчып тора. З.Мансуров та моны читләтеп үтми. Аның «Илбакча һәм колонист» исемле шигыре кырым татарлары фаҗигасен яңарта. Биредә шагыйрь сәясәт китереп чыгарган милли әхлак проблемасын «табигать»кә «төреп бирүе» белән үзенчәлекле. Шуның өстенә ул табигать белән яулап алучы арасындагы каршылыкны шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтендә күрсәтүгә дә ирешә. Татар җирләренә килеп утырган чит халыкның бакчасында җимеш үсми, «колонист» төп сәбәпне туфрак составыннан эзли.

*Хуҗа булып алган, ә үзенең*
*агачларга, сизәм җаны ят.*
*—Туфрак кына ачы...*
*(Нишләтәсең—*
*өлешеңә тигән ганимәт).*

Шагыйрь З.Мансуров иҗатында аерылып торган тагын бер зур үзенчәлек—ул да булса мифология белән бәйләнеш. Соңгы елларда тормышыбызны сихер, магия, төрле юраулар, йолдызнамәләргә мөрәҗәгать итүләр басып алды. Билгеле, моның сәбәбе илдәге тотрыксызлык икәнен күпләр аңлый. Шуңа карамастан, кеше бөтенләй үк ышанып бетмәсә дә, төрле юрауларга колак сала. Киләчәкне алдан әйтүче, киләчәк турында алдан хәбәр бирүче затларга өмет белән ышанып карау гомумән кешегә хас сыйфатлардан санала. Бүген кеше тәгәл генә үзен иртәгәсе көндә нәрсә көткәнен дә әйтә алмый торган заманда яши. Аның мәшәкатьләрен (проблемаларын) дәүләт тә, эш бирүче дә, күршесе дә, туганы да аңлап бетерә алмый. Шулчак кеше яклауны мифлардан эзли башлый. Әлеге проблемалар әдәбиятка да үтеп керә бара. Һәртөрле үзгәрешләргә иң сизгер кешеләр булып шагыйрьләр санала. Шагыйрьлек—ул үзе үк илаһи талант. Һәр шагыйрь кеше тормышында яки җәмгыятьтә нинди хәлләр буласын ничек тә булса алдан хәбәр итәргә, алдан күрергә тырыша. Әлеге сыйфатларга дини карашлар буенча Алла ихтыярын кешеләргә алдан хәбәр итүче, төшендерүче изге затлар, яки пәйгамбәрләр генә ия була. Күрәсең, нәкъ менә шул сәбәпләр шагыйрьләрнең күпләп мифологик образларга мөрәҗәгать итүенә китерәдер дә. Мифологик образлар дигәндә, еш кына Пәйгамбәр яки Фәрештә образлары күз алдында тотыла, әмма хәзерге шигърият Газраил, Иблис образларына да кытлык кичерми.

Пәйгамбәрләр—Аллаһ тарафыннан сайлап алынган кешеләр. Кеше, күпме генә тырышмасын, үз теләге белән генә пәйгамбәр була алмый... Пәйгамбәрләргә хас төп биш төрле сыйфат атала: а) дөреслек һәм үз сүзенә тугрылык; б) ышанычлылык; в) интеллектуальлек; г) гөнаһсызлык; д) белемнәрен башкаларга тарата белү, педагогик сәләт. Пәйгамбәрләр дини шәхес буларак халык аңында гаять зур урын алып торганнар, аларга хөрмәт-ихтирам зур, алар, гадәти кешедән аермалы рәвештә, могҗизаларга

ия булганнар. Тарихи шәхес буларак та алар милләт, дәүләт тарихларына зур өлеш керткәннәр, халыкны әйдәп баручылар, башлыклар, патшалар (Давыд патша, Сөләйман патша), вазифасын үтәгәннәр, шулай ук оппозицион көчләрне тәшкил иткәннәр.

Пәйгамбәр образы З.Мансуровның «Хозыр галәйһис-сәламне эзләү» поэмасында киң чагылыш таба. Әсәрдә Хозыр пәйгамбәр аеруча ачык, күпкырлы һәм тулы образ итеп бирелгән. Поэма, Борынгы шәрык әдәбияты традицияләренә ияреп, баблардан төзелгән. Прологта сүз Хозыр галәйһис-сәламнең югалуы, лирик персонажның аны эзләп, юлга чыгуы турында бара.

Эзләү процессы белән параллель рәвештә автор, Хозыр пәйгамбәргә төрле битлекләр кидереп, ахырда аның чын йөзен ачыклауга алына. З.Мансуров, аңа төрле иҗтимагый статуслар бирә, күптөрле рольләргә кертә, укучыны сискәндереп җибәрә торган, татар шигъриятендә монарчы күренмәгән әр-яна эпитетлар аша сыйфатлый. Поэмада Хозыр бабабыз дигән образ, «изге көтүче»гә әйләнеп, кыяфәтен үзгәрткән пәйгамбәр дә булып ала; ярлы-ябагай хәленә дә кала; Кол Галине күргән карт сыйфатын да ала; бәлаләргә тарган балаларны бихисап күп тапкыр ак юлга чыгарыша; мәңгелеккә барыр мосафир һәм үлми яши торган изге җан булып күзаллана; фани дөнья адәмнәренә җибәрелгән илче буларак кабул ителә; япон шпионы дип, төрмәгә дә ябыла; яхшылыкны яклаганы өчен «сары йорт»та да башы «череп» ала; пенсиясез калган пәйгамбәр буларак, картлар йортына илтеп тыгыла; шул рәвешле Ай кызының кешеләрдән бизгән күнелдәшенә әйләнә; аңа партбилетлы «пәхтә» пәйгамбәр титулы да насыйп була; Намус сурәтендә сөргендә пәйда булырга да язган булып чыга; ахырдан Хозыр галәйһис-сәламгә Кар кешесе кыяфәтендә кешеләр янына барып чыгу да елмая. Күренгәнчә, биредә ниндидер мифик зат язмышындагы үзгәрешләр түгел, ә конкрет зыялы шәхес тормышы күзаллана. Шул рәвешле, З.Мансуров шартлы алым аша мифологик юл белән ил тарихын торгызуга ирешә. Шул рәвешле, мифологик материал «өченче хакыйкать»кә әверелә бара. Автор Хозыр галәйһис-сәламне традицион рәвештә, кешелек аңында инде кабул ителгән, сакланып калган формада күрсәтергә тырыша. Ләкин шул ук вакытта колакка ят яңгыраган, укучы гадәтләнмәгән сыйфатламалар да уйлап чыгара.

*Кермәгәне өчен колхозына,*
*Тиңләштереп корткыч кулакка,*
*Хозырыңны Совет хөкүмәте*
*Әллә сөрде микән ГУЛАГка?!—*

дигән юлларда автор Хозырны эзләү хәйләсе белән илдә барган сәясәтне дә тәнкыйтьләп ала, моннан соңгы строфаларда ул асыл затларыбызның «сары йорт»та, Черекkүлдә черетелүе турында да искә төшерә, яки икенче бер мисалда инде автор тәнкыйтьне киная белән генә әйтеп калмый, турыдан-туры гаепләү карары да чыгара:

*Япкаңнардыр, бәлки, японнарның*
*шпионы, диеп, бу мәҗик?!*
*«Империя зла» исеменә*
*юкка гына лаек булмадык...*

Тарихи фактларга хәзерге көн күзлегеннән карау белән бергә, шагыйрь илдә бүгенге көндә барган вәзгыятьне дә күз уңыннан ычкындырмый, контрастны арттырып, гаять үтемле итеп тасвирлый:

*Пенсиясез калган пәйгамбәрне*
*тыктылармы картлар йортына?!*

Шулай итеп, борынгыдан килгән пәйгамбәрне хәзерге көндә эзләп табу өчен автор төрле фаразлар, гипотезалар кора. Бу нисбәттән пәйгамбәр образы бирелешенең вакыт һәм пространство хронотобы да мөһим. Автор Хозырны төрле вакыт һәм урын чикләренә урнаштырып карый, халык авыз иҗаты мисалы булган мажаралы әкиятләрдән килгән традиция буенча, ул аны дөньяның төрле почмакларыннан эзли.

*Иләсләрне изге әләмәнгә*
*әйләндерми изге каш кына...*
*... Парламенттан сорыйм пәйгамбәрне:*
*«Килеп чыкмадымы каршыңа?»*

Шагыйрьнең «изге каш» ымына игътибар итик. Әсәрдән укучы, әдәбият белемендә синекдоха дип аталган троп аша, гәрчә поэмада бу турыда бер сүз булмаса да, озак еллар идарә иткән Л.Брежневны танып ала. Ә менә китерелгән мисалның ахыргы ике юлы соңгы еллар сәясәтенә ишарә ясый. Пәйгамбәр һәм парламент ассоциатив чылбыры поэманың гомуми хиссиятен һәм Хозырны эзләү процессының фокуслылыгын тагын да арттыра төшә. Шул рәвешле, З.Мансуров, Хозыр галәйһис-сәлам образын төрле иҗтимагый рольләргә кертеп, төрле вакыт һәм пространство чикләренә урнаштырып, ана җыелма образ буларак характеристика бирергә омтыла, билгеле бер дәрәҗәдә аны типиклаштыра, аның төрле сыйфатларыннан мозаика төзи. Әмма шуны да онытмаска кирәк, бу сыйфатлар әсәрдә ике функцияне үтәү максатында кулланыла: беренчесе, Хозыр образын ачып бирү булса, икенчесе—илдәге иҗтимагый, сәяси мәсьәләләрне киная, читләтеп әйтү рәвешендә күрсәтү, аларга автор мөнәсәбәтен белдерү.

Әсәрнең композициясенә килсәк, беренче бабта сүз беренче карашка болыннар, чәчәкләр турында барган кебек тоела, ләкин чәчәкләр арасында лирик геройның Хозырны эзләве, ә чәчәкләрдә кеше сыннарын күрүе беленә.

*Гөлстанда нинди генә*
*хәшәрәтләр яшәми!..*
*Чәчәкашар чирүенә*
*чәчәк ни дә, чәчән ни.*
*Ашамасмы яэҗүҗ-мәэҗүҗ,*
*хуҗаларча хуш күргәч,*
*милләтләрең мәңге-мәңге*
*«чәчәк атып» утыргач?!*

Күргәнебезчә, З.Мансуров чәчәкләр бакчасы детален ил сурәтен төзү максатында куллана, басып алучы кавемнәрне «чәчәкашар чиру» дип атый. Әлеге образлы сурәт, укучы аңында абстракт картина тудыруга ярдәм итү белән беррәттән, күтәрелгән мәсьәләләрнең үтемле һәм онытылмаслык итеп янгыравына китерә. Мисалга алынган юлларда исә «пәйгамбәр—дәрвиш—чәчән—чәчәк» ассоциатив чылбыры төзелә. Автор фикеренчә, ул үзе дә карачкыдай кешеләр, кяферләр күренсә, күңеленә кер кунса, иргәҗел кыяфәтен үзгәртеп, гөлгә әверелә. Шулай итеп, чылбыр компонентларының барысына да уңай сыйфатлар: аклык, сафлык, мәңгелек мәгънә, хикмәт йөртүче булу хас булуы күренә.

Поэманың өченче бабы аеруча тәэсирле язылган. Аның сюжетына З.Мансуров Хозыр картның колхоз үгезен кыйнавы турындагы шартлылыкка нигезләнгән кыйссаны сала, аны контр көтүче, «коммунистик нәсел калдырасы үгез»не үтерүче дип, гаепләү процессын фараз итә, бәлки, Хозырның кешеләрдән китүе, читләшүенең сәбәбе нәкъ менә шундадыр, дигән фикерен әйтә. Әлбәттә, бу баб фәлсәфи юнәлеше белән аерылып тора; автор иман белән имансызлык көрәше, иманның имгәтелүе турында фикер йөртә, пәйгамбәр исә шул имгәтелгән иманның сынландырылуы булып карала. Һичшиксез, бу катлаулы схемалы бабта символлар да бик көчле. Иман һәм имансызлык төшенчәләре дигәндә, иҗтимагый күренешләрне, ягъни кеше һәм аны шәхес буларак рәнҗетүче дәүләт системасы, милләт һәм аны кысрыклаучы империяне дә күз алдында тотарга мөмкин. Бу аспекттан чыгып караганда, пәйгамбәр образы гуманлылык, кешелеклелекне гәүдәләндерә, ләкин автор пәйгамбәрнең дә, аның белән бергә кешелеклелекнең дә кешеләрдән китүе, читләшүе турындагы пессимистик нәтиҗәгә килүе белән үзенчәлекле.

Башка бабларда да алда әйтелгән фикерләр исбатлана, ныгый гына бара: шагыйрь «имансызлык коммунасы», катилләр, Явыз Иванның Казанны казаматка әйләндерүе, колонистлар турында нәфрәтләнеп яза; пәйгамбәрләрдән ваз кичсәк, аларны да

корбан итсәк, хәтта Өммелхәер (Шәфәгать анасы) дә бездән баш тартыр, йөз чөерер, дигән фараз бирә. Хозыр вакыйгаларда актив катнашучы булып сурәтләнә. Ул сүзен аталарча, бабаларча самимилек, җылылык белән әйтә, әмма сүзне бик кыска тота, шуның белән Хозыр кешеләрдән ахыр чиктә барыбер китүен һәм кире кайтмаячагын кисәткәндәй була. Пәйгамбәрнең китүенә, инде бүтән бер дә әйләнеп кайтмаслык итеп китүенә дәлил булып поэманың эпилогы килә. Аның хәтта «нәтиҗәсез эзләү соңында» дип аталуы да инде укыганчы ук хәлләргә ачыклык кертә шикелле. Лирик персонаж үз алдына шомлы сорау куя: «Кыяматтә генә күрешергә / язган мәллә безгә, пәйгамбәр?!» Ләкин соңрак үзе үк Хозырның ни өчен китүен аңлатып бирә: «Тупсалардан сөрдек теләнчене, сөмсез сүзебезне йөз әйтеп». Автор эзләнүләреннән соң шундый аяныч нәтиҗәгә килә: ятим кызны Айга озатучылар да, алыпларны кара кабергә егучылар да, Таһир белән Зөһрәне суга ташлаучылар да, Йосыфны тирән коега атучылар да, Хозыр Ильясны куучылар да—без үзебез, кешеләр:

*Алыпларны, Аллам, алыпларны*
*кара кабергәчә кем ега?*
*Йомыкыйлар изге Йосыфыңны*
*көн дә ыргыталар коега.*
*Зобанилык Таһир—Зөһрәләрне*
*Тора һаман суга ташлатып.*
*Күңелләрдән көн дә куалыйбыз*
*Хозырильяслыкны... таш атып.*

Әмма Хозыр-Ильясны кууда гына түгел икән хикмәт, автор кешеләрне күңелләреннән хозырильяслыкны куу турында, ягъни үз иманыңнан йөз чөерү турында искәртә. Кешедә бүгенге көндә Хозыр пәйгамбәрне терелтергә, табарга дигән омтылыш түгел, ә аңа ясин чыгарга, ягъни җирдәге соңгы пакьлек, сафлык утравын да тәмам бетерергә дигән фикер-ният яши, дигән нәтиҗә ясала.

Поэма шундый тетрәндергеч сүзләр белән тәмамлана. Күрүебезчә, әсәр пәйгамбәр образын гәүдәләндерүгә генә түгел, ә пәйгамбәрлек һәм кешелек төшенчәләрен тормыштагы яшәеш закончалыкларына бәйләп бәян итүгә багышлана.

Поэмада шагыйрь кулланган алымнарның сатира тудыру эффектын аерым карау дөрес булыр. Беренчедән, төп геройның үзенчәлекле портретына игътибар итик. Поэманың башында пәйгамбәрнең портреты традицион сурәтләүләрдән аерылмый. Шагыйрь тора-бара бу образга заман сурәтләрен өсти башлый. Шулай да образның халык мәнфәгатьләрен кайгырту вазифасы кимеми, киресенчә, мәгърифәтчеләргә хас булганча, арта гына бара. Икенче төрле әйткәндә, «таш атканга аш ата» булып чыга. Дөрес, поэмада пәйгамбәрнең вазифасы лирик персонажның фантазиясе аша гына чагылдырыла, әсәрдә образ үзе күренми. Шагыйрьнең бу алымы үзен аклый, чөнки легендаларда да Хозыр Ильяс яхшылыкны ничек, ни рәвешле эшләгәнен кешегә күрсәтмәгән бит.

Икенчедән, геройның эш-гамәлләре аерым игътибарга лаек. Шагыйрьнең уйдырмасы буйлап барганда, түбәндәге хәлләр ачыла. Хозыр, кыяфәтен үзгәртеп, Президент сараена барып керергә мөмкин. Илбашына мөрәҗәгать итәргә аны татар зыялыларының мохтаҗлыгы мәҗбүрләмәдеме икән, дип фаразлый автор. Бу очракта геройның портреты белән эш-гамәлләре бераз каршылыкка да кереп ала. Көтүче кыяфәтле кешенең Президент сараена барып керә алу факты үзе үк гадәти күренеш түгел бит. Шуңа күрә әлеге факт гротеск дәрәҗәсендә күпертелгән дигән тәэсир кала.

Өченчедән, хакимият сәясәтен сурәтләү үзе дә игътибарга лаек. Поэма эчтәлеге барышында шагыйрьнең фараз итүе колхозлашу, репрессия, торгынлык елларына барып тоташа. Колхозга кермәгән өчен корткыч кулакка тиңләп, ГУЛАГка сөрү; япон шпионы дип төрмәгә ябылу; артык акыллы булганы өчен, «сары йорт»та башын черетү; ахыр чиктә әлеге «пенсиясез пәйгамбәр»не картлар йортына илтеп урнаштыру фаразлары градация рәвешендә көчәйтелеп бирелә. Автор күрсәтелгән урыннарның һәрберсеннән (аларны шагыйрь «җәһәннәмле җир» дип атый) Хозырны эзли, әмма таба алмый. Ахырдан ачынып Ай кызыннан сорарга мәҗбүр була:

*Күрәсеңдер, күркем, күрәсеңдер,*
*янындарак торгач Алланың.*
*Кешелекнең кысан күңеленә*
*син үзең дә сыя алмадың.*

Ай кызына «җиткәч», шагыйрьнең сәяси сатирасы тагын гротеск дәрәҗәсенә кадәр үстерелә, Җирдәге имансызлыкның дәрәҗәсен күрсәтү өчен «Ай кызын тотып көчләү» сурәтен файдалана. Алга таба шигъри сурәтләр тагын да көчәя төшә. Авторның сатира угы партия номенклатурасына юнәлтелә:

*Партбилетлы «пөхтә пәйгамбәрләр»*
*бик күп бездә, бәгърем, буталма.*
*Парламент та сорауга җавап бирә алмый:*
*Юлбарыстай халык югалганны...*
*Кемне генә борчыр бу маза?*

Шигырь юлларындагы «юлбарыстай халык» метафорасына Кырым татарлары язмышы яшеренгән дип уйларга мөмкин. Шигъри фараз алга таба Хозырны БМОдан эзләтүгә барып тоташа, ә аннары пәйгамбәрнең Кар кешесе кыяфәтендә йөрү ихтималы барлыгы беленә. Шулай итеп, мифик зат Хозыр Ильяс кешеләр янына килми башлый, аның истәлеге булып «пәйгамбәр чәчәге» генә кала. Шагыйрь поэмасының әлеге бүлеген «Бисмилла урынына» дип исемләгән. Әсәрдәге сатирик ирония укыган саен көчәя бара. Шул рәвешле илдәге тормыш, әхлак, көнкүрешне сурәтләү реаль җирлеккә мифологик образ кертү аша башкарыла.

Белгәнебезчә, мифологиядә Хозыр Ильяс образы ак киемле карт рәвешендә, көтмәгәндә генә килеп чыгып, кешедән ярдәм сорый. Аның ничек күренсә, шулай юкка чыгу гадәте дә бар дип әйтелә. Ул үзе дә—кешегә авыр вакытында ярдәм итәргә сәләтле мифологик зат. Аның нәкъ менә шул сыйфатлары шагыйрьләргә язар өчен азык булып тора да. Илнең үткәндәге тарихында халыкка карата канлы террорны, гаепсез халыкның үз арасында илаһи зат Хозыр Ильяска тиң кешеләр булганлыгын сурәтләүдә шагыйрь сатирага мөрәҗәгать итә.

Гомумән, З.Мансуров шигырьләрендә бик көчле сәяси сатира сизелә. Аның сатирасы кайвакыт тупас та яңгырый, шулай булуга карамастан, ул төгәллеге, шартлы сәнгатьчә алымнары белән аерылып та тора. Мәсәлән, 1993 елда Мәскәүдә «баш күтәргән» парламентны тупка тоту вакыйгасын шагыйрь менә ничек сурәтли:

*Инде хәзер урыс орден ала*
*үтергәне өчен урысны...*
*Тәһарәтсез кыргый тәрәккыят*
*тора төсле тоташ уч—каннан.*
*Нәрсә көтеп була гомер бакый*
*«Балта ашы» ашап үскәннән?!*

Нибарысы алты юллык шигырьдә берничә гасырлык Россия тарихы чагыла. Монда Алтын Урда да, Казан ханлыгы да, канлы революция дә, «үзгәртеп һәм үзгәртмичә кору» да бар. Шагыйрь аз сүзләр белән зур тарихны сурәтләп бирә. Хәтта моның белән генә чикләнеп тә калмый: халык әкиятен, фразеологизмга әйләндереп, сәнгатьлелекне көчәйтә.

Әйе, З.Мансуров лирикасы кеше, яшәеш, галәм, яшәү мәгънәсе турындагы фәлсәфи уйлар белән сугарылган. Ул татар милләтен берләштерүгә юнәлгән, бу иҗат милли җанлылыгы белән үзенә тартып тора.

**Фәридә ХӘСӘНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

# «КИТТЕК!»—ДИДЕ ГАГАРИН

*СССРның беренче очучы-космонавты Юрий Алексеевич Гагаринның «Космоска юл» дигән китабында болай дип тә әйтелгән: «Безгә чын очучылар булу өчен күп нәрсәләрне үзләштерергә—югары пилотажга, маршрут буйлап очарга, һавада атарга, төркем белән оча белергә өйрәнергә кирәк иде. Боларның барысына да безне Колосовка алмашка килгән квалификацияле очучы-инструктор Ядкарь Акбулатов өйрәтте. Аның күзе аучыныкы кебек үткер, ул һавада барысын да күрергә өлгерә һәм кечкенә генә җитешсезлеккә дә игътибар итә иде... Квалификацияле башка очучылар кебек, ул да аз сүзле, хәтта бераз үз эченә бикләнгәнрәк кеше, ләкин аның һәр киңәше хәтер дәфтәренә язып баруга лаек иде».*

*Ядкарь Шакирович белән мин 1976 елны, ул Казан дәүләт педагогия институты каршындагы балалар-үсмерләр спорт мәктәбе директоры булып эшләгәндә очраштым. Аны шул чакта сөйләткәннән соң блокнотка күчкән сүзләрне тәртипкә салгач, менә шундый хатирә килеп чыкты.*

**Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ**

—Оренбург училищесы—очучы кадрлар әзерләү буенча илебезнең иң өлкән уку йортларыннан берсе. Биредә тәрбияләнгән йөзләрчә очучылар, шул исәптән Михаил Громов, Андрей Юмашев, Анатолий Серов, Валерий Чкалов, Григорий Бахчиванджи кебек бөркетләр Советлар Союзы Герое исеменә лаек булды. Юрий илебезгә әнә шундый күренекле кешеләр биргән училищеда укыды.



Курсант Гагарин белән беренче очрашу хәтердә яхшы сакланып калган. Болай булды бу. Көннәрдән бер көнне мина яңа экипаж тапшырдылар. Мин өч егетне—Юрий Гагарин, Валерий Захаров һәм Иван Доронинны реактив самолетларда очарга өйрәтергә тиеш идем. Һәм менә алар белән беренче дәресне үткәрергә килдем. Экипаж старшинасы булган Юрий Гагарин мин килеп керүгә сикереп торып басты да елмаеп рапорт бирә башлады:

—Иптәш капитан, өч кеше составындагы экипаж занятиеләргә әзер!

Мин, аның елмаеп басып торуына бераз гаҗәпсенеп, сорау бирдем:

—Курсант Гагарин, сез нигә елмаясыз?

—Болай гына, иптәш капитан. Сезнең белән беренче дәрес бит...

—Яхшы. Ә миниатюр старт кайда?

—Алып килергә өлгерми калдым, иптәш капитан.

—Хәзер үк йөгерегез һәм алып килегез. Биш минуттан өстәлдә барысы да урнаштырылган булсын! Һәм мондый хәл бүтән кабатланмасын!

Аннан соң мин Доронинны яка астарын алмаштырырга, ә Захаровны төймәләрен чистартырга җибәрдем.

Шул көннән соң миңа экипажның тышкы кыяфәте һәм дәрескә әзерлекнең торышы буенча бер генә кисәтү дә ясарга туры килмәде.

Авиациядә вак-төякләр юк. Очучыдан беренче чиратта нык дисциплина, һәр эштә пөхтәлек һәм төгәллек таләп ителә. Курсантлар моны яхшы аңладылар һәм бу сыйфатларны үзләрендә тырышып тәрбияләделәр.

Юрий иптәшләре кебек гап-гади бер егет иде. Очарга бик ярата, зәңгәр күккә җаны-тәне белән гашыйк. Хәер, бер тапкыр очып караган һәр кеше үзенең тормышын самолетлардан, зәңгәр күктән башка күз алдына китерә алмый...

Бервакыт Валерий Захаров колагына салкын тидерде һәм аны госпитальгә салдылар. Захаров анда озак кына ятып чыкты һәм бу вакыт эчендә иптәшләреннән шактый артка калды. Җитмәсә, дәүләт имтиханнары да якынлашып килә иде. Мин егетләр белән сөйләштем һәм алар Валерийга ярдәм итәргә бик теләп риза булдылар. Захаровның самолетын очышка әзерләү, аны карау, ягулык салу, кислород баллоннарын әзерләү кебек эшләрнең барысын да Доронин белән Гагарин үз өсләренә алдылар. Юрий икенче иптәше Иван Доронинга да теоретик фәннәрне үзләштерергә ярдәм итте (сүз уңаеннан, ул теорияне бик яхшы белә иде). Нәтиҗәдә Иван дәүләт имтиханнарын «5»ле билгеләренә генә тапшырды.

Кайчагында мин курсантларның хәлен белергә кергәли идем. Андый вакытларда Юрий сикереп тора, шинелемне алып элеп куя, урындык тәкъдим итә, ә үзе елмая. Бу елмаюны онытu һич мөмкин түгел. Мондый елмаю эчкерсез, саф күңелле кешедә генә булырга мөмкин, һәм Юрий чыннан да шундый кеше иде.

1961 елның 12 апрель көне күңелгә мәңге уелып калды. Без, бер төркем офицерлар, класста утыра идек. Шулвакыт йөгерүдән тыны кысылган курсант килеп керде:

—Офицер иптәшләр, космоска кеше җибәргәннәр бугай!

—Ничек! Нигә алай дисең?

—Әле генә радиодан шул турыда сөйли башладылар.

Без барыбыз да тыңларга йөгердек. Һәм, чыннан да, радио аша Левитанның тантаналы тавышы яңгырый иде: «...»Восток» космик иярчен корабленең очучы-космонавты, Совет Социалистик Республикалар Союзы гражданины очучы майор Юрий Алексеевич Гагарин...»

Беренче минутларда «космонавт безнең Юрий түгел микән?» дигән уй башка да кереп чыкмады. Чөнки шатлыклы хәбәр үзе генә дә бөтен нәрсәне оныттырырлык иде. Шулай да бераздан уйлана башладым: Гагарин. Таныш фамилия. Тукта әле, бу минем элекке курсант Юрий түгел микән соң? Алай дисәң, Гагарин фамилиясен күп кеше йөртә. Аннан соң, аны моннан бер ел элек кенә, ул Оренбургка килгәч, күргән идем. Ул чагында Юрий өлкән лейтенант иде. Ә монда—майор. Озакламый минем шикләнүләремнең урынсыз булуы ачыкланды. Бер сәгатьтән бөтен училище беренче космонавтның безнең элекке курсант икәнлеген белә иде инде. Аның минем укучым булуы ачыклангач, шатлыгым икеләтә артты.

1961 елның июнь аенда Юрий Гагарин Оренбургка—туган училищесына кунакка килде. «Әйт әле, Юра, «Киттек!» («Поехали!») дигән сүзне син кайдан алдың?»—дип сорадым мин аннан шул чагында. Юрий елмаеп җавап бирде: «Бу бит Сезнең сүзегез, иптәш командир!»*

**Ядкарь АКБУЛАТОВ**

---

* Гагарин космик корабль күтәрелә башлагач әйткән сүз. Акбулатов та аны самолет җирдән аерылгач әйтә торган булган. Бу сүз хәтта җырга да кучте: «Он сказал «Поехали!», Он махнул рукой,И словно по Питерской,Питерской Пронесся над Землей!»

Марсель
Бакиров

# ЧУРА БАТЫР

*Казан дәүләт университеты профессоры,Республикабызның атказанган фән эшлеклесе Марсель Бакировка күптән түгел 75 яшь тулды. Ул фән һәм мәдәният җәмәгатьчелегенә, журналыбыз укучыларына әдәбиятчы, фольклорчы һәм шигырь белгече буларак билгеле. Тулырак итеп әйткәндә, ул әлеге өлкәләр буенча язылган һәм фән дөньясында югары бәя алган берничә гыйльми монография һәм өч йөздән артык фәнни хезмәт авторы. Галим һәм тәҗрибәле педагогны ихлас күңелдән юбилее белән котлыйбыз һәм укучыларыбызга аның тарихи-героик «Чура батыр дастаны»на багышланган һәм эчтәлеге белән моңарчыга кадәрге традицион карашлардан нык аерылып торган тикшеренүен тәкъдим итәбез. Анда дастанның тарихи җирлеге яңача карала һәм Чура батыр реаль шәхес түгел, ә бәлки Казанны саклаганда корбан булган меңнәрчә бабаларыбызның гомумиләштерелгән символик образы дигән оригиналь фикер үткәрелә. Димәк, халкыбыз тарафыннан шәһит бабаларыбызга һәйкәл рәвешендә иҗат ителгән «Чура батыр дастаны» аларга реаль тормышта да һәйкәл куелырга тиешлеген раслап тора һәм шуны гамәлгә ашырырга чакыра.*

Дастаннарның «Чура батыр» исемлесе Казан ханлыгы чорына карый һәм әлеге татар дәүләтенең Явыз Иван IVгә каршы героик көрәшен, җиңелү фаҗигасен эпос теле һәм эпик образлар ярдәмендә бәян итеп, тасвирлап бирә. Әлеге әсәрнең, ориенталист И. Березин төзеп чыгарган «Турецкая хрестоматия» (К., 1862) җыентыгындагы татар текстыннан тыш, казакъ, нугай, Польша татарлары, шулай ук өлешчә башкортлар арасында язып алынган һәм төрле басмаларда дөнья күргән төрле милли версияләре билгеле.

«Чура батыр»ның казакъ варианты («Шора батыр» һәм аның әтисенә багышланган «Нәрек» дастаннары) эпик «кырык нугай батыры» циклына кертеп карала һәм «нугай» төшенчәсе ошбу очракта казакъларның да кыпчак-нугай катламына нисбәтле героик үткәненә бәйле рәвештә кулланыла. Эпос белгече В. М. Жирмунский фикеренчә, бу әсәрләр казакълар һәм нугайлар күченеп йөргән, үзара аралашкан Җаек буе һәм дә аннан аргы биләмәләрдә—Көнбатыш Казакъстанда иҗат ителгәннәр. Шуңа күрә дә аларда казакъ тарихына хас булган калмыкларга каршы көрәш мотивы Чура батырның эшчәнлеген-көрәшен билгеләүче төп коллизия итеп тасвирланган да *(В. М. Жирмунский. Тюркский героический эпос.—Л.: Наука, 1974.—С.394—395, 515—516)*.

Фольклорчы-археограф, профессор Әбүбәкер Диваев әле генә аталган ике казакъ эпос-дастанында, шулай ук әсәрнең үзе язып алган архаик вариантында *(Batırlar жыгы.—Alma—Ata, 1939.—T.1.—B. 261—296)* Чура батыр туган төбәгеннән барып

калмыкларга каршы көрәшеп йөргән Казан каласы да асылда Идел буендагы без белгән кала түгел, ә Жидесу төбәгендә, Алмалыкта урнашкан һәм элек Казан дип аталган башка шәһәр булган дип исәпли. Казакъ дастаннарын һәм Ә.Диваев вариантын махсус өйрәнгән академик А.С.Орлов та билгеле бер дәрәҗәдә аның фикеренә кушыла һәм, калмыкларны куып җибәргәч, Чура батырның Казанга хан булып кайтуы Идел буе чынлыгы белән ярашмый дип карый *(А.С.Орлов. Казахский героический эпос.—М.: Изд.АН СССР, 1945.—С. 111—112).* Казан татарларының беркайчан да калмыклар белән сугышмавына игътибар иткәндә һәм «Нәрек», «Шора батыр» (вар. «Чора батыр») дастаннарында тасвирланган тарихи чынлыкның күбрәк Урта Азия регионына туры килүен исәпкә алганда, ошбу галимнәрнең фикере дөреслеккә шактый якын булып тоела. Чөнки XV—XVIII йөзләрдә нәкъ менә Урта Азиядә, ягъни көнчыгыштан хәзерге Казакъстан белән чиктәш Жунгариядә хакимлек иткән ойратлар (калмыклар) үзләренең тирә-ягындагы биләмәләргә, шул исәптән Жидесу төбәгенә дә, кат-кат яу чабып торган.

Нәрек (вар. Нәрик, Нарыкбай) белән Шора (Чура) батыр чыккан «тама» исемле ыру да һәм, икенче версия буенча, янә аргын кабиләсе дә («асылым артык аргынмын») Урта Идел буенда түгел, ә киресенчә, төгәлрәк әйткәндә, Каспий—Арал дингезләре арасында һәм Жидесу төбәген дә эченә алучы Урта Азия регионында көченеп йөргән *(В.В.Востров, М.С.Муканов. Родоплеменной состав и расселение казахов.—Алма-Ата: Наука, 1968.—С.69—70; Дамир Исхаков. От средневековых татар к татарам нового времени.—К., 1998.—С. 154, 158—159).* Һәм, «Шора батыр» дастанында әйтелгәнчә, тамалылар Жидесуда урнашкан Казан исемле калада да төпләнгән булган. (Сүз уңаеннан әйтик: Казан дип исемләнгән, яисә әлеге сүз кушылып ясалган географик атамалар, шул исәптән торак пунктлары хәзер дә Казакъстанның төрле регионнарында очрый *(Т.Жанузак. Казакъ топонимикасы.—Алматы: Дайк-Пресс, 2007.—101, 282 б.).* Янә килеп калмыкларга каршы көрәшү өчен тама яугирләреннән төзелгән һәм башында Чура батыр торган хәрбиләрнең ошбу әсәрдә Аксак Тимер гаскәренә тиңләнүе, ягъни баскак әмирнең культ объекты рәвешендә телгә алынуы да бары Урта Азия җирлегенә нисбәт итеп кенә аңлатыла ала. Янә килеп, В.М.Жирмунскийның, В.В.Бартольд белән бер үк фикердә булып, XVI—XVII йөзләрдә мөселман авторларның «мәҗүси» калмыкларны Урта Азия мөселманнарының иң дәһшәтле дошманнары итеп санаганнар» дип әйткән сүзләре дә «Нәрек» һәм «Шора батыр» дигән казакъ дастаннарының төп идеясенә һәм эчтәлегенә тулысынча туры килеп тора. Һәм нәкъ шуңа күрә казакъ версиясендәге «Казанны кяфер («кәпер») алыр дип, әтием утырган алтын так (тәхет) яу кулына калыр дип, чыктым юлга мин» дигән юллардагы «кяфер» сүзен, кайберәүләрчә, русларга карата кулланылган дип карауның да зарурилыгы юк. Ник дигәндә, Урта гасыр мөселман авторларының башка диндәге халыкны «гәүр», «кяфер» дип атаулары ул, гомумән, гадәти күренеш булган.

Ләкин шунысы гаҗәп: әлеге өч казакъ дастанындагы төп каһарманнарның исемнәре, хәтта Чураның әти-бабасы исеме дә, шулай ук ыруг-кабилә атамасы да, «Чура батыр» эпосының татар, нугай һәм кырымтатар версияләрендәге исемнәр белән шактый тәңгәл килә. Аерым алганда, һәр ике төркемдә дә Чураның әтисе Нәрык (вар. Нарән, Нәрең, Нәрик, Нәрек, Нәрыкбай) дип, әнисе—Миңлесылу (вар. Минле Аруг, Минсылу, Акминде), батыр дусты—Колынчак (вар. Колыншак), Чураның әти-әнисен рәнҗеткән яки аның үзен үтерергә теләгән дошманы Али би (вар. Гали бәй) дип исемләнә. Каһарманның асылы, ягъни ыру-кабиләсе исеме тама (күкес/ көкеш яки аргын кабиләсенең бер өлеше) дип күрсәтелә *(Д.Исхаков. Чура батыр кем ул? // Идел.—1994.—№9.—Б.17).* Бары Нәрыкның төп йорты, туган җире генә төрле регионнарга бәйләп бирелә. Алда исемләнгән казакъ вариантларында ошбу җир тама кабиләсе яшәгән һәм Казан дигән каланы да эченә алган төбәк итеп, татар версиясендә—Дагстан, кырымтатар вариантында—Кырым, нугай һәм Польша татарлары версиясендә Урта Идел буена урнашкан Казан дип күрсәтелә. Бу инде, димәк, сюжет төзелешләрендә һәм конфликтның характерында җирле аерымлыклар булса да, «Чура батыр» эпос-дастанының төрле милли версияләре асылда бер үк уртак чыганактан башлангыч алган һәм үзара «кан алмашкан» дигән сүз. Ләкин

аерымланыбрак торучы өч вариантлы казакъ версиясе иң борынгы җирлек булганмы, әллә инде үзара якын булган татар, нугай, кырымтатар һәм Польша татарлары версияләренең берәрсеме—хәзергә моны кистереп әйтү кыен.

Шулай да монда, «Алпамыш» дастанының казакъ варианты борынгырак булган сыман, «Чура батыр» эпосының казакъ версиясе нигезендә дә борынгырак катламның, шул исәптән әкияти-мифологик мотивларның күбрәк катнашканлыгын аерып күрсәтергә кирәк. Ачыклап әйткәндә, нугай, кырымтатар һәм татар версияләреннән аермалы буларак, Ә.Диваев вариантында Чура батыр баласызлыктан интеккән Нәрыкбай һәм Гөлханыс гаиләсендә могҗизалы юл белән, ягъни болар, кат-кат гыйбадәт кылып, изге Баба Төкләскә (Төкле Бабага) ялварганнан соң, дөньяга килә. Төрле батырлыклар эшләргә каһарманга аның Чуар дигән гайрәтле житез аты, куәтле кылычы һәм җәясе ярдәм итә. Дошманнарына каршы көрәшү өчен үзенә ярдәмгә дип Казанга—тамалар гаскәрен алып килергә барганда—ул хәтта, әкият батыры кебек, аждаһа белән дә көрәшә. Янә килеп, башка милли версияләрдә башлангыч конфликт чибәр хатын өчен барган итеп тасвирланса, әлеге казакъ вариантында ул урынны Чуар толпар ала. Әмма дастанның реаль тарихилыкка корылган нигезе, ягъни Чура батырның нәкъ менә үз ыру-кабиләсен җәберләп яшәүче айраклыларга һәм казакъларның дошманнары булган баскынчы калмыкларга каршы көрәше, әсәрне тарихи-героик эпослар рәтенә куя һәм, һичшиксез, аны Урта Азия регионы белән бәйли. Ә инде сүз барган дастанның архаик мотивларны киңрәк гәүдәләндерүен, кадимирәк булуын күз унында тотканда, ошбу казакъ-кыпчак варианты (асылда—чагыштырмача мөстәкыйль версия!) башка милли версияләр өчен архетип, ягъни ин элгәрге оеткы-өлге ролен үтәмәде микән дигән урынлы сорау да туа. Һәрхәлдә, безнең бу фаразыбыз, шул исәптән аерым галимнәрнең архаик казакъ вариантларын Җидесу регионындагы элгәрге Казан каласына бәйләп каравы турындагы кызыклы фикер киләчәктә, бәлки, ныклабрак та тикшерелер дип ышанасы килә.

Шуның белән бергә, казакъларда «Чура батыр» дастанының нугай, татар һәм кырымтатар версияләре белән шактый авазлаш булган сонрак чорга караучы варианты да бар. Ансында инде Чура батыр, әлеге милли версияләрдәге кебек ук, Идел буендагы Казанны рус яуларыннан яклап көрәшә.

Дастанның «Чура батыр хикәяте» дип аталган татар версиясе Чура туганга кадәрге хәлләрне сурәтләүдән башланып китә. Аның булачак әтисе, Казый исемле би (бәк) тарафыннан тәрбиягә алып үстерелгән Нарәң батыр Миңлесылу исемле бик чибәр кызга өйләнә. Ләкин ана Казый бинең энесе гашыйк була һәм, ире югында килеп, аздырырга тырышуы Нарәң кулыннан үтүгә китерә. Күчеп килгән икенче урында да шул ук хәл кабатлана: Хаҗитархан солтанының, Миңлесылуның чибәрлегенә кызыгып, ирен юри йомыш белән читкә җибәрергә һәм моның хатыны белән якынлык кылырга тырышуы шулай ук аның өчен дә үлем белән тәмамлана. Шушы ук традицион мотивның архаиграк варианты белән без янә дастанның «Шора батыр» дигән казакъ версиясендә очрашабыз. Анда Нәрекнең чибәр хатынына калмыкларның Үгезхан исемле ханы кызыгып, ирен «18 айлык юлга» җибәрмәкче була. Әмма ошбу текстта да Үгезханның бозыклыгы үлем белән очлана.

Юлда качып китеп барганда, Миңлесылуны тулгак тота башлый һәм ире, хәерле сәгатькә багышлап намаз һәм дога укыганнан соң, шулай ук Чура исемле колын азат иткәч, боларның ир балалары туа. Ирекка чыккан кол Чура хөрмәтенә моңа, әсәрдә әйтелгәнчә, Чура дип исем кушалар. Ләкин чура сүзенең мәгънәсе «кол» төшенчәсен билгеләү белән генә чикләнми, санскрит телендәге кебек үк, төрки халыкларда аның батыр, каһарман, батыр сугышчы дигән мәгънәләре дә бар (*Л.Будагов. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий.—СПб., 1869.—Т. 1.—С. 674; Г.Ф.Саттаров. Татар исемнәре сүзлеге.—К.: Тат.кит. нәшр., 1981.—Б.213*). Төрки халыкларның үз эпос батырларын Чура дип атаулары шуның белән аңлатыла да.

Бала тугач, Нарәннең гаиләсе Кырымга барып төпләнә. Шушыннан соң инде Чура дастанда алгы планга чыга һәм төп образ булып әверелә. Башта аның, «Идегәй» әсәрендәге кебек, батыр балачагы тасвирлана: бозау көткәндә, зирәклеге һәм кыюлыгы-тәвәккәллеге белән иптәшләреннән өстен чыгып, аларның башлыгы

булуга ирешә ул. Аннары көтү кайтканда тегеләрне, һәркөн ат урынына үгез-бозауларга атландыртып һәм чыбыкка бәйләгән яулыкларны байрак итеп болгый-болгый кайтырга өйрәтә һәм «Без Чура батырның гаскәребез!» дип яр-оран салырга боера. Бу «сугыш уены» көтелмәгән нәтиҗә бирә: Чура батырның хәтәр гаскәре бар икән дигән хәбәр бөтен тирә-юньгә тарала. Әлеге имеш-мимешләр хәтта Идел буенда яшәүче җирле халыкның, яу килүдән куркып, елганың икенче ягына күченә башлавына сәбәп була.

Бу хәл Кырымда яшәүче Чураның үзенә килеп ишетелә, һәм ул, атасы Нарәң батыр алып биргән гайрәтле атка атланып, биленә куәтле җәя һәм садак тагып Идел буена юлга чыга. Елганың икенче ягына күченүчеләр арасында ул яр буенда аһ-ваһ килеп йөрүче бер картка тап була. Суда үгезе тугарылып, арбасы-йөге белән бергә, моның кызы агып китеп бара икән. Чура тиз генә кереп кызны коткара да, юлын дәвам итә. Шунда аның артыннан, үзе югында кәләшен коткарган өчен рәхмәт әйтергә, танышырга дип бер ир-егет куып җитә. Бу әлеге кызның кияве һәм Чураның булачак көрәштәш дусты Колынчак батыр булып чыга. Кырым батырын картның өенә алып кайтып кунак итәләр. Төн кунганда ике батыр арасында булган сөйләшү һәм киләчәктә кыз кемгә булачак дип шарт-сүз куешу Чураның җиңүе белән тәмамлана. Ике яшь йөрәк уртак тел таба һәм ахырда, карт өендә зур туй ясап, Чураны өйләндерәләр. Колынчакка исә каһарман үзенең кыз кардәше Айсылуны кодалый. Тар даирәдә һәм шәхси кысада булган бу вакыйгалар Чураның киләчәктә күрсәтәчәк батырлыкларына үзенчәлекле кереш рәвешендә кабул ителә.

Хатынын алып Кырымга кайтуына Чураны фаҗига каршы ала. Ул монда юк чагында Акташ дигән җирдән килгән Гали бәк боларның йорт-җирен талап, ата-анасын кыйнап һәм җәберләп, төрлечә мыскыл итеп киткән икән. Житмәсә, киткәндә үзе белән әтисенең Карагир дигән иң яхшы атын да алган. Җавабы һәм әҗере, дастан традициясе таләп иткәнчә, каты һәм кырыс булып чыга: Чура Гали бәкнең башын кисеп, атны кире өенә алып кайта. Сүз уңаенда өстик: үзе янә Казанга китткәч, Гали бәкнең туганнары килеп кабат моның әти-әнисен талап, бөлдереп китәләр. Бу хәл соңыннан Нарәң батырның улын эзләп Идел буена барып чыгуына сәбәп була.

Казанда Чура батыр, үз янына «Колынчак батырны чакыртып алдырып, шулай ук андагы батырлар белән кушылып» шәһәрне бертуктаусыз ябырылып торучы рус яуларыннан саклый башлый. Шушыннан соң инде каһарманның Казанга бәйләнешле героик тормышын һәм батырлыгын күрсәтү әсәрдә үзәк урынны ала. Бу уңайдан дастанда игътибарны аеруча нык җәлеп иткәне шул: шәһәрне саклаганда Чура батыр Шагали (Шаһгали) хан белән тыгыз бәйләнештә торган итеп, хан исә каһарманга һәм башка батырларга төрлечә ярдәм итеп торучы һәм изге эшләренә теләктәшлек итүче хөкемдар итеп сурәтләнә. Бу, әлбәттә, тарихи дөреслеккә туры килми. Белүебезчә, Шаһгали—Мәскәү тарафыннан Казан тәхетенә өч мәртәбә куелган марионетка-курчак хан. Ул колониаль сәясәт алып баручы русларга беркайчан да каршы чыкмаган, һәрвакыт аларның җырын җырлаган һәм шуның аркасында халыкның нәфрәтенә дучар булган.

Бу урында, һичшиксез, Казан ханлыгы тәхетенең күп еллар буена Чыңгыз нәселеннән чыккан берничә династия вәкилләре һәм аларның тарафдарлары өчен «ызгыш алмасы» булганлыгын һәм әлеге көчләр артында, бигрәк тә соңгы дәверләрдә, йә Кырым, йә Мәскәү торганлыгын аерым рәвештә искәртеп китәргә кирәк. Шушыңа бәйле рәвештә Казанның морза-бәкләре һәм аларның иярченнәре дә ике фиркага дә, ягъни капма-каршы ике төркемгә бүленгән булган. Бу төркемнәрнең беренчесе Мәскәү кулы астында, ягъни рус дәүләтенә буйсынып яшәүне яклаcа, икенчесе Кырымга бәйлелек ягын каерган, әмма шул ук вакытта ханлыкны рус йогынтысыннан азат итү өчен дә көрәш алып барган. Менә шундый шартларда тәхеткә Мәскәү тарафыннан кат-кат утыртылган Шаһгалинең (әсәрдә әлеге ханның исеме Шагали дип бирелә) дастанда уңай образ итеп тасвирлануы, билгеле, аның гамәли-реаль эшчәнлеге белән дә, шулай ук әсәрнең идея юнәлеше белән дә кискен каршылыкка керә.

Бер уңайдан искәртик: кырымтатар версиясендә әлеге катлаулы чорда тәхеттә

утырган ханның исеме атап әйтелми, ә Польша татарлары версиясендә Сафа, нугай версиясендә исә Гәрәй яки бер вариантта ханбикә Сөембикә дип күрсәтелә. Моның, ягъни Шаһгалинең татар версиясендә «идеаллаштырып» тасвирлануы сәбәбен, минемчә, ил язмышын хәл иткән фаҗигале хәлләргә карата чичән-җырауларның һәм, гомумән, халыкның гыйбрәтле-сатирик нәтиҗә чыгаруы һәм үкенү-тәүбәгә килергә чакыруы формасы итеп кабул итәргә кирәктер. Ачыклап әйткәндә, халык Казанны алуда үз гаскәрләре белән катнашкан сатлык Касыйм ханы Шаһгалине, нәкъ менә юри көлеп, ягъни фольклорга хас пародия алымын кулланып, Казанны яклаучы хан итеп тасвирлый. Моның белән халык, шул чордан соң килгән буыннарга һәм безгә кинаяле тел белән: «Хыянәтчел ялгышлык ясаган бабаларыгыз өчен тәүбә итеп, гыйбрәт алыгыз, безнең ханнар сатылу-хыянәт юлына басмыйча, менә шушылай халык белән бердәм булып көрәшергә тиеш иделәр!» дип әйтергә тели. Халык иҗатында сакланган «Шаһгали җыры» дип исәпләнүче җыр да шушы ук фикерне һәм соңлап килгән үкенү тойгысын белдерә. Анда Казан алынгач янә тәхеткә утыру турында хыялланган әлеге хан исеменнән: «Дус-дус дип йөргәнем бар да дошман икәнсез... Бездән калган малларны руслар килеп алалар» дигән гыйбрәтле-үкенечле сүзләр әйтелә.

Ары таба дастанда Шагали (Шаһгали) ханның халык белән «бердәмлеген» раслаучы яңа мәгълүмат китерелә: ул Чураның әтисе Нарәнне, улы янына килгәнен ишетеп, үз сараена кунакка алдыра, төрлечә хөрмәт күрсәтә, кыйммәтле кием бүләк итә. Ләкин аңарчы Кырымнан бөлеп, хәерче хәленә төшеп килгән карт батырны улы Чура каршылый. Ул аңа өс-башын алмаштыру, ат һәм яугир тага торган кирәк-яраклар алу өчен акча бирә һәм дә билгеләнгән көнне, атка атланып, үзенең гаскәренә таба байрак күтәреп килергә куша. Шунда янына «бу нинди гаскәр?» дип чаптырып килгәч, мине сугып ек, аннары, гаскәр яныбызга килгәч, мин үз җавабымны күрсәтермен, ди. Һәм шулай эшлиләр дә. Гаскәре алдында Чура, атыннан төшеп, әтисе алдына тезләнә һәм яугирләренә боера: «Әй, гаскәр! Сез барыгыз да аттан төшегез! Бу килгән—минем атам—Нарәң батыр»,—ди. Менә шундый зур кадер-хөрмәтләр күргәннән һәм хан янында булганнан соң инде, ата кеше үзе яшәгән төбәккә—Кырымга—кайтып китә һәм өендә хатыны белән тантаналы мәҗлес уздыра.

Шагали хан үзе генә түгел, ә аның кызы Сарыкани да (кырымтатар вариантларының берсендә кызның исеме—Сары ханым) рус яуларына каршы көрәшүчеләр ягында торучы итеп сурәтләнә. Казанны саклаучы батырларга ул төрле бүләкләр өләшә, ә Чурага тартма эчендәге «күкчыбык» дигән кылыч бүләк итә. Каһарман шул коралы һәм атлы гаскәре белән кат-кат ябырылып торучы, шәһәрне алырга ашкынучы рус яуларын кыра.

Дошман як Чура батырның һөҗүмнәреннән тәмам гаҗиз була, мөшкел-авыр хәлдә кала. Аптырагач, руслар, батырны ничек үтереп булыр икән дип, күк җисемнәре буенча күрәзәлек итүче астрологларга мөрәҗәгать итәләр. Болар: «Чура батырга дошманнан бер кыз бирсәң, шул кыздан бер угыл булса, Чура батырның әҗәле шул угланнан булыр» дигән нәтиҗәгә килә. Белүебезчә, «ата белән баланың үзара сугышы» сюжеты, хәтта каһарманның үз улын яки үз әтисен үтерүе мотивы дөнья фольклорында һәм әдәбиятында күптәннән билгеле. Җөмләдән, безнең эрага кадәр V йөздә үк яшәгән борынгы грек драматургы Софоклның «Эдип патша» дигән трагедиясендә чит патшалыкта үскән Эдип, кем икәнен дә белмичә, үзенең әтисен үтерә. Фирдәүсинең «Шаһнамә» эпосында, әрмәннәрнең «Давид Сусанский» дигән эпик поэмасында һәм русларның «Илья Муромец и сын» былинасында да без бер якның үлеме белән беткән шундый ук фаҗига белән очрашабыз.

Вакыйгаларның ары таба үсешеннән күренгәнчә, руслар астролог әйткәнчә эшлиләр дә. Үзе янына махсус рәвештә озата килүче арчилар белән җибәрелгән марҗа кызын Чура батыр хуш күреп кабул итә һәм моның белән яши башлый. Әмма кыз, балага узу белән үк, үзен Казанга җибәрүчеләрнең сүзен тотып, кире үз ягына качып кайта. Аннары инде Чурадан туган бала, ягъни әтисенең язмышын хәл итәчәк угыл, руслар арасында тәрбияләнеп үсә. Ә менә дастанның кырымтатар

версиясендә Чура—исеме әйтелмәгән Казан ханының Сары ханым исемле кызына өйләнгән итеп күрсәтелә һәм баланы да шул таба. Ләкин ошбу кыз көтмәгәндә генә дошман ягына чыгып китә, димәк, бу очракта да Чураның улы руслар арасында тәрбия ала.

Шактый вакытлар узгач, Чура батыр сугыш мәйданында йөзгә-йөз үзенең үсеп житкән улы белән очраша. Казан—Мәскәү арасындагы бәрелешләрнең шактый еллар буена дәвам иткәнлеген исәпкә алганда һәм эпик вакытның кысып та тасвирлана алуын истә тотканда, моңа, әлбәттә, гажәпләнергә кирәкми. Ошбу «гәүр» маржадан туган бала рус явы белән татарларга каршы сугышырга, Казанны алышырга килгән булып чыга. Әтисе белән болар сугыш мәйданында бик озак алышалар, көч ягыннан да, осталык буенча да бер-берсенә бирешмиләр. Ике арадагы каты орыш бигрәк тә кырымтатар версиясендә шактый тәфсилләп тасвирлана. Моңа кадәр бер-ике селтәнүдә әллә никадәр дошман яугирләрен түшәп салган яу батырының, күпме генә тырышып караса да, улын үтерергә көче житми. Ахырда моның аты тәмам кызып, тыя алмаслык хәлгә килеп, өстендәге батыр жайдагы белән бергә Идел ярыннан егылып төшә. Суга батып үлгәндә Чураның ачынып әйткән соңгы сүзләре мондый:

*Индегедән арбаган бездәй ирләргә*
*Казан атлы сар да (шәһәр дә) юк.*

Әсәр дөнья күргән басмаларда арбаган сүзенең мәгънәсе «бәхет, уныш» дип күрсәтелгән. Безнеңчә, бу сүз йә «сихерләнгән, алданган» мәгънәсендә килгән «арбаг» тамырыннан алынган, йә булмаса—монысы дөресрәктер дә бәлки—ул башта, гарәп шрифты белән язылган текстта «һәлак булу» мәгънәсен белдерүче «арда» рәвешендә булган. Димәк, Чура батыр асылда: «моннан соң инде һәлак булган безнең кебек ирләргә Казан дигән шәһәрдә гомер итү насыйп булмаячак» дип саубуллашу-бәхилләшү сүзләрен әйтә. Ошбу сүзләрнең төбендә шулай ук шәһәрне саклаучы ирләр кырылып бетеп, Казан руслар кулында калачак дигән мәгънә дә ярылып ята. Бу мәгънәне, әлбәттә, ошбу фажигале язмышның шаһиты яки замандашы булган чичән-жыраулар салган. Һәм дастанның ахырында шулар ук исеменнән, әлеге мәгънәне раслап, «Соңра урыс гаскәре галиб (жиңүче) булып, Казан шәһәрен алды. Урыс падишаһына табигъ булдылар (буйсындылар). Бу Казан шәһәрен алганнан берничә ел соңра Хажитархан (Әстерхан) шәһәрен янә алды» дигән үтә гыйбрәтле бетем дә өстәлгән.

Һәм аерып әйтергә кирәк: дастанның нугай һәм кырымтатар версияләрендә Чураның әжәле, туганда ук судан булачак дип юралган булса да, асылда бу үлемнең үз улы аркасында булганлыгы шиксез. Мифологиядә һәм әкияти-мифологик эпоста аеруча куәтле дошманны шул затның үз коралы белән генә үтереп була дигән мотив бар. Дастанда да шушы ук мотивның үзенчәлекле төстә файдаланганлыгы сизелеп тора. Үзенчәлекле төстә дигәндә, без Чура канының маржа каны белән катышуын күздә тотабыз. Чөнки нәкъ шушы хәл халыкта «батырның үлеме маржадан» дигән мәкаль тууга сәбәп була. Венгр галиме Х.Б.Паксой да Чураның үлеме әсәрдә үтә үткер һәм кинаяле-символик итеп тасвирлануына дөрес бәя бирә: «Маржа кызы белән бәйләнү сәбәпле, ул үз үлемен таба, ә бит моны бер генә батыр да, хәтта бернинди гаскәр дә эшли алмас иде»,—дип яза (*Х.Б.Паксой. Чура батыр кисәтүе // Идел.—1994.—№9.—Б.12*).

Ләкин дастанда Казанны саклауның барып чыкмавына һәм ике арадагы сугышның күп корбаннарга китерүенә сәбәп булган башка төрле хаталарга да ишарәләр бар. Беренчедән, бу—Казанны дошманнан саклау белән Кырымнан килгән каһарман гына диярлек шөгыльләнгән итеп тасвирлануы, пайтәхеттәге морза-бәкләрнең исә, капма-каршы төркемнәргә бүленеп, ил язмышын кыл өстендә калдыруы. Өстәвенә, бер-бер артлы алышынып торучы кайбер ханнарның—Мәскәү марионеткаларының—баскынчылар ягын каеруы. Әсәрнең нугай вариантында Казанга килгәч Чура авызыннан әйтелгән сүзләр нәкъ менә татарлар арасында бердәмлек булмавын раслап тора:

*Халык әйткән хак икән,*
*Айсыз икән ханыгыз,*
*Бу Казанның ханы бар да, намы юк.*
*Казые бар, түрә юк.*

Икенчедән, Казанны саклаучыларны символлаштыра торган Чура батырның үз-үзен тотышында да вакыт-вакыт кызу канлылык, дуамаллык һәм күбрәк үз көченә генә таянуы кебек сыйфатлар сизелеп кала. Яшь фольклор белгече Лилия Ибраһимова бик дөрес билгеләгәнчә, болар—героик холыклы каһарманның тискәре яклары *(Л.Х.Ибраһимова. Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны.—К.: Фикер, 2002.—Б.49).* Шул ук вакытта болар, һичшиксез, Казанның язмышы хәл ителгәндә җитди хаталарга юл куелуына һәм киң масштаблы яки коалицион бердәмлекнең булмаганлыгына да ишарә итә.

Дастанның берничә планлы яки күпкырлы сәяси-идеяви рухы һәм эчтәлеге урыны-урыны белән, чыннан да, теге яки бу чорның рухи атмосферасы һәм тарихи чынлыгы белән яраша. Алда әйтелгәнчә, әсәрнең бер нугай версиясендә, мәсәлән, баскынчы русларга каршы торучы Казан ханының исеме Гәрәй дип, ә кырымтатар версиясендә Сафа дип күрсәтелә. Бу хан Казан тәхетендә берничә мәртәбә утырган Гәрәйләр династиясе дигән Кырым ханнарының берсе буларак кабул ителүне сорап тора. Җөмләдән, 1521 елда Кырым фирка-төркеме тарафыннан ханлык башына мендерелгән Сәхипгәрәй хан, килү белән үк, җавап рәвешендә Мәскәүгә һөҗүм ясый һәм ике елдан руслар яклы Хөсәен ханны куып, Әстерханны яулап ала. Шуннан соң тәхеткә утырган Сафагәрәй дә абыйсының сәясәтен дәвам итә һәм өч мәртәбә хан булып тору дәверендә Мәскәү төркемен бик нык ээзрлекли, руслар һөҗүмен кире кайтарганнан соң, Мәскәүгә үзе яу белән бара. Мондый кара-каршы яулар берничә мәртәбә кабатлана һәм басым ясап әйтергә кирәк: руслар ягыннан мондый сугышлар яулап алу, буйсындыру максатын күздә тотса, татар яулары, башлыча, җавап рәвешендә һәм талау, мал үзләштерү максаты белән була *(И.Л.Измайлов. Завоевание Казанского ханства: причины и последствия // Татарский народ после 1552 года: потери и приобретения.—Казан, 2003.—С. 104—105).* Ошбу тарихи хакыйкатьне объектив карашлы рус галимнәре дә таный. В.В.Похлёбкин, мәсәлән, болай дип яза: «Казан ханлыгы Мәскәү дәүләтенә караганда чагыштырмача һәм формаль яктан ныграк тынычлык яклы була. Ул беркайчан да күрәләтә кыдрачланмый. Ханлыкның Мәскәүгә кагылышлы берninди яулап алу планнары да булмый. Казан яуларының күпчелеге йә русларның басып керүләренә каршы юнәлдерелгән кирәкле саклык чаралары төсендә, йә булмаса ана кадәр ясалган рус һөҗүмнәренә гадәти җавап рәвешендә оештырыла» *(В.В.Похлёбкин. Татары и Русь.—М.: Международные отношения, 2005.—С. 117).*

Казан шагыйре Шәриф Хаҗитарханиның[1] «Зафәрнамәи вилаяти Казан» («Казан мәмләкәтенең җиңү бәяны») әсәрендә Иван IVнең 1550 елда Казанны алырга дип килгән яуларына каршы татар гаскәренең батырларча сугышуы һәм шәһәрне саклап калуы тасвирлана. Зур батырлык күрсәткән һәм исемнәре аталган каһарманнар арасында автор беренчеләрдән итеп Сафагәрәй ханны күрсәтә һәм «Сафагәрәй—баһадир хан». «Әгәр җәфалаучылардан үч алмасам, үзем җәфаланучыга әйләнермен дип әйтеп, үзенең сугышчан атын иярләп, биленә дошманнарны кыра торган зиннәтле кылычын тагып, ислам дине өчен сугыш юлына басты»,—дип яза *(С.Х.Алишев. Казан ханлыгы чорындагы тарихи чыганаклар.—Казан, 2002.—Б. 12-13).* Рус империячел дәүләтенең, Казанны алу белән үк, татарларны көчләп чукындыру һәм йоту-ассимиляцияләү сәясәтенә кучүен исәпкә алганда һәм ханлыкны корал белән буйсындырганда ук шул максат күздә тотылуына игътибар иткәндә, ислам диненең элек электән үк татар халкын берләштерүче һәм этнос-милләт буларак юкка чыгудан саклаучы фактор булганлыгы шиксез. Шуна күрә дә бер үк дин тоткан һәм хәтта үзара якын-кардәш телдә сөйләшкән кырымлыларның Казанның һәм ханлыкның мөстәкыйльлеген саклауда билгеле бер өлеш кертканлеге, шул исәптән эпос-дастанда да Чураның Кырымнан килгән батыр итеп тасвирлануы аңлашыла.

1 Бу әсәр Кол Шәриф тарафыннан язылган дигән фикер дә яши. (Редакция).

Инде урынлы сорау туа: кем булган соң ул Чура батыр, аның берәр прототибы булганмы? Фольклорчыларның һәм тарихчыларның кайберләре (мәсәлән, Ф.Урманчиев белән Л.Ибраһимова һәм Д.Исхаков) бу сорауга унай җавап биреләр һәм әлеге каһарманга өлге-прототип ролен үтәгән шәхес Казан аксөяк-бәге Чура Нарыков булган дигән караштa торалар, хәтта һәр версиягә дә шул шәхес өлге итеп алынган дип исәплиләр. Моның өчен, әлбәттә, Чура Нарыковның рус елъязмаларында теркәлгән исем-фамилиясе, ягъни үзенең һәм атасының исеме дастандагы Чура һәм Нарән (Нарык) исемнәре белән тәңгәл килүе нигез һәм дәлил итеп алына. Хәтта тюрколог В.Жирмунский да заманында шул ук алдавыч кармакка эләгә *(В.М.Жирмунский. Тюркский героический эпос.—Л.: Наука, 1974.—С. 515)*. Шушыңа бәйле рәвештә Чура Нарыковның сәяси-иҗтимагый эшчәнлегендәге тискәре яклар да—татар авторлары тарафыннан тартып-сузулар һәм шомарту-йомшартулар исәбенә—Казан ханлыгын саклап калу һәм яшәтү хакына эшләнгән кирәкле гамәлләр итеп күрсәтергә яки исбатларга тырышыла.

Ләкин кырын эшне аклап яки карадан ак ясап булмаган кебек, Чура Нарыковның да, Мәскәү мәнфәгатен яклап, Сафагәрәй белән Сөембикәгә һәм аларның ханлыкның мөстәкыйльлеген саклау сәясәтенә каршы юнәлдергән хыянәтчел эшләрен дә аклау мөмкин түгелдер. Аерым алганда, ул, Казан өстенә яу-гаскәр җибәрүләрен сорап, Мәскәүгә ике тапкыр илчеләр юллый һәм кырымлыларның барсын да (Сафагәрәй ханны да кертеп!) руслар кулына әсирлеккә тотып бирергә вәгъдә биргән кеше *(Һади Атласи. Себер тарихы. Сөембикә. Казан ханлыгы.—К., Тат. кит. нәшр., 1993.—Б. 318-319)*. Шулай ук Шаһгалигә тәлинкә тотып» әлеге ташка үлчим ханның юк абруен сакларга тырышып йөргән «олы морза» һәм, хәле мөшкелләнгәч, аңа Казаннан качып китәргә ярдәм иткән «зур сәяси фигура» да—ул. Казан ханлыгы мәнфәгатьләре өчен «тырышканлыгын» раслап, Чура Нарыков хәтта үзе дә, гаиләсе, яраннары һәм мең кешелек сакчылары белән соңыннан Мәскәүгә качып чыгып китә, әмма юлда хан гаскәре тарафыннан куып җитеп үтерелә *(Казанская история.—М.-Л.: Изд. АН СССР, 1994.—С. 80-83)*.

Тарихи чыганакларда шулай ук Чураның 1547 елда Мәскәү яклы морзалар белән бергә Сафагәрәй хан тарафыннан җәзалап үтерелүе турында да мәгълүмат сакланган. Чөнки, рус чыганакларыннан билгеле булганча, «рус хөкүмәте Кырым фирка-төркеменә каршы булган морза-бәкләрне ачыклау-барлау һәм, алтын, мех, төрле кыйммәтле бүләкләр биреп, системалы рәвештә аларны сатып алу белән шөгыльләнә. Шулай ук килешү турында сөйләшүләрдә катнашучы барлык илчеләр дә, юл бүләге бирү сылтавы белән, сатып алыналар». Менә шундый чаралар ярдәмендә «Иван IVнең татар агент-шымчылары Сафагәрәйне бәреп төшерү һәм аның урынына руслар кандидатурасы Шаһгалине хан итеп утырту өчен сарай түнтәрелеше әзерлиләр» *(В.В.Похлебкин. Татары и Русь.—М.: Международные отношения, 2005.—С. 108, 113)*. Табигый ки, Чура Нарыков ошбу фетнә-түнтәрелешне әзерләү һәм оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе була. Димәк, аның кабат тәхеткә утырган Сафагәрәй тарафыннан нәкъ шуның аркасында үлем җәзасына тарттырылган булуы турындагы мәгълүматның дөреслеккә туры килүе бик мөмкин.

Дастандагы ата һәм ул исемнәре белән Казандагы әле генә без күздән кичергән хыянәтче бәкнең исем-фамилиясе туры килүенә карап кына аларны үзара тиңләштерү, икенчесе беренчесенең прототибы булгандыр дип карау, безнеңчә, дөреслектән шактый ерак тора. (Белүебезчә, төрле кешеләрнең , шул исәптән күренекле шәхесләрнең исем-фамилияләре һәм аталарының исеме үзара туры-тәңгәл килү бүгенге көндә дә еш очрый бит!) Шушы ясалма схемага ярашып, әлеге кире тип булган Чура Нарыковтан, имеш, ул үзен куып җиткән хан гаскәре белән (димәк, үз иле яугирләре белән!) «тиңсез сугыш-бәрелештә, нәкъ менә халык дастаннарындагыча, батырларча һәлак була» дип герой-каһарман ясарга тырышу да гаҗәп дәрәҗәдә урынсыз. Шулай ук әлеге «Казан морзасының тарихи эшчәнлеге белән» аның дастани язмышының үзара туры килмәвен «тарихи эпос әсәрләре белән тарихи вакыйгаларның еш кына үзара каршылыкка керүе» белән бәйләп аңлату да, шулай ук «әсәрнең тәэсир көчен арттыру ихтыяҗы» белән бәйләү дә бу очракта һич тә аклана алмый.

Чура Нарыковның сатлык җан булуын халык, һичшиксез, белгән һәм аны өнәмәгән, хәтта куралмаган булырга тиеш. Менә шуна күрә дә башкортларда «Сура (Чура) батырның урыс гаскәрләренә ярдәмгә баруы» дип исемләнгән тарихи риваять сакланып калганлыгына һич тә гаҗәпләнергә кирәкми *(Народные сказки, легенды, предания и были Башкирии.—Уфа: Башк. кн. изд., 1969.—С.190).* Анда кат-кат һөҗүм итеп тә Казан каласын ала алмаган рус гаскәренә нәкъ менә Чураның ярдәмгә килүе һәм, төнлә халык йоклап беткәч, дошманга яшерен керү һәм чыгу юлларын күрсәтеп, шәһәрне алырга ярдәм итүе турында сөйләнелә. Ошбу риваятьтә тасвирланган Чура белән русларны үз халкы өстенә яу белән килергә чакырып яткан Чура Нарыков арасында шактый охшашлык булуы шиксез. Шулай ук Яшел Үзән районының Караужа (Кара Хуҗа) авылында тарихчы-археограф Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан язып алынган ярым легенда характерындагы тарихи риваятьтә дә Чура би Казан ханлыгына хыянәт иткән итеп, ягъни Мәскәү патшалыгына серләрне саткан кеше буларак күрсәтелә. Шуның өчен хан аны, «байлык житми иде сиңа, мә, ал» дип авызына эретелгән көмеш коеп үтергән диелә «Караужа» исемле әлеге риваятьтә *(М.Әхмәтҗанов. Татар шәҗәрәсе.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1995.—Б. 33—34).* Кыскасы, халык иҗатының аерым үрнәкләрендә Чура батыр образы белән сатлык җан Чура бәк шәхесе бер-беренә капма-каршы куеп тасвирлана.

Бәлки чичән-жыраулар икейөзле Чура Нарыков бәкне дә дастанга, марионетка Шаһгали хан кебек үк, юри гыйбрәт итеп һәм Чура асылда дошманга каршы үзләре тасвирлаган батыр шикелле көрәшергә тиеш иде дип кертkәннәрдер? Болай уйларга, безнеңчә, нигез юк. Нигә дигәндә, халык иҗатында Чураны дастандагы кебек идеаллаштырган һәм нәкъ менә мөдһиш Иванга һәм аның яуларына каршы сугышучы пәһлеван итеп тасвирлаган борынгы җырлар һәм бәетләр дә бар. Аларның берсе, К. Насыйриның 1880 елгы календарендә басылып чыккан «Казан бәете» исемендәгесе, Чура батырны ни рәвешле тасвирлавы ягыннан борынгы казакъ тарихи җыры белән аваздаш *(Л.Ибраһимова. Алда күрсәтелгән хезмәт.—Б.54—56).* Әлеге җырда да, татар бәетендә дә Чура батыр Иван IVне, ашап утырган җиренә кереп, башын чабып өзгән итеп тасвирлана. Шул рәвешле төрки халыклар, үзләренең хыялында, ягъни уйланма белән үрелгән лиро-эпик иҗатларында булса да, баскак рус патшасын үзләре теләгән җәзага тарттырганнар.

Казанны алырга кат-кат килүче рус яуларына каршы батырларча көрәшеп йөргән һәм дастан каһарманына прототип булган Чура исемле реаль шәхес булгандырмы, юкмы—бу сорауга сакланып калган тарихи чыганаклар буенча кистереп кенә унай җавап биреп булмый. Дөрес, 1764 елда күчерелгән «Җәмигъ әр-рөмүз» («Серләр җыентыгы») китабына кушымта рәвешендә теркәлгән беренче буыны Кукәс, икенчесе—Нәрык, өченче буыны—Чура исемнәренә туры килүче һәм барысы унбер буын тәшкил итүче шәҗәрә сакланып калганлыгы билгеле. Әмма ошбу шәҗәрәдә теркәлгән Чураның рус яуларын кайтаруда катнашканлыгы турында бернинди дә мәгълүмат юк. Иван IVнең 1550 елдагы дәһшәтле явын җиңү-түнтәрүгә багышланган «Зафәрнамәи вилаяти Казан» («Казан мәмләкәтенең җиңү бәяны») дигән әдәби һәм тарихи-публицистик характердагы әсәрдә дә, гәрчә Казанны саклауда катнашкан күренекле батырлар исемләп аталып чыкса да, алар арасында Чура исеме күрсәтелмәгән. Ахыр килеп, Казанның һәлакәте һәм татар ханлыгының яулап алынуы белән тәмамланган иң соңгы хәлиткеч сугыш турындагы язма тарихи чыганакларда һәм шул чорга караган истәлекләрдә дә Чура исеме телгә алынмаган. Хәлбуки, мәркәзне саклауда аеруча зур батырлык күрсәтүчеләрнең һәм каһарманнарча һәлак булучыларның исемнәре берәм-берәм атап күрсәтелсә дә!

Югарыда сөйләнгәннәрдән үзеннән-үзе бер мөһим нәтиҗә соралып тора: дастандагы Чура батыр образы, безнеңчә, конкрет бер шәхесне гәүдәләндерүче каһарман түгел, ә җыелма образ булырга тиеш. Аның прототибы асылда—Казанны саклап көрәшкән һәм сугыш мәйданында корбан булган дистәләрчә батырлар. Чура сүзенең «батыр», «батыр сугышчы» дигән мәгънәсе үзе үк ошбу гомумиләштерү сыйфатына ия булган исемгә төрле каһарманнарны җыю, бергә берләштерү сыйфатына ия. Менә шуңа күрә дә үз балаларының батыр-баһадир булып үсуен

теләп, ата-аналарның элек Чура исемен кушарга ратканлыклары һәм Казан ханлыгы чорында, язма чыганаклардан күренгәнчә, андый исемнәрнең шактый булганлыгы бик табигый. Моны шулай ук Чүриле (Чура иле) яки Чурай дип аталучы борынгы авыл исемнәреннән һәм «чура» (~колчура, акчура) эпонимыннан ясалган фамилияләрнең шактый таралган булуыннан да чамаларга була. Чура исемле кешеләр, әлбәттә, Казанны һәм аның тирә-ягын дошман яуларыннан саклаган, әмма исеме тарихи язма чыганакларда теркәлмәгән яугирлар арасында да булмаган түгел, булгандыр. Җөмләдән, Яшел Үзән төбәгенә бәйләнешле «Карауҗа» исемле алда телгә алынган риваятьтә әлеге авылга нигез салган Карауҗаның (Кара Хуҗаның) улының улы Чура батыр «Иван Грозный гаскәрләре Казанны алган вакытта шушы авыл җирләре өчен сугышып үлгән» дип күрсәтелә *(М. Әхмәтҗанов. Җиде бабаңны беләсеңме? // Ялкын.—1994.—№1.—Б.4).*

Ләкин ярым легенда, ярым риваять сыман әлеге текстта берьюлы ике кеймәнең койрыгын тотарга омтылу сизелеп тора. Чөнки гаҗәпнең дә гаҗәбе: анда ошбу Чура батырның, алда әйтелгәнчә, баскак русларга сатылып, җәзалап үтерелгән этисенең исеме дә Чура (= Чура би)! Димәк, сатлык Чура Нарыков прототибына ишарә итә торган Чура бәк тә, шулай ук рус яуларына каршы көрәшеп һәлак булган Чура батыр да—икесе дә бер үк гаиләдән булып чыга! Житмәсә, икесе дә бер үк исемдә! Белүебезчә, төрки татар гаиләләрендә ир баланы, рус семьяларындагы кебек, атасының исеме белән атау гадәте беркайчан да булмаган һәм хәзер дә юк. Моннан ошбу ярым риваятьтә тарихи Чура шәхесе белән фольклор әсәрләрендә гәүдәләнгән легендар Чура батыр образының ясалма рәвештә бер үк җепкә теркәлгәнлеген, димәк, текстның бары бер Чурага бәйләнешле өлешен генә чыганак итеп файдаланырга мөмкин булганлыгын тану кыен түгел. Кызганычка каршы, «Чура батыр» дастанын тикшерергә алынган фольклорчылар, эклектизм юлына басып, әлеге текстның берьюлы ике өлешенә, ягъни ике версиясенә дә таяналар һәм, фикерләрен кат-кат үзгәртә-үзгәртә, «билгесезне билгесезлек аша» исбатларга тырышалар.

Тарихи әдәбиятта Чура Нарыков һәм аның исеме билгесез улы—икесе дә үтерелгән итеп күрсәтелә. Янә килеп, дастанда тасвирланган Чура батыр да һәм шулай ук кырымтатар версиясе буенча аның улы да һәлак булган итеп бирелә. Әмма дәүләтчелегеннән мәхрүм калган татар халкы хыялында гына булса да Чураны кабат терелтә һәм, бәет героена әверелдереп, дошманыннан үч алдыра—Мөдһеш Иванның башын кистерә. Сәнгати уйланмага һәм халык хыялына нигезләнгән әлеге тасвир руслар Казанны алганнан соң, Сөембикә, имеш, гаскәр җыю өчен манарасыннан аккош булып очып чыгып киткән дип сөйләнә торган социаль-утопик легенда белән шактый аваздаш (әлеге легенда качып китәргә мәҗбүр булган татарлардан күчеп, чуаш фольклорында сакланган). Моннан тыш, элекке Минзәлә кантонының Чураш авылында археограф Сәет Вахиди язып алган легенда-хикәяттә дә Чура батыр исән калган итеп телгә алына. Һәм, Иванга каршы сугышканнан соң, Арча төбәгендә үз отряды белән килеп Наласа авылын нигезләве, аннары, күченеп китеп, хәзерге Сарман районында урнашкан Чураш авылына нигез салуы бәян ителә *(М.Әхмәтҗанов. Мәдәни мирасыбыз сакчысы // Татарстан.—1997.—№5.—Б.40).*

Ләкин әлеге материалларда урын алган мәгълүмат белән Яшел Үзән районында теркәлгән «Карауҗа» легенда-хикәяте һәм шәҗәрәсе арасында исем-антропонимнарның аталышы ягыннан да, шулай ук эчтәлекләренең характеры буенча да уртаклык юк. Бу, әлбәттә, исеме Чура тамырыннан ясалган һәр авылның теге яки бу рәвештә үзен легендар Чура батырга илтеп бәйләргә тырышуы һәм аның турында үзенчәлекле үз иҗатын тудыруы белән бәйләнгән. Ә инде дастанның татар версиясендә нәсел башында торган бабаның һәм күпчелек геройларның исемнәре, башка милли версияләрдәге кебек үк, бозылмыйча саклануына килгәндә, ошбу уртаклык, барыннан да элек, чичән-жырауларның эпик традициягә турылыклыгы белән аңлатыла. Икенчедән, бу нәсел башында торучы исеменең Алтын Урда чорыннан ук килүче абруйлы ыру-кабилә этнонимы яки күренекле клан атамасы белән тәңгәл килүе һәм Казан ханлыгында да андый аксөяк нәселләрнең өлешчә дәвам итүе белән бәйләнгән. Мәсәлән, Туктамыш хан бәкләре Карахуҗадан башлангыч алучы аргын һәм барын дигән клан-нәселләр—шундыйлардан.

Тарихи риваять-легендалар арасында Чура батыр язмышы белән азмы-күпме аваздаш булган Батман батыр турындагы хикәят аерым игътибарга лаек. Чура кебек үк, халык аңында гомумиләштерелгән әлеге эпик каһарман үзенең батырлыкларын Казан алынганнан соң күрсәтә. «Русия патшасы,—диелә текстта.—Гаскәр кылып, шәһри Казанны алып әкябирләрнең (бөекләрнең) һәммәсенең башын кистерде. Шуның өчен Казанда кол нәселе дип кылмышлар, олуглардан һич калмаганы өчен. Әмма качкан кемсәләрдән берсе Батман батыр иде. Казан суы артында урманда ат менеп йөрер иде. Бәгъзе вакытларда Казан эченә кереп утыз-кырык баш кисеп, дәхи Казан суы артына чыгып китәр иде». Көннәрдән бер көнне су аръягына чыккан «бер маржа» моны йоклаган хәлендә очрата һәм таш белән бәреп үтерә. Батырның аты, иясенең үлгәнен белгәч, биленнән кабып аны хода теләгән жиргә илтеп куя. Кяферләр Батман батырның сөяген таба алмыйлар. Бәс, батырның үлеме маржадан булды, шуның өчен «батыр үлеме маржадан» дип мәсәл кылалар» *(Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1987.—62—64 б.).* Ике батырның да үлеме «маржа»га бәйләп тасвирланганлыгын исәпкә алганда, безнеңчә, әлеге хикәят-легенда «Чура батыр» дастанының үзенчәлекле татар версиясе тууына күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясаган булса кирәк дип уйларга нигез бар. Әмма ул чакта әле эпик каһарман гомумиләштерүче Чура (=батыр, батыр сугышчы) дигән гомумтөрки исем белән аталмаган булса кирәк.

Җыеп һәм нәтиҗә ясап әйткәндә, «Чура батыр» дастанының татар версиясе—гомумтөрки тарихи-героик эпосының Казан ханлыгы чорына караучы бер саллы үрнәге. Анда мәркәзебез Казанны һәм дәүләтчелегебезне яклап көрәшкән ил батырларының җыелма образы, ягъни масса күләмендә күрсәтелгән халык батырлыгының үзәк каһарманга бәйләп гомумиләштерелгән героик тибы гәүдәләндерелгән. Шул ук вакытта символик мәгънәгә ия булган Чура батыр образына шәһәрне саклаганда шәһит булган бабаларыбыз фаҗигасенә мөнәсәбәтле трагик мәгънә дә салынган. Халыкның тарихи хәтере һәм сәнгати уйланмага төрелгән социаль-эстетик бәяләмәсе буларак сакланган бу эпос-дастан безне, узганнардан гыйбрәт һәм сабак алып, халкыбызны милләт буларак саклап калу һәм яшәтү идеясенә каһарманнарча хезмәт итәргә чакыра.

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкарьләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# И

**ИСХАКЫЙ** (Исхаков) Гаяз (Мөхәммәтгаяз) Гыйлаҗетдин улы (мөһаҗирлектәге псевд. Иделле) (22.2.1878, Казан губ. Чистай өязе Яуширмә а.—22.7.1954, Анкара, Истанбулда җирләнә), язучы, публицист, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе; 20 йөз башындагы татар яңарыш әдәбиятына нигез салучыларның берсе. Гаяз, Гаяз Исхаков, Казанлы, Гаяз Исхакый, Иделбай, Бикбулат, Биктимер, Бичура углы, Котлы Мөхәммәт, Тимер, Ураллы, Хәбибрахман әл-Болгари, Кәндилле, Хәмит, Чынгыз, Япанчы кебек исемнәр һәм тәхәллүсләр б-н яза һәм басыла.

Мулла улы. 12 яшенә кадәр туган авылында әтисендә укый, 1890−93 елларда Чистайда танылган дин эшлеклесе Закир Камал мәдрәсәсендә, 1893−97 дә—Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсендә белем ала. 1898−1902 дә Казан татар укытучылар мәктәбендә укый, Көнбатыш Европа, рус иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-эстетик фикерләре б-н таныша, И.С.Тургенев, И.А.Гончаров, Ф.М.Достоевский, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, М.Горький иҗаты б-н кызыксына; татар теленә А.С.Пушкинның «Капитанская дочка» («Капитан кызы», 1899), Н.В.Гогольның «Старосветские помещики» («Борынгы алпавытлар», 1902) әсәрләрен тәрҗемә итә. 1901 дә аның тырышлыгы б-н «Шәкертлек» дигән яшерен түгәрәк оеша, гектографта «Тәрәкъкый» г-тасы басыла. 1902 нең көзеннән Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. Ун-тка керү нияте б-н 1903нең җәендә Казанга кайта, ләкин ата-анасының ихтыяры б-н туган авылына кайтырга һәм мулла вазифаларын башкарырга мәҗбүр була. 1904тән янә Казанга килә, шул чордан башлап үзен тулысынча иҗтимагый-сәяси һәм әдәби эшчәнлеккә багышлый. 1905-07дә И. милли хәрәкәттә актив катнаша: шәкертләрнең «Берек» исемле яшерен оешмасын оештыра, Казандагы татар яшьләренең яшерен сәяси «Хөррият» җәмгыятен, татар яшьләренең эсерларга якын «Таңчылар» төркеме лидеры була; Россия мөселманнарының «Иттифакъ әл-мөслимин» фиркасе съездларында радикал татар яшьләре вәкиле буларак та катнаша; «Таң йолдызы», «Тавыш», «Таң мәҗмугасы» г-таларының фактик мөхәррире вазифаларын башкара. Рев. эшчәнлеге, хакимияткә каршы ясаган чыгышлары өчен 18 тапкыр кулга алына, Чистай, Казан, Мәскәү, С.-Петербург төрмәләрендә утыра, Архангельск губернасына сөргенгә озатыла. 1909−11 дә сөргеннән качып, И. ике тапкыр Төркиягә барып чыга, анда әдәби эшчәнлек б-н шөгыльләнә, «Сират әл-мөстәкыйм» («Туры юл»), «Төрк дәрнәге дәргиси» («Төрек җәмгыяте мәҗмугасы») исемле төрек басмаларында языша. Романовлар Йортының тәхеткә утыруының 300 еллыгы унае б-н 1913 нең 3 апрелендә игълан ителгән амнистия карары нигезендә тоткынлыктан чыгарыла (Казанда яшәргә рөхсәт бирелми). Мәскәүдә, Петербургта яши, «Ил» г-тасын нәшер итә. 1917 елгы Февраль рев-циясен хуплап каршылый, Вакытлы хөкүмәтнең милли сәясәтен яклап чыга. Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче съездында Идел буе һәм Урал төрки-татарлары өчен милли-мәдәни автономия— Идел-Урал Штаты төзү фикерен алга сөрә. Аның бу идеясе Бөтенроссия мөселманнарының 2 нче съездында да (Казан, 1917), Милләт Мәҗлесендә дә (Уфа, 1917−18) хуплау таба. И. Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шура әгъзасы итеп сайлана. Совет хакимиятен кабул итми. Большевиклар эзәрлекләвеннән качып Себер якларына (Петропавловск шәһәренә) китә, «Маяк» г-тасын чыгаруда катнаша (1918−19). Әле 1918 дә үк Милли Идарә тарафыннан илчелек әгъзасы итеп сайланган И. 1919 да Версаль тынычлык конференциясендә катнашу өчен Ерак Көнчыгыш аша Европага юнәлә. 1920 нең мартыннан 1922 нең җәенә кадәр Парижда, аннары Берлинда яши. 1925 тә И. Төркиядә; Истанбулда «Төрк юрду» ж-лында, «Җөмһүрият» г-тасында хезмәттәшлек итә. Әмма мәкаләләрендә татарлар б-н башкортларның милли дәүләтен төзергә, төрки халыкларны берләшергә чакырган өчен, совет дипломатиясенең төрек хакимиятенә ясаган басымы нәтиҗәсендә И. Төркиядән китәргә мәҗбүр була. Премьер-министр Ю.Пилсудский чакыруы буенча (алар Архангельск губернасында сөргендә танышалар), 1927 дә И. Польшага күчеп килә, анда «Идел−Урал комитеты»н оештыра, Варшава ун-тының шәрекъ

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

факультетында төрек телен укыта. 1931 нең декабреннән 1932 елның башына кадәр Иерусалимда үткән Бөтендөнья мөселманнар конгрессында катнаша, докладында советлар Россиясендә ислам динен кысу, мәчетләрны ябу, дин әһелләрен эзәрлекләү турында сөйли. Бу хакта ул Мисыр, Иран, Гыйрак, Әфганстан, Йәмән, Марокко дәүләтләре башлыкларына һәм Рим Папасына мөрәҗәгать итә. 1933-36 да И. Ерак Көнчыгыш буенча сәяхәт кыла, Кытай, Манчжурия, Япония, Кореяда яшәгән төрки-татарларны берләштерү, Мукден конгрессын оештыру һәм үткәрү, «Ерак Шәрекътәге мөселман төрки-татарларның милли-дини Идел-Урал мәркәзе»н төзү буенча зур эш алып бара. 1936 да И. Варшавага әйләнеп кайта, 1939 да Польшага фашистлар Германиясе басып кергәч, Төркиягә күчә һәм гомеренең ахырына кадәр шунда яши. Мөһаҗирлек елларында И. —«Милли юл» (1928 декабре—1930), «Яңа милли юл» (Берлин, Варшава, 1930—39) ж-ллары, «Милли байрак» (Мукден, 1935—45) г-тасы нашире һәм мөхәррире була. Бу басмаларда ул татарларны югалган дәүләтчелекләрен кайтару, милли азатлыкка ирешү өчен берләшергә чакыра.

И. иҗатының башлангычы 19 йөз ахыры—20 йөз башына—татар әдәбияты үзенең Яңарыш чорына аяк баскан дәвергә туры килә. Шартлы рәвештә язучы иҗатын 4 чорга бүлеп өйрәнергә мөмкин: 1) 1897—1904 елларны үз эченә алган мәгърифәтчелек дәвере; 2) «таңчылык» баскычы—инкыйлаби идеяләр б-н мавыккан 1905—10 еллар; 3) милли бердәмлек идеяләренә өстенлек биргән 1911—18 еллар; 4) мөһаҗирлек дәвере—татарларның милли дәүләтчелеген торгызу идеологиясен актив алга сөргән 1918—54 еллар. И. беренче әдәби тәҗрибәләре үрнәкләре һәм төрек теленнән татар теленә тәрҗемәләре («Җәррах баба» хикәясе) сакланмаган. Иҗатының башлангыч чорында ук прозаик, драматург, публицист буларак танылa. Әсәрләренең төп мотивы—урта гасырлар мөселман әдәбиятларында ук киң таралган «гыйлем—наданлык» антиномиясе. Аның фикеренчә, җәмгыятьнең социаль—икътисади һәм рухи тәрәккыятен тәэмин итү һәм кешене тәрбияләүдәге төп чара булып Акыл, Гыйлем һәм Сүз сәнгате тора. Беренче басылган әсәре—«Тәгаллемдә—сәгадәт» (1897) хикәясе. Анда автор җәдит мәдрәсәсендә укыган шәкерт Хәлимнең милләт хадиме булып житешүен һәм шәхси тормышында да бәхеткә ирешүен тасвирлый. «Бай угылы» (1897, басыла 1903) повестенда күтәрелгән мәсьәләләр дә бу хикәягә якын тора. Аның төп герое Кәрим, надан ата-ана кинәше б-н җәдит мәдрәсәсен ташлап китә, үзенә «тәрбияче» итеп куелган урам малае Фәхринең тискәре йогынтысына бирелеп, иркә, азгын яшүсмергә әверелә, җинаятьләр кыла, язгышларын берсендә һәлак була. И.ның мәгърифәтчелек прозасы һәм драматургиясендә күп төрле мотивлар ярдәмендә ачылган феминизм мәсьәләләре үзәк урынны алып тора. Авторны язучы итеп киң таныткан «Кәләпүшче кыз» (1900) повестеның героинясы Камәр дә акчага хирыс, уйнашка этәрүче Зөһрә карчык һәм азгын приказчик Вафа корбаны итеп гәүдәләнә. «Өч хатын белән тормыш» (1900) пьесасында ул татарлар арасында таралган күп хатынга өйләнү гадәтенә каршы чыга, гаиләдә хатын—кызларның ирләр б-н тигез хокуклыгын яклый. Француз һәм төрек драматургиясе йогынтысында язылган «Ике гашыйк» (1902) пьесасында да искергән феодаль-патриархаль гореф-гадәтләр, гаилә корудагы сословиечелек күренешләре тәнкыйть ителә. Бу темага багышланган әсәрләр арасында «Очрашу, яки Гөлгыйзар» (1903) романтик повесте аерым бер урын алып тора. Әсәрдә шәркый мөселман һәм Европа мәдәниятендә кабул ителгән мәхәббәт, өйләнү, гаилә кору турындагы карашлар чагыштырыла, бер-берсенә каршы килгән фикерләр әйтелә. Повесть геройлары Гөлгыйзар б-н Габдулла Көнбатыш материализмы, Шәрекънең идеализмы һәм рухияте, Коръәндәге язмыш һәм кеше ихтыяры, Ч.Дарвинның табигый сайланыш теориясе, А.Бергсонның интуитивизмы һәм тормыш фәлсәфәсе турында фикер алышалар.

И. иҗатында гына түгел, бәлки 20 йөз башы татарларның иҗтимагый һәм әдәби тормышында вакыйга булып торган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902-1904) исемле мәгърифәтчелек антиутопиясендә бүгенге татарларның ерак бабалары—болгарларның 10—13 йөзләрдә югары мәдәни үсеш баскычына аяк басулары, ә инде 19—20 йөзләргә житкәндә, икътисади һәм рухи төшенкелек кичереп, әхлаки бозыклыктан, йогышлы яман чирләрдән кырылып, 21 йөз ахырында милләт буларак тарих аренасыннан юкка чыгулары турында сөйләнә. Әсәрдә болгарларның үлеп бетүләренең сәбәбе— кадими «голәмәләр сыйнфының» милли татар яшьләренең тәрәккыяткә, фәнгә, Европа һәм рус культурасын үзләштерүгә, рус уку йортларында белем алуларына каршы чыгуы аркасында туган иҗтимагый торгынлык нәтиҗәсе итеп аңлатыла. Әсәрнең сюжет җепләре, анда чагылыш тапкан иҗтимагый идеаллар, әдәби-эстетик фикерләр, образ-сурәтләр Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, С.Рәмиев, Г.Камал, Н.Думави, Ф.Туйкин һ.б. бик күп язучылар иҗатларында үстерелде һәм сәнгати эшкәртелде.

Марксизм эстетикасының көчле тәэсирен кичергән, «танчы»лык чорында иҗат ителгән әсәрләрнең әйдәп баручы мотивын—«Тартышуда гына табарсың син үз бәхетеңне!» исемле шигарь (девиз) тәшкил итә. И. Думага сайлаулар һәм революцион хәрәкәткә бәйле реаль вакыйгалар Чистай төрмәсендәге хәлләрне сурәтләгән автобиографик һәм публицистик язмалар рәвешендә «Зиндан» (1907) повестенда чагылыш таба. Социалистик идеяләр б-н өретелгән феминистик карашлар йогынтысында искергән йолаларга, сословиечелеккә каршы чыккан, бай ата-анасы йортыннан ярлырак гаиләдән булган сөйгәне Ибраһим янына качкан Галия образы «Алдым-бирдем» (1907) драмасының төп героинясы булып тора. Драма авторның үзе тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителә һәм М.Горький инициативасы б-н «Заветы» ж-лында басылып чыга (1914, № 6). Рус язучысы б-н И. күп хатлар алыша. Аңа язган хатларның берсендә М.Горький: «Кайчагында минем башыма шундый бер уй килә: әгәр дә берәр татар кешесе рус халкының татарлар б-н бергә көрәше булып гомер кичерүе рус халкының яшәеше турындагы күзаллауларына нинди йогынты ясаганын күрсәтсә, татарларга да, русларга да зур булышлык күрсәтер иде»,—дип яза. Татар пролетар әдәбиятының үрнәге булган «Тартышу» (1908) драмасында социал-демократларның, «танчы»-эсерларның, народник яшьләрнең самодержавиегә каршы чыгышлары сурәтләнә. Диалогларда пьесада катнашучылар «татар революциясе», «рус революциясе» дигән төшенчәләрнең мәгънәсе, үзенчәлекләре турында әңгәмәләр алып баралар. Алар анлавынча, «Татар революциясе»—ул мәгърифәтчеләрнең, җәдитчеләрнең 19 йөз ахыры—20 йөз башы татар иҗтимагый һәм рухи тормышын европалаштыруга омтылулары, «рус революциясе» исә—1905-07 елларда татарлар б-н русларның бергәләп самодержавиегә һәм аның бюрократиясенә каршы бергәләп чыгыш ясаулары. Народниклык идеяләренең көчле тәэсире «Мөгаллим» (1908) һәм «Мөгаллимә» (1913) драмаларында аеруча ачык күзәтелә. Аларның төп геройлары Салих һәм Фатыйма, ир-егетләр б-н хатын-кызларның никахлары аларның милләт каршындагы иҗтимагый бурычларын үтәүгә аяк чала дип, мәхәббәттән дә, гаилә корудан да баш тарталар, үзләренең эшчәнлекләрен милләт мәнфәгатьләре б-н бәйле бөек идеалларга хезмәт итүгә багышлыйлар: халыкның социаль-сәяси активлыгын, мәдәнилек дәрәҗәсен, милли аңын күтәрү өчен шәхси бәхетләрен корбан итәләр. И. антиклерикаль темаларга язылган комедияләре б-н дә танылa. Ул кадимче муллаларның схоластик фикерләвеннән, җаһиллекләреннән «Җәмгыять» (1909) һәм «Кыямәт» (1909) комедияләрендә ачы көлә.

20 йөз татар иҗтимагый һәм рухи тормыш манзарасы бөтен тулылыгында И.ның «Тормышмы бу?» (1911), «Мулла-бабай» (1910, тәмамланмаган), «Теләнче кызы» (1–3 кит. 1906–14) романнарында гәүдәләнә. «Теләнче кызы»—татар әдәбияты тарихында тәнкыйди реализм кысаларында (Л.Н.Толстойның «Воскресение»—«Яңадан туу» романы йогынтысында) язылган һәм күпмедер дәрәҗәдә мәгърифәтчелек реализмы һәм пролетар әдәбият өчен хас алымнар б-н үрелгән беренче роман. Автор татар милләтенең яңарышында җәмгыятьтәге социаль каршылыкларны, хатын-кыз азатлыгын уңай хәл итүне әһәмиятле бер шарт дип саный. Алданрак язылган әсәрләреннән аермалы буларак, бу романында автор Толстойның явызлыкка каршылык күрсәтмәү фәлсәфәсе б-н бәхәскә керә, хатын-кызларны язмышларын үз кулларына алырга өнди. Бу идеяне кабул иткән романның төп героинясы Сәгадәт күңелсез үткән яшьлеге б-н араны өзәргә, бай ире Габдулла йортыннан Петербургка укырга китәргә көч таба, үзен халыкка хезмәт итүгә багышларга карар кыла. Габдулланың әхлакый үзгәрүенә, Сәгадәтнең рухи яңаруына зур йогынты ясаган автобиографик Мансур образында халыкчылык идеяләре дә көчле чагылыш таба. Тормыш-көнкүрешне натуралистларча һәм фотография ысулы б-н М.Горькийча тасвирлап, бу әсәрендә И. «тормыш төбе»нә ташланган геройларның күмәк портретын иҗат итә. Аларның эчке рухи дөньясы төшләр, символик сурәтләр, монологлар, табигать күренешләре б-н янәшә куелган чагыштырулар ярдәмендә дә ачыла. «Тормышмы бу?» психологик романы мәдрәсә шәкертенең көндәлеге формасында язылган. Анда И. татар җәмгыятенең эчке һәм тышкы халәте шәркый мөселман традицияләреннән Көнбатыш мәдәниятенә таба хәрәкәт итү һәм көчү рәвешендә гәүдәләнә. Моны ул әсәрнең төп герое—башта ислам фәннәрен өйрәнгән, үзләштергән, аннары рус һәм Европа мәдәниятенә таба йөз тоткан, ислахчы булып халкына хезмәт итәргә хыялланган мәхдүмнең—мулла улының рухи эзләнүләре рәвешендә чагылдыра. Әмма тормыш киртәләрен җиңә алмаган герой уртакул авыл мулласы вазифаларын башкаручы булып кала. Автор яшәешнең мәгънәсен җуйган, үз-үзенә «Тормышмы бу?» дигән риторик сорау куйган геройның газаплы уй-кичерешләрен күрсәтә. Тәмамланмый калган «Мулла бабай» романында реалистик осталык, тирән психологизм, мул һәм ачык этнографик буяулар б-н татар тормышы, кадими һәм җәдиди

мәдрәсәләрдә укыту системасы, төрле тип руханилар һәм хәлфәләр образлары гәүдәләнә. Романның төп герое имам Хәлим халкыбызның акыл иясе һәм гомумкешелек кыйммәтләренә ия булган дин әһеле булып күз алдына килеп баса. 1910–11 дә язучы Фрейд тәгълимате рухында психоанализга корылган, «Фамилия сәгадәте» исеме б-н аталган «Татар гакълы», «Мәдрәсә җимеше», «Көтелгән бикәч», «Шәкерт абый» дигән хикәяләр бәйләмен яза. Бу циклда кеше психикасының ансыз катламнарын, невроз халәтләрен, эротик мәхәббәтне чагылдыруга шактый урын бирелә.

1910 елларда И.ның иҗтимагый-сәяси карашлары һәм сәнгатьчә фикерләве җитди үзгәрешләр кичерә. Ул инкыйлаби-сыйнфый көрәш идеяләреннән баш тартып, гомуммилли мәнфәгатьләрне яклау юлына аяк баса, бөтен көчен татар җәмгыятенең төрле катламнарын берләштерүгә һәм милли үзаңны үстерүгә юнәлтә. Бу эшне язучы татар милләтенең бөтендөнья мәдәнияте казанышларын үзләштерүдә, тәрәккыяткә ирешүдә мөһим чара дип саный. Күп санлы публицистик һәм әдәби әсәрләрдә милли бердәмлек темасына басым ясау И.ны татар милли азатлык хәрәкәтенең танылган лидеры итеп таныта. Россия дәүләтенең сәяси тарихы кысаларында милли мәсьәләләрне яктырту, мәдәни, дини, гаилә мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерү аның бик күп әсәрләренең үзеген тәшкил итә. Милли кыйммәтләрне чагылдыру ягыннан «Сөннәтче бабай» (1911) повесте аерылып тора. Аның төп геройлары—Корбангали карт б-н аның карчыгы Гөлйөзем—татар халкының иң яхшы әхлакый сыйфатларын үзләренә туплаган образлар. Аларның озакка сузылган бәхетле гаилә тормышы бик күп буыннарның тарихи тәҗрибәсенә, гасырлардан күчеп килә торган мөселман традицияләренә нигезләнә. Әсәрдә пейзаж, этнографик детальләр, татар халкының милли характер үзенчәлекләре (хезмәт сөючәнлек, кунакчыллык, чисталык) сәнгати яктан бик тә дөрес һәм үтемле итеп тасвирланган. Повестьның хикәяләү стиленә Н.В.Гогольнең «Борынгы алпавытлар»ындагы җинелчә ирония һәм юмор б-н хикәяләү алымы зур йогынты ясаган. «Зөләйха» (1912, басыла 1918) романтик трагедиясендә мөселман татарларны көчләп чукындыру һәм урыслаштыру сәясәте күрсәтелә. Аның геройлары—рухи яктан нык, илаһи гаделлек, азатлык, изгелек, кешелеклелек идеалларының тормышка ашачагына ышанган кешеләр. Зөләйха ахыр чиккә кадәр үзенең кешелек дәрәҗәсен, милли-дини хасиятләрне саклап калырга тырыша. «Остазбикә» (1915) повестенда мөселман мәдәнияте өчен хас кыйммәтләр: гаилә, балаларга карата мәхәббәт, ананы хөрмәтләү, милләткә тугрылык алга чыгарыла. Язучының хатын-кызга карата гуманистик карашлары тирән психологизм б-н остазбикә Сәгыйдә образында гәүдәләнә. Аның гаҗәеп олы акылы һәм югары әхлаклы гамәлләре алдында ире Вахит хәзрәт тә баш ия.

«Ул әле икеләнә иде» (1914) һәм «Ул әле өйләнмәгән иде» (1916) повестьларында И. милләтара никахлар мәсьәләсен күтәрә. Аның геройлары милли менталитет һәм дини традицияләр кысаларыннан чыгу талпынышы да ясап карыйлар. Әсәрләрдә мәхәббәт һәм гаилә турында төрле карашлар үзара очраша, автор аларны гомумкешелек позицияләреннән дә, христиан һәм ислам диннәре күзлегеннән дә чыгып аңлатырга тырыша. Рус хатын-кызлары образлары әсәрдә гадәттә романтик рухта идеаллаштырып биреләләр; аларга каршы исә катып калган, рухи торгынлык кичергән мохитта яшәргә мәҗбүр булган, шуңа күрә интеллектуаль яктан да түбәнрәк торган татар хатын-кыз образлары каршы куела.

Мөһаҗирлек дәверендә язылган публицистик һәм әдәби әсәрләренең төп темасын татар халкының колониаль бәйлелеккә эләгүе, сугышлар, инкыйлаби тетрәнүләр, көчләп урыслаштыру, совет хакимиятенең дошманы дип игълан ителгән милли зыялыларны һәм руханиларны юк итүе нәтиҗәсендә туган зур тарихи фаҗига тәшкил итә («Дулкын эчендә» драмасы, 1920). Язучы патша Россиясенең рус булмаган халыкларны изү сәясәтен кискен тәнкыйтьли («Өйгә таба» повесте, 1922), төрки халыкларны берләшергә, югалткан дәүләтчелекләрен торгызырга, милли азатлык өчен көрәшергә чакыра. «Локман Хәким» (1923) әкият-антиутопиясендә киләчәктә СССРда мәйданга чыгачак тоталитар хакимият турында алдан хәбәр бирә. Импрессионистик стильдә язылган «Көз» (1923) психологик повестенда И. урыслаштыру сәясәте нәтиҗәсендә морзалар катлавының юкка чыгачагын искәртә. Сукырларча Көнбатышка иярүнең милли тамырларны югалтуга китерү мәсьәләсе «Жан Баевич» (1923) комедиясенең төп конфликты булып тора. Карикатура һәм фарс рәвешендә сурәтләнгән төп герой Мольер пьесаларындагы көлке геройларны хәтерләтә. 1930 елларда И. Якын һәм Ерак Көнчыгыш илләренә сәяхәт кыла, милли азатлык өчен көрәш турында күпсанлы һәм күләмле мәкаләләр б-н чыгышлар ясый. «Ислам мәмләкәтләрендә» (1933) исемле мәкаләләр циклында мөселман илләрендә ислам диненең торышына анализ ясала, большевикларның Идел буе һәм Урал мөселманнарының дини хокукларын кысу сәясәте тәнкыйтьләнә. Аныңча ислам—татар милләтенең тәрәккыятенә,

анын бербөтен булып яшәвенә, халык буларак әхлакый куәтен, кодрәтен саклап калуга ярдәм итүче универсаль рухи көч. КПСС ҮКның татар халкына үз тарихын һәм әдәбиятын өйрәнүне рәсми рәвештә тыйган «Татар партоешмасының хәле һәм массакүләм-сәяси, идеологик эшне яхшырту чаралары турында» дип аталган 1944 елгы 9 август карарына И. «Олугъ Мөхәммәд» (1947) исемле тарихи драма б—н җавап бирә. Пьесада Олугъ Мөхәммәд хан образы руслар б—н тату яшәргә омтылган хан итеп сурәтләнә; рус тарих фәнендә шактый кин таралган Алтын Урда—золым символы дигән карашлар кире кагыла.

И.—төрки халыкларның азатлык хәрәкәте тарихына багышланган күп кенә хезмәтләр авторы. Алар арасында татар халкының милли дәүләтчелеге мәсьәләсенә багышланган «Идел-Урал» (1927) хезмәте, анын татар, рус, француз (1933), япон (1934), инглиз һәм поляк (1938) телләренә тәрҗемәләре аеруча зур әһәмияткә ия. Анда Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы тарихына, аларның матди һәм рухи мәдәниятенә кыскача күзәтү ясала, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң татар халкының авыр колониаль изүгә дучар ителүе, анын үз динен, телен, менталитетын саклап калу өчен алып барган авыр көрәше турында сөйләнә. Хезмәттә И. татарларның тарихи үсеш дәвамында югалган мөстәкыйльлекләрен «Идел-Урал» дәүләте рәвешендә торгызу мөмкинлеген исбатлый. Бу мәсьәлә И. тарафыннан 1917—18 дә үк көн тәртибенә куела, мөһаҗирлеккә киткәч «Өйгә таба» повестендә һәм «Олугъ Мөхәммәд» тарихи драмасында сәнгати чаралар б-н чагылдырыла. И. фикеренчә, Россия патша заманында да, большевиклар килгәч тә «халыклар төрмәсе» булып кала. Ул андагы бөтен иҗтимагый—сәяси катаклизмнарның үтә актуаль мәсьәләнең —милләтара мөнәсәбәтләрнең унай хәл ителмәве турында: «Рәсәйдә революция әле тәмамланмаган. Большевиклар чоры бу революциядә бер күчеш этабы гына. Инкыйлабның төп асылы милли мәсьәләгә барып тоташа. Шуңа күрә ул милли мәсьәләне хәл иткәндә генә, бәйсезлек өчен көрәшне даими дәвам итүче халыклар тулаем азатлыкка ирешкәндә генә тәмамлана ала»,—дип яза ул. Ул ш. у. журналистика («Гәзитчелек эшендә 25 ел», 1931), әдәбият тарихына һәм әдәби тәнкыйтькә багышланган хезмәтләр авторы. «Шималь төрек әдәбиятына бер нәзар» исемле басылмый калган монографиясендә татар әдәбиятының барышына культура-тарих мәктәбе һәм биографик метод принципларыннан чыгып бәя бирә. Мәкаләләренең байтагында татар мәгърифәтчеләре К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, И.Гаспралы, Р.Фәхретдиннәр эшчәнлеге; Ф.Кәрими, С.Максуди, Г.Тукай, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Г.Камал, Г.Коләхмәтов һ.б. әсәрләре анализлана. Публицистик чыгышларында большевикларның әдәбият өлкәсендә алып барган сәясәтләре тәнкыйтьләнә. Аерым әсәрләре («Алдым—бирдем», «Шәкерт абый», «Сөнәтче бабай», «Калуш») 1913—16 да рус телендә дә дөнья күрә.

Совет хакимияте елларында эмигрант язучы һәм «халык дошманы» дип тамгаланган И.ның әсәрләре онытылуга дучар ителде. 1980 еллар ахырында гына анын мирасы халыкка кире кайтарылды. И. исемен аклау эшенә әдәбият галиме И.Нуруллин һәм язучы Ә.Еники зур өлеш керттеләр. Аның әдәби иҗаты, сәяси-тарихи карашлары Н.Дәүләт, С.Чыгътай, М.Таһир, И.Нуруллин, Һ.Мәхмүтев, Л.Гайнанова, М.Хәсәнев, Ф.Мусин, М.Сәхапов, Х.Миңнегулов, Ф.Галимуллин, Ф.Ибраһимова, Р.Ганиева, А.Шәмсутова, Р.Харрасова, Р.Яруллина, Б.Т.Гали һ.б. авторлар хезмәтләрендә яктыртыла.

1991 дә ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге булдырылды, Яуширмә авылында язучының музее ачылды.

Әсәр.: Мәҗмугаи асар: 8 томда. К.—М.—СПб., 1911—18; Әсәрләр. К., 1998—2005. Т.1—4, 6, 8.

Әд.: Нуруллин И. Два письма М.Горького // Вопр. литературы. 1988. № 4; Гали Б.Т. Щедрый талант. Общественно—политическая деятельность и исторические взгляды Г.Исхаки. К., 2002; Сахапов М. Исхаки и татарская литература XX века. К., 2003; Мусин Ф. Гаяз Исхакый. К., 1998; Харрасова Р. Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. К., 2002; Шәмсутова А. Гаяз Исхакый иҗатында феминистик проблемаларның идея-эстетик эволюциясе. К., 2003; Миңнегулов Х. Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. К., 2004; Ганиева Р. Гаяз Исхаки // Ислам на Европейском Востоке: Энцикл. словарь. К., 2004.

*Автор: Р.К.Ганиева.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# СӘХНӘДӘ УЛ—АККОШ, САНДУГАЧ...

*Морзалар нәселеннән ул. Татар авылында туып-үскән, ә үзе Европа аксөякләре салоннарында, король сарайларында формалашкан югары вокал сәнгатендә зур биеклеккә ирешкән җырчы. Кыскасы, бүгенге әңгәмәдәшебез—Зилә Даян кызы Сөнгатуллина, Тукай бүләге лауреаты, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты.*

**—Авылдан килеп, сәнгатьнең югары төрена—операга кереп китү ничек насыйп булды Сезгә, Зилә ханым?**

—Моның сәбәбен күп еллар узгач кына, менә шушы яшемдә генә аңлый башладым бугай. Казанга һичкем этеп-төртеп түгел, ә үзем килеп кердем, үз көчем белән. Теләк ул кечкенәдән тәрбияләнә икән. Операга килү дигәннән. Әтием бик музыкаль кеше: баянда яхшы уйный, музыка грамотасын да белә иде. Гомумән, белемле кеше иде: университетны ике мәртәбә укып тәмамлаган—үзе филолог, үзе юрист. Мин алтынчы класска кадәр музыка белемен әти-әниемнән алдым. Аннан соң өйдәгеләр безне, биш баланы, радио тыңларга өйрәттеләр. («Маяк» радиосыннан еш кына классик музыка тапшыралар иде). Сәләте бар дип, жиденчене тәмамлагач, мине Салават районы үзәгенә—Малаязга, балалар сәнгать мәктәбенә бирделәр. Эксперименталь балалар сәнгать мәктәп-интернаты итеп, махсус биналар салып ачканнар иде аны. Бөтен Башкортстаннан җыелган балалар бергә укыдык.



Уфадан килеп укыттылар безне. Вокал осталыгына, хор, музыка тыңларга шунда өйрәтә башладылар. Чайковскийның музыкасын тыңлау миндә, үсмер кызда, тирән эз калдырды. Исемдә: кичләрен утны сүндереп музыка тыңлаталар иде. Караңгыда авазларга дикъкать бермә-бер көчлерәк була икән.

**—Ул мәктәптә татар, башкорт музыкасы программалары да бар идеме?**

—Юк, анысы булмады. Укытучыларыбыз һәммәсе диярлек руслар иде. Ә укыту программасы бөтенләе белән рус һәм Европа классиклары әсәрләреннән төзелгән иде. Мин сигезенче сыйныфны укып бетергәндә әтием вафат булды. Әле үләренә шактый вакыт элек, мине янына чакырып китерде дә, әйтте: «Кызым, шифоньер башына язу яшереп куйдым, анда бер адрес яздым. Берәүгә дә әйтмә. Сигез классны тәмамлагач, Уфага шул адрес буенча бар—укы», —диде. Шулай итеп, мин унбиш яшемдә сәнгать училищесына, вокал бүлегенә укырга килдем.

Малаязга, туган авылым Нәсибашка (сүз уңаеннан: язучы, галим, драматург Нәкый Исәнбәтнең якташы мин!) татар, башкорт җырчылары еш килә иде. Фәридә Кудашева, мәсәлән. Ә Уфада укый башлагач, Казаннан Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова һәм башка җырчылар килеп концерт куялар, без, студентлар, аларга бик теләп йөри идек. Әлфия апаның төрле милләт көйләрен һиндча да, үзбәкчә дә, казакъча да җырлап шаккатырганы әле дә истә...

Күңелем гел Казанга тартылды. Мин бит Еникеевлар нәселеннән. Әнинең әтисе, ягъни бабам Мәхмүт Еникеев, Пенза ягыннан Казанга килеп, укытучылар семинариясендә укыган. Тукай белән таныш булган. Нәкъ менә Тукайның өндәве буенча, бабам Уралга,

хәзерге Башкортстанга балалар укытырга киткән дә инде! Соңрак, совет чорында, зур хезмәтләре өчен Михаил Калинин үз кулы белән аңа орден тапшырган. Ә дәү әнием, ягъни Мәхмүт бабамның хатыны—Арча ягы кызы иде. Гаиләләре белән тегүче булганнар, Башкортстанга килеп, авылдан-авылга күчеп йөреп,тегү теккәннәр. Ул заманда безнең тирәдә тегүчеләр житешмәгән, күрәмсең. Шунда бабам белән очрашып, өйләнешкәннәр. Әбиемнең теккән-чиккән әйберләрен хәтерлим әле. Безне, оныкларын, курчак кебек итеп киендерә иде. Теленнән бер дә Тукай исеме төшмәде, һаман аның шигырьләрен яттан сөйли иде.Үзе гел Арчаны, Казанны сагынып яшәде.

**— Зилә ханым, Нәсибаш—татар авылы. Димәк, башта мәктәптә татарча укыгансыздыр ?**

—Юк шул. Мәктәптә мин баштан ук рус классында укыдым. Ә болай авыл халкы үзара мишәрчәрәк сөйләшә анда.

**—Мишәр авылымыни ул?**

—Әйе. Бик зур авыл, өч мең йортлы. Ана инде 450 ел! Казанда укый башлагач, Вафирә Гыйззәтуллина минем сөйләшүне ишетү белән үк: «Ә, бу мишәр!»—дигән иде. Ул чагында әле мин мишәрнең кем икәнен дә белмим, үземне чын татар дип уйлыйм. Дөрес,бала чагымда әнидән сорый идем, нишләп без Казан радиосы сөйләгән кебек сөйләшмибез, дип. (Көлә).

**—Алдагы соравым Сезнең язмышка төбәп биргәндәй була инде. Берәүләр әйтә,үз милли балалар бакчасы, милли мәктәбе,милли югары уку йорты булса гына, татар милләте сакланып калачак, ди. Ә кемдер гаиләдә милли тәрбия бирүне төп чара дип саный. Улыгыз Рөстәм татарчаны су кебек эчә. Тәрбияме, мәктәпме?**

—Гаилә, һичшиксез, гаилә беренчелрәк! Балачакта гаиләсендә орлыгы салынса, өйдә туган телдә сөйләшсәләр, китап укысалар, үскәч тә туган телен ташламый инде ул.

**—Зилә ханым, тавышыгыз—югары сопрано, бик затлы тавыш. Нәкъ менә операларда җырлар өчен тугансыз гүя. Бу нәзеклек, югарылык каян килә?**

—Югары аваз алырга курыкмау балачактан башланды. Берзаман шулай, әлеге дә баягы, «Маяк»радиосыннан Алла Савинкова дигән җырчыны тыңлап утырабыз, Алябьевның «Сандугач»ын җырлый. Дәү әни дә бездә иде. Тыңлады да: «И-и, кызым, карале, моның тавышы саламнан чыккан кебек бит!»—диде, таң калып. Бик төгәл чагыштыру бит! Нәзек,югары тавышлы диясе килгән инде, димәк.Үзем дә яшьтән үк шактый югары тавышлы идем. Хорда гел башлап җырлаталар иде. «Менә хәзер Зилә җырлый да, сез кушыласыз,» —дип, мине алгарак куя иде укытучыбыз. Өйгә кунаклар килсә дә җырлаталар. Оялганмындыр инде—ишек артыннан гына җырлый идем. Берзаман хыяллана башладым, радиодан җырлаучы булам, дип.

**—Һәм булдыгыз да бит инде!..**

—Әйе шул, булдым. (Көлә).

**—Беренче тапкыр Казанга килүегезне сөйләгез әле..**

—Фәхрибану әбием, безнең якта картәни диләр, гел Казанны сөйли иде дидем бит әле.Анда Кремль бар дип ишетеп үстем.Ул Кремль нииндидер алсу хыял аша, әкияти булып күз алдыма килә иде. Поездда шәһәргә килеп керү белән тәрәзәдән иң элек Кремльне,Сөембикә манарасын күрдем. 1968 ел бу, 18 яшьлек чагым. Чемоданымны күтәреп, вокзалдан җәяүләп үзәккә таба, консерваторияне эзләп киттем. Әллә ике сәгатьләп бардым шунда... Карасам,кабул итү имтиханнары күптән беткән. Ә мин нәкъ менә консерваториягә керергә дип килгән идем бит. Хәтта кайсы педагогта укыячагымны да анык белеп: Лазько Валентина Андреевнада. Йөри торгач, ике айдан мине Нәҗип Жиһанов консерваториягә алды. Аның белән күрешү кызык булды. Юньләп тыңлап та тормады: «Ничә яшь? Унсигез? Биш елдан килерсең», —ди. Мин бирешмим.Кабинетында, теге атаклы ак рояле янында, тагын, тагын җырлап күрсәтәм. Программа таләп иткәнчә әзерләнеп килгән идем: татарныкы булмаса да, башкорт җыры бар, русча да җырлыйм, Европа опералары арияләрен дә.Тыңлады Жиһанов, җырлавымны ошатты. Алай да бәйләнә, кире борырга сылтау эзли.

—Синең буең бәләкәй,—ди бу.
Үзе дә бик озын буйлы кеше түгел иде бит инде. Мин әйтәм:
—Сез дә бәләкәй буйлы бит!
—Ого, настойчивая!—дип куйды гаҗәпләнеп.
—Биш елдан килерсең, дидегез. Мин әле үсәм бит,—дим. Чыннан да, уку чорында—биш ел эчендә алты-җиде сантиметрга үстем! Шулай итеп, Казан кешесе булып киттем. Татарчамны камилләштердем.

**—Сез Казанга максатчан рәвештә, нәкъ менә опера җырчысы булам дип килдегезме?**
—Минем юлым, Уфадан чыгып китү белән, туп-туры барды. Консерваториядә укыганда ук операларда катнаша башлаган идем инде. Укып бетергәч, туры опера һәм балет театрына эшкә килдем.

**—Туган ягыгыз, Башкортстан республикасы үз итәме Сезне?**
—Халыкның белгәне белә инде ул, ярата да үзенчә. Әмма җитәкчелек тарафыннан алай әллә ни зур илтифат сизгәнем юк. 18 яшемнән чыгып китеп, әле дә булса туган төбәгемдә зур иҗат кичәсе уздыра алганым юк. Мортаза Рәхимов, күргән саен: «Кайт, кайт!» дип йодрык күрсәткән була да ул. Үзенчә, якын итүедер инде.



**—Иң мөһим, иң уңышлы рольләрегез дип кайсыларын саныйсыз?**
—Берничәсен искә төшерим: «Кара йөзләр» операсында—Галимә, «Алтынчәч»тә—Алтынчәч, «Муса Җәлил»дә—шагыйрьнең хатыны (Әминә), «Самат» операсында—Әлфия, аннары инде итальян, рус, немец, француз классик операларыннан арияләр. Әйтик, Чайковскийның Иолантасында Иоланта,«Евгений Онегин»ында—Татьяна. Тагын Верди, Моцарт, Пуччини һәм башка бик күп композиторларның операларында җырладым.

**—Тукай премиясен Сез кайсы ролегез өчен алдыгыз әле ?**
—Бату Мөлековның «Кара йөзләр» операсындагы Галимә роле өчен. Ул вакытта композитор Бату Мөлеков үзе, либретто авторы Гәрәй Рәхим һәм төп партияләрне җырлаган ике җырчы—мин һәм Хәйдәр Бигичев—барыбыз берьюлы «Тукай»лы булдык.

**—Халык артисты исеменә дә бик яшьләй ия булдыгыз бугай...**
—Үзебезнең республика исеменә кадәр, иң элек Каракалпакстанныкын бирделәр әле. 1980 елны, шул республикада узган Татарстан сәнгате фестивале вакытында булды ул. Урта Азия чөлләсендә, кояш астында көненә җидешәр-сигезәр концерт биреп йөрдек. Каракалпак республикасыннан мактаулы исем алып кайткач, безнекеләр дә исем бирмичә булдыра алмады инде. Шулай итеп, утыз яшемдә Татарстанның халык артисты булып киттем. Соңрак инде, әйткәнемчә, Тукай бүләге, Россиянең мактаулы исемнәре өстәлде.

**—Татар тамашачысы операга, балетка йөрми диләр. Театр җитәкчелеге үзләренең татар операларың куймавын әнә шуңа сылтап аңлатмакчы. Сез бу фикер белән килешәсезме?**
—Аңламаган кеше операга килми, ә килгәне аны аңлый. Кечкенә генә бер мисал. Опера җырчысы Клара Хәйретдинова бар, авыл кызы. Туганнары, нигездә, авылда яши, Биектау районында. Араларында сыер савучылар, терлекчеләр күп—гади җир кешеләре. Элегрәк, Клара опера-балет театрында эшли генә башлаган чорда, спектакльгә килеп, аңламыйча аптырап утыра иде болар. Сәхнәдә Клара күренгәч, сөенешәләр иде, горурланалар. Шулай, Клараларын күререгә дип йөри торгач, акрынлап спектакльнең эчтәлегенә керә, музыкасын ярата башлыйлар. Бүген әнә

шул апа-җиңгиләр—театрның даими тамашачылары! Гомумән, мәңгелек музыка нәрсә ул—халык көйләре һәм классика. Алар дәүләт ярдәменә мохтаҗ. Тегесе попса дигәне—җыр чүбе—болай да үсә, су сибеп үстермәсән дә.

**—Бервакыт Сезне Италиягә, Миланга вокал буенча стажировкага чакырылган дип сөйләп йөргәннәр иде...**

—Әйе, шундыйрак хәл була язып калды. Омскида театр белән гастрольдә йөрибез шулай. Ул вакытта «Молодые голоса России» дигән фестиваль бара. Безнең арадан унлап җырчыны җыеп, Мәскәүгә җибәрделәр. Консерваториянең камера залында (акустика җәһәтеннән иң сизгер зал!) җырлатып сыныйлар. Европага җибәрү өчен сайлап алу иде бу. Мине вокал «чарларга» Австриягә юлларга булдылар. Әй, сөенеп, сикергәләп йөрдем инде. Италиягә дип сайланган җырчылар китте, ә без, Австриягә җибәреләселәр, чакыру көтәбез дә көтәбез, ә ул юк та юк. Кыскасы, халыкара мөнәсәбәтләр үзгәреп китү сәбәпле, безгә юл ябылды.

**—Алай да, соңгырак елларда чит илләргә күп йөрдегез кебек..**

—Әйе, бик күп илләрдә булдым. Америка, Германия, Франция, Англия, Ирландия, Испания, Финляндия, Төркияне инде әйткән дә юк. Ирландиядә Рубин Абдуллин (аталы органчы, консерватория ректоры—Ф.Н.) белән концерт бирдек. Шунысы кызык: татар халык җырларын органга кушылып җырладым. Көтелмәгәнчә, гаҗәп эффектлы булды. Англиядә исә Рәшит Мостафин оркестры белән ике бүлекле татар концерты бирдек. Анда, татар булмаган җирдә, халык музыкасын тын да алмыйча тыңлыйлар, аягүрә басып кул чабалар. Алар бит татарны кыргыйлар, варварлар дип күзалларга күнеккәннәр,килеп тотып-тотып карыйлар. Гомумән, чит илләрдә бездәге кебек «попса»га, дөбер-шатыр синтезаторлар белән җырлауга исләре китми.

**—Табигатьтән бирелгән тавышың булса, консерваториядә укып йөрмәсәң дә ярый дигән фикерне ишеткәләргә туры килә. Сез моңа ни әйтерсез?**

—Консерватория тәмамлаган җырчының музыканы анлавы бөтәнчә инде анын! Ерак йөрисе юк: заманында Илһам Шакиров, бер нота да белмәгән килеш, авылдан килеп, консерватория тәмамлаган җырчы ич! Ә Хәйдәр Бигичев, гомумән, тракторчы, трактор «аккомпанемент»ына кушылып җырлап үскән егет, Отеллоны җырларлык булып житеште. Беренче тапкыр Төркиягә фестивальгә барганыбыз хәтердә. Баштарак безнең кайбер җырчылар фонограммага заманча көйләр җырлады. Тамашачының исе дә китми, кереп-чыгып йөриләр. Без Хәйдәр белән Рөстәм Яхин романсларын, халык җырларын җырлап җибәрдек, рояльгә кушылып. Залның реакциясе бер мизгелдә үзгәрде. Хәмдүнә әйтә:

—Җүләр икәнмен, синтезаторга җырлап маташам, ә сез булдырдыгыз!—ди. Шуннан баянга кушылып җырларга тотынды һәм зур алкышлар алды. Кыскасы, чит ил тыңлаучысы халык музыкасын, фольклорны һәм классиканы гына югары бәяли. Асыл сәнгатьне чүптән бик яхшы аера беләләр анда.

**—Зилә ханым, Сез—менә дигән җырчы булуыгыз өстенә, вокал педагогы да бит әле. Консерваториядә кафедра җитәклисез, профессор. Әйтегез әле: бүгенге шоу индустриясе заманында югары, классик вокал үрнәгендә тәрбияләнгән җырчылар үз урынын таба аламы?Мәйдан җитәме аларга?**

—Беләсезме, вокалист, урысча әйтсәк, штучный товар бит ул. Ел саен вокал бүлеген дистәдән дә азрак җырчы тәмамлый, һәм аларны опера театрлары шундук суырып алып бетерәләр. Безнең консерваториядә әле тагын халык музыкасы бүлеге бар. Бусы ни өчен кирәкме? Сәләтле авыл баласы, башлангыч музыка белеме булмаса, туп-туры вокал бүлегенә килеп керә алмый бит, менә шуларга юл ачар өчен кирәк ул. Мин ул бүлек студентларына да дәрес бирәм. Мисалга Филүс Каһиров дигән егетне китерәсем килә. Моңы да бар, тавышы да яхшы. Лауреат исемнәрен алды. Бездә укып, зәвыклы җырчы булып чыгар дип өметләнәм. Ул, әлбәттә, халыкчан җырчы булыр. Ә кем белә—бәлки операда да җырлый алыр? Авылдан килеп, мин дә, Хәйдәр Бигичев та, Клара да, Мөнир Якупов та, бөтәннәр дә опера җырчысы була алдык түгелмени! Иң мөһиме—операсы үзебезнеке булсын, милли булсын!

**Флюра НИЗАМОВА**

*«Идел» журналына 20 яшь*

## *МЕНӘ БЕЗ ДӘ ҮСЕП ҖИТТЕК...*

2009 ел—«Идел» журналы өчен бик үзенчәлекле. Безгә 20 яшь тула! Арада ике дистә ел журналга тугры укучыларыбыз бар. Рәхмәт сезгә! Сез безне илһамландырып, дәртләндереп торасыз.




«Идел» һәрдаим яналыкка омтыла. Моны редакция коллективының эзләнүләре нәтиҗәсе диярге дә була. Яна макет, яна сәхифәләр, яна идеяләр синен күнеленә дә хуш килгәндер, хөрмәтле укучым.

Гади кеше, гади язмыш... Еш кына без битараф кыяфәт белән алар янынннан үтеп китәбез. «Идел» әлеге хатаны төзәтү нияте белән сан саен Гади кеше турында кызыклы язмалар бастыра. Ә бөек булу җинелме? Яки тарихи йортлар нигә инри?—болар хакында да син тирән мәгънәле язмаларны безнен «Идел»дә укыйсың, укучым.

Яшь язучылар, яшь шагыйрьләр өчен журнал күптән инде киң иҗат мәйданына әйләнде. Языгыз, бәхәсләшегез, килегез—бездән якты йөз һәм такта чәй!

...Әкрен генә тормыш дәфтәре ачыла һәм кем ничек тели—шулай аның буш битләрен тутыра. Ахырдан эш-гамәлләре өчен һәрберсе үзе җавап тота. Ә менә «Ләүхелмәхфүз» китабының соңгы битенә ниләр теркәлә?—монысын Аллаһ кына белә...

**Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА,**
*баш редактор*

---

● *Егерменче, утызынчы елларда Татарстанда «Колхоз яшьләре», «Комвуз студенты», Мәскәүдә «Яшь авыл», «Яшь педагог», «Яшь эшче» журналлары чыгып ала. Сугыштан соң татар телендә бер генә яшьләр журналы да чыкмый инде.*

● *Татарстан Язучылар берлеге җитәкчеләре яшьләр журналы чыгару мәсьәләсен РСФСР язучыларының I (А. Шамов), II (М. Әмир), III (Г. Ахунов) съездларында кузгаталар. Ләкин эш гел КПСС Үзәк Комитетына терәлеп кала.*

● *Татарстан язучыларының 1968 елның 25 мартында үткән VII съездында балконнан листовкалар ыргытыла. Аларда татар телендә яшьләр журналы чыгару таләп ителә.*

● *1970 елда яшь язучыларның «Идел» альманахы чыга башлый. 1989 елда аңа алмашка «Идел» яшьләр журналы килә. Ул татар һәм рус телләрендә чыга.*

● *Журналның беренче баш мөхәррире—Римзил Вәлиев. Аннары «Идел»гә Фәиз Зөлкарнәй (1991—1997), Рашат Низамиев (1997—2006), Нәбирә Бикчурова-Гыйматдинова (2006 елдан) җитәкчелек итә.*



Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

# *ТАШКА ОРДЫМ БАШНЫ*

Үз халкыңны ярату хисе кайдан килә? Кайчан пәйда була ул? Моңа төгәл генә җавап бирү авыр... Шунысы шөбһәсез, халкыңны яратыр өчен син үз мәдәниятеңнең вәкиле булырга тиеш. Гасырлар дәвамында тупланган рухи байлыкка үзеңне ия итеп тою, мең ел элек яшәгән кан кардәшләрең белән ике арадагы бәйләнешне сиземли алу—күпләргә тәтеми торган бәхет... Һәм сагыш... Йөрәк булып укмашып күкрәк читлегенә кагучы сагыш...

Телеңнең байлыгын, тирәнлеген, тарихилыгын белеп, белеп кенә түгел, аның коралына әверелеп! үзеңнең кирәксезлегеңне тою... чал мәдәниятеңнең юкка чыга баруына шаһит булу бәхетсезлеге.

Шушы хәлгә килешмичә ничек сөрән салмыйсың?!

Ләкин алда салкын таш дивар. Битарафлык дивары.

Күпме генә кычкырма, беркем ишетми, беркем искәрми. Һәркем үзенең көндәлек мәшәкате белән мәшгуль. Һәм аларны гаепләп тә булмый. Димәк, милләтнең умырткасы сынган, үз-үзен саклау инстинкты юкка чыккан.

Хәер, нигә милләт дидем әле? Дәүләт тотучы, һәм шул дәүләтне үз милли мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру чарасы итә алган халыкны гына милләт дип атарга мөмкин.

Тарихлардан килгән рухи мирасын белмәгән, белсә дә, аңа кимсетеп караган, бары тик чит халыкларның мәдәниятенә ирешергә омтылган халаяк милләт исеме белән аталырга хаклы түгел.

«Татар угълы татармын!»—дип горурланып язган бөек Дәрдмәндне күпләребез кабатлый алмый инде. Хәзер күпчелекне татар угыллары, татар оныклары тәшкил итә... татарлар түгел.

Бала туу йортларына кереп яңа туган нарасыйларны поплар чукындырып чыга—халыкның исе дә китми.

Шулар ук уртак ватан дидекемез Русияне сакларга—кемнән?—килгән егетләребезгә «изге су» бөркеп йөри—без ләм-мим.

Милли һәм төбәк компонентларын мәктәп программасыннан алып ташларга—димәк, татар телен мәктәпләребездән куып чыгарырга!—дигән канун чыгаралар—халыкта ник бер дулкынлану әсәре сизелсен... Ул гынамы, шул канунны гамәлгә кертүче фиркага сайлауларда сиксән процентка кадәр тавышыбызны бирәбез. Димәк, үзебез үк телебезгә, асылыбызга булган шушы һөҗүмне яклыйбыз...

Пушкин Русиядәге даими вәзгыятьне ике сүз белән бик төгәл әйтеп биргән: «Народ безмолвствует».

Ләкин Пушкин яшәгән заманда әлеге билгеләмә безнең халыкка туры килми иде! Октябрь инкыйлабына кадәр татар рухи бәйсезлеген җуймыйча яшәде. Милли-мәдәни кысрыклауга каршы тиешле җавабын да бирә белде. XIX гасырда инде татар милли мәнфәгатьләр өчен канкоешлы фетнәләр белән түгел, төрле прошениеләр язып, судлар аша көрәште. Тарихчылар яхшы белә, архивларда андый хатлар, гаризалар йөзләгән, меңләгән... Дөрес, татар төрле мәктүпләрне Мәскәүгә XX гасырда да күп язды, бүген дә яза... Тик аларның эчтәлеге башка. Бер-берсе өстеннән өлкән туганга жалу яза хәзерге татар угълы.

Чү, сүз башың бит Шүрәле иде, диярләр. Үз халкынны ярату турында башладын да...

Нәкъ шулай!

Нәфрәтләнә белгән кеше генә ярата ала.

Мөштәри урамында, Язучылар йортына каршы, шактый таушалган борынгы бер йорт бар. Яшь Ульяновны шунда кулга алганнар. Исегездәме, аны мәхбүс итәргә килгән жандарм офицеры гыйсъянчы студентка: «Алдында бит стена!»—дип әйткән, имеш. «Стенасын стена, ләкин черек»,—дип жавап биргән булачак Ленин. Мондый диалог, әлбәттә, кайсыдыр совет язучысының хыял жимеше генә... Әмма зур мәгънә бар бу сүзләрдә!

Заманында һуннардан саклану өчен Кытайның беренче императоры Шихуанди йөзләрчә чакрымга сузылган бөек дивар өйдергән.

Диварны җимереп була, ләкин аның артында сакланырга да мөмкин.

Һәр халыкның гореф-гадәте, йолалары, жыйнап әйткәндә, мәдәнияте шундый дивар ул. Дөнья жилләренә күңелең ачык булса да, йөрәгеңдә шундый какшамас дивар булырга тиеш.

Даланың кодрәтле хуҗалары һуннар кайда бүген? Кытай дивары күптән инде чик сызыгы түгел, ул бүгенге бөек дәүләтнең эчендә калды. Анын өстендә бүген туристлар йөри. Гыйбрәт дивары!

Һуннарның варислары булган Алтын Урда татарлары үз шәһәрләре тирәли дә дивар кормаганнар. Дала үз балаларын күңел киңлегенә дә тиендерә, күрәсең. Ләкин күңел киңлеге еш кына ачыгавызлык дигән сыйфатка да әверелә. Алтын Урда кодрәтле заманнарда бу якларга килгән бер көнбатыш сәяхәтчесенең язмасы истә калган. «Нигә сез калаларыгызны диварлар белән ныгытмыйсыз?»—дип сорый ул бер морзадан. «Диварны куркаклар гына кора,—дип жавап бирә тәкәббер татар.—Ә без кемнән куркыйк?» Күп вакыт та үтми, илдә үзара ызгыш китә—1360-1380 елларда тәхеттә 25 хан алышына, урыс елъязмачылары бу чорны «великая замятня» дип атыйлар,—шунардан файдаланып берничә мең урыс ушкуйнигы көймәләр белән Идел буйлап төшеп ханлыкның башкаласы Сарайны талыйлар, хан казнасын төяп китәләр. Бераздан Аксак Тимер чирүе Алтын Урданың барлык шәһәрләрен тар-мар итә. Татар иле шуннан соң инде күтәрелә алмый, таркала.

Сарай шәһәренең ташлары бөтен Русиягә сибелгән. Әмма алар дивардан түгел, искиткеч гүзәл биналарның, кабер ташларының кыйпылчыклары. Куеныңа салып куй берәрсен, татар угылы татар!

Дивар корырга яратмасак та, без анда-монда ташлар калдырырга маһир халык. Шундыйларның берсенә абынып егыла язган студент гәзиткә хат язып жибәргән. Иелеп кардан чистартса, туксанынчы еллар башында куелган бу ташка: «Монда Шиһабетдин Мәржанигә һәйкәл булачак»,—дип язылган икән.

Куелмаган һәйкәл тирәсендәге бәхәсләрне хәтерлим әле мин. Ана дин әһелләре бик ярсып каршы төшкәннәр иде. Янәсе, шәригатьтә кешегә һәйкәл кую катгый тыела. Алар шулай итеп һәйкәлне пот белән тәңгәлләштерделәр. Хәер, алар каршы төшмәсә дә һәйкәл куярга атлыгып торучы юк иде, ахрысы. Татарның пары бәхәсләшкәндә чыгып бетә аның.

Сәйдәшкә һәйкәл кирәк, дип күпме лаф ордык. Мәдәният фондында (а-у, кайда ул хәзер?) кемнәрдер шул ниятне сылтау итеп халыктан байтак кына акча да жыйды. Ә сынчылар, рәссамнар туктаусыз бәхәсләште, түрәләр бөек аһәңдарга лаеклы ландшафтны таба алмый интекте. Ул арада бернинди тавыш-тынсыз гына Казан үзәгендә Шаляпин һәйкәле калкып чыкты. Шунысы гажәп, татар булмаганнар сынлаштырылса, бернинди бәхәскә урын калмый бездә, ландшафт та тиз табыла. Менә шул, Сәйдәш һәйкәлен салырга дип жыелган халык акчасы ничектер бик сәер рәвештә юкка чыкты, инде пар да чыгып беткән иде, рәхмәт Шәймиевкә, ниһаять, Сәйдәш һәйкәлен дә күрүгә ирештек. Тик нигәдер ул ТДГПУның (гуманитар-педагогика университеты, Татар дәүләт университетын ачу урынына педагогия институтының исемен шулай мәгънәле итеп үзгәрттеләр) яңа бинасы каршына куелды. Аңа тәгаенләнгән урында исә «Бакыр бабай»—империя стилендә эшләнгән Державин һәйкәле утыра. Ландшафт шулай кушкандыр, хәерле булсын.

Шул ук туксанынчы еллар башында берничә мөфти (хәзер ике мулланың берсе мөфти) Екатеринбургның үзәгендә «Монда җәмигъ мәчете булачак» дигән язулы таш куюны оештыра. Сөенә-сөенә халык җыела. Дөрес, мөфтиләрнең аларда гаме булмый. Янәшәдә—гарәп илләреннән килгән вәкилләр! Икенче көнне оештыручылар истәлек ташын кай тарафкадыр алып китәләр. Баксаң, шәһәр хакимияте белән килешенмәгән, урын тәгаенләнмәгән, әлеге тамашаны гарәп химаячеләреннән шактый акча каеру максатында уйнаганнар икән...

Кремль дивары янында тагын бер истәлек ташы бар. Казанны саклаганда шәһид киткән бабаларыбызга шул төштә һәйкәл куелачагы турында язылган анда. Хәтеремдә, әлеге мәсьәлә 1992 елда Татарстанның Фәннәр академиясендә, «Мирас» җәмгыятенең (а-у, кайда син?) утырышында тикшерделәр. Шәһәр мэриясе һәйкәл проектына конкурс та игълан иткән иде. Аның берничә турын да үткәрделәр. Гадәттәгечә, бәхәс купты. Әлеге дә баягы ландшафт туры килми, дип аның урынын каршы як дивар кырына билгеләделәр. Хәзер әлеге һәйкәлне салу турында сөйләнгән кеше күренми. Пар чыгып бетте. Сәяси вәзгыять тә үзгәрде. Беренче урыс инкыйлабыннан соң татарда «яфрак асты» дигән төшенчә киң кулланышта булган. Бүген бу безгә дә туры килеп тора.

Югыйсә Казанны саклап шәһид китүчеләргә һәйкәл булмавы тарихи гаделсезлек бит! Чөнки аны яулап алганда һәлак булучыларга памятник 1826 елда ук куелган һәм ул әле дә Казан елгасында, Кремльгә каршы, кукраеп утыра бирә. Инде аның башына тәре дә утырттылар, ул памятник кына түгел, гыйбадәтханә дә. Кашындагы атамасы да (әлегә акшарланган) мәгълүм: «Победа над татарами» дип язылган анда!

Шунысын да әйтү урынлы булыр, әлеге гаделсезлек татарның бәгырен даими тырнап торган. Инкыйлабтан соң «хөррият» килгәч, 1924 елда Татарстанның Үзәк башкарма комитеты РСФСРның Мәгариф халык комиссариатына тәкъдим белән чыга: «О разрешении переконструировать памятник «Победа над татарами» в «Памятник содружества народов». Мәскәү бу тәкъдимгә каршы төшүен төшми, әмма һәйкәлнең исеме үзгәртелмичә кала. Хәер, исемен үзгәртеп кенә аның асылын алмаштырып буламыни?! Шуңа күрәме, 1935 елда Татарстанның Үзәк башкарма комитеты рәисе Г.Байчурин ВКП(б) өлкә комитетына һәйкәлне юкка чыгарырга тәкъдим итә. Янәсе, ул инде җимерек хәлдә, аны төзәтер өчен кирәк булган 65 мең сум акча бюджетта юк. Мәскәүдәге тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау комитеты бу тәкъдимне хупламый. Ләкин татарларны җиңү хөрмәтенә салынган һәйкәл үз урынында кала бирә! Димәк, кемнәргәдер аның татар бәгыренә кадалган ханҗәр сыман тырпаеп торуы кирәк булган. Меңләгән чиркәүләрне, мәчетләрне җимергән заманда колониализмга һәйкәл буларак салынган бинаның сакланып калуын бүтәнчә ничек аңлатасың?

Һәйкәлләрне җимерергә кирәкми. Ватанны яклап соң тамчы каннарына кадәр сугышып һәлак булган бабаларыбызга җыйнак кына бер һәйкәл куярга да мөмкинлегебез юк икән, без халык телендә «Грозный һәйкәле» дип аталган чиркәүгә карап гыйбрәт алыйк. Нинди хәлдә калганлыгыбызны аңларбыз бәлки.

Ташка ордым башны!

Йә таш, йә баш ярылыр,—дигән сүзләрне мәрхүм шагыйребез Илдар Юзи зинданда үз-үзен һәлак иткән декабрист Булатов авызыннан әйттерә.

Кайсысы ярылачак—монысы һәркемгә аңык.

Ләкин ташларның җаны юк дип тә беркем раслый алмас. Ташлар да елый...

Күктүбәдә тау башында җирләнгән урыс шагыйре М.Волошин үз каберенә чәчәкләр түгел, һәркемнең бер таш алып менүен васыять иткән. Хәзер кабер өстендә ташлардан шактый зур калкулык өелгән.

Куендагы ташны Татар диварының нигезенә салыйк. Дивар калыкмаса, татар дигән халыкның кайчандыр бу җирдә яшәвенә ишарә булып, шул ташлардан бәлки нәни генә калкулык үсеп чыгар...

*2008 ел, март*

*Мин!*

**Аделия ӘСХАТОВА**

# *«ТАТНЕТ—ТАТАР ХАЛКЫН ҺӘРТӨРЛЕ БӘЛАДӘН КОТКАРА ТОРГАН ДӘВА ТҮГЕЛ»*

*Айнур Сибгатуллин—Халыкара «Татнет йолдызлары» интернет-проектлар конкурсы рәисе, Татнет турында күпсанлы язмалар авторы, «Татар тарихы җәмгыяте» сайтын алып баручы.*

**—Айнур, син «Идел» журналы сәхифәләрендә Татнет турында үз фикерләрең белән уртаклашканнан соң күп вакытлар үтте. Бүген үзең өчен нинди яңа ачышлар ясадың?**



—Әйе, бу чорда яна ачышлар күп булды. Алар арасында яхшылары да, начарлары да бар. Шулай да, яхшылары күбрәк. Болар—интернет-проектлар, яңа кешеләр, яңа идеяләр. Тулаем алганда, минем өчен WEB 2.0дә ачышлар саны күбрәк булды. Алар арасында социаль челтәрләр, блоглар, википедия, yourtube кебек видеохезмәтләр һәм башкалар бар. Татнет бөтендөнья пәрвезе үсешенең төп юнәлешләренә ияреп барырга тырыша, шулай да бераз артта калабыз әле. Хәер, Татнет кайбер нәрсәләрдә интернет челтәрендәге күп кенә милли секторларны нык узып китте. Мәсәлән, Windowsны татар телендә җәелдерүдә. Дөрес, бездә «Duslar.ru» исемле татарча социаль сайт бар инде, әмма анда аралашу нигездә рус телендә бара. Татарстан Республикасында «Электрон Татарстан» программасы кысаларында бик өметле проектлар эшли башлады, ләкин дәүләт органнары сайтларында татар теле күз буяу өчен генә саклана. Татнетка ярдәм күрсәтү өчен бюджетлар, грантлар, республика кануннары кирәк.

**—Өченче Бөтендөнья татар яшьләре форумы секцияләрендә татар сайтлары турындагы мәсьәлә тикшерелде. Күп кенә кешеләр, татар сайтлары яшьләр арасында популяр түгел, дигән фикер әйтте.**

—Беренчедән, күп кенә милләттәшләребез татар телендә сайт бар дип уйламый да. Ә кеше белмәгән нәрсә ничек популяр булсын ди инде? Икенчедән, интернетта иң күп укыла торган сайтлар—ул, кагыйдә буларак, профессиональ веб-студияләр тарафыннан эшләнгән сәүдә проектлары. Әлеге сайтларны булдыруга берничә йөз мең, хәтта миллион доллар сарыф ителгән. Һәм алар Татнет сайтларыннан техник яктан күпкә өстен. Өченчедән, татар сайтларына туган теле, тарихы, мәдәнияте, традицияләре белән кызыксынган татарлар гына керә. Әгәр кеше боларның барысына да битараф булса, ул һич тә Татнет белән кызыксынмаячак.

**—Татнетка соңыннан үти алмаслык зур өметләр баглыйбыз дип уйламыйсыңмы?**

—Татнет—татар халкын һәртөрле бәладән коткара торган дәва түгел. Татнет—ул ассимиляцияләшүгә каршы чаралар күрү һәм татарларның милли үзаңын саклау коралы һәм калканы. Аны милләтебезнең киләчәге хакына оста итеп файдаланырга мөмкин. Татнет—ул кешеләрне яңа проектларга, актив эшчәнлеккә, телне,

мәдәниятне һәм тарихны өйрәнүгә рухландыручы аралашу өлкәсе. Шул ук вакытта ул нинди дә булса сайтларда аралашканнан соң, күпмедер вакытка татарлыктан ваз кичтерү көченә дә ия.

**—Без Казан дәүләт университетының татар филологиясе студентлары арасында сорашып белешү үткәргән идек. Безнең «Сез татар сайтларына еш керәсезме?» дигән соравыбызга, ни кызганыч, күпләр: «Кызыксынмыйм» яки «Кирәкле дип тапмыйм» дип җавап кайтарды. Синеңчә, мондый мөнәсәбәт нәрсәгә бәйле?**

—Моның сәбәпләре күп булырга мөмкин. Әйтик, интернет өчен акча түләргә кирәк, ул күп вакытны ала, студентка укырга, өстәмә рәвештә акча эшләп алырга вакыт калмый. Күпчелек кеше өчен интернет бер мавыгу шикелле генә. Хәзер барысы да «Классташлар» («Одноклассники») сайты белән мавыга. Бередә татар сайтлары Рунетта иң күп ачыла торган сайттан һәрчак калыша. Нәрсәне үзгәртергә кирәк, дисезме? ТР хакимиятләренең татар теленә мөнәсәбәтен үзгәртергә—Татнет үсешенә акча бүлеп бирергә кирәк.

**—Казанда татар яшьләре бераз сүлпәнрәк. Ә Мәскәүдә алар активмы?**

—Мәскәүдә яшәүче татар яшьләре Казан яшьләренә караганда активрак дип әйтмәс идем. Әйдәгез, актив яки пассив төшенчәләренең нәрсә анлатканын ачыклап үтик әле. Моны ничек бәяләргә? Татар дискотекаларына яки сабан туйларына йөрүчеләр саны белән дисезме? Кызганыч ки, яшьләр «активлыгы»ның зур өлеше шунда гына күренә шул. Мин татар яшьләренең активлыгы чәй эчеп утырудан яки дискотекаларда биюдән тыш, реаль эшләрдә—өмәләрдә катнашуда, хәйриячелек белән шөгыльләнүдә, сәяси таләпләрне яклауда, үзеннең һөнәри осталыгыңны милләтебез үсеше хакына риясыз куллануда ачыграк күренә дип уйлыйм.

**—Халыкара «Татнет йолдызлары» интернет-проектлар конкурсы турында да фикерләрегез белән уртаклашсагыз иде. Анда нинди яңалыклар булды?**

—Алты ел рәттән үткәрелгән соңгы конкурста 237 сайт катнашты. Бу—рекордлы сан. 234 сайт Россия Федерациясеннән, шул исәптән 217 сайт Татарстан Республикасыннан һәм 3 сайт чит илләрдән (Казакъстан, Үзбәкстан, Канада) иде. 127 нче веб-студия һәм аның житәкчесе, конкурсны оештыру комитеты әгъзасы Марат Мамяшевның актив ярдәме белән конкурс сайтының тулы редизайны һәм логотибы эшләнде. Без шулай ук сайт контентын нык үзгәрттек, конкурс һәм Татнет турында күп материаллар, видеоязмалар, шул исәптән минем «Татар интернеты» исемле китабымның тулы электрон версиясен өстәдек. Моннан тыш, оештыру комитеты әгъзасы Раил Гатауллинның актив ярдәме белән конкурс сайты татарчага тәрҗемә ителде. Сайтның адресы үзгәрде—без икенче дәрәҗәдәге доменга күчтек. Хәзер безнең адресыбыз—tatar.su. Жюри һәм оештыру комитетының составы да үзгәрде. Жюри рәистәше итеп ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Исмәгыйль улы Вәлиев сайланды. Жюри составына элеккечә Рунет, Азнет, Казнет һәм Үзнет интернет-индустриясенең төп белгечләре кертелде. Татар телендәге сайтларның эчтәлегенә бәяләмә бирүче жюри әгъзалары арасында «Идел» журналы баш редакторының беренче урынбасары Азат Ахунов та бар. Корпоратив сайтлар да күп. Масс-медиа сайтлары да сан буенча алардан аз гына калыша. Шуның белән бергә без татар телендәге өч сайтны да саклап калдык. Һәрхәлдә, без «Татнет йолдызлары» конкурсы Татнет сайтлары, бигрәк тә татар телендәге сайтлар санының артуына булышлык итәр, дип уйлыйбыз. Әгәр моңа ирешә алсак, конкурсны оештыруыбыз бушка китмәгән дип исәпли алачакбыз.

**—Синең «Татар интернеты» исемле китабың татар телен, аның тарихын һәм мәдәниятен яратучылар арасында популярлык казанды. Мин аны актив яшьләр өчен «юл күрсәткеч» дип тә әйтер идем. Шундый авыр эшкә керешкән чакта син үз алдыңа нинди бурыч куйдың?**

—Китап чынлап та юл күрсәткеч рәвешендә язылды. Минемчә, татарлар яшәгән һәр төбәктә кешеләр Татнеттан нәрсәне һәм ничек табарга мөмкин икәнлеген белеп торырга

тиешләр. Бу китапта минем Татнеттагы эшемә нәтиҗә ясала. Аның ярдәмендә һәр кешенең татар мәгълүмати кинлегенә тиз генә кереп үзенен үсеше өчен бик күп файдалы мәгълүматлар алуын теләр идем. Хәзер мин «Татар интернеты» исемле китабымның тулыландырылган икенче басмасын әзерлим. Ул беренче китаптан нык аерылып торачак. Атап әйткәндә, татар телендәге барлык сайтларны җентекләп тикшерергә исәплим.

**—Киләчәктә Татнет активистларын нәрсә белән шатландырырга телисең? Яңа планнарың бармы?**

—Үз блогым—rahmetov.ru белән эшләячәкмен. Татарлар турында википедияләр (tatar.info) проектын ахырына җиткерергә телим. Ислам интернет-премияләре проекты чиратта тора. Бер ел элек үзем аны үткәрү тәкъдиме белән чыккан идем. Күптән түгел генә РФ Элемтә министрлыгы карамагындагы эшче төркем составына кертелдем: мин анда интернет челтәрендә күптеллелек темасын тормышка ашырачакмын.

## *Галәмәт*



**Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА**

## *«ЗИНҺАР, МИНЕ ДӘ КАЛДЫРМА...»*

Гомер бакый изгелек белән яманлык этешә-төртешә бер сукмактан атлаган. Кайсы җиңгән дә, кайсы җиңелгән дип өздереп әйтә алмыйбыз, чөнки дөньяда аларны үлчәп барырлык үлчәүләр юк. Ләкин: «Шайтан гына өметсез» диләр. (Ник дигәндә, тәүбәгә килсә дә Аллаһ тарафыннан аңа кичерү булмаячак). Без һәрвакыт изгелек өскә калкып чыга дип ышанабыз. Тикмәгә генә борынгылар «Изгелек җирдә ятмый»,—димәгәндер, күрәсең. Ник мин һәрберебезгә дә таныш мәңгелек төшенчәләр турында сүз куертам соң әле? Без үзебез үк катлауландырырга яраткан шушы гап-гади тормышта чәбәләнеп-чуалып беткән хәл-вакыйгалар очрый, һәм ни гаҗәп, болар йә изгелек, йә яманлык белән бәйле була. Рәмзия ханым Казан бисталәренең берсендә яши. Ул тумышы белән Арча кызы икән. Күңелендә биклəп-саклап йөртүе авыр, күрәсең, кунагыбыз үз башыннан кичергәннәрен әрни-әрни сөйләргә тотынды.

—Сүземне әнидән башлыйм. Чөнки бу хикәятемнең төп герое—ул. Алдан ук әйтеп куям, мин аны һич кенә дә яманларга җыенмыйм. Еллар узды, яралар төзәлде, үпкә-сапкалар онытылды инде. Ләкин төзәтеп-матурлап та сөйлисем килми. Алай ул ялган булыр иде. Элек татар авыллары әхлаклы иде дисәк тә, анда да җилбәзәк кызлар, азгын егетләр бар иде. Сирәк иде, әлбәттә. Минем әни яшьлегендә чибәр кызлардан санала. Шуңа күрә, матурлыгыннан масаеп, егет арты егет алыштыра. Хәтта күрше авыллардан да аны озатыштырып йөриләр. Ил-көндә бер яманатың таралса—аны төзәтүе бик авыр икән, әни кияүгә чыгып, балалар тапса да, аңа тагылган «җилбәзәк» кушаматы шул килеш кала. Житмәсә, әтигә барганда ул авырга узып өлгерә. Усал телле каенанасына: «Син фәлән иден»,—дип чеметеп торырга җитә бу. Әти дидем дә... Бер-бер артлы туган ике малайдан соң, әти саналган бәндә акча эзләп Себергә китә. Ул аннан кире әйләнеп кайтканда дөньяга мин —бәхетсез җан туам. Ник «бәхетсез» диярсез, чөнки әти гаиләсе өчен мин уйнаштан туган

бала саналам. Болай да әнидән көнләшкән әти, күзен дә йоммыйча, Аллаһтан да курыкмыйча: «Син ирен читтә чакта бүтән белән чуалгансың, бу кыз минеке түгел, малайларны калдыр да, балаң белән әниләреңә олак»,—ди. Аңа каенана да кушыла: «Жирбит, оятсыз, сөйрәлчек, һаман элеккеләрне куасың, фәлән-фәсмәт». Кыскасы, икәүләшеп әнине эт итеп тиргәп ташлый болар. Абыйларга ни, алар бит әле сабый гына, берсе дә җәберләнгән ананы яклый алмый. Әни нишли? Әлбәттә, үзенең гаепсез икәнен аңлатырга тырыша. «Бала синеке»,—дип, әтинең аяк астына ятып-ятып елый. Тегеләрнең барыбер күнеле йомшармый. Нәтиҗәдә, без сукыр әбинең сәләмә йортына кайтып егылабыз. Әни мине җүнләп карамый, сукыр карчыкка ыргытып, киенеп-бизәнеп эшкә йөри. Кибеткә сатучы булып урнаша ул. Моны әтигә үч итеп эшләгәндер инде. Безнең заманнарда авыл ирләре өчәр-өчәр «борын»га укмашып кибеттә эчеп ята иде бит. Әни мут та, чибәр дә, телгә дә оста. Ирләр аның белән сүз уйнатыр өчен генә дә кибеткә сугылып үтә. Әти ара-тирә килеп ком бураннары да кузгатып китә, тик файдасы гына булмый: һәр тавыштан соң кибеттә ирләр отыры күбәя. Ир белән хатын бер-берсеннән көнләшеп арыгач, алга табан ызгышып-талашып яшәү мөмкин хәл түгеллеген аңлый һәм килешү төзеп карый. «Кибетеңне биклә дә, өйгә—балалар янына кайт»,—ди әти. Куанычыннан әнинең башы түшәмгә тия. «Хәзер Рәмзияне алам да, кайтам, бәгырь җимешем»,—ди ул. Шунда әтинең күзе-кашы җимерелә. «Сөйрәлчектән туган баланны күземә күрсәтмә,—дип акыра ир.—Йә син, йә кызың. Сайла!»

Әни, билгеле, ике ут арасында яна. Житмәсә, аңа гайбәтчеләр: «Ирең өйләнергә хатын эзли»,—дигән хәбәр ирештереп торалар. Менә шунда әни миннән котылырга ниятли дә инде. Мине курчак кебек киендереп, Казанга юл тота. Киров урамында без автобустан төшәбез. Анда Нурулла мәчете чаты бар. Әни мине шул чатта утыртып куя да, үзе урамның икенче ягында яшеренеп карап тора. Аның уенча, кемдер баланы җәлләп алып китәргә тиеш. Аннан соң ул котылдым дип, җиңел сулап авылга—ир йортына йөгерәчәк.

...Мин башта кызыксынып тирә-якны күзәтәм. Ят урын, ят кешеләр... Аннан нәни йөрәгемә шом үрмәли. Әни кайда соң? Ул миңа: «Тик кенә утыр, мин сиңа курчак эзлим»,—дигән иде. Нишләп озаклады икән?» Көтеп-көтеп тә килмәгәч, шыңшый башлыйм. Үткән-сүткән миңа игътибар итә. Мәчеттән әллә ничә тапкыр чалмалы бер карт чыгып, минем тарафларга күз салып ала. Шыңшу зур тизлек белән үкереп елауга әйләнә. Бу юлысы минем каршымда башта бер-ике, соңрак өч-дүрт кеше туктый. Теге чалмалы бабай да тек-тек атлап килеп баса. Олылар пошаманга төшеп:

—Кем баласы икән?—диләр.—Адаштынмы әллә?—диләр. Чалмалы карт:

—Күптән утыра бит бу нарасый, әллә милисә чакыртыйк микән, җәмагать?—ди.

Мин тагын да катырак елап җибәрәм. Яныма кешеләр җыела да җыела.

«Бу хәлләрне энәсеннән җебенә кадәр ничек хәтерлисең? Сиңа бит нибарысы ике генә яшь булган!»—дип гаҗәпләнмәгез. Мин әни теле белән бәян кылам. Соңыннан ул барысын да үзе сөйләде.

Әнинең өметләре акланмый. Мине милиционер да култыгына кыстырып китми. Күрәсең, әнинең мәрхәмәте уянгандыр, бәлки кызгангандыр, ул, ах-вах итенеп, төркем эченә ташлана. «Әй кызым, кибеттә чират иде»,—дип, мине кулына күтәрә.

Хәзер мин үз хатирәләремә күчәм. Шаяртып әйткәндә, үз телемә сүз бирәм. Әни белән әти һаман кавышмыйлар. Абыйлар ата йортында, ә мин сукыр әбидә үсәм. Әни көннән-көн явызлана, бер сәбәпсезгә мине кыйный. Үземне белә-белгәндә мин сәгать саен тукмала идем инде. Әни бөтен бәхетсезлеген миннән күрә иде. Ул гел-гел бер төрле такмаклар иде:

—Үлмисең дә ичмасам! Синең арканда мин ирсез тилмерәм. Үлсәң—кабер туфрагыңны таптап-таптап күмәр идем.

Бервакыт ул мине урамнан чәчемнән сөйрәп барды. Әлеге дә баягы әче битәр:

—Үлмисең дә ичмасам! Суга да батмыйсың ичмасам!

Шунда безгә авыл абыстае Гайшә әби очрады.

—Кызыңны бик рәнҗетәсең икән дип ишеткән идем, Рауза, хак икән,—диде ул.—Картаймыш көннәреңдә шушы бала кулыңа калмагаен әле,—диде.

Әни авызыннан төкерекләр чәчрәтә-чәчрәтә җавап кайтарды:

—Калмам, калмам, абыстай! Минем ике малаем бар, алар багыр,—диде.

Сигезенче сыйныфтан соң мин авылдан качтым. Башта педагогия училищесында укыдым. Аннары институт тәмамладым. Авыл турында онытырга тырыштым. Сукыр әби мәрхүмә иде. Ә әти белән әни никах янарткан иде. Кунакка кайтам дисәм дә, газиз нигезем юк иде минем. Әниләрнең тормышы бозылыр дип тә шикләндем. Мәрхәмәтсез әти мине барыбер кызым дип танымас иде.

Аллаһы Тәгалә бәхет капкаларымны бикләмәгән икән, мин әдәпле, тәртипле егет белән гаилә кордым. Өч балабыз туды. Үзем ана назы тоймыйча үскәнгә күрә аларны яратып-сөеп туялмадым. Иремдә дә бала ярату хисе бик көчле иде. Ул төзелештә участок башлыгы иде. Акчага беркайчан да кытлык кичермәдек. Фатир да алдык, шәһәр читендәге бистәдә яңа йорт та салдык. Шулай тернәкләнеп яшәп ятканда гына авылдан коточкыч хәбәр китерделәр. Мин элек тә туган яклардан күнелсез хәбәрләр ишетә идем. Ике абый да эчә икән, беркайда да эшләмиләр икән. Монысы адәм ышанмаслык иде: әниләрне өйдән кыйнап чыгарганнар. Карт белән карчык күршеләрнең кара мунчасында тереклек итә ди. Иремнән берни дә яшерми идем. Ул кинәт кенә әйтеп куймасынмы!

—Әйдә, икесен дә үзебезгә алып килик. Йорт иркен, рәхәтләнеп торсыннар.

—Юк, юк!—дип кычкырганымны үзем дә сизмәдем. Йөрәгемдә нәфрәт уты дөрләде. Мине каккан-суккан чит-ят кешеләр нишләп бусагамнан атларга тиеш әле. Яшәсеннәр, мунча тәс аларга!

Ун көннәр чамасы янып-көеп йөрдем. Ахырдан сабырландым. «Дөньяда ана хакы дигән нәрсә бар, һичьюгы шунысын уйларга кирәк, Рәмзия»,—дидем.

Ирем белән авылга киттек. Андагы кичерешләремне сөйләсәм—елармын дип куркам. Карт белән карчык мунча пәриләренә әверелгән: икесе дә корымга буялган, икесе дә шыр сөяк. Тамак төбенә төялгән утлы төерне йотып, әнигә эндәштем:

—Әйдә, киен, син безгә күченәсең.

Әни йомгак кебек аяк астыма тәгәрәде. Үзе:

—Кызым, җимешем, кайлардан очып кунган фәрештә соң син!—дип тәкрарлый.

Мин, билгеле, әти дигән кеше тарафларына күз дә салмыйм. Ул аякларын салындырып ләүкәдә утыра. Безнең сүзгә катнашмый. Әнине култыклап машинага илткәндә генә артыбыздан чыкты. Сез инде, бу хатын шулай китеп барган, диярсез. Юк шул, зәгыйфь, мескен тавыш бөтен җанымны айкады:

—Зинһар, мине дә калдырма, мин бит синең әтиең, кызым...

*Алмагачның алмасы*

**Искәндәр СИРАҖИ**

# *Нәфисә Хәйруллина: «АРТИСТКА БУЛМАСАМ— БӘХЕТСЕЗ БУЛЫР ИДЕМ»...*

Хатын-кызлар очрашса—иннек-кершән, ирләр очрашса—хатын-кызлар хакында сөйләшә бит инде. Филармониядә бер төркем ир-ат сөйләшеп утырабыз. Сүз башлыча хатын-кызлар хакында бара: яшьрәкләр мәхәббәт фронтындагы җиңүләре белән мактана, өлкәнрәкләр тегеләй яки бу сәхнә йолдызының яшь чагын искә ала. Шунда Илһам Шакиров әйтеп куйды:

—Г.Камал театры актрисасы Фирдәвес Хәйруллина ифрат чибәр иде—гашыйк булып та йөрдем...

Әйтте дә, бетерде—башкача ләм-мим. Бөтенебез кызыклы тарих көтсәк тә, олуг җырчы сөйләмәде. Ә менә Фирдәвес ханым үзе бер очрашканда сөйләде. Ул чакта инде вафатына да санаулы көннәр генә калган иде булса кирәк.

—Казан театр училищесында укып йөргән чак. Безнең курс белән очрашуга Илһам Шакиров килде. Әле яшь, матур чагы, җор телле кеше—сүзгә кесәгә керми. Күбебезгә үзе дә сораулар биргәләде. Күземне алмый карап утырдым. Эчтән генә хыялланам да әле: менә дәресләр бетәр дә, мин урамга чыгармын, ә анда мине зур розалар букеты тотып бөек Илһам Шакиров көтеп торыр кебек... Очрашу тәмамланып җырчыны озаткач та гел шуны гына уйлап йөрдем.

Дәресләр бетеп кайтырга чыктым, янәшәмнән генә такси бара—узмый да, туктамый да. Карасам, Илһам абый утырган, кулындагы роза букеты артыннан күренми дә. Барысы да нәкъ мин хыялланганча! «Әйдә, утыр»,—ди. Без ул көнне төнгә чаклы Аккош күле буенда йөрдек...

***

Фирдәвес Хәйруллина күңелгә эчкерсез, ягымлы, зыялы һәм искиткеч чибәр актриса булып кереп калган. Арабыздан китүенә инде биш еллап узса да, ул вафат та булмаган кебек—Г.Камал театры сәхнәсендә аның варисы Нәфисә калды.



«Мин ышанам сиңа» спектакленең премьерасын карап утырам. Төп рольдә Нәфисә Хәйруллина. Уен манерасында әнисе чалымнары бар. Төс-кыяфәте дә Фирдәвес ханымныкы: куе, озын кара чәч, кап-кара шомырт күзләр, каратутлырак йөз, шул ук самими караш, энҗе бөртегедәй тигез, ак тешләрен җемелдәтеп елмаю... Чын героиня. Соңгы елларда татар театрында лирик героиня уйнардай артист калмаган иде. Дөресен генә әйткәндә, чын мәгънәсендә чибәр актрисалар да бармак белән генә санарлык калды. Шуңа да зур сәхнәдә әле өченче ролен генә уйнаучы Нәфисә тамашачының да, матбугатның да игътибарын үзенә җәлеп итте. Аны күрми узу мөмкин түгел. Юк, чибәрлек җәһәтеннән генә түгел—актриса буларак та искиткеч әйбәт ул!

Мин беренче тапкыр аны Туфан Миңнуллинның «Дивана»сында, Диана ролендә күрдем. Бер дигән характерлы героиня икән дигән тәэсир калды. Ә инде «Мин ышанам сиңа» спектаклендә күргәч—лирик героиня икәнен дә аңладым. Театр өчен бу зур табыш, чөнки татар театры инде үзенең романтизмын югалта, салкын, тышкы эффектларга гына корылган спектакльләр күрсәтә башлаган иде. Сәбәбе гади—героиня юк. Режиссерлар ничарадан бичара дигәндәй романтизмнан баш тартырга мәҗбүр булдылар. Тамашачы исә коры, хиссез тамаша карарга яратмый—ул сәхнәдә барган вакыйгаларны йөрәге аша уздырырга, каһарманнар кичергән хисләрне тоеп утырырга тиеш. Тышкы эффектларга гына корылган спектакль никадәр генә яхшы куелмасын, аның гомере озын түгел. Шул ук вакытта бик гади генә драматургиягә, әмма каһарманнарның ихлас кичерешләренә корылган самими генә тамашага халык яратып йөри. Тәнкыйтьчеләрне алдап булса да, тамашачыны алдап булмый шул.

Ни өчен язган каһарманымнан читкә китеп театр-тамашачы мөнәсәбәтләрендә казына башладым соң әле? Төптәнрәк уйлап карасаң, монда һич кенә дә аерымлык юк, чөнки спектакльгә җылылыкны, лириканы нәкъ менә каһарманнары бирә. Ә инде лирик героинясы булмаган режиссер нинди җылы, кешелекле спектакль куя алсын?! Теләсә кайсы актриса чын лирик героиня да була алмый бит әле...

Шуңа да Г.Камал театрында Нәфисә Хәйруллинаның үсеп килүен күреп чын күңелдән сөендем, үзе белән дә сөйләшеп алырга булдым. Тормышта ул сәхнәдәгедән дә мөлаемрак, аралашучан, яна гыйлемнәргә омтылучан туташ икән. Һәрхәлдә, кыска гына әңгәмәбез шундый тәэсир калдырды. Мин бары шунда гына олуг җырчының моннан күп еллар очрашкач ни өчен Фирдәвес ханымга бер күрүдә гашыйк булуын аңладым. Нәфисә дә әнисенә ике тамчы су кебек охшаган—ул аның яшьлеге кебек...

—Миндә актриса булу теләге балачактан ук бар иде. «Һичьюгы сәхнәдә басып кына булса да торыйм инде»,—дип әниемә әйтә идем. Ул көлә иде. Ә инде үндүрт яшьләремдә чын-чынлап актриса булырга җыенганымны күргәч, теше-тырнагы белән каршы чыкты: «Табибә бул, гаилә кор, әмма сәхнәгә кызыкма»,—диде. Мин барыбер ул кайчан да булса йомшарыр дип өметләндем... Белмим, әнием исән булса кем булыр идем икән?

—Ә кем булыр иден дип уйлыйсын?

—Әгәр актриса түгел икән, кем булсам да барыбер. Мин бик бәхетсез кеше булыр идем...

—Театр синең өчен шулай мөһимме?

—Мөһим генәме соң! Ул минем тормышым!

—Ә сиңа табибәнең ак халаты да килешер иде...

Кыз миңа шундый өздереп карап куйды. Шаяртамы, чынлап әйтәме дип сынап карый кебек—сүзне икенчегә борып алып китүдән башка чара калмады. Күпләр белән артык такт саклап тормасам да, бу баланы үпкәләтәсе килми иде.

—Әгәр дә сайлау алдында калсаң: йә шәхси тормышың, йә театр дисәләр нишләр идең?

—Әлегә андый сайлау булганы юк. Әмма беләм—әгәр гашыйк булсам, мин бөтен дөньямны онытып яратыр идем. Мөгаен, сайлау да мәхәббәт файдасына булыр иде... Хәер, нигә алдан фаразларга. Минем бит театрдан тыш танышларым да юк. Димәк, киләчәктә сайлау алдында калу куркынычы да бермә-бер кими.



—Сиңа әле егерме генә яшь бит, танышырсың.

—Бәлки. Әмма мин театрал булмаган кешеләр белән аралаша алмыйм. Алар белән нәрсә сөйләшәсен дә белмим. Хәтта туган-тумача да үпкәли—борын күтәрәсен ди. Минем бит бөтен тормышым театр бинасында уза, чит кешеләр белән аралашырга вакытым да калмый.

—Син дөньяны белмисең инде...

—Әйе. Театр бит ул зур бер гаилә кебек. Анда аралашуга, дуслашуга булган бөтен ихтыяҗлар да канәгатьләндерелә. Артистларның күбесе гомере буе театр буфетында ашап, өйгә йокларга гына кайтып яши. Мин дә шулай. Шуңа күрә театрдан башка тормышымны, читтән килгән дусларны, мәхәббәтне күз алдына да китерә алмыйм.

—Ә рольләреңне күз алдына китерәсеңме?

—Юк, бары тик алар әле бик күп булырлар дип кенә өметләнәм.

Бераз сөйләшеп утыргач, Нәфисәдән әнисенең фотосын сорадым. Алар бернечә иде. Арадан берсен сайлап алдым да, аңа нәкъ шул ук позада төшәргә киңәш иттем. Икенче көнне фоторәссамыбыз Александр Эшкинин фотоларны алып килеп тә житкергән. Бөтен редакция белән исебез китеп карап тордык... Хәер, нәрсә сөйләп торам соң—үзегез дә күрәсез бит...



Язучылар Шәриф Камал, Кави Нәҗми, мәшһүр музыкант Фәйзулла Туишев. 1940 ел.




Балалар язучысы
Әминә Бикчәнтәева
(1913—1986).



Абдулла Алиш (уңда) һәм журналист
Исмәгыйль Усманов. 1930 ел.



*Кызылармиячеләрдән бер төркем. Сулдан беренче—шагыйрь Рәхим Саттар. 1935 ел.*



*Язучы, публицист Тәүфикъ Әйди (1941—2001). Ул озак еллар "Казан утлары" журналында бүлек мөдире булып эшләде.*



*Шагыйрь Фәнис Яруллин һәм режиссер Равил Тумашев. "Әнә килә автомобиль" спектакленнән соң төшерелгән фото. 1975 ел.*

## Сания Әхмәтҗанова



Сания Юныс кызы Әхмәтҗанова 1962 елда Татарстанның Арча районы Курса Почмак авылында туган. Сигезьеллык мәктәпне, аннары Арча педагогия училищесын тәмамлый. 1981-1986 елларда читтән торып Казан дәүләт педагогия институтының рус-татар бүлегендә югары белем ала.

Хезмәт юлын 1981 елда Казандагы 84 нче урта мәктәптә башлангыч сыйныфлар укытучысы буларак башлый. 1991-1994 елларда балалар бакчасында тәрбияче, 1994-2000 елларда мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 2000 елдан мәктәп эшеннән журналистика-язу хезмәтенә күчә: укытучылар журналы булган «Мәгариф»тә бүлек мөхәррире булып эшли башлый. Бүген дә милли мәгарифтәге хезмәтен әдәби эшчәнлек белән бергә бәйләп алып бара.

Мәктәптә укыганда, беренче шигырьләре һәм яшь хәбәрче язмалары район һәм «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталарында басыла. Педучилищеда белем алган елларында язучы Р. Фәизов җитәкләгән «Тукай якташы» әдәби түгәрәгенә йөри һәм күпмедер дәрәҗәдә иҗади чыныгу ала.

Сания Әхмәтҗанова туксанынчы елларда популяр җыр текстлары авторы буларак халыкка танылды. Аның шигырьләренә иҗат ителгән җырларны Р. Закиров, А. Галимов, А. Хисамиева, Э. Хәйруллина, А. Хәбибуллина кебек танылган җырчылар бик теләп башкара. Җырчы һәм композитор З. Хәйретдинов белән иҗади хезмәттәшлек нәтиҗәсе буларак, инде ике дистә ел дәвамында халык яратып тыңлый һәм җырлый торган «Пар алма», «Кура җиләк», «Дәшмә мина, соң инде», «Әйтер сүзең әйтеп кал», «Сары кашкарыйлар», «Ялгыз әнкәй» кебек җырлар дөнья күрде. Аның башка композиторлар белән иҗат иткән уңышлы җырлары да шактыйга җыйнала.

«Идел-Пресс» нәшрияты 2002 елда С. Әхмәтҗанованың «Оч иреккә, җырым» исемле беренче китабын бастырып чыгарды.

Соңгы елларда Сания Әхмәтҗанованың иҗади активлыгы көчәйде. Милләт язмышы, рухи иминлек, яшәү мәгънәсе турында яңа шигъри тупланмалары көндәлек матбугатта, аерым алганда «Казан утлары», «Мәйдан» журналларында, «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан» газеталарында даими басылып тора; лирик таланты һәм иҗат үзенчәлекләре яңа җыр текстларында тагын да ныграк ачыла бара. С. Әхмәтҗанованың яшәешебезнең актуаль темаларына багышланган публицистик мәкаләләре дә укучыларда һәм әдәби җәмәгатьчелектә мәгълүм бер кызыксыну уятты, уңай бәя алды. 2008 елда Татарстан китап нәшриятында шагыйрәнең «Пар алма» дип исемләнгән яңа шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Кереш сүзне күренекле шагыйрь Г. Морат язган.

Татарстан Язучыларының 27 майда үткән Идарә утырышында, Берлекнең Кабул итү коллегиясе карары нигезендә, Әхмәтҗанова Сания Юныс кызы (тәкъдимнамә бирүчеләр—Рафаэль Мостафин, Рашат Низами, Шаһинур Мостафин) Татарстан Язучылар Берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.

### ПАРЛАМЕНТТА ОЧРАШУ

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның 19 май—Татарстан Матбугаты көнендә республикабызның гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре белән очрашуы инде күркәм гадәткә әверелде. Дәүләт Советының Кече залында үткәрелгән әлеге очрашуда парламент житәкчесе журналистларны республика хакимияте исеменнән һөнәри бәйрәмнәре белән котлады, аларга хезмәтләрендә иҗади уңышлар һәм саулык-сәламәтлек теләде.

Спикер әйтеп үткәнчә, бүгенге көндә Татарстанда 1092 исемдә газета-журнал басыла, 50 телевизион компания эшли. Матбугат басмаларының 112се татар телендә чыга. Республикада гаммәви мәгълүмат чараларының ишле булуы әйбәт, әмма Мәскәү басмалары һәм телерадиоканалларының өстәмә көндәшлек тудыруы турында да онытмаска кирәк. Татарстанда мәгълүмат вертикале дә урнашты. Әмма очрашуда әйтелгәнчә, хакимият гаммәви мәгълүмат чараларына басым ясарга омтылмыйча, аларның күпкырлы эшчәнлегенә төрле яктан ярдәм итәргә тиеш. Чөнки җәмгыятебез тормышында бергәләп хәл итәсе проблемалар елдан-ел арта тора.

Очрашуда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, Республика «Татмедиа» матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы житәкчесе Марат Моратов та чыгыш ясады.

### «НӘҮРҮЗ» ФЕСТИВАЛЕ КОЛАЧ АЛА

Быелгы фестиваль Оренбург, Чувашия, Башкортстан, Казакъстан, Кыргызстан, Якутия, Төркия, Әзәрбайҗан, Хакасиядән иң яхшы коллективларны бергә җыйды. 2 июнь көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында минзәләлеләр Ринат Әюпов куйган «Мөһаҗирләр» спектакле белән фестивальне башлап җибәрде.

Ачылу тантанасы 3 июньдә Г. Камал исемендәге театр каршында узды. Фестиваль әләмен быел Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Ринат Тажетдинов белән «Тюрксой» җәмгыяте житәкчесе Д. Касеинов күтәрде. Аннан соң фойеда күренекле җырчы-артист, татар театрына нигез салучыларның берсе Ильяс Кудашев-Ашказарскийга бронза һәйкәл ачылды. Аны Мәскәүдә яшәп иҗат итүче скульптор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кадим Җәмитов эшләгән. Тантанада И. Кудашев-Ашказарскийның оныгы Санкт-Петербургтан килгән Назирә ханым да катнашты. Әлеге изге эшне башкарган өчен житәкчеләргә һәм скульпторга рәхмәтен ирештерде. Моннан берничә ел элек театрга ул бабасының скрипкасын бүләк иткән иде. Әнә шул уен коралының моннарын тантанада Фуат Әбүбәкеров яңгыратты. «Ашказар» дигән татар халык җыры Башкортстаннан килгән күренекле җырчы Идрис Газиев тарафыннан башкарылды.

Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева Россия мәдәният министры Александр Авдеевның котлау хатын укыганнан соң, үзенең тәэсирләре белән уртаклашты һәм теләкләрен дә житкерде. «Бу безнең өчен зур рухи бәйрәм. Төрки театрларның байлыгын күрә алабыз»,—диде ул. Киләчәктә аны ел саен оештыру тәкъдимен дә җиткерде. «Тюрксой» җәмгыяте житәкчесе Д. Касеинов әйтүенчә, фестивальнең монда үтү очраклы түгел. Бу Тукай, Камаллар җире. Казан—төрки дөньяның мәдәни үзәге».

Шул кичне тамашачы М. Фәйзи исемендәге Оренбург татар дәүләт драма театрының А. Гыйләҗев әсәре буенча куелган «Без уникe кыз идек» дигән спектакльне карады.

Фестивальдә өч көн эчендә 21 спектакль тәкъдим ителде. Алар ун телдә уйналды. Спектакльләрне Мәскәү, Санкт-Петербург, Израиль, Чувашия, Екатеринбургтан килгән тәнкыйтьчеләр карады. Башка еллардан аермалы буларак, быел җинүчеләр билгеләнмәде.

Фестиваль 5 июньдә Тынычлык бистәсендә театрлар Сабан туе белән тәмамланды.

### ИЗГЕ БОЛГАР ЖЫЕНЫ

13 июнь көнне республикабызның Болгар шәһәрендә 20 нче мәртәбә Изге Болгар җыены үткәрелде. Бу юбилей Идел буе Болгарстанында ислам дине кабул ителүнең 1120 еллыгы, Болгар бабаларыбыз җиренә Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабәләре килүнең 1420 еллыгы буларак та зурлап уздырылды.

Гадәттәгечә, быел да Татарстан һәм Башкортстаннан тыш, Чувашия, Мари Иле, Мордовия республикаларыннан, Ульян, Пенза, Самара, Пермь, Нижгар, Волгоград, Әстерхан өлкәләреннән, Себер һәм Уралның төрле төбәкләреннән егерме меңләп кеше җыелган иде.

Быелгы җыенның үзенчәлеге шунда: әлеге тантананы оештыруга җитәкчелек итүгә ТР Мәдәният министрлыгы алынды. Россия Үзәк Диния нәзарәте, Бөтендөнья Татар конгрессы, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Дин эшләре идарәсе, ТР Диния нәзарәте һәм Россия Мөфтиләр шурасы да үз өлешләрен кертте. Спас районы хакимияте җитәкчеләренә дә рәхмәтле булды халык.

Бәйрәм дәрәҗәсе олы кунаклар белән билгеләнә. ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Төркия Республикасының Диният эшләре җитәкчесе Али Бардакуглы, Россия Үзәк Диния нәзарәте мөфтие Тәлгат хәзрәт Таҗетдиннең һәм башка олы кунакларның катнашуы җыенга ямь өстәде.

## ОРЕНБУРГТА ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе Оренбург өлкәсендә Татар мәдәнияте көннәре кысаларында чаралар үткәрүдә катнашты. Делегация составында ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, ТР Дәүләт Советы депутаты Ринат Закиров һәм башка рәсми затлар бар иде.

Татарстан делегациясенең Оренбургка сәфәре Советлар йорты белән танышудан башланып китте. Шуннан соң Оренбург өлкәсе губернаторы Алексей Чернышов, өлкәнең Законнар чыгару җыены җитәкчесе Дмитрий Кулагин һәм өлкә хакимияте вәкилләре белән очрашу булды. Очрашуда аграр секторны үстерү мәсьәләләре, шулай ук төбәкара хезмәттәшлек перспективалары (шул исәптән нефть чыгару тармагында да) тикшерелде. А. Чернышов әйтүенчә, бүген «Татнефть» һәм аның кече структуралары Оренбург өлкәсендә геология-эзләү эшләрен алып бара.

Аннары Фәрит Мөхәммәтшин белән Алексей Чернышов Оренбургтагы Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салдылар.

Оренбург өлкәсендә Татар мәдәнияте көннәре кысаларындагы чараларны М. Фәйзи исемендәге Татар дәүләт драма театрында Татарстанның сәнгать осталары концерты дәвам итте. Тамашачыларны сәхнәдән Зилә Вәлиева сәламләде. «Оренбург төбәге Татарстан һәм татар мәдәнияте өчен—аерым бер сәхифә,—дип ассызыклады ул.—Дәрдмәнд, Мирхәйдәр Фәйзи, Муса Җәлил, Бату Мөлеков кебек күренекле шәхесләрне генә түгел, татар язучылары, композиторлар, милли зыялыларның тулы бер плеядасын бүләк иткән төбәк бу».

Фәрит Мөхәммәтшин һәм делегация әгъзалары визит барышында өлкәнең төрле милли-мәдәни автономия вәкилләрен бер урынга туплаган парк комплексы—«Милли авыл»да татар йортын ачуда да катнашты.

## ДУСЛЫКНЫ НЫГЫТУ—ЗАМАН ТАЛӘБЕ

11 июньдә Уфада Башкортстан Халыклары ассамблеясенең II съезды булып узды. Татарстаннан әлеге милләтара форумда ТР Дәүләт Советы Рәисе, ТР Халыклары ассамблеясе башлыгы Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

Съезд мөнбәреннән форумга җыелучыларга сәламләү сүзе белән Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимов мөрәҗәгать итте. Башкортстан башлыгы үз чыгышында федераль мәгариф стандартларыннан төбәк-милли компонентны алып ташлау буенча РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлләрен тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәяләде. Аның әйтүенчә, бу милли мәгарифнең барлык уңай казанышларын бер селтәнүдә юкка чыгарды.

Татарстан парламенты җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин үз чыгышында, ТР Дәүләт Советының ил җитәкчелегенә Европа төбәкләре телләре яки аз санлы халыклар телләре хартиясен ратификацияләү турында мөрәҗәгатен яклауга әзер булуы өчен, Башкортстан Президентына рәхмәт белдерде.

Ф. Мөхәммәтшин, Мортаза Рәхимовка мөрәҗәгать итеп, Татарстанда—Башкортстан һәм Башкортстанда Татарстан көннәрен уздыруны яңартып җибәрү теләген җиткерде.

Татарстан парламенты спикеры чыгышының ахырында Башкортстан һәм Татарстан халыклары арасында күп гасырлар буена сакланып килгән дуслык мөнәсәбәтләренең мөһим казаныш булып торуын белдерде. «Нәкъ менә дуслык, татулык безгә дөньякүләм кризистан ныгып чыгу мөмкинлеге бирәчәк»,—диде ул.

***Рәсми хәбәргә өстәмә:***

*Башкортстан белән Татарстан халкы өчен шатлыклы вакыйга: хәзер Уфа белән Казан арасында очкычлар шимбәдән башка һәр көнне, ягъни атнасына 6 тапкыр очачак.*

*Уфа–Казан маршрутында очкычлар, озак кына тәнәфестән соң, берничә ел элек кабат оча башлаган иде. Ләкин алар атнасына өч тапкыр гына очты. Халык өчен анысы да куаныч булды.*

*Уфа белән Казан арасында һава бәйләнеше булдыруны «Казан авиация ширкәте» башлады. Әлеге очышларда «Л-410» маркалы очкычлар кулланыла.*

## АГЕНТЛЫКНЫҢ СТАТУСЫ ҮЗГӘРДЕ

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев 15 майда «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләрнең республика агентлыгы турында»гы Указга кул куйды. Бу документ нигезендә, Татарстан Республикасының «Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр агентлыгы «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгына үзгәртелде. Яңа структура Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең махсус билгеләнештәге башкарма органы булып торачак. Ул, нигезләмәгә таянып, матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә дәүләт идарәсе мәсьәләләре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## ИСТАНБУЛДА ТАТАР ЙОРТЫ

Төркиянең тарихи үзәге «Топкапы»да Татар йорты ачылды. Тантанада ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Россиянең Төркиядәге Генераль консулы Владимир Ивановский, Истанбул мэры Кадыйр Топбаш катнашты.

«Топкапы» шәһәр мәдәният паркындагы Төрки телле халыклар музей комплексында Татарстан сәнгате һәм традицион мәдәниятләр үзәген ачканда, Төркиянең рәсми булмаган башкаласы хакиме К. Топбаш бу көннең ике тугандаш халык мөнәсәбәтләрендә яңа сәхифә ачуын искәртте.

Аннары паркның концерт мәйданчыгында Сабан туе гөрләде. Анда З.Вәлиева Татарстан Президенты М. Шәймиевнең котлавын ирештерде. Халыкара «Тюрксой» оешмасы генераль директоры Д. Касеинов билгеләп үткәнчә, әлеге бәйрәм татар милләте вәкилләре яшәгән илләр мәдәниятенең мөһим өлеше булып тора.

## ГАЛИМНӘР—ИЛ ТЕРӘГЕ

15 майда Татарстан Фәннәр академиясенең чираттагы гомуми җыелышы булып узды. Аның эшендә ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, беренче вице-премьер Р. Моратов, икътисад министры М. Сафиуллин, фән һәм мәгариф министры А. Гыйльметдинов, яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министры М. Бариев, элемтә һәм мәгълүмат технологияләре министры Ф. Фазылҗанов, кайбер сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләре, академик һәм югары уку йортлары вәкилләре һ.б. катнашты.

Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә. Мазгаров үз чыгышында билгеләп үткәнчә, республикада фән белән шөгыльләнер өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Татарстанда 86 дәүләт фәнни үзәге, 38 югары уку йорты, 1300 фән докторы, 6 мең фәннәр кандидаты бар. Хисап тоту чорында Академия әгъзаларының, галимнәр һәм структура бүлекләре хезмәткәрләренең иҗади активлыгы республиканың фәнни потенциалын күтәрүгә, аның көндәшлеккә сәләтен үстерүгә, фәнни оешмаларның, уку йортларының, фәнни-тикшеренү институтларының һәм башка фәнни учреждениеләрнең эшчәнлеген координацияләүгә юнәлтелгән. «Әмма өстенлекле фәнни тикшеренүләр алып баруны финанслау республиканың алга таба ныклы үсеше өчен мөһим шарт булып тора»,—диде академик Ә. Мазгаров.

Парламент җитәкчесе Ф. Мөхәммәтшин кризис шартларында галимнәр, институтлар, аерым алганда, Фәннәр академиясенең роле бермә-бер артуын искәртте. «Хәтта кризис шартларында да фәннең өстенлекле юнәлешләренә ярдәм итү юлларын эзләүгә дәүләт һәм хакимият органнары җәлеп ителә. Чөнки фән республикада кризиска каршы кабул ителгән чаралар чылбырында мөһим бер буын булып тора.

Фикер алышуда республиканың күренекле галимнәре фәннең актуаль проблемалары турында эшлекле чыгышлар ясадылар.

«Иң мөһиме—республиканың икътисади алгарышын тәэмин итү кирәк»,—диде парламент җитәкчесе. Ул шулай ук галимнәрнең һәрвакыт дәүләт ярдәменә исәп тота алуы хакында да әйтте. Дәүләт Советы бюджетка төзәтмәләр кертүгә карамастан, өстенлекле проектларны финанслау җае табылачак. Галимнәрдән дә кризис чорында тәвәккәлрәк эш итү сорала. «Фәннәр академиясенең 20 еллык юбилее уңаеннан һәр галимнән нәтиҗәле эш таләп ителә»,—диде Ф. Мөхәммәтшин. Моннан тыш, парламент җитәкчесе фәнни җәмәгатьчелекне белем бирү стандартларында милли компонентны, ягъни туган телдә белем бирүне саклап калуны яклауда да активрак булырга чакырды.

## БАЛЕТ БӘЙРӘМЕ

Рудольф Нуриев исемендәге XXII классик балет фестивале Европаның мәдәният өлкәсендә мөһим вакыйгага әйләнде. Чөнки фестиваль кысаларында Татарстан туфрагына дөнья күләмендә танылган балет йолдызлары аяк басты.

Фестивальне йомгаклап, 21-22 майда Россиянең эре театрлары солистлары һәм чит ил кунаклары катнашында гала-концертлар узды. Гала-концертның бер бүлеге аның режиссеры Наталия Садовская инициативасы белән Парижда узган Дягилев сезоннарының 100 еллыгына багышланган. Дягилев труппасы Париждагы спектакльләре белән Европага безнең балет мәктәбенең иң көчле мәктәпләр белән көч сынаша алырлык икәнлеген раслаган иде. Шулай

итеп, беренче бүлектә И. Стравинскийның «Жар-птица», Н. Римский-Корсаковның «Шәхрезадә» балетларыннан өзекләр һәм концерт номерлары күрсәтелде. Икенче бүлектә тамашачы Берлиннан Дина Тамазлакару, Вена дәүләт операсыннан Алия Таныкпаева чыгышлары белән хозурланды.

## ПУШКИН БӘЙРӘМГӘ ҖЫЙДЫ

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасы янындагы Александр Пушкин һәйкәле янында бөек рус шагыйренең тууына 210 ел тулуга багышланган шигърият бәйрәме үткәрелде.

Шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салганнан соң, шигърият сөючеләрне Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова сәламләде. «Пушкин шундый шагыйрь ки,—диде ул,—балачакта һәммәбезгә килә дә, гомерлеккә безнең белән кала. Аның шигырьләре һәрберебезнең дә күңелендә яңгырап тора, ул—шатланганда да, кайгырганда да ышанычлы дустыбыз һәм, гомумән, аның шигърияте бөтен заманнарда да халык рухына көч-дәрт өстәп тора».

Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Илфак Ибраһимов үз чыгышында Александр Пушкинның 176 ел элек Казанга килеп китүе, шуңа күрә башкалабызның бөек шагыйрь язмышында үзенчә урын алуы, Россиянең ирекле халыклар иле булырга тиешлеге хакында әйткән әдип иҗатының Габдулла Тукай шигъриятенә рухландыргыч көч өстәве турында искәртте. Аннары ул Язучылар берлегенә күптән түгел генә кабул ителгән шагыйрь һәм тәрҗемәчеләр Наил Ишмөхәммәтов белән Фатих Котлыга әгъзалык таныклыкларын тапшырды.

Театральләштерелгән тамашалар, җыр һәм музыка белән аралашып барган бәйрәмдә шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Елена Бурундуковская, Борис Вайнер, Ольга Левадная, Николай Алешков, Лоренс Блинов, Илсөяр Иксанова, Альбина Әпсәләмова һ.б. чыгыш ясады.

Шигърият бәйрәмен шагыйрә Лилия Газизова һәм Татарстанның халык артисты Михаил Меркушин алып барды. Тантанада Татарстан мәдәният министры урынбасары Гөлшат Нигъмәтуллина катнашты.

## КЫТАЙ ТАТАРЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Татарстан Дәүләт Советы бинасында парламент Рәисе Ф. Мөхәммәтшин Кытайдан килгән татар яшьләре белән очрашты.

Кытайда бүген 5800 татар яши. Кайчандыр ил-җирләрен, Идел буе, Россия төбәкләрен калдырып, шунда китеп төпләнергә мәҗбүр булган милләттәшләребез балаларын тарихи Ватанга—Татарстанга китертеп укытуны хуп күрә. Республикабыз җитәкчеләре аларның гозерләренә колак салып, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты белән берлектә, Кытайдагы татар яшьләрен Казанда укытуны гамәлгә ашырып килә. Кытайдан яшьләрнең беренче төркеме 2005 елда килеп, КДТУ базасында башта бер ел дәвамында татар һәм рус телләрен өйрәнде, аннары республиканың төрле югары уку йортларында белем алуга кереште.

Күптән түгел Кытайдан яшь милләттәшләребезнең 25 кешелек икенче төркеме килеп, КДУ базасында телләр өйрәнә башлады. Бер ел эчендә дәүләт телләрендә иркен сөйләшергә өйрәнгәч, яшьләр төрле вузларда укый башлаячак.

Кытайдан килгән яшьләр белән очрашуда парламент Рәисе Ф. Мөхәммәтшин аларга: «Арагызда вакытларын әрәм-шәрәм итеп йөрүчеләр булмас, дип өметләнәбез. Татар телен камил итеп өйрәнегез. Бүген телебезне саклау проблемасы бик актуаль. Ә Кытайда калган әти-әниләрегез, туганнарыгыз балалары өчен тыныч булсын—без сезнең укып чыгып, кирәкле, файдалы белгечләр булып җитешүегез өчен кулдан килгәнчә ярдәм итеп торырбыз. Мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланыгыз, сез монда чит кешеләр түгел, ә үзебезнекеләр»,—диде.

Очрашуда шулай ук Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Татарстанның тышкы элемтәләр Департаменты директоры Тимур Акулов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, КДУ профессоры, академик Миркасыйм Госманов катнашты. Кытайдан килгән яшьләр арасында аларның Казанда укуларын оештыруда көч куеп йөргән шәхесләр—Бөтенкытай халык вәкилләре җыены депутаты, профессор Абдулла Аббас, Голҗа шәһәрендәге татар мәдәнияте үзәге рәисе урынбасары Торсынтай Гали дә бар иде.

## ДУСЛЫКНЫ НЫГЫТЫРГА КИРӘК

Июнь башында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Тюрксой» халыкара оешмасы генераль директоры Д. Касеинов белән очрашты. Парламент җитәкчесе «Тюрксой»ның милли тел, тарих, мәдәният һәм сәнгать охшашлыгы белән берләшкән илләр һәм халыклар арасындагы төбәкара хезмәттәшлекне үстерүдәге әһәмиятен билгеләп үтте. Бу унайдан, Казанда үткән төрки халыкларның «Нәүрүз» театр фестивalенең роле дә зур. Җыенда катнашучыларның күп булуын Д. Касеинов та ассызыклады.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙГА БАГЫШЛАНА

«Казан Кремле» музей-тыюлыгында «Гаяз Исхакый: Бөтен тормышы—халыкка хезмәт итү» дигән күргәзмә ачылды. Күргәзмә XX гасырның беренче яртысында

танылган татар сәясәт эшлеклесе Гаяз Исхакыйның Россиядән күчеп китүенә 90 ел тулуга багышланган.

Экспозициянен төп максаты—Гаяз Исхакыйның чит илдә яшәү чорындагы сәяси эшчәнлеген яктырту.

Беренче тапкыр халыкка тәкъдим ителә торган уникаль документлар һәм материаллар Гаяз Исхакыйның бүлгәләнгән татар диаспорасын оештыру эшчәнлеген, сәяси эшчәнлеген активлаштыруны чагылдыра. Күргәзмәдәге кыйммәтле экспонатлар арасында Гаяз Исхакыйның Версаль шәһәрендә үткән конференциядә тыныч сөйләшүләр өчен коллегия әгъзасы таныклыгы, Идел-Урал Төрки-татар мәдәни җәмгыятенең гомерлек президенты итеп сайлануын дәлилләүче сертификат (1934 елдан), татар диаспорасы арасында оештыру эшләрен яктыртучы фоторәсемнәр, революциягә кадәрге чорда язылган китаплары, кульязмалары, чит илдә басылган журнал һәм газеталар, шәхси әйберләре бар.

### ЯУГИР ШАГЫЙРЬНЕ ОЛЫЛАУ

Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге конференцияләр залында татар әдәбияты классигы, күренекле шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 100 ел тулуга багышлап, «Фатих Кәрим—шагыйрь һәм яугир» дигән темага төбәкара фәнни-гамәли конференция уздырылды. Аны Татарстан мәдәният министрлыгы, ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Татарстан Язучылар берлеге оештырган иде.

Фәнни-гамәли конференциядә Ф. Кәрим тормышындагы «ак таплар»; үткән гасырның 20-30 нчы еллар мохите һәм шагыйрь; Ф. Кәрим: әсәр, чор, язмыш; Кадрия Ишукова хатларында һәм көндәлекләрендә аның ире Ф. Кәрим; Ф. Кәрим—поэма остасы; шагыйрьнең бердәнбер драмасы; Ф. Кәримнең поэтик фикерләве дигән темаларга докладлар белән язучы һәм галим Рафаэль Мостафин, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор Фоат Галимуллин, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, Фатих Кәримнең кызы Ләйлә ханым Кәримова, филология фәннәре докторы, профессор Тәлгат Галиуллин, филология фәннәре докторы, профессор Азат Әхмәдуллин һәм филология фәннәре кандидаты, тәнкыйтьче Равил Рахмани чыгыш ясады.

Конференциянең пленар утырышында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К. Миңнуллин, ТР мәдәният министры урынбасары Г. Нигъмәтуллина, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, шагыйрь И. Ибраһимов, Башкортстанның Бишбүләк муниципаль район Советы сәркәтибе Г. Хисмәтов катнашты һәм чыгыш ясады.

### ОЛПАТ ШӘХЕС, ОЛУГ ГАЛИМ

Татарстан Фәннәр академиясе бинасында атаклы тарихчы галим, педагог, академик Миркасыйм Госмановның 75 яшьлек юбилее унаеннан зур тантана булып узды.

Тантананы Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты А. Зыятдинов ачып җибәрде. Ул юбилярны кайнар котлап, ана ТФА президенты М. Мазгаровның рәхмәт хатын һәм котлавын ирештерде.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова Президент М. Шәймиев Указы нигезендә М. Госмановка «Фидакарь хезмәт өчен» медален һәм Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшинның Рәхмәт хатын тапшырды. Р. Ратникова үз чыгышында олуг галим җитәкләгән археографик экспедицияләрнең Россия һәм республикабыз буенча җәмгысе 850 авыл-шәһәрдән 9 меңнән артык кульязма һәм шәркый телләрдә язылган мең ярымга якын иске басмаларны җыеп, туплап, татар тарихын баетуда гаҗәеп күп көч, тырышлык куюын билгеләп үтте.

Күренекле галимне Татарстан мәгариф һәм фән министры А. Гыйльметдинов, КДУ ректоры М. Сәлахов, РИУ ректоры Р. Мөхәммәтшин, Татар энциклопедия институты директоры урынбасары Г. Сабирҗанов, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К. Миңнуллин, Тарих институты җитәкчесе Р. Хәкимов, КДУның татар филологиясе, тарихы һәм Көнчыгыш телләр факультеты деканы И. Гыйләҗев, Татарстанның демографик хәлен күзәтү үзәге башлыгы Ф. Илдарханова котлады.

### КОНЬЯДА—ТЕАТРЛАР ПАРАДЫ

«Мең сулыш та, бер тавыш». Төркиянең Конья шәһәрендә узган Халыкара төрки театрлар фестивале шулай дип атала иде. Анда Кыргызстан, Македония, Косово, Казакъстан, Гагаузия (Молдавия), Башкортстан, Болгария, Әзәрбайҗан, Төркия һәм Татарстан дәүләт театрлары катнашты.

Минзәлә театры артистлары әлеге мәртәбәле фестивальгә татар әдәбияты классигы Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» хикәясе буенча Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ренат Әюпов сәхнәләштергән спектакль белән катнашты.

### ТӘРҖЕМӘ ҮЗӘГЕ

Казанда мөселман татар-төрек тәрҗемә үзәге ачу ниятләнелә. Мондый карар ТР мөфтиенең беренче урынбасары Рамил хәзрәт Юнысов, шулай ук ТР мөселманнарының диния нәзарәте хезмәткәре Хәйдәр

хәзрәт Камалетдинов һәм Төркия республикасының дин эшләре буенча идарәсе башлыгының мәгариф мәсьәләләре буенча урынбасары катнашында Истанбулда узган очрашу кысаларында кабул ителгән.

Әлеге үзәк башкалада алдагы бер ел эчендә барлыкка килергә мөмкин. Биредә татар дини әдәбиятын төрек теленә, төрек әдәбиятын исә татар һәм рус телләренә тәржемә итү белән шөгыльләнәчәкләр.

## МӘШҺҮР БИЮЧЕ ИСТӘЛЕГЕНӘ

«Татмедиа» агентлыгында Рудольф Нуриев турындагы китап тәкъдим ителде. Бу мәшһүр биюче турында берничә дистә хезмәт дөнья күргән, әмма монысында Рудольф Нуриевның Казанда үткәргән көннәре турында язылган. Ул биредә 17 ел элек—үләренә ярты ел кала булган. Китап—«Рудольф Нуреев в Казани» дип атала. Хезмәтнең авторлары—Рөстәм Ишморатов, Марат Мәһдиев һәм Зөлфирә Туганова.

## ТАТАР ТОКЫМЫННАН БУЛГАН МӘШҺҮР НӘСЕЛ

ТР Милли музеенда «Князь Юсуповлар нәселенең тарихы. Казан-Петербург-Париж» дигән күргәзмә ачылды.

Ул «Юсупов сарае» дигән фәнни-популяр фильм күрсәтүдән башланды. Морза гаиләсенең тормышы казанлыларда зур кызыксыну уята. 1830 елда Санкт-Петербургның Мойка елгасы буенда салынган йортта князь нәселенең биш буыны яшәеше күз алдына килде.

Күргәзмәдә шулай ук князь Юсуповларның уникаль документлары—төрле грамоталар, Указлар, Россия падишаһларыннан килгән хатлар тәкъдим ителде.

## ТУГАН ЯК БИЗӘКЛӘРЕ

Татарстан Республикасы Милли музеенда Фаил Зыязовның «Туган як төсләре» дип аталган күргәзмәсе ачылды. Ул 1 октябрьгә кадәр эшләячәк.

Фаил Зыязов— танылган рәсем остасы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Милли музейның элеккеге баш рәссамы. Аның иҗат җимешләре милли төсмер, туган якка мәхәббәт, рәсемнәрендә урын алган геройларга хөрмәт белән сугарылган. Күргәзмәгә куелган «Ак күлмәкле татар кызы», «Чәй артында», «Икмәк», «Сөембикә» кебек милли рухлы картиналары тамашачыларны ихлас сөендерә.

Биредә шулай ук рәссамның натюрмортлары, тарихи портретлары, архитектура һәйкәлләре төшерелгән хезмәтләре һәм пейзажлары белән дә танышырга була.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

***

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә җитди өлеш керткәне, актив фәнни-педагогик һәм җәмәгатъ эшчәнлеге өчен «В. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты» югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениесе профессоры **Госманов Миркасыйм Габделәхәт улы** «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

***

Фәнни эшчәнлегендәге казанышлары өчен «В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты» югары һөнәри белем дәүләт мәгариф учреждениесенең кафедра мөдире, филология фәннәре докторы, профессор **Тәлгат Нәби улы Галиуллинга** Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

***


Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә лаеклы өлеш керткәне өчен «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы «Сөембикә» журналы редакциясе» баш мөхәррире урынбасары **Әмирханов Марат Әмирхан улы** «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә: «Җәй».*

*Дүртенче биттә:* язучы **Рөстәм Зарипов**.

# Яңа китаплар




«Ватаным Татарстан»: газетаның 90 еллыгы уңаеннан истәлекләр, документлар, фоторәсемнәр. Казан: «Идел- Пресс» нәшр., 2009.—224 б. Тиражы—1000 данә.

Заманында «Эш» (1918-1920 еллар), «Татарстан хәбәрләре» (1920-1922), «Татарстан» (1922-1924), «Кызыл Татарстан» (1924-1951), «Совет Татарстаны» (1951-1960), «Социалистик Татарстан» (1960-1992) дип аталган хәзерге «Ватаным Татарстан» газетасының чыга башлавына былтыр 90 ел тулган иде. Шул уңайдан бәйрәми очрашулар, кичәләр, фәнни конференцияләр уздырылды. Менә хәзер газета тарихы, анда хезмәт куйган шәхесләр, баш мөхәррирләр һәм гади хезмәткәрләр турында китап та нәшер ителде.

«Ватаным Татарстан»—татарның төп газетасы. Газета тарихы ул—милләт тарихы. Әлеге җыентык шушы тарихны тагын бер кат барлау һәм киләчәк буыннарга мирас итеп калдыру максатыннан нәшер ителгән.

Китапның төзүче-редакторлары: Габделбәр Ризванов, Мөнир Әһлиуллин, Мөнир Абдуллин, Рәсимә Галиева.




**Фәүзия Бәйрәмова**. Туран Иле. Фәнни-популяр язмалар. Казан: «Аяз» нәшр., 2008.—336 б. Тиражы—1000 данә.

«Туран Иле... Котыптан—кыпчак далаларынача, Татар бугазыннан—Каф тауларынача җәйрәп яткан татар җирләре...

Анда гомер-бакый төрки-татар халкы яшәгән, алар дистәләрчә мөстәкыйль дәүләтләр тотканнар, йөзләгән шәһәрләр төзегәннәр, дастаннар язганнар, алтын-көмештән дөнья музейларына куярлык затлы сәнгать әсәрләре иҗат иткәннәр. Татар халкының бу бөек тарихы әле һаман житәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән һәм лаеклы бәясен алмаган. Язучы һәм тарихчы-галим Фәүзия Бәйрәмова бүгенге көндә дә татар халкы яшәп яткан бу борынгы җирләрдә булып, милләтебезнең үткәне һәм хәзергесе турында шушы китабын язды».

Китапта борынгы татар тарихы турында, моңарчы архивларда булып та, фәнни әйләнешкә кермәгән байтак мәгълүматлар тупланган.



Рөстәм Зарипов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)